ISSN 0206—4189

КАЗАН УТЛАРЫ

6.2000

Tatarstan Respublikası Prezidentı

UKAZI

2000 yılda Tatarstan Respublikasınıŋ Ğ. Tuqay isemendəge Dəwlət premiələren birü turında

Zəlfət



İ. Əxmətcanov

Ş. Şəydullin



A. Slavutskiy

A. Patrakov

M. Galitskiy

Tatarstan Respublikasınıŋ Ğ.Tuqay isemendəge Dəwlət premiələre komitetı təqdimnəren qarağannan soŋ, **qarar birəm:**

2000 yılda Tatarstan Respublikasınıŋ Ğ. Tuqay isemendəge Dəwlət premiələren tübəndəgelərgə birergə:

1. V. İ. Kaçalov isemendəge Qazan Dəwlət Rus zur drama akademiə teatrı icat tərkemenə: rejissyor-quyuçı **Slavutskiy Aleksandr Yakovleviçqa**; rəssam-quyuçı **Patrakov Aleksandr Mixayloviçqa**; təp rol'də uynauçı **Galitskiy Mixail Olegoviçqa**—«Tübədəge skripkaçı» spiktakle øçen.

2. Aktyor, nəfis süz ostası **İldus Xənif ulı Əxmətcanovqa**—Ğ Tuqay əsərlərennən tøzelgən «Søy gømerne, søy xalıqnı» həm «Øzelgən ømet» konsert programmaları øçen.

3. Şağir **Zəlfətkə (Malikov Dəlfət Ğosman ulına)**—«İke urman arası» *(Tatarstan kitap nəşriatı, 1995 yıl)* həm «Yørəgemne bılbıl çaqtı» *(«Ruxiət» nəşriatı, 1999 yıl)* şiğer kitapları øçen.

4. Rəssam **Şəydullin Şamil Mortaza** ulına «Yaŋa Sabantuy» kartinalar siklı øçen.

Tatarstan Respublikası Prezidentı
Qazan, Kreml'. 2000 yıl, 24 aprel'

M. Ş. ŞƏYMİEV

Казан утлары
Qazan utları

2000

6
(932)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

Татарстан хөкүмәте,
Татарстан Язучылар берлеге,
редакциянең хезмәт коллективы

БАШ МӨХӘРРИРЕ

Равил Фәйзуллин

ИДАРӘ:

Гариф Ахунов,
Харрас Әюпов,
Зилә Вәлиева,
Фоат Галимуллин,
Тәлгат Галиуллин,
Миркасыйм Госманов,
Аяз Гыйләҗев,
Алмаз Гыймадиев
(җаваплы сәркәтип)
Флүс Латыйфи
(баш мөхәррир урынбасары),
Салих Маннапов,
Туфан Миңнуллин,
Хатип Миңнегулов,
Ринат Мөхәммәдиев,
Гәрәй Рәхим,
Булат Солтанбәков,
Ренат Харис,
Розалина Шаһиева.

Мөхәррирләр: **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

Гамәли хезмәткәрләр: **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
Исәп-хисап бүлеге: **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Фәнис ЯРУЛЛИН. Илаһи бер яктылык. *Шигырьләр* 5
Кави ЛАТЫЙП. Үр арты үр. *Сугыш хатирәсе* 10
Нәҗибә САФИНА. Кеше булып яшәү—язмышым 45
Аллер ТИМЕРГАЛИН. Игезәкләр. *Повесть* 61
Мәрзия ФӘЙЗУЛЛИНА. Нәниләргә багышланган иҗат 140

ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Яманлыкның чыганагы нәрсәдә? *(Бертольт Брехт шигырьләре)* 53

ПУБЛИЦИСТИКА

Габделхак ШӘМСЕТДИНОВ. Милли сәясәт һәм милли матбугат 142

ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

Мирза МӘХМҮТОВ. Коръән сүзе татар телендә 147

МАНСУР ХӘСӘНОВКА 70 ЯШЬ

Азат ӘХМӘДУЛЛИН. Олы галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе 161

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Кояш ТИМБИКОВА. Шагыйрәнең хыялында йөрткән китабы *(Рецензияләр конкурсына)* 168

СӘНГАТЬ

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Шагыйрь артист 175

НӘБИ ДӘҮЛИНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Шамил МАННАПОВ. Кайтмый еллар, кайталар җырлар 180
Безнең календарь 186
Укучы сүзе 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан 191

В НАШЕМ НОМЕРЕ:

Журнал выходит один раз в месяц

«Проза и поэзия»: К. ЛАТЫП «За далью-даль», повесть А. ТИМЕРГАЛИНА «Близнецы»; стихи Ф. ЯРУЛЛИНА, Н. САФИНОЙ, М. ФАЙЗУЛЛИНОЙ.
«Образцы мировой литературы»: стихи Б. БРЕХТА *в переводе поэтессы Л. Шагирзян.*
«Публицистика»: Г. Шамсутдинов. «Национальная политика и национальная печать».
«Жизнь и религия»: М. МАХМУТОВ. «Учение Корана на татарском языке».
«К 70-летию Мансура Хасанова»: статья А. АХМАДУЛЛИНА «Крупный ученый, видный общественный деятель».
«Литературная критика»: К. ТИМБИКОВА рецензирует книгу С. Сулеймановой «Здравствуй, жизнь!»
«Искусство»: статья Г. БАЙРАМОВОЙ о творчестве артиста театра им. Г. Камала, лауреата Тукаевской премии И. Ахметзянова.
«К 90-летию Н. Даули»: статья Ш. МАННАПОВА «Не возвращаются годы, возвращаются песни».
Наш календарь.
Слово читателя.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: фоторепродукция из картины А. Абзгильдина «Сабантуй», поэтесса М. Файзуллина.

IN OUR ISSUE:

The magazin edits monthly

"Prose and poetry": K. LATIP «The distance after distance», A. TIMERGALIN 'S novel «The twins», the verses of F. YARULLIN, N. SAFINA, M. FAIZULLINA.
"Samples of world literature": B. BREHT 'S verses with L. Shakirzan 's translation.
"Publicism": G. Shamsutdinov «The national politics and press».
"Life and religion": M. Mahmutov «Teaching Koran in Tatar».
"Commemorating the 70 th anniversary of Mansur Hasanov": A. AKHMADULLIN 'S article «The great scientist, prominent public figure».
"Literary criticism": K. TIMBIKOVA 'S review S. Suleimanov 's book «Hello, life!».
"Art": G. BAIRAMOVA'S article about I. Akhmetzanov's creative works.
"Commemorating the 90 th anniversary of N. Dauli": SH. MANNAPOV 'S article «The years not returh and the songs return».
"Our calendar".
"Readers word".
The diary of social and cultural life.
In our covers: photoreproduction from A. Abzgildin 's picture «Sabantuy», poetess M. Faizullina.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмахәнәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 16.04.2000 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108[1]/[16].
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8653 Заказ Э-212
Журнал Татарстан Республикасынын Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2000 ел.

ШИГЪРИЯТ

Фәнис Яруллин

ИЛАҺИ БЕР ЯКТЫЛЫК

Сорау белән җавап арасы

«Нишләргә соң?»—дигән сорауларны
Куеп тора тормыш гел алга.
Бәгырь учагында бәргәләнеп
Шул сораулар көн вә төн яна.

Бер сораугa җавап таптым дисәң,
Икенчесе туа сорауның.
Яңа сорауларга җавап эзләп
Мең кат урыйм уйлар урманын.

Кайчагында акыл арый хәтта,
Билгесезлек буа тынышны:
Тик сорауга җавап тапмый торып
Дәвам итеп булмый юлыңны.

Бер сораудан бер сорауга яшим,
Белмим башка яшәү чарасын.
Гомерем дә минем, нибарысы,
Сорау белән җавап арасы...

Ярлыка

Мал өчен, дан өчен түгелә кан,
Җир җитми—күңелләр тарлыкка.
Нәфсенә кол булган бәндәңне
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

Күпләрнең өмете өзелгән,
Ышанмый хакыйкать барлыкка.
Адашкан, саташкан җаннарны
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

Кешеләр үзенә кул сала,
Түзмичә изелү-хурлыкка.
Сабыры түкәнгән мескенне
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

Юләрләр хакимлек иткәндә
Инсаннар әйләнә сарыкка.
Сарыкка әйләнгән инсанны
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

Сугышлар. Суешлар. Кырышлар.
Халыклар ачулы халыкка.
Гөнаһка баткан бу дөньяны
Ярлыка, Ходаем, ярлыка.

* * *

Газраилгә эш кимеде бугай,
Кешеләр үтерә хәзер бер-берләрен.
Мөнкир-Нәнкир сорау алыр өчен
Эзләп таба алмый каберләрен.

Ишетмичә генә калдык ахры
Исрафилнең җиргә сур өргәнен.
Күреп торабыз бит әрвахларның
Кабереннән кубып йөгергәнен.

Җәннәтләрнең серле капкалары
Ябыламы, әллә ачыламы?
Бу әрвахлар кая йөгерә соң?—
Һәммәсе дә Алла каршынамы?

Соңгы яшь тә кипкән инде

Кемдер морза нәселеннән,
Кем—мулла нәселеннән.
Мин үзем бар эшне белгән
Ярулла нәселеннән.

Итек баскан, тула баскан,
Йон кайнаган казанда.
Киез эшләпәләр сугып
Дан тоткан ул заманда.

Сабан сөргән, иген иккән,
Абзарда өч ат тоткан.
Эшләгән ул ал-ял белми,
Ялкаулыклар ят булган.

Ташны да бик яраткан ул,
Койма, йортлар таш булган.
Үзе таштай булгангамы,
Кушамат—Чаташ булган.

Таштан салынган йорт-нигез,
Таралмас дип белгәндер.
Тамырларым мәңгелек дип
Тынычланып үлгәндер.

Тик тормышның мәрхәмәтсез
Һәм аяусыз җилләре.
Йолкып атты тамыры белән
Хәтта бу таш өйләрне.

Черек йорт кына утыра
Бабамнар нигезендә.
Соңгы яшь тә кипкән инде
Тәрәзәләр күзендә.

Саубуллашу

Сау бул, бакчам, сиңа быел
Соңгы килдем.
Озын кышлар ничек узар,
Әле белмим.

Күңеллерәк булсын өчен
Кышкы көнем,
Йөрәгемә кадап куйдым
Соңгы гөлең.

Сау бул, күлем, көчең сакла
Язлар өчен.
Камышыңны алдым—шигырь
Язар өчен.

Сау булыгыз, кошкайларым—
Дускайларым.
Исән-имин үткәрегез
Кыш айларын.

Сау бул, бакчам, күрешмәсәк
Әгәр башка,—
Алма булып пешәрмен мин
Алмагачта...

Телем-телем телмәс иде

Салкыннарда өши-өши,
Кояшларда яна-яна—
Үскән саен агачларның
Кайрылары катылана.

Их, нигә соң йөрәкләрнең
Булмый икән кайрылары?—
Телем-телем телмәс иде
Пычак булып кайгылары.

Кояш баеганда

Әкрен генә кояш баеп килә,
Бар дөньяда серле кызыллык.
Шәрә башлы тауның өсләрендә
Ак болытлар ята кызынып.

Яфракларга шәфәкъ уты капкан,
Урман-кырлар яна шул утта.
Сайрар кошлар сайравыннан туктап
Хәйран калып утыра тынлыкта.

Җил дә исми. Ул да чалкан ятып
Кояш баеганны күзәтә.
Әй бу кичләр, әй бу хозурлыклар
Күңелләрне әллә нишләтә.

Уйлар китә ерак-еракларга,
Сокланудан тыннар кысыла.
Урап калдырасы килә гомер җебен
Биек агачларның очына.

Әкрен генә кояш баеп килә,
Җирдә, күктә сихри кызыллык.
Әллә нигә кояш баешына
Ешрак карыйм хәзер кызыгып.

Ак кәгазьдә—ак уйлар

Төшмә, каләм, кулларымнан,
Төшмә соңгы көнгәчә.
Син әйтәсен беркем әйтмәс,
Әйтер сүзең әйт, яшә.

Үз халкыңның күңеленә
Иң яраклы ачкыч бул;
Биеклеккә менәр өчен
Ышанычлы баскыч бул.

Җаннан җанга сукмаклар суз,
Кушылсын моңнар моңга.
Гашыйкларны очраштыр да
Ашык син тагын юлга.

Гаделлекне иман ит син,
Хакыйкатьне кыйблаң ит.
Синең бер тамчы караңа
Тулы кояш сыйган бит.

Төшмә, каләм, кулларымнан,
Сызыйк гел яңа юллар.
Ак чәчәкләр булып калсын
Ак кәгазьдә—ак уйлар.

Тоткын йөрәк

«Юк!»—диеп тә әйткәнең юк
Һәм «әйе» дә димәдең.
Шул ике сүз арасында
Эленеп калды йөрәгем.

Йолдызларга атылырмы,
Очармы ул упкынга—
Синең хөкем-җавап кирәк
Бу бичара тоткынга.

Кем матурлар дөньяны

Йөрәгем—кош оясы,
Ояның юк хуҗасы.
Әллә инде бер агачка
Аны элеп куясы?!

Бәлки күрерләр иде,
Күргәч—керерләр иде.
Эченә ак мамык түшәп,
Җылы өрерләр иде.

Агач шатланыр иде,
Оя җанланыр иде.
Яфраклардан яфракларга
Җырлар таралыр иде.

Элим әле ояны,
Ник буш тотам мин аны?
Кем матурлар, без үзебез
Кайгыртмасак дөньяны?

* * *

Мине хәзер, никтер, күкләр тарта
Күктә әллә күңеллерәкме?
Фәрештәләр канатларын кагып,
Җилкендереп тора йөрәкне.

Нинди балкыш ялт-йолт итә анда,
Күз кысамы әллә берәрсе?
Күз кысуы шундый якты булгач,
Нинди икән аның иясе?

Фәрештәләр калфагыдыр бәлки,
Йолдыз дигәннәре—кем белә.
Энҗе-мәрҗән калфаклардан гына
Шундый йомшак нурлар бөркелә.

Җир кызлары, рәнҗемәгез миңа,
Хушлашмыйча китсәм беркөнне.
Күптән инде мине күкләр чакыра,
Биеклекләр тарта күңелне.

Яктылык

Күңелемдә нииндидер бер яктылык,
Бетми дә ул, кимеми дә өләшеп.
Килегез, кил! Күпме кирәк алыгыз,
Читтән генә карамагыз көнләшеп.

Кышын аны карлар итеп таратам,
Ул аклыктан күзләрегез камашсын.
Гашыйк җаннар чыгып күңелем кырына
Шул яктылык буранында адашсын.

Сибәм җәен болындагы гөлләргә,
Нурлар белән көнне үрәм көннәргә.
Илтегез, дип, аны күбрәк җирләргә—
Йөрәгемне җилгәрәмен җилләргә.

Бетми дә һич, кимеми дә өләшеп,
Күңелемдә нииндидер бер яктылык.
Йөгерәмен офыклардан офыкка,
Күкрәгемнән кояш чыга атылып.

1999.

Чәчмә әсәрләр

Кави Латыйп

ҮР АРТЫ ҮР

СУГЫШ ХАТИРӘСЕ

I

...Менә жил дә, гармун да тынып калды: без—олаулардагы яшьләр, Шыгырдан авылының олы урамы буйлап ярты чакрым чамасы атларны куалагач, нигезе таш булган агач бинаның ишегалдына килеп тукталдык та, егетләрчә, олаулардан сикереп төштек. Җигелгән атларның камыт бауларын, дугаларга тартылган тезгеннәрен, аркалыкларын бушатып, малкайларның алларына сугылмаган солы саламы салганнан соң, хәрби комиссариат урнашкан бинаның беренче текә баскычларына аяк бастык. Бусагада френчлы, галифеле, күн итекле, чандыр гәүдәле, озынрак буйлы бер кеше басып тора иде.

—Төкле аягыгыз белән,—диде ул.—Кайсы авыл егетләре?

—Чишмәлеләр...

—Вакытында килеп житкәнсез,—диде ул, френч кесәсеннән чылбырлы сәгатен чыгарып.—Рәхим итегез!

Без-никрутлар, берәмләп, бина эченә уздык. Безне каршы алучы, житдиләнеп, «Военком» дип ишегенә табличка язып куелган кабинетка кереп китте. Янәшәдәге икенче ишектәге табличкада «Медицина комиссиясе» диелгән иде. Аннан зифа буйлы, елмайган йөзле, ак халатлы бер ханым чыкты да, чуаш акценты белән урысча: «Сахотите, репята ф капинет,—диде.—Срасу по отному растевайтесь. Члены комиссии стесь. Смелее! Смелее!..»

Беренче булып, комиссия әгъзалары урнашкан бүлмә ишеген мин ачтым да, кереп тә киттем. Артымнан яшьтәшләрем иярде.

—Калганнарыгыз бераз сабыр итегез,—диде шундагы күзлекле ир.

Беравыктан фречлы кеше комиссия бүлмәсенә керде һәм өстәл янына килеп утырды.

—Кемнән башлыйбыз?—диде ул.

—Әнә—теге галстуклы егеттән, иптәш комиссар. Укытучы икән ул.

—Чишен—диде күзлекле ир.

Оялып кына чишендем дә, шәрә килеш комиссия әгъзалары каршысына килеп бастым.

Күзлекле минем буй белән авырлыкны үлчәде.

—Буең йөз алтмыш алты сантиметр, авырлыгын алтмыш ике килограмм. Дүрт килограмм житми,—диде күзлекле, кырыс кына.

—Сугыш еллары никрутлары, нишләмәк кирәк,—диде хәрби комиссар.

Табибә ханым көпшә куеп, башта минем йөрәк тибешен, үпкәне тынлады, аннары күз-колакларны тикшерде дә, салмак кына:

—Авырлык житмәү комачауламый, яраклы,—диде һәм үз алдындагы кәгазьгә эре хәрефләр белән: «Яраклы!»—дип язып та куйды.

—Бик яхшы, укытучыны НКВД частенә озатачакбыз,—диде хәрби комиссар, ниндидер тәкәбберлек белән.—Каралучы Латыйпов, укытуынны дәвам иттер, китәргә вакыт житкәч, хәбәр итәрбез... Котлыйм!

Урыныннан торып, ул минем кулны кысты:

—Сынатма, чекист хезмәте мактаулы да, жаваплы да ул... Синең яхшы егет икәнлегенне мин беләм. Шигырь дә язасың икән: «Сабанчы жыры» дигән шигыренне «Авангард» газетасында укыган идем. Сабан сөрә белгән кебек, мылтык та тота бел. Килештекме?..

—Чиратта кем?—диде табибә, ачы тавыш белән.

Тиз генә киенеп, мин комиссия әгъзалары утырган бүлмәдән чыгып киттем. Күнел күтәренке иде...

Олауда гәпләшә-гәпләшә авылга кайтабыз: унбер егеттән икебез—мин һәм Хәмидулла НКВДга, тугызы—Кызыл Армия сафларына алынганбыз. Егетләрнең тугызы да Хәмидуллага бәйләнә:

—Жиде класс белемең белән НКВДга эләктең, дөрес түгел бу! Кави инде лаектыр, үзе урта белемле, үзе укытучы. Ә син—карачкы!

Бәхәсләшә, үртәшә, шаяра-көлә авылга кайтуыбызны сизми дә калдык. Үзебезнең урамда мина абыемнын яшьлек дусты, фронттан яраланып кайткан, кәртле уйнап «Очко» кушаматы алган Зыя очрады.

—Йә, энекәш, солдатка яраклымы?—диде ул.

—Яраклы, Зыя әбзәй.[1]

—Нинди гаскәргә жибәрергә булдылар?

—НКВДга,—дидем мин, эрелек белән.

—Димәк, син, туган, йә тере Сталинны, йә үле Ленинны саклаячаксың.

—Кем белә...

—Әйтте диярсең, шулай булачак. Миндә сиземләү хисләре көчле. Катын[2] да шулай дир.[3] Шикләнәсенме әллә?

—Алдан кычкырганнын башы таз...

Зыя кәләпүшен салды:

—Таз, имеш, катынлы була торып, гармунчы Зыя әбзәнә күрше авыл кызлары да гашыйк. Чәч нинди куе, бармак түгел, тарак та керми... Солдатка китү көнең билгелеме?

—Юк... Иртәгә таннан Татар Тимәшенә, мәктәбемә... Балалар көтәдер. Армиягә китәмен дип, күнел ачып йөрисем килми...

Таң белән, таныш юлдан, күрше авылга тәпиләдем. Үрдәге жил тегермәнен, ана янәшәдәге зиратны узып, басулар буйлап киттем. Зиреклеккә житкәч, очкан кошларга карап тордым. Пәке белән кара камыш кисеп алдым да, алга таба атладым. Басуда жырлый-жырлый урак уралар: милли жыр үзләренә дәрт-дәрман бирәдер, жилкенеп эшлиләр. Юл өстендәге чуаш авылын узгач, яланаяк Бола елгасын кичтем... Менә мин балалар укыткан Татар Тимәше авылы! Елга янында гына мин фатир торган йорт һәм ике катлы агач мәктәп... Берәм-берәм балалар

[1]Әбзәй—абый.

[2]Катын—хатын.

[3]Дир—ди.

килә башлады. Класска керүче һәр бала, минем белән исәнләшә дә, тыныч кына үз урынына барып утыра.

Дәресне башларга вакыт житте. Беренче дәрес: ана теле. Балаларның иң яратканнары, күңелләренә иң хуш килгәннәре. Ана теле дәресендә алар мишәрлекләрен дә оныталар, саф татарча укырга, шигырь сөйләргә омтылалар. Ноябрь уртасына кадәр укыттым мин, аннары армиягә китәргә дип, туган авылдан ат белән килеп алдылар. Бөтен класс, утыз баладан утызы да диярлек, елый-елый Бола елгасына кадәр озатты: әниләре, әбиләре, бабалары белән бергәләп. Апакайлары арасында минем сөйгән кызым Гөләндәм дә бар иде: кара кашлы, кара күзле, алсу йөзле, тыйнак-сабыр холыклы, сугыш башлангач, Мәскәүдән кучеп килгән кыз. Ул миңа чигүле кульяулык бүләк итте, юлга өч йөз сум акча бирде...

Икенче көнне әнием, ике энем, бабай, күршеләр, кыскасы, туган нигез, туган авыл белән саубуллашып, унбер яшьтәш, чаналарга утырып, хәрби комиссариатның жыену пунктына юл тоттык. Күңелне моңсулык басты, шулай да югалып калырга теләмәдем, күтәренке булырга омтылдым. Шаяра-шаяра, мәзәкләр сөйли-сөйли, билгеләнгән урынга килеп житкәнебезне сизмәдек. Безне әлеге таныш хәрби комиссар каршы алды, кулында солдатка китүчеләрнең исемлеге иде. Ул яшьләрнең исем-фамилияләрен берәм-берәм шәхсән үзе барлап чыкты. Татар егетләренең һәммәсе килгәнлеге, ә чуаш авылларыннан ике егетнең юклыгы ачыкланды.

—Пүртләреннән[1] милиционерлар белән алып килергә!—диде военком.—1927 елгылар—сугыш чорының соңгылары. Әле дә даһи Сталин үзләрен саклап тотты. Гитлер әнә унөч-ундүрт яшьтәгеләрне фронтка ала. Егерме жиденче елгыларга тарихи миссия башкарырга туры киләчәк: алар аталары, абыйлары белән бергә Берлинны алып, рейхстагка Жиңү байрагы кадаячаклар. Сизәмен, алар үзләре дә фронтка атлыгып торалар. Хәерле сәгатьтә, сугыш елларының соңгы солдатлары! Көнбатыш якларында аталарыгыз көтә сезләрне!

Саубуллашу башланды... Минем яныма көтмәгәндә яшь бер ханым килде дә, исәнләшкәннән соң, болай диде:

—Син укытучы Кави буласынмы?

—Әйе, шул үзе.

—Алайса, мин сиңа бер сөенеч әйтәм.

—Нинди сөенеч ул?

—Редакциягә жибәрелгән «Жинеп кайтырбыз!» дигән шигырең «Авангард»ның бүгенге санында басылды. Менә ул газета, истәлеккә саклап тот. Шигырьләреңне фронттан да жибәр. «Сабанчы жыры» исемле беренче шигыреңне дә укучылар яраткан иде, хатлар килде. Сине без бар редакция белән озатырга килдек, хәерле юл телибез. Онытма район хезмәт иясләрен. Хуш, яшь шагыйрь!.. Егетләрнең күңелләрен күтәрерлек шигырьләр яз...

—Сау булыгыз, озатырга килүегез өчен барыгызга да ихлас күңелдән рәхмәт!..

2

Желеккә үтәрлек суыкта, карга бата-бата, жиде йөз егет станциягә таба атладык. Ә шоссе юлда чаналар, әмма беребезгә дә олауга утырырга ярамый, рөхсәт юк. Чуар колонна әсирләрне хәтерләтә. Саубуллашырга теләүчеләрне инде якын да китермиләр, мылтыклардан һавага атып, өркетәләр. Егетләрне күрергә, аларга соңгы жылы сүз әйтергә теләүчеләр, берәм-берәм, яланда күренеп китә. Безне—булачак солдатларны, шоссе юлы белән түгел, авыллардан читләтеп, яланнар аша, турыдан-туры тимер юл станциясенә алып баралар. Янәшәдә

[1] Пүртләреннән—өйләреннән *(чуашча)*.

авылдашым, колгадай Хәмидулла көчкә атлый, аның кычыткан шулпасы эчеп, еракка сәфәрне ничек кичерүен яхшы беләм мин: йөзенә үләи төсе чыккан. Тешләрне кысып, алга таба аяк сөйрәүче бер ул гына булса иде дә бит! Минем җилкәдә биштәр, ул сохари белән тулы. Сугышка ала калсалар дип, ел буе әнием әзерләде. Тоттырасы иде Хәмидулла кулына бер генә сынык сохари. Ярамый, мылтыклы озатучыларның күрүләре ихтимал: солдатка түгел, җәһәннәмгә китәрсең. Ниһаять, станциягә килеп җиттек. Сузылган гармунны хәтерләтеп, йөк вагоннары тора. Безне турыдан-туры фронтка алып китәчәкләр микәнни?.. Юк, алай булмады: безләрне вокзал белән янәшәдәге соры бер бинага урнаштырдылар. Менә кайда шау-шу, базар! Үзләренә күрә «спекулянтлар» да табылды: күрә, белә торып алдашалар, күзләрен дә йоммыйлар. Әйберләрен алыштыралар, саталар: алыш-биреш каннарына сеңгән диярсең. Кемнәрдән өйрәнгәннәр: ата-бабаларыннанмы, күрше авыллардагы чуашлар-«юлдаш»ларданмы?.. Колак элпәләрен ярырлык гауга! Әйтерсең лә, җиде йөз кеше зур бер мичкә эчендә. Авыл белән авыл арасында мускул-көч сынаш бара. Тамак ялгарга утырсаң, сохарины кулдан тартып алалар. Ике катлы соры бина— эчендә нинди генә күңелсезлекләр вә хәтәр хәлләр булып үтмәде: урлашу, янау, яшеренеп көмешкә эчү, авыз-борыннар канату... Көчленеке замана дигәндәй, йодрык-көч хәл, хөкем итте. Ә инде олы бер төркем егетләр төялгән эшелон Пенза якларына киткәч, бина эче тынып калды. Мин үземне башым белән тын күлгә чумгандай хис иттем. Көн артыннан көн, төн артыннан төн үтә, ә без, район военкоматларында комиссияләр тарафыннан НКВД сафларында хезмәт итәргә яраклы дип табылучылар, ике катлы бинаның өске катында яшәвебезне дәвам итәбез: частьләрдән энкаведистларның килеп алуларын көтәбез. Көтәбез, ләкин, ни сәбәпледер, күренмиләр, үзләре белән юлда берәр хәл булмагае?..

Ниһаять, команда бирелде: «Частькә алып китүчеләр килгән, эшелон көтә. Вагоннарга!» Караңгы бина эчендә һавага, суга, икмәккә зарыгып-тилмереп ятучылар өчен сөенеч иде бу!

Көнбатышка таба безнең эшелон кузгалып киткәч, сулышым иркенәйгәндәй булды: «Озату пункты» дип аталган соры бинада унөч көн, унөч төн иза чиккәннән соң!» Урысча «телячий», ә татарча «бозау»ныкы дип йөртелгән вагонда «буржуйка» миче янында урын таптым мин үземә... Аста салам булса, баш очында әлеге биштәр: сохари тәме борынга керә. Вагон ишегенең баш бармак сыярлык ярыгы бар, ябылып ук бетми. Булачак фронтовикларны кышкы ачы җил берәм-берәм «кытыклап» карый, шүрәле димәссеңме? Өстемдә фуфайка, башымда куян бүрек, аякларда, армиягә китәр алдыннан әнием бастырткан киез итекләр. Туры килсә, киез итекләрне әниемә кире җибәрергә исәп. Язган булса, мина күн итек бирәчәкләр. «Буржуйка» аяк очында гына булганга, киез итекләрне салып, яланаяклы килеш, жылыга күрәме, яткач ук, йокыга киткәнмен, һәм, үзем дә сизмәстән, сул аякның үкчәсен пешергәнмен. «Теге Ахиллес үкчәсе сымак булмагае?»—дип шиккә калдым, уянгач... «Буржуйка» ны чиратлашып, дневальный итеп билгеләнгән чакта ягабыз. Вагондагы кырык кешенең һәркайсы «аучы»: берәр станциядә эшелон тукталган арада, вагоннан сикереп төшә дә, бомбага тотылган вокзалның коймасын каера. Каерылып, сындырылып алынган такта— «ау» ганимәте шул. Интендант-тәэминатчы урнашкан вагоннан коры паекларны дневальный алып кайта. Ә бүлүчесе, өләшүчесе взвод командиры ярдәмчесе... Ярам төзәлә инде, әмма күбрәк бер урында утырамын. Егетләр мина «Мулла» кушаматы тактылар... Алдымда сөлге—бабам ядкаре, саубуллашканда бирде: «Гомер юлың шушы сөлгедәй озын вә пакъ булсын иде, йә Хода!»—диде ул.—Син сугыштан әйләнеп кайтканчы, үлеп китсәм, төсем итеп сакларсың». Икмәк валчыклары коелмасын дип, тамак ялгаган чакта, сөлгене аз гына сүтеп, тезләремә куям. Туклангач, пөхтә итеп төрәм дә, аны биштәргә урнаштырам. Ә куен кесәсендәге яраткан кызым бүләк иткән кулъяулыкка: «К+Г» дип, ефәк җеп белән ике хәреф чигелгән.

Әйе, урыным вагон ишегенә каршыда. Ишек ярыгындагы яктылыктан файдаланып, үзем белән бергә юлга алган «Гөләндәм»[1] поэмасын укыйм. Әсәрнең җисеменнән битәр, исеме мине тарта. Гыйшкым да Гөләндәм исемле иң... Көнчыгыштан көнбатышка, көнбатыштан көнчыгышка киткән эшелоннарны, ишек ярыгыннан күреп кенә түгел, ә санап-барлап барамын. Хәер, көндезен аларны мин үз күзләрем белән күрсәм, караңгы төшкәч, тәгәрмәчләре тавышыннан таныймын. Көнчыгышка китүче эшелоннарны бармак белән дә санап булса, көнбатышка юл тотучылары бихисап. Тагын шул: көнбатышка юнәлүче вагоннарның тәгәрмәчләре җәһәтрәк әйләнеп зыңгылдаса, көнчыгышка таба баручы поездларның тизлеге акрынрак булганга, зыңы колакка тупасрак ишетелә... Безнең паровозга көнбатышка агылучы эшелоннарга да юл бирергә туры килә... Көтелмәгән тагын бер тукталыш. Янәшәдә генә көнчыгыштан килүче хәрби эшелон килеп туктады. Фронтка баручы солдатлар дөбер-шатыр вагон ишеген ачты.

—Нинди станция бу?—диде берсе.

—Кем белсен? Ә сез кемнәр буласыз?

—Фронтовиклар.

—Ничек фронтовиклар, фронтка барасыз гына түгелме?

—Фронтка юл тоткач, фронтовиклар булмый, кемнәр булыйк... Ә сезне сугыш җилләре кая алып бара?

—Үзебез дә белмибез.

—Хәрби сер, димәк?

—Шулайрак.

—Эшелон көнбатышка юл тоткач, фронткадыр инде.

—Кем белә...

—Ашау ничегрәк?

—Икмәк, шикәр... Концентрат та бирәләр. Бисмилла әйтсән, җитәрлек.

—Син татар икән, мин дә татармын, Себердән... Бисмилла әйтмәсән, ничегрәк соң?

—Биштәреңне чишәсең дә, сохари кимерәсең.

—Сохари, имеш. Безнең вагоннарга күчегез!

Себер татары «Аракы» дип язылган шешә күрсәтте:

—Бездә бусы да бар... Сикер, егет, минем вагонга!..

Мин икеләнеп калдым: «Фронтовик янына күчәргәме әллә?.. Вакытыннан элек сугыш кырына барган өчен гаепләмәсләрдер?!»

—Нәрсә югалып калдың?—диде мыеклы солдат.—Үзеңне дезертир дип санарлар дип уйлыйсыңмы?.. Юк, синең хакта чын патриот дип командирдан туган авылыңа хат яздыртачакмын. Эшелон кузгалганчы, безнең вагонда урнашып кал. Әйткәнне тыңламасаң, соңыннан үкенерсең...

—Үкенмәм, кыскасы, син үз юлыңда бул, артыңнан куып җитәрмен. Хуш-ш!

—Син дә хуш!.. Үзеңне сакла!

—Рәхмәт, атакай! Сугыш кырында очрашканчыга кадәр...

—Кыр почтасы номерын әйтмәдең?..

Шул чакта «Таяк-генерал» дип кушамат тагылган взвод командиры ярдәмчесе килеп чыкты да, зәһәрләнеп, болай диде:

—Ни өчен син ят кеше белән ләчтит сатасың, бәлки ул, шпиктыр?

—Фронтовик ул.

—Сак булырга кирәк. Юлда кем генә очрамас! Абвер турында ишеткәнең бармы?

—Юк.

—Ишетмәсәң ишет: Германиянең хәрби разведка һәм контрразведка органы ул. Җитәкчесе адмирал Канарис...

Куе төтен чыгара-чыгара фронтовиклар эшелонын паровоз алга алып китте.

[1] «Гөләндәм» *(Поэма)*:—Нур Баян. Казан. Татгосиздат, 1940.

—Әй, син, кем, улкайларны рәнҗетмә!—диде Себер татары, кычкырып.

Вагон ишегеннән кычкырган карт солдатка «Таяк-генерал» җавап бирмәде, ык-мык кына итте... Инде ераклаша барган фронтовиклар эшелонның кызыл фонаре гына күренде. Мин хәбәрсез югалган әтиемне искә төшердем, ул кырык икенче елның январь башларында сугышка киткән иде. Фронтта, Ржев шәһәре тирәсендә икәнлеген белдереп, анардан ике сәлам-хат килде, аннары тынып калды, юк, тәмам югалды, гүя үзен җир йотты. Абыем исән, Сталинградны саклаганда яраланганнан соң, Мәскәү янындагы Серпуховта госпитальдә дәваланды... Ә хәзер сугыш кырында артиллерист. Фронтта, бәлки, очрашырбыз...

Безнең эшелон да кузгалды... Ташбака адымы белән булса да, Орел станциясенә килеп җиттек. Шәһәр хәрабә хәлендә, җир тетрәгән диярсең. Безгә вагоннардан чыгарга рөхсәт иттеләр. Унбиш тәүлек сәфәрдән соң, беренче мәртәбә кайнар аш ашаттылар. Вокзалда такталардан яна гына ясалган озын өстәлләр урнаштырылган иде. Станциядә эшелон алты сәгатькә якын торды. Вокзал тирәсендә бөтерелеп йөрим: бер төркем шәһәр яшьләре күзгә чалынды, шунда килдем. Ачык һавада урнашкан буфет янында карт уйныйлар. Тын гына күзәтеп торам: өстәлгә таратып салынган картлар арасыннан тәре тузын табучы егет кисәге бер мизгелдә егерме биш сумны отмасынмы!.. Мин дә бәхетне сынап карарга ният кылдым. Ун сумны өстәлгә чыгарып салып, беравык уйланып торгач, тәре тузы дип, бер картне күрсәттем. Юк, тузы түгел, тәре кызы булып чыкты. Уенчы минем ун сумны бөгәрләп куен кесәсенә тыкты. Мин икенче ун сумны чыгардым, бусын да оттырдым. Өченче мәртәбә дә шул ук хәл булды. Берничә минут эчендә мин өч йөз сумнан колак кактым. Йөгереп барып, вагондагы биштәрдән әнием ядкаре-җылы оекбашны алдым да, янадан карт уйнарга килдем:

—Сал картларне, барыбер отачакмын!

—Кәничне!—диде карт салучы.

Юк, бу юлысында да бәхет минем якта түгел иде... Беркайчан да ота алмавымны мин дүртенче тапкыр уңышсызлыкка дучар булгач кына аңладым. Тәре тузы мошенникның җиңендә икән! Ләкин соң иде инде, эшелон кузгалып китә башлагач, бер сүз дә әйтми генә, бик тә күңелсез хәлдә, мин вагонга мендем.

—Синең белән ни булды?—диде Хәмидулла.

—Бәхетне сынап карарга теләгән идем.

—Ә ничек?

—Карт уйнап, ләкин уенчы мошенник булып чыкты. Сукыр бер тиенсез калдым.

—Әниең бәйләгән оекбашны да оттырдыңмы?

—Кайдан беләсең?

—Биштәреңнән алдың ич, тәртибең укытучыныкына ошамаган.

—Беренче сәфәр, поездга да беренче мәртәбә утыруым. «Дөньяны сәфәр йөреп танныйлар»,—дип әйтә иде шул бабай.

—Дөньяны намуслы кешеләрдән генә тора дип уйлагансың, ялгыш уй бу!

—Күңелем сизә: солдат тормышы минем өчен җиңел булмаячак. Ул оттырудан башланды. Намуссызлар ота—шул әрнетә минем күңелне. Тәкъдир кушуымы әллә?

—Син миннән күбрәк беләсең, укымышлы кеше.

—Картежник, диген!

—«Таяк-генерал» ишетмәсен, башыңны ашар!

Карт уены минем күңелдә бер төер булып калды, инде мин беркайчан да карт уйнамаска сүз бирдем...

Поезд көнбатышка ургыла. Вагон ишеге ачык, карап барам: герман солдатларының каберләре белән яланнар тулы, күмелгән җир-туфраклары да, тәреләргә әверелгән агачлары да советларныкы...

Гомель шәһәренә житкәч, эшелон Сож елгасы аша ясалган күпердән бик тә акрын вә сак үтте. Күпер вакытлыча агачтан салынган иде. искесен фашистлар шартлатканнар. Днепр буендагы Речицаны узып, Припять янындагы Мозырьны уздык. Лунинец станциясеннән Случь елгасына таба борылгач, Ровно өлкәсе башланды. Көнбатыш Украина жиренә житкәч, мин йокыга киткәнмен. Ә таң тишегеннән мине, әлеге дә баягы, «Таяк-генерал»ның тавышы уятты:

—Тиздән Сарны, соңгы станция!—диде ул, бакырып.

Күп ара үтмәдек, эшелон туктады. Ике якта да кара урман иде.

—Вагоннан чыкмаска!—диде «Таяк-генерал».

—Нәрсә булды икән?

—Хәзер белеп киләм,—диде «Таяк-генерал».

Тынлык күңелгә шом салды...

—Диверсантлар бездән алда баручы эшелонның өч вагонын шартлатканнар,—диде «Таяк-генерал».—Үлүчеләр дә бар икән. Безнең эшелон башлыгына рация аша хәбәр бирелгән. Тимер юл вакытлыча ябык. Рельслар буйлап жәяү атларга туры килер... Взвод, тыңла минем команданы!.. Вагоннан чыгып, сафка басарга!

Биштәрләр аскан егетләр бәрелә-сугыла сафка тезелде.

—Сөйләшмәскә! Жырламаска!

Карта чыгарып, «таяк-генерал» жәяү узасы юл озынлыгын санарга кереште:

—Егерме километр чамасы икән. Хәер, урман аша кыскарак. Ләкин эшелон башлыгы рөхсәт итмәде. Мыекка чорнагыз: армиядә приказга буйсынасың, рөхсәтсез ярамый. Шулай булгач, шпаллар буйлап тәпилисе генә кала... Рядовой Латыйпов, син вакытлыча минем ординарецым булырсың. Сал катомкаңа «КЗ»ны. Кагылгысыз запас! Минем өчен генә түгел, барыбыз өчен дә. Кем әйтмешли, сез тук булсагыз, мин дә тук... Эшелон башлыгы диверсантлар дигән була...

«Нинди диверсантлар?»—дип сорыйсым килә минем. Ләкин тукталып калам: «Сөйләшмәскә!»—боерды «генерал»...

Егерме километрга якын жәяү атлагач, безнең арттан поезд килеп житте һәм без, буш вагоннарга утырып, Сарныга таба юл тоттык. Ниһаять, егерме бер тәүлектән соң, безнең эшелон соңгы станциягә—Сарныга килеп житте. Вагон ишегеннән мин папахалы бер кешене күреп алдым.

—Бригада командиры полковник Яхимович,—диде «генерал».—Үзенең штабы белән мине һәм сез-яшь солдатларны каршы алырга килгән...

Ләкин алай булып чыкмады.

—Эшелон башлыгы майор Денисов, минем янга!—дигән боерык яңгырады.

—Эшелон башлыгы майор Денисов, полковник Яхимович янына!—дип кабатлады икенче берәү.

Аннары өченчесе тотып алды:

—Эшелон башлыгы майор Денисов, сезне комбриг чакыра!

Эшелон буйлап майор жәһәт кенә атлап килде дә, рапорт бирде:

—Иптәш полковник, 1170 нче эшелон тулы составы белән билгеләнгән соңгы пунктка килеп житте! Гадәттән тыш вакыйга—«ЧП» юк.

—Исәнме, майор!—диде комбриг, кул биреп.—Килеп житүегез белән. Озакладыгыз.

—Егерме бер тәүлек килдек.

—Бәхетле сан... Хәер, отчет соңыннан... Егетләрнең кәеф-сафалары ничек?

—Күтәренке, иптәш полковник.

—Шулай булсын.

—Ә сездә хәлләр ничегрәк?

—Ул хакта иртәгә сөйләшербез, майор... Егетләргә мунча ягылган, казарма әзер... Рота, взвод, отделениеләргә бүләргә кирәк аларны. Команда бир, майор!

—Эшелон, тынла минем команданы! Вагоннардан чыгарга! Сержантлар, үтәгез боерыкны!

Без вагоннардан төшеп, сафларга тезелдек.

—Кемнең белеме бер класс, бер адым алга!

Белемнәре бер класслылар бер адым алга атлап, сафка бастылар.

—Кемнең белеме ике класс—ике адым алга!

Ике класслылар ике адым алга атлап, сафта үрә каттылар...

Өч класслылар, дүрт класслылар, белемнәренә күрә, аерым сафлар тәшкил итте. Белемнәре биш, алты, җиде, сигез, тугыз класслылар да шул бер тәртипне узды.

Соңыннан гына:

—Кемнең белеме ун класс—ун адым алга!

Ун класс белемле бер мин булып чыктым. Отделение командирлары, һәммәсе, берьюлы, миңа ташланды һәм алар авызыннан бер җөмлә яңгырады:

—Әйдә, минем отделениегә!

Нишләргә дә белмичә, тәмам югалып калдым, ә күзләрем белән теге безнең юл башлыгы «генерал»ны эзләдем. Әмма аңардан җилләр искән иде. Бик тә «генерал» кул астында хезмәт итәргә теләгән идем мин. Ә болары кемнәр икән?.. Шул нияттән, «Әйдә, минем отделениегә!»—дип әйтүченең һәрберсенә тәкәббер сорау бирәм:

—Хәрби дәрәҗәгезне әйтсәгез иде?

—Кече сержант, погоннарда ике тар тасма...

— Ә сезнең хәрби дәрәҗәгез?

—Өлкән сержант, погонда киң бер тасма.

—Ә сезнеке?

—Сержант, погоннарда өч тар тасма.

—Димәк, сез берегез дә генерал түгел?!

—Түгел.

—Ә погоннарда тар бер тасмалы кем?

—Ефрейтор...

«Юлда килгәндә мин ефрейторга буйсынганмын икән, погоннарында тар бер тасма иде»,—дидем мин, уйланып.

Погоннарында өч тар тасмалы түрә-сержант отделениесендә хезмәт итәргә ризалык бирдем. Ләкин бер шарт белән: «Армиягә алынганчы укытучы булып эшләгән Татар Тимәшәнең өч егетен һәм авылдашым Хәмидулланы миннән аермаска!» Сержант моңа каршы булмады. Без—егетләр моңа бик шатландык.

3

Йөк автомобильләренә утыртып, безне мунчага алып киттеләр. Студебеккерлар урам буйлап үкереп бара. Бәләкәй тәрәзәле тәбәнәк таш йортлар, тәреле костеллар, тар урамнар, борылышлы тыкрыклар күңелгә шом өсти.

—Командасыз кузовтан төшмәскә!—диде отделение командиры сержант Головач, мунча янына килеп җиткәч.

Солдатлар тып-тын.

—Мунчага!—дигән команда бирелде.

Солдатлар борчаклардай кузовтан коелды...

—Чабынырга себеркесе дә булса!—диде Хәмидулла.

—Бәлки, син баш уарга җылы катык та сорарсың.

Озак юындым: мунча керүдән җаңга рәхәт, тәнгә сихәт таптым—солдаттагы беренче мунча!

—Сафка!—диде Головач, мунча ишеген ачып.—Тизрәк!.. Бүгеннән үзегезнең солдатлар икәнлегегезне онытмагыз. Һәрнәрсәне тиз эшләргә кирәк... Күлмәк-ыштаннар алыгыз!

Киенергә дип, мин эскәмиягә килеп утырдым. Эссе мунчадан соң ятып йоклыйсым килде. Каршыга жирән чәчле Сиражи килеп басты. Мин укытучы булып эшләгән авылдан иде ул.

—Сиңа бер сүзем бар иде,—диде Сиражи.

—Булса, әйт.

—Базарга барып килик, шушы тирәдә икән.

—Рөхсәтсез ярамас.

—«Ә» дигәндә әйләнеп киләбез.

—Киттек, алайса: бер аягыбыз монда булса, икенчесе анда...

Базар борын төбендә генә иде, күперне узуга мәш килгән халыкка кушылдык.

—Күмәч исе килә,—диде Сиражи, иснәнеп.

—Күмәч сатып алырга акчаң бармы соң?

—Акча миндә бер букча...

—Күмәч сатам, күмәч!—диде ачы тавыш белән күркәдәй бер хатын.

Сиражи ике күмәч сатып алып, берсен миңа сузды. Шул чакта әллә кайдан хәрби патруль килеп чыкты...

Без килгәндә мунча янында борчулы Головач басып тора иде.

—Кайда югалдыгыз?—диде.

—Базарда йөриләр,—диде патруль.

—Кесәңдә нәрсә ул?—диде Головач, миннән сорап.

—Күмәч... Рәхим итегез, иптәш сержант.

Күмәчне алгач, Головач, иснәп карады да, аны урталайга сындырды. Аннары ике кисәген дә кире миңа бирде.

Солдатлар сафка тезелгәч, рөхсәтсез базарга барганыбыз өчен, Головач Сиражи белән миңа өчәр наряд игълан итте.

Казармага кайтып урнашкач, йокы калдырып, Сиражи һәм мин бәрәңге әрчергә мәҗбүр идек: бер бәрәңге, ике бәрәңге, өч бәрәңге... Солдатка йокы әрәмме?... Шулай итеп солдат хезмәтенең беренче көне дә, төне дә мажаралы үтте. Икенче тәүлектә дә, отбойдан соң, идән юдык. Өченче төндә әлеге шул бәрәңгене әрчедек: бер бәрәңге, ике бәрәңге, өч бәрәңге... Солдатка йокы әрәмме?.. Өч тәүлек батальон солдатлары, сержантлары һәм офицерлары кабыгын Сиражи белән мин әрчегән бәрәңгене ашадылар. Чираттан тыш бирелгән нарядның асылын кулларымның уч төбенә «кәҗә мае» чыккач кына төшендем. Төнката бәрәңге әрчеп интектем. Ә таң белән нар-сәке дип аталган йокы урынына сержант Головач янына кайтып ава идем. Мин аның белән янәшәдә йоклый идем. Сул якта сержант Головач булса, унда озын буйлы әлеге Сиражи йоклый иде. Ранжирга, ягъни буйга карап, отделение командирының күршесе Сиражи булырга тиеш иде. Белемем ун класс булгангамы, һөнәрем укытучыгамы, Головач үзенең янында мин йоклауны хуш күрде. Урта буйлы булуыма карамастан, чираттан тыш наряд бирсә дә, урынымны үзгәртмәде. Өч тәүлек Сиражи белән миңа аз йокларга туры килде. Ә инде дневальныйның «сафка!»—дигән тавышы ишетелүгә, уктай атылып торасың да, чолгауны аяк балтырына чолгый башлыйсың. Йокыдан уянып-тарынып бетмәгәнгәме, чолгау кулдан ычкынып, сүтелә дә китә. Ә аны яңабаштан урау озакка сузыла. Моның өчен Головачның чираттан тыш наряд бирүе ихтимал, бик ихтимал!

Гыйнвар ае, казарманың ишекләреннән кышкы суык керә. Ә безгә кыш бабай нипочем. Хәер, бу якларда кырык градуслы суык юк. Шулай да Көнбатыш Украина Кырым да, Кавказ да түгел. Жилләр зәһәр. Әйе, Көнбатыш Украина мәгънәсез, зәһәр вә каһәр жилләр белән атаклы. Физик күнегүләр ясарга чыккач, штаб урнашкан якка йөгерәбез дә, кире кайтып, озын казарма тирәсен биш тапкыр әйләнәбез. Ә кайчак шәһәр читендәге хәрби склалдарга кадәр барып житәбез. Күзгә сакчылар чалынып китә. Суык булуга карамастан, алар шинельләрдән генә. Утыз градуслы суыкта гына постта торучы сакчыларга толып бирелә. Көнбатыш Украина жирендә утыз градуслы суык булуы кем әйтмешли, үзе бер «ЧП» ул!

Иртәнге ашны ашагач, комсомолларга ашханәдә калырга куштылар, җыелыш була икән. Җыелышта башлангыч комсомол оешмасын булдыру турында сүз барды: беренче булып батальон командиры сүз алып сөйләде... Менә комсомол бюросы әгъзаларын сайлауга керештеләр, яшерен тавыш белән түгел, ә ачык рәвештә. «Рядовой Латыйповны бюро составына тәкъдим итәм»,—диде капитан Федорчук. Ышанасым килми, чираттан тыш нарядлар алучы кеше ничекләр итеп мона лаек булсын? Минем кандидатурам бертавыштан сайлангач, эчкә җылы кереп китте: юлда килгәндә, мәгънәсез кәрт уены уйнаулар, өч төн тоташ йокы калдырып бәрәнге әрчүләр онытылды да куйды. Җыелыштан сон, взвод командиры капитан Федорчук мине комсомол бюросына сайлануым белән котлады, кайчандыр үзе дә укытучы булып эшләвен әйтте. «Дуслар булырбыз!»—диде.

Әйе, кәрт уйнаган, нарядлар алган күнелсезлекләр томан артында калды. Укулар-өйрәнүләр башланды. Иртән политинформация тынлаталар, көндезен сугышчан техникаларны өйрәтәләр, строевой әзерлекләр алып бару унае белән, айт-два бастырталар. Кырга алып чыгып, тактика дәресләрендә түш, корсак белән шуыттыралар, ату урыннарында винтовкалардан мишеньнәргә аттыралар. Пуля дигән җүләр «сөт артыннан китсә», Головач йә ашны икмәксез генә ашата, йә икенчегә дигән ботканы бирми. Икмәксез дә, әбәт вакытында боткасыз калырга да туры килде мина, өйрәнүнен беренче көннәрендә. Аннары атарга да остарып киттем. Головачтан битәр, мона капитан Федорчук сөенә иде. Чөнки начар атсам, карабодай ботканы, башбаштаклыгы аркасында, сержантнын үзенә эләгә иде.

Солдатлар өчен казарманы туган йорт дип әйтерсен: бер түшәм астында яшибез, янәшәдә ятып йоклыйбыз... Солдат вакытынын минуты да санаулы. «Солдатнын хезмәте йоклап уза»,—дигәнне ишеткәнем бар минем. Ялган бу! Вакытсыз йоклап кара, күрсәтер күрмәгәненне Головач! «Сикереп торып бас! Кире урнына барып ят!»—дип, яткыза-яткыза, торгыза-торгыза тенкәнә тияр. Йокын туйдымы, туймадымы, урыныннан сикереп тор да, пулядай физзарядкага атыл! Урынынны җыештыра белмәсән, җыештыра белгәннәрдән өйрән. Өйрәнергә теләмисен икән, отбой бирелгәч, кулына швабра тот!

Фронтка әзерләнү өчен махсус оештырылган батальонда көндезләрен вакыт тактик өйрәнүләрдә узса, төннәрен без—яшь солдатлар патрульләр идек. 1939 елны Советлар Союзына кертелгән Көнбатыш Украина территориясендә, шул исәптән Ровно өлкәсендәге Сарны шәһәрендә хәрби положение иде. Ровно—Волын төбәгендә, тәгәл әйткәндә, Кременец урманнарында СС зондеркомандалары хәрәкәт итә. Хәрби эшелоннарнын, йөкләр төялгән поездларнын йөрешен безнен уналты укчы бригаданын «Бронепоезды-39» тәэмин итә: «Литер-А»га вә «Литер-Б»га бүленеп, Олевск-Сарны-Рафаловка белән Сарны-Костополь-Ровно участокларында курьерлыкны башкара. Бригада бронепоезды йөргәнче, көнбатышка юнәлүче йөк поездлары, хәрби эшелоннар һәлакәткә дучар була торды. Бу диверсияләрне бригаденфюрер СС Модель башкисәрләре башкара икән. Сарны гарнизонында көн саен фаҗига артыннан фаҗига. Менә тагын күрше частьтәге зенитчы кызны үтергәннәр. Ул хакта сержант Головач әйтте.

—Үтереп, кызнын мәетен бәкегә ташлаганнар,—диде ул, ярсулы йөрәгенә түзә алмыйча, арлы-бирле йөренеп.

Сержантнын аякларында хром итекләр иде. Әлеге хром итекләрне без—отделениенен биш солдаты базарда сатылган ярты потка якын шикәр комы исәбенә әмәлләдек. Тәмәке тартмаучыларга, махорка урынына, шикәр комы бирелә иде. Хром итекләр безнен отделение өчен күмәк иде, кемнәрдер тарафыннан алар йә тантаналы, йә кайгылы чакта файдаланылды. Бәкегә ташланылган зенитчы кызга Головач гыйшык тотып йөргәнгә, матәм көннәрдә хром итекләрне киярго аны лаек дип

таптык. Әйе, «москаль» кызларын үтерәләр, ә шәһәрдәге фәхишәләр типтереп яши бирә. Аларны тануы да мәшәкатьле түгел, сул аякларында ефәк кызыл тасма—шартлы билгеләре шул. Шунысы көенечле, көзгедәй ялтырап торган хром итекләрне зенитчы кыз үз күзләре белән күрмичә теге дөньяга китте. Инде ул мәңге йокыда, ә без—тереләр өчен йокы үлчәп кенә бирелә.

Иртән торып сафка баскач, Головач авызыннан «ЧП!» дигәнне ишеттем.

—Хәтәр вакыйга! Кыскасы, «ЧП!»—диде сержант, кабатлап.—Постта торучы безнең отделение солдаты Хәмидулла Зартдинов, диверсант дип, дивизия штабында эшләүче бер өлкән сержантны атып үтергән.

—Минем авылдаш Хәмидулла Зартдиновмы?..

—Әйе, ул. «Смерш»[1] киләсен көт тә тор.

—Ни дип килә ул?

—Анысын синең белән миннән сорамыйлар. Командование кирәк дип тапкан икән, әйдә казынсын.

Икенче көнне таң тишегеннән «Смерш» казармага килеп тә житте һәм сугышчыларга бер-бер артлы сораулар бирде: «Хәрби вә сәяси яктан үрнәк булган өлкән сержант ничек һәм нинди шартларда атып үтерелгән? Зартдинов атканын үз күзләрегез белән күрүче булмадымы? Атып үтерүче кемнендер заданиесен үтәмиме? Казармадан югалып йөрмәдеме? Советлар властена, даһи Сталинга каршы сөйләмиме? Кулак токымыннан түгелме?..» Сораулары—безгә, ә җавап үзенеке: «Рядовой Зартдинов гаепле!» НКГБист шулай дип әйтә икән, солдатлар да, сержантлар да, офицерлар да аның дәлилләренә каршы дәлилләр таба алмыйлар. Сизгер күңелем белән килешеп үк бетмәсәм дә, авызга су капкандай мин дә яши бирәм: солдат хезмәтенең башы гына бит әле, кеше рәтле аякка чолгау чорный, гимнастеркага ак яка да тегеп куя белмим, атканда пуля да «сөт артыннан киткәли». Ә менә Хәмидулла, кораллар склады янында сакта торганда, кешене дә атып үтергән: ялгышмы, язмышмы?.. Хәмидулланы төрмәгә утыртырлар микәнни? Ә бит ул өч тапкыр: «Тукта! Кем килә?»—дип кисәтү ясагач кына, кат-кат пропуск белән парольне сорагач кына, билгесез кешегә аткан. Үзе шулай ди. Аклану өченме, дөресе шулаймы?..

Йокы ястык сорамый... Бу тәгаен солдат йокысы хакында әйтелгән. Салам белән тутырылган матрацны каз мамыгыннан эшләнгән йомшак түшәктәй хис итәсең. Изрәп йоклаганда чал чәчле әниең вә акбүз аттай чабып, балачагың төшенә керә...

—«Рядовой Зартдинов, сине сержант Головач чакыра!»—дигән дневальный тавышына уянып киттем дә, Хәмидуллага төрттем:

—Уян!

—Кем чакыра, «Смерш»мы?

—Юк, ул түгел, сержант Головач.

Сукрана-сукрана киенде дә, Хәмидулла китеп барды. «Кешене нинди тәмле йокысыннан уятты. Головачка солдат йокысы жәл түгел. Ә бит икмәк, ботка, шикәр, тәмәке ... шикелле солдатка йокы да үлчәүле... Ни дип аны Головач чакырды икән? Татлы йокысын калдырып, казармага төн уртасында «Смерш» килеп йөрмәс».

Шактый вакыт узгач, Хәмидулла кире әйләнеп килде.

—Винтовканы пирамидага куйганда затворын ябып калдырганмын,—диде ул.—Головач шуңа чакырткан. Гауптвахтага утыртам, ди.

—Борчылма, авылдаш. Әле ант бирмәгән солдатны гауптвахтага утырта алмыйлар.

—Алайса, ни өчен Головач Сиражи белән синнән, рөхсәтсез базарга барганыгыз өчен, өч көн, өч төн бәрәңге әрчетте?..

—Бәрәңге әрчү белән гауптвахтада утыру—жир белән күк арасы.

[1]«Смерш»—Смерть шпионам! («Шпионнарга үлем!»)—дигәнне аңлата. Хәрби контрразведка.

Шәхсән мин үзем бәрәнге әрчүне җәза дип санамас идем. Ул эшне мин өйдә чакта күп башкардым. Вакланмыйк!.. Йокла, төн карчыгасы!

Хәмидулла берничә минуттан гырылдап йокыга китте: «генерал-йокы» аны үз канаты астына алды. Иртәгә солдат түземлерәк, сабыррак булып уяныр кебек иде. «Дөрес уйлыйсың»,—дигән сымак Хәмидулла йокы аралаш елмаеп куйды. «Хәерлегә генә булсын иде!»,—дидем мин, төшендә елмайган—өнендә елый дигәнне балачактан әнидән ишеткәнгә. Мин дә йокыга талдым...

Икенче көнне, иртәнге аштан соң, политинформация тынламыйча, хәрби дәрәҗәсе подполковник булган врач-терапевтны җирләргә киттек. Модель террорчылары үтергән дип уйлаган идек, алай булып чыкмады, үпкә авыруыннан үлгән икән. Йөзе лимон шикелле сары булса, борыны урыс язучысы Гогольныкы кебек очлы иде. Хәшәрәт микроблар үпкәсен кәрәздәй тишкәләгән, янәсе. Табибны җирләү мина начар тәэсир итте. Болай да салынкы күңел сүнде дә китте. Үпкә авыруыннан вафат подполковник—хәрбиләрдән, күзләрем белән күргән, кулларым белән җирләгән беренче кеше иде. Атып үтерелгән өлкән сержант, диверсантлар бәкегә салган зенитчы кыз турында ишеткән генә идем. Ә бу мәетне күрдем, үз кулларым белән табутны урнаштырдым, өстенә туфрак салдым, коралдашлар белән бергә, өч тапкыр һавага салют бирдем. Өерләре белән диверсантлар йөргәндә, урамнарда, урманнарда бер гаепсез кешеләргә ерткычларча ташланганда, ничекләр итеп җир-ана кочагында ятарга мөмкин?! Сизәм, Модель башкисәрләре белән көрәш башлана гына, кыскасы, безнең аяк астындагы җирне ут-ялкын чолгап алмагае? Энкавэдист өчен һәр диверсант тере мина ул...

Туганнар зиратыннан кайтканда мине сусау басты. Берәр йортка кереп, су сорыйсы гына иде дә бит, кертмәячәкләр, без—мылтыклы өчен ишекләр бикле. Аннары сержант Головачтан сорыйсы бар ә, ул, кире беткән хохол, рөхсәт итмәячәк, юк, итмәячәк! Ялыну солдатка килешми, хәер, андый сыйфат мина элек тә ят иде, хәзер дә ят.

Урам буйлап барганда, каршы килүче бер атлы күренде, олауда зур мичкә. Олаучының өстендә җылы тун, башында йолдызлы бүрек, аягында обмоткалы ботинкалар, кулында кыска чыбыркы.

—Взвод, унга!—дип кычкырып салды Головач.

Без—сафтагылар бер кеше булып уң якка чигендек. Узып китте дигәндә генә, мин олаучыны танып алдым: эшелон белән килгәндә егетләрне өркеткән, кулыннан таяк төшмәгән: «Таяк-генерал» иде бу! Ә бит аны мин олы бер командир дип уйлаган идем ул чакта. Су ташучы атын туктатып, мичкә өстендә утырган килеш, Головач белән гәпләшә башлады:

—Чак кына исән калдым, диверсантлар атты. Үземә пуля тимәде, ә менә мичкәне тиште. Агачтан иде, бусы тимердән, очучылар бирде. Инде снаряд тимәсә, пуля тишә алмас. Котла син мине, сержант Головач. Штаб башлыгы үзенең боерыгы белән өйгә кайтып килергә ун көн отпуск бирде. Бәлки, минем урынга вакытлыча бер кеше табарсың. Үзең дә беләсең, безнең бригаданың «кукуризниклары» бар. Разведка өчен гаять файдалылар дип сөйлиләр. Шул «кукуризниклар»га су ташыйм да инде мин...

Без атлап киттек. «Таяк-генерал», тун якасын күтәргән килеш, тимер мичкә өстендә утырып калды...

4

Ниһаять, һәр солдат байрак үбеп, Ил-Ватанга тугрылыклы булып хезмәт итәргә ант итте. Инде фронтка китүне көтә башладык: атакайлар белән бергәләп, безнең дә Берлинны аласыбыз, рейхстагка Җиңү байрагын кадыйсыбыз килде. Бүген-иртәгә әлеге «бозау» вагоннарына төялеп, фронтка юл тоттык дигәндә, һич тә көтмәгәндә,

казармада бик тә күңелсез бер хәлгә дучар булдык. Сержантлар, ягъни отделениеләрнең командирлары, помкомвзводлар-взвод командирларының ярдәмчеләре, фронтка китү уңае белән, офицерлардан яшерен мәҗлес оештырганнар. Шунда салмыш сержантлар арасында җәнҗал купкан, үзара йодрык сугышы башланган. Сержант Головач биш кешегә каршы берүзе сугышкан. Шуңа кадәр барып җиткән ки, алтысы да сапер көрәкләре белән «коралланып», бер-беренә һөҗүм иткәннәр, сугыша-сугыша канга батып беткәннәр. Тикмәгә: «Исереккә дингез тубыктан»,— дип әйтмиләр икән шул. Бүлмәгә капитан Федорчук кереп, пистолеттан өч тапкыр түшәмгә аткач кына... әлеге исерекләр үзара сугышуны туктатырга мәҗбүр булганнар. «Смерш» килеп җиткән, алты сержантны да үзе белән алып киткән. Өч тәүлек көттек аларның казармага кайтуын. Дүртенче тәүлектә бишесе кайтты, ә сержант Головач күренмәде. Безнең отделение командирсыз калды. Командир вазифаларын мина үтәргә туры килде. Бу бары тик өч тәүлеккә сузылды, аннары Головач казармага кайтып керде.

—Мин югала торган хохол түгел,—диде украинлы Головач.—Калачтан Луганск шәһәренә тикле җәяүлеләр юлын үттем, генерал-лейтенант Лелюшенко җитәкләгән армия сафларында Харьков юнәлешендә «Райх», «Адольф Гитлер», «Үле баш» дивизияләренә каршы йөзгә-йөз килеп сугыштым. Безнең батальон белән янәшәдә генә полковник Людвик Свобода җитәкчелегендәге чехлар батальоны хәрәкәт итте. Көньяк-Көнбатыш фронтының сәргаскәре, армия генералы Николай Федорович Ватутин иде. Ровно өлкәсенең Кременец урманнарында Модель өерләре белән аяусыз көрәш алып бару ниятеннән, уналтынчы укчы бригада, шул исәптән безнең аерым 203 батальон да, Ровно-Сарны якларына китерелде. НКВД гаскәрләрен Мәскәү аша Беренче Украина фронтының яңа сәргаскаре, армия генералы Николай Ватутин сорап алды. Күп тә үтмәде, мәкерле диверсантлар фронт сәргаскәрен, засададан яшерен атып, каты яраладылар һәм үлемгә дучар иттеләр. Бу һәлакәткә кадәр фашистлар разведчик Николай Кузнецов башына җиткәннәр иде. Гауптвахтада утыручылар әйтүенчә, Беренче Украина фронтының яңа сәргаскәре, Советлар Союзы Маршалы Георгий Константинович Жуков әмере белән, Кременец урманнарында яшеренүче диверсантларга каршы, сугыш операцияләре башланачак икән...

—Юк, минем рейхстагка байрак кадыйсым килә,—диде Зартдинов.

—Фриц үзенә штык белән кадаса нишләрсең?

—Миңа барыбер, минем язмыш «смирт» кулында.

—«Смерш» кулында диген.

—Төшенкелеккә бирелмик!—диде сержант Головач, хром итекләрен шыгырдатып.—Шулай да йә Камчатка, йә гүр-шахта!

—Штрафниклар ротасын оныттың, иптәш сержант.

—Урыслар әйтмешли, анысы в уме,—дидем мин.

—Хәтердә саклаганнары дисенме, алары күп инде,—диде Зартдинов.

—Бәлки, берсен әйтерсең?—диде сержант.

—Соныннан,—диде Зартдинов.

—Соңыннан икән, соңыннан...

5

«Тревога-а-а!» Йокыдан уянып, мин тиз генә киендем дә, пирамидадан винтовканы алып сафка бастым: «Нәрсә булды икән?»

—Гадәттән тыш вакыйгага!—диде борчылуы йөзенә чыккан Головач.—Рядовой Зартдинов югалган. Дневальный әйтүенчә, ул ишек алдындагы бәдрәфкә чыккач, казармага кире әйләнеп кермәгән. Без аны җир тишегеннән булса да эзләп табарга тиешбез! Исән икән, ул үзе кайтыр.

Кем белсен, бәлки кайта да алмас. Үзегез дә беләсез, әле кайчан гына зенитчы кызларда матәм булган иде. Мәрхүмә каберенең өстенә яна кар да яумаган...

Безнең отделение ике төркемгә бүленеп, хәбәрсез югалган солдатны эзләргә керешге. Бер төркеме үзенең билгеләнгән юнәлеше белән китте, ә без—алты гаскәри, әлеге Головач житәкчелегендә, телеграф баганалары буйлап урманга юл тоттык. Шом салып тимер чыбыклар шаулый, баганалар гүли, алар әйтерсең лә Хәмидулланың югалуы турында тирә-якка хәвефле хәбәр тарата.

«Шаулый чыбык, гүли баганалар,
Бездән хәбәр көтәдер аналар»,—

дигән шигъри юллар хәтергә килә.

«Хәмидулла табылмаса, әнисенә ни дип кенә язармын икән?..» Уйлана-уйлана урманга керүебезне сизми дә калганмын. Һәр агач шикле, кемдер атып жибәрер дә, күкрәкне тотып, жир өстенә егылырсың-аварсың кебек. Шунар жирдәге чыбык-чабыклар сынмасын дип, фашистлар синең аяк тавышыңны ишетмәсен дип, саклык белән атлыйсың. Ай бер калка да бата, тагын калка да тагын бата. Ә син прожектор нурлары сымак агачлар арасыннан үтеп кергән яктылыкны эзлисең.

—Ай чыкты,—диде биш чакрымнан артык ара узып та бер генә сүз дә әйтмәгән Головач.

—Чыкты,—диделәр егетләр, сержантка кушылып.

Күрәсең, яктылыкка бер мин генә түгел, ә командир да, коралдашлар да сөенә иде.

—Зартдиновны әйтәм, бәлки, табылыр?—дидем мин.

—Кем белсен?—диде Головач.

—Табылсын гына иде инде, Зартдинов коралдашым гына түгел, минем авылдашым да бит әле.

—Ул үзе качмадымы икән?—диде чуаш Кибек.—Бәлки Зартдинов дезертирдыр?

—Бер казаннан ашаган иптәшенә шулай әйтергә ничекләр итеп синең телең бара?—диде Сиражи Имамов.

Эзли-эзли аяктан егылырга житеп, урманда йөрдек, сазлыкларда фашистларның берничә шалашы да табылды. Күнелләр төшенке иде, беркемнең дә гәпләшәсе килмәде. Шәхсән минем ашаган сосискам тамакка, гүя таш булып утырды. Безнең белән радист та бар иде, частьтән: «Кайтырга!»—дигән депеша килде.

Кайтырга чыктык, аякларның тыңлыйсылары килми, гүя озын чандыр гәүдәле Хәмидулла үзенә таба аркан белән арттан тарта иде. «Армия сафларына алынгач, күз алдында тазарып киткән егетне фашистлар бөктеләр микәнни, ә? Ышанасы килми, юк, килми!» Коралдашларымнан алдарак мин уйланып бара идем, күзләремә жир өстендә яткан бернәрсә чалынып китте: «Бүрек түгелме соң бу? Әйе, бүрек!» Теләр-теләмәс кенә бүрекне иелеп алдым: «Солдат бүреге, кайдан, ничек, кем ташлаган?» Жентекләп карарга керештем: «Х. З.»,—дип, ак жеп белән жөйләнгән ике баш хәрефне укыгач: «Хәмидулла!» дип, бар тавышка кычкырып жибәрдем.

—Ни булды, рядовой Латыйпов?—диде Головач.

—Менә!—дидем мин, сержантка кызыл йолдызлы бүрекне тоттырып.

—Нинди бүрек?

—Күрмисезмени, солдат бүреге.

—Кайдан килгән?

—Анысын әйтә алмыйм, ә менә бүрекнең эчендә «Х. З.» дип ике баш хәреф жөйләнгән.

—Димәк, рядовой Зартдиновны әлеге диверсантлар урлаганнар!—диде Имамов.

—Качканда бүреген башыннан төшереп калдырган булса, нишләрсең?—диде Кибек.

—Рядовой Зартдинов шушы тирәдә булырга тиеш,—диде сержант, бүрекне кулында әйләндергәләп.—Ул йә урманда, йә хуторда.

—Үтергән булсалар?—диде рядовой Князев, ниһаять, сүзгә кушылып.

—Авызыңнан җил алсын!—дидем мин. Ә үзем уйга калдым: «Аh, Хәмидулла, беләсе генә иде: исәнме син, үтерделәрме әллә? Нинди генә үлем белән үлдең икән?»

—Юк, рядовой Зартдиновны эзләп тапмыйча кайтмыйбыз!—диде Головач һәм кәгазь кисәгенә язып радистка сузды:

—Хәзер үк тапшыр!

—Тынлыйм.

«Ике тәүлек торкарланырга рөхсәт!»—дигән җавап алынды частьтән.

Энгер-меңгер вакыт иде, урман аша турыдан-туры утарга киттек.

—Өйдә жылынып чыккач, эзләүне дәвам итәрбез,—диде Головач.

Хужа хатын безне якты чырай белән каршы алды: шпиг ашатты, жылы сөт бирде. Диверсантлардан зарланып елый-елый сөйләде ул. Төнлә килеп, ана дуңгызын урлап киткәннәр икән.

—Шпигны ашагыз, тегеләр сизсәләр, үземә бер калжа калдырмыйча алып китәчәкләр. Ичмасам, сез-егетләргә булсын. Сезләрне күргәч, үз улымны күргән кебек булдым, ул да солдат. Өченче Украина фронтында сугыша, менә хатлары!—Гитлер башкисәрләрен әйтәм, яшәргә ирек бирмиләр, каһәр сукканнар! «Без яңа тәртип урнаштырачакбыз!»—дигән булалар, ә үзләрен котырынганнар диярсең: ана димиләр, бала димиләр—төнлә килеп үтерәләр, суялар, асалар...

—Үзләре генә түгел алар, аларга полицайлар да булыша,—диде жылы мич башында утыручы чал сакаллы карт.

Инде тукланганнан соң, тәмам сөякләрне жылыткач, хужабикәгә рәхмәтләр әйтә-әйтә чыгып киттек.

—Хәерле юл сезгә, тагын килегез,—дип озатып калды хужа хатын.

—Рәхмәт, анакай,—дидем мин.

Утарлар аша, Головач артыннан казлар шикелле ияреп, авыл советына киттек. Без килеп кергәндә, анда өч кораллы кеше утыра иде.

—Кайсыгыз голова[1] була?—диде сержант.

—Мин,—диде кара мыеклы кеше, урыныннан торып.

—Таныш булыйк, чекист-разведчик, фамилиям Головач,—диде сержант.

—Яхшы, безнеңчә, әйткәндә, добре,—диде авыл советы рәисе.—Нинди йомыш белән килдегез?

Командир аңлатып бирде.

—Сезгә мин озатучы бирә алам,—диде голова, үз каршысында утырган озын чәчле, сакал-мыек баскан берәүне күрсәтеп.—Фамилиясе Кульбака. Бригаденфюрер СС Модель башкисәрләреннән качкан, әнә кулында автоматы да бар.

Сөйләшә торгач, Кульбаканың абыйсын бригаденфюрер СС Модельның адъютанты үз кулы белән атып үтергәнлеге беленде.

—Нәрсә өчен?—диде Головач.

—Боерыгын үтәмәгәне өчен... Төнлә белән полицайлар ярдәмендә Модель башкисәрләре кызыл погонлы бер солдатны урлап кайттылар: өстендә шинель, аягында обмоткалы ботинка, яланбаш... Обер-лейтенант солдаттан сорау ала башлады: частьтә ничә солдат бар? Кораллар нинди?.. Офицер күпме сорау бирсә дә, солдат авызына су капкандай дәшмәде. Инде яхшылык белән телен ачтыра алмагач, Модельның адъютанты үтергәнче кыйнады, аннары тагын сорау алырга керешә. Ә солдатның җавабы бер булды: «Белмим!» Модель полицай абыйга солдатны җәзаларга кушты.

—Нинди җәза иде соң?

---

[1] Голова—башлык, рәис *(укр.)*.

—Әйтсәм, кеше ышанмаслык жәза! Беләсезме нинди жәза: солдатның күзләрен сукырайтырга боерды абыйга офицер.

—Әйе, сукырайтырга,—диде Кульбака.—Юк, ерткыч түгелмен, ә кешемен һәм кеше булып калырмын дип, абый фашистның боерыгын үтәүдән баш тартты. Ә син шулаймыни, алайса, үзен теге дөньяга кит!—дип, обер-лейтенант абыйга атты. Йөрәген тотып абый идәнгә ауды. «Абыйны нишләттен?»—дип, фашистка ташлангач, ул мине келәткә бикләргә кушты... Һәм, без сакчы белән бер сүздә булып, икәү качтык. Полицай абыйның вафат булуын әнием белми әле.

Кульбаканың күзләреннән яшьләр тәгәрәде.

—Сабырлык, хлопец икәнсен, шулай булып кал,—диде Головач.

—Мин дә шуны теләр идем,—диде рәис.

—Димәк, сез качканда теге егет исән иде?—диде сержант.

—Солдатны әйтәсезме?

—Аны.

—Әйе, исән иде.

Урман аркылы Дубовка дигән утарга юнәлдек, куе наратлык башланды. Кульбака әйтүенчә, агачларның төбендә бункерлар—яшерен нәүрәпләр булу мөмкин. Аларда кораллар һәм ашамлыклар, шнапслар-эчемлекләр саклана икән, кораллары аерым, әлбәттә. Ниһаять, Дубовка утары күренде, урман кырыенда гына акшар белән агартылган бер хата тора, аннан йөз метр чамасы читтәрәк салам түбәле сарай һәм келәт иде.

—Әнә шул келәткә мине яптылар да инде,—диде Кульбака.

Без тиз генә келәтне һәм хата белән сарайны чолгап алдык. Головач кушуы буенча Кибек һәм Кульбака йортка, Князев сарайга юнәлде, ә без—сержант, мин һәм тагын ике солдат карт имән төбендә ятып калдык, минем кулда винтовка, ә кесәдә ракетница иде. Көтмәгәндә генә тукылдаткан тавыш ишетелде. «Нәрсә бу: тукран тукылдатамы, әллә аталармы? Юк, тукран тукылдатмый, пулемет белән автоматлар чираты бу!»

—Немецлар!—дип, атылып чыкты Князев сарайдан.

Безнең янга Кибек белән Кульбака йөгереп килде.

—Хужалар хата эчендә, ире дә, хатыны да,—диде Кульбака.

—Хәзер үк икесен дә чакырып кил,—диде командир.

—Ярый.

Алар килгәч, Головач хужалардан ничә фашист яшеренгәнен сорады.

—Белмим,—диде ире.

—Ә син?—диде сержант, инде хатынына.

—Юк...

Командир тагын иренә мөрәҗәгать итте:

—Бар әйт, бирелсәләр, исән калачаклар.

Хужа сарайга кереп китте, күп тә үтмәде, тагын мылтыктан аткан тавыш яңгырады.

—Хужаны аттылар булса кирәк,—диде Имамов.

Карчык та шулай уйладымы, карты янына ашкынды.

—Ярамый,—дидем мин, карчыкка безнен яныбыздан китәргә рөхсәт итмичә.

—Китсен,—диде Головач, мина ишарә ясап.

—Берәр хәл булса, әби, безгә рәнҗемә,—дидем мин.

—Рәнҗемәм.

Карчык укына-укына сарай эченә кереп югалды. Тирә-як кабер тынлыгына чумды. Кинәт, һава ярып, сарайдан аттылар.

—Аталар, әйдәгез җавап бирик!—диде Имамов.

—Сабырлык,—диде Головач,—сарайдан карчык чыксын.

—Бәлки, ул чыкмас та?—диде чуаш Кибек.

—Карчыкны әйтәм, солдат дип атып үтермәгәйләре,—диде Имамов.

—Немец карчыкны солдаттан аера беләдер,—дидем мин.

—Аермас та, сарайда дөм караңгы,—диде Кульбака.

Тагын аткан тавыш ишетелде.

—Нәрсә көтәбез, әйдәгез, ут ачыйк!—дидем мин.

—Кызма, рядовой Латыйпов, кызма,—диде сержант.—Акыл белән эш итәргә кирәк. Без монда алты бөртек кенә. Тагын бер кат әйтәм, акыл белән эш итәргә кирәк.

—Акыл белән эш итәбез дип, безне фашистлар үтереп бетерүләре мөмкин!

—Латыйпов хак әйтә,—диде Имамов.

Бу мине дәртләндереп җибәрде һәм үзем дә сизмәстән ракетницаны кесәдән алдым.

—Нишләмәкче буласың?—диде Головач.

Мин дәшмәдем, сөйләшәсем түгел, ә хәрәкәт итәсем килде: «Карт белән карчыкны, тәгаен, атып үтерделәр... Бәлки, Хәмидулла да шул сарай эчендәдер?» Мин сикереп тордым.

—Кая барасың?—диде командир.

—Сарайга!

—Атып үтерерләр.

—Үтерсеннәр, түземлегем бетте, күпме көтәргә мөмкин!

—Кирәк икән, тагын көтәрбез,—диде сержант.

—Соңгы тапкыр безнең ультиматумны белдерергә дә, ут ачарга!—диде Князев.

—Дөрес уйлыйсың,—диде сержант.

—Аның башы түгәрәк,—диде Имамов.

—Кемне генә җибәрик соң?—диде Головач.

—Мине!—дидем.

—Юк, ярамый,—диде командир.

—Миңа ярыйдыр?—диде Имамов.

—Юк,—диде сержант.

—Димәк, мин барам,—диде Князев.

—Син дә бармыйсың.

Барыбыз да Кульбакага текәлеп карадык.

Кульбака теләр-теләмәс сарайга юнәлде.

—Әйт, исән калырга телиләр икән, бирелсеннәр!—диде сержант.

—Гут,—диде Кульбака.

—Немец телендә сөйләшә булса кирәк,—дидем мин.

—Ипилек-тозлык маташтыра,—диде сержант,—ул хакта аның белән гәпләшеп алдым.

Үле тынлык урнашты, Головач миңа карап алды, ул бик тә борчулы иде: «Кем белсен, Кульбака фашистларга бирелеп, сарайдан безгә атар?!»

Шулчак сарайда аткан тавыш ишетелде. Пуля яндыра торган булып чыкты, салам түбә гөлт итеп яна башлады. «Тереләй янсалар да җәл түгел!»—дидем мин, мәлгуньнәргә нәләт укып. Янгын көчәйгәч, мин дә, яудашлар да коралларны кыса төштек: «Кача күрмәсеннәр, ике аяклы күселәр!» Салам түбә янып беткәч, ут сарайның үзенә күчте: патроннар, гранаталар шартларга тотынды.

Фашистлар белән безнең арада көчле атыш башланды. Сарай исә дөрләп яна бирде, кинәт көчле шартлау булды. Кызу ут ялкыны керфекләрне көйдерде, койрыклары утта пешкән—телгә алынган күселәр шикелле, бер-бер артлы, фашистлар атылып чыкты. Әмма чыккан берсе, берничә метр узган саен, җир өстенә тәгәрәде...

Сарай ишеге алдында рядовой Зартдиновның гәүдәсен күтәргән берәү күренде, без тынып калдык: «Кем булыр бу?»

—Атмаска!—дигән команда бирде сержант.

—Полицай Остап булам мин,—диде ул.

—Модель кайда?—диде Головач.

Полицай дәшмәде.

—Әйт, теленне йоттыңмы әллә?

—Модельның кайда икәнлеген төгәл әйтә алмыйм, ә сарайда фрицлар бар,—диде полицай.

Остап безне сарай эченә алып керде.

—Сарайда берәү дә күренми,—дидем мин.

Салам белән капланган бер урынны төртеп күрсәтте полицай:

—Менә монда алар, нәүрәптә...

Минем нәүрәп капкачын ачуым булды, автоматтан аттылар. Җиргә тезләндем.

—Ни булды?—диде Головач, беләктән тотып.

—Нәрсәдер күкрәккә тиеп китте...

—Имамов, рядовой Латыйповны сарайдан алып чык,—диде командир.

Сарайдан чыккач, Сиражи Имамов минем изүне ычкындырып җибәрде.

—Авыртамы?—диде Сиражи.

—Белмим,—дидем мин.

Озак вакыт үтмәде, минем янга ике кешене китереп салдылар.

—Кемнәр алар?—дидем мин.

—Берсе Хәмидулла Зартдинов, ә икенчесе Кульбаканың абыйсы,—диде Имамов.—Икесе дә үлгән...

6

Мине саклык белән генә чанага күтәреп салдылар: янымда Головач белән олаучы иде. Икенче чанада Хәмидулла белән өлкән Кульбака мәетләре һәм исән-аман радист... Олау артыннан әсиргә алынган өч диверсант, ике полицай һәм конвой белән аларны озата баручы минем яудашлар атлый.

—Латыйпов, хәлең ничек?—диде сержант.

—Үзем дә белмим.

—Иң мөһиме, төшенкелеккә бирелмә, әйтте диярсең, әйбәт булачак.

Еракта паровоз кычкыртканы ишетелде.

—Тимер юлга килеп чыктык,—диде сержант, куанып.—Станца моннан ерак микән?

—Ике чакрым чамасы,—диде олаучы.

—Поездны туктатырга кирәк,—диде Головач.—Яралы кешегә минуты да кадерле!

Головач, олаудан сикереп төште дә, поезд килгән якка йөгерде, кулында ракетница иде.

—Үткер кеше,—диде олаучы.

—Милләттәшең,—дидем мин.

—Әйе, хохол сынатмас!

Һавада утлы ракета күренде, аның артыннан тагын берсе ялтырады: «Головач ракеталары, поездны туктатырга сигнал бирә!»

—Поезд туктадымы?—дидем мин, олаучыдан.

—Юк,—диде ул.—Ишетмисеңмени, әнә нинди пышылдап килә, мунча ташына су салган сымак.

«Та-та-та!»—автомат очереды ишетелде. «Ни булды, монда да фашистлармы әллә?»

Головач йөгереп килде.

—Поездны туктаттым,—диде ул.

—Кайда, күренми ич?

—Урман эчендә, автоматтан атып туктаттым.—Әйдә, атыңны чаптыр!—диде Головач, олаучыга.

Олаучы атны йөгертә башлады.

—Туктат!—диде сержант.

—Ни булды?—дидем мин.

—Рядовой Имамовны үзебез белән алырга кирәк,—диде командир.—Ул сине озата барыр.

—Әсирләр качмасмы?—дидем мин.

—Качсалар, бирелмәсләр иде,—диде сержант һәм Имамовны чакырып алды.

—Утыр арбага.

—Тыңлыйм, иптәш сержант.

—Инде чаптырсаң да була,—диде сержант.

Олаучы атны салмак кына юыртты, чанада мин яралы кеше булгангамы, җан фәрманга чаптырырга кыюлыгы җитмәде.

—Тизрәк! Тизрәк!—диде безне күреп алган машинист,—расписаниедән чыгам.

—Товар поезды икән, ә мин пассажирларныкы дип уйлаган идем,—диде Имамов.

—Яралыны кайсы вагонга урнаштырыйк?—диде Головач.

—Өченче вагонга,—диде машинист.

Күтәреп керделәр дә, мине вагон идәненә салдылар.

—Йә хуш, рядовой Латыйпов,—диде Головач, поезд кузгалышлый вагоннан сикереп.—Сине мин Сарны госпиталеннән эзләп табармын.

Вагонда Имамов кына калды, командир кушуы буенча, мине ул госпитальгә кадәр озатырга тиеш иде. Головачтан аерылу миңа бик тә күңелсез булып китте: ул минем командирым гына түгел, ә якын кешем дә, элек моны мин ничектер сизмәгәнмен икән...

—Яраң бик сызлыймы?—диде Сиражи.

—Сызлый... Сиражи, син карап бар, без Сарныны узып китмик.

—Узмабыз, минем күзләрем үткен, көндез йолдызларны күрә.

Сиражи вагон ишеген ачты:

—Алда утлар җемелди, кич якынлаша.

Тагын күпмедер ара узгач, Сиражи:

—Килеп җиттек!—дип кычкырды.

Поезд туктагач, ул:

—Борчылма, мин хәзер әйләнеп киләм,—дип, вагоннан сикерде.

Берничә минуттан тышта:

—Солдат!—дигән тавыш ишетелде.

Минем җавап бирәсем килмәде, яра сызлый иде. Өч кеше вагонга сикереп менде: берсе Сиражи, ә икенчесе машинист иде, ә өченчесен танымадым.

—Командирың кайда?—диде машинист.

—Ул поезд барышында вагоннан сикереп калды,—дидем мин.

—Юбасар-р-р! Менә кем ул синең командирың,—диде машинист.

—Юк, ул чекист,—дидем мин.

—Хәер, иптәш комендант, аларның үз кануны,—диде машинист.

—Әйтәм дә яралы солдат товарныйга килеп эләккән,—диде офицер,—ә мин баш ватам.

Носилка күтәргән ике санитар-солдат вагонга менде.

—Кем яралы?—диде аларның берсе.

—Әнә ул,—диде офицер, миңа күрсәтеп.

—Иптәш майор, яралыны вагоннан, зинһар, тизрәк алып чыгыгыз, вакыты бик тә кадерле.

—Алайса, ни дип ләчтит сатасың?!—диде ачулы Имамов.

—Кем сата, минме?—диде машинист.

—Кадалып киткере!—диде Имамов һәм машинистны вагон ишегеннән төртеп төшерде.

—Алай ярамый,—диде комендант.

—Без—«әҗәлче»ләргә ярый!—диде Имамов.

—Нигә алай дип әйтәсең?—дидем мин.—Юк, син дә, мин дә «әҗәлче»ләр түгел.

—Ә бит дөресе шулай: сине яраладылар, Зартдиновны үтерделәр. Хуш! Исән булсам, килермен мин сине күрергә.

—Ә менә Хәмидулла килә алмас инде,—дидем мин.

7

Яра жинел булып чыкты, шулай да, госпитальгә китерелгән көнне үк, операция ясадылар, бәләкәй генә бер палатада икенче ай ятам. Үзем бирелдә, ә уйларым йә коралдашлар, йә туган як турында. Хәмидулланы жирләгәннәрдер инде, тәгаен өч тапкыр залп биргәннәрдер. Зенитчы кызны да шулай жирләгәннәр. Улы Хәмидулла хакында «кара язу» алган Мәликә апаның елый-елый күз яше беткәндер. Госпитальдән язган хатны алып укыгач, минем әни дә бик өзеләдер. Ишеткән булсалар, үзем укыткан укучыларым да борчыладыр. Әйткән теләкләрен үтәп булмады шул. «Абый, үзенне сакла!»—дигәннәр иде алар, саубуллашканда. Головачны әйтәм, һич тә күнелдән китми, кара кашларын сикерткәләп һаман күз алдында тора. Сиражиның хәлләре ничегрәк икән? Күрергә киләм дисә дә, никтер килә алмады. Машинист белән дорфарак кыланды, шәхсән минем үземә аның вагондагы тотышы ошамады. Әҗәл белән беренче тапкыр йөзгә-йөз килү үзенә шулай нык тәэсир иттеме?.. Модель адъютанты тарафыннан атып үтерелгән туган абыйсын Кульбака кайда жирләде икән? Аның берничә башкисәре әсиргә эләкте, ә обер-лейтенант үзе кайда?.. Капитан Федорчук ничек яши икән?.. Бүтән яудашлар да күренми, кош теледәй булса да үзләреннән хат-хәбәр дә юк, маршал Жуков боерыгын үтәп, соңгы сугыш операцияләренә әзерләнәләрдер. Шулай булмаса, берәресе күренер иде... Палата ишеге шар ачылгач, уйларым бүленеп калды, күрше койкага берәүне кертеп салдылар: башы, бите, гәүдәсе, аяклары бинт белән чорналган, ике күзе генә күренеп тора.

—Кем ул?—дип сорадым мин шәфкать туташыннан.

—Танкист, немецлар минасына эләккән.

—Кайсы милләттән икән, белмисенме?

—Казакъ бугай...

Казакъ егете ике тәүлек аңсыз яткач, өченчесендә эчәргә су сорады. Аннары аны шәфкать туташы кашык белән ашата башлады, тора-бара үзенә жан керде. Мин моңа бик тә сөендем, катнаш татарча, катнаш казакъча сөйләшә, гәпләшә башладык. Ул Сарныда танкистларның резерв полкында хезмәт итә икән, кырга өйрәнүгә чыккач, диверсантлар минасына эләгеп танк эчендә янган, инде фронтта бер тапкыр яраланган булган.

—Диверсантлар белән читенрәк, идән астыннан эш итәләр,—диде танкист.

—Әйе, аларны «Ура!» кычкырып кына жинеп булмый...

Бер-беребез белән туган телләрдә гәпләшкәнгәме, койкаларыбыз чат янәшәдә булгангамы, казакъ егете белән без тәмам дуслашып киттек, хәтта йоклаганда бер кулымны аның күкрәгенә куеп йоклый идем. Җәрәхәтләре каты сызлаганда да, әрнегәндә дә ул: «Кулынны ал»,—димәде. Шуна барып житте ки, күкрәгендә минем кул жылысын тойса гына йокыга китә иде. «Палатада суык, туңдыра»,—дигәч, казакъ егетен мин кочаклап йоклый башладым. Ә менә башы ак бинтлар белән чолганганга «аның чәчләре бөдрәдер»,—дип уйлый идем.

Иртән күрше палатадан култык таяклы берәү килеп керде дә:

—Егетләр, уяныргa вакыт,—диде.

—Мин йокыдан уяндым, син дә уян,—дидем мин, казакъ егетенә.

Ләкин ул жавап бирмәде.

Санитарлар танкистны палатадан носилка белән алып чыктылар, ул үлгән иде.

Палатада япа-ялгызым калгач, шәфкать туташыннан качып-посып кына коридорда йөри, күрше палатага керә башладым...

Беркөнне иртән күзләремне ачып карасам, теге казакъ егете койкасында берәү ята иде.

—Кем ул?—дидем мин, шәфкать туташына, палатага кергәч.

—Кем дип әйтим, синең шикелле бер яралы,—диде шәфкать туташы елмаеп кына.—Хәер, йокыдан уянгач, үзеннән сорарсың, яралылар тиз таныша.

Ашханәгә килдем.

—Синең дә күршең булган дип ишеттем,—диде минем белән бер өстәлдә тукланучы яралы карт солдат.

—Әйе, инде палатада күңеллерәк булыр.

—Булыр микән?

—Нигә алай дисең?

Безнең өстәлне яралылар сырып алды.

—Ник дәшмисең?—дидем мин, яралы карт солдатка.

—Бик беләсең киләме?—диде карт солдат, хәйләкәр елмаеп.—Алайса, әйтим инде, моны синең иртәрәк белүең яхшырак. Синең янына немецны урнаштырганнар!

—Үзең мыеклы, ә юк сүз таратасың,—дидем мин.—Немецны ничекләр итеп солдатлар госпиталенә урнаштырсыннар?

—Урнаштырганнар шул, миңа ышанмасаң, баш врачтан сора.

Иртән безнең палатага дәвалаучы хирург белән баш врач керде.

—Кәеф-сафалар ничек?—диде хирург.

—Шәптән түгел.

—Нигә алай дисең? Минем уемча, тиздән син сафташларың янында булачаксың. Йә, күлмәгеңне сал әле, яраң ничек икән?

Хирург җентекләп яраны карарга кереште, ә минем уемда, тәнемдәге ярадан битәр, бер палатадагы фашист иде: «Шулай ук минем күрше койкада ятучы дошман микәнни? Бу турыда ничек кенә белергә соң? Авыз ачып баш врачка бер сүз әйтсәң, тегенең ишетүе мөмкин, юри йоклаган булып кыланадыр әле!»

—Кәеф шәптән түгел дигән буласың, яраң ябылып килә, йөрәк тә әйбәт тибә... Күршеңнең хәле ничегрәк?

—Үзен тотышы, палатадагы тәртибе?—диде баш врач, мине дәвалаучы хирургка кушылып.

—Ә кем соң ул?—дидем мин, ниһаять, сорарга батырчылык итеп.

—Кем генә булмасын, безнең өчен барыбер, чөнки без—табиблар,—диде баш врач.

—Карл Маркович, сез немец телен беләсез, сорагыз әле, операциядән соң авыру үзен ничек хис итә икән?—диде баш врач.

Хирург күрше койкадагы авыру янына килеп, немец телендә берике җөмлә әйтте. Авыру дәшмәде.

—Ә моның хәле чыннан да шәптән түгел,—диде хирург.

—Тамагына ашыймы соң?—диде баш врач.

—Үзе ашый алмый, шәфкать туташы ашата...

Берничә тәүлектән соң, бер палатада ятучы бәндә турында миңа шулар ачыкланды: чыннан да ул милләте белән немец, Идел буенда туып-үскән немец түгел, ә Алман немецы. Госпитальгә үзен партизаннар китергәннәр, шәһәр шифаханәсенә салсак, төнлә килеп, аны яудашлары үтерерләр, андый очраклар булгалады дигәннәр.

Ун көнгә якын немец белән бер палатада яшәргә мәҗбүр булдым. Икенче палатага йә аны, йә мине—икебезнең берсен күчерегез дип сорап-ялварып та карадым, әмма баш врач мин әйткәнне колагына элмәде. Немец биш тәүлек урыныннан тора алмыйча ятты. Шәфкать туташы, каршысына утырып, үз кулыннан ашатты. Ә мин исә, җаны көйгән чакта, немецны су белән «сыйлый» идем, бик тә инде ялварып сорый иде ул, кем әйтмешли, кеше түгел, таш булса, таш та эрер. Кайчагында мин аның дошман икәнлеген оныта да идем, тик авылдашым Хәмидулла күз алдына килгәч кенә, уянып китеп, нәфрәт дингезенә чума идем...

8

Минем өчен көтеп алган көн килде, госпиталь белән саубуллаштым. Сарны урамына чыккач, үземне яна тугандай хис иттем: язгы һаваны сулап туя алмыйм! Алай гынамы сон? Шатлыктан «Ура!» кычкырасым килә: күнел күр, рух күтәренке. Ә шулай да госпитальдә ятып тәмам хәлсезләнгәнмен, аякларда көч-дәрман бары тик гәүдәне күтәрерлек кенә. Штабка килдем, анда: «Капитан Федорчук взводы вакытлыча Рафаловкада»,—диделәр. Сарны-Ровно поездына утырып, Рафаловка шәһәрчегенә юл тоттым: вагонда түгел, ә анын түбәсендә, билет алып булмады. Шулай итеп, мин «куян хокукы»нда поездда кайтам, сагаям: поезд туннельне чыкканда баш бәрелүе мөмкин. Вагон түбәсеннән күреп, диверсантларнын атып төшерүләре дә ихтимал. Атсалар, пуля тиеп, жиргә кош сымак кадалып төшәрсен! Язгы янгыр сибәли, дөресрәге, ул юеш кар белән катнаш, битне уттай яндырып ала, ә үзе су...

Взвод урнашкан агач йортнын бусагасына аяк баскач, ин беренче очраткан кешем—сержант Головач булды. Мине күрүгә ул:

—Вакытында кайттын,—диде.

—Шулай була күрсен.

—Штрафниклар белән бергәләп һөжүмгә әзерләнәбез. Тиздән Кременец урманнарына бәреп керәчәкбез.

—Фашистлар берәм-берәм үтермәсәләр?!

—Анысы безнен үзебездән тора. Кем пан булып киткән, кемнен башы беткән!

—Имамов та шулай дип әйтергә ярата иде.

—Нигә «иде», рядовой Имамов исән-аман. Мәкалыгә килгәндә, ул да көн-төн шуны кабатлый, яхшыга гына булсын иде. Хәтта вак-төяк сугышчан операциягә чыкканда да бәхилләшә. Хәер, штрафниклар—«әжәлче»ләр батальонында да үләргә беркемгә дә сон түгел. Рядовой Зартдинов әнә «Смерш»тан үлеп котылды, ә әжәлдән котыла алмады. Үзен музыка белән жирләдек, өч тапкыр салют бирдек. Ә Кульбака үз абыйсын туган авылынын зиратына күмгән... Госпитальгә сине күрергә барып булмады, гафу ит, кинәттән безнен взводны Сарныдан бирегә күчерделәр. НКВД наркомы урынбасары генерал-полковник Аполлоновтан шундый әмер килде. Штраф батальон белән без—энкаведистлар эш итәргә тиеш икән.

—Штрафникларга ышанмыйлар, күрәсен.

—Мин үзем дә шулай уйлыйм. Сынатмасак иде.

—Сынатмабыз, иптәш сержант.

—Күнелен күтәренке күренә, димәк, яран төзәлде?

—Төзәлде, ингә терәп винтовкадан атарга да мөмкин. Әйе, машинистны куркытыр өчен генә түгел.

—Ул шаярулар өчен мина чак кына эләкмәде. Комбат үзенә чакыртты, капитан Федорчук коткарып калды. Шулай итеп «Смерш»ка барып житмәде. Рядовой Имамов өстеннән шикаять килде. Ничекләр итеп машинист безнен фамилияләрне белгән? Шаккатам.

—Жил исеми салам селкенми.

—Монын белән ни әйтмәкчесен?

—Минемчә, машинист белән булган низагны Имамов кемгәдер сөйләгән. Үзе белән булганны дип әйтүем. Ә инде, иптәш сержант, сезнен автоматтан атып паровозны туктату турында мин госпитальдә дә ишеттем. «Теге сержантлар белән сугышкан сержант Головачмы?»—дип миннән дәвалаучы хирург та сорады.

—Ә син нәрсә әйттен?

—Безнен частьтә Головачлар әллә ничәләп, тәгаен әйтә алмыйм,—дип жавап бирдем.

—Ул хирург белән танышмын, яра ачылганда ана күренәм.

—Сез дә яралымы?

—Әйе, Харьков тирәсендә яраланган идем, кыр госпиталендә нәкъ егерме бер көн дәваландым. Медицина капитаны Карл Маркович Вейхерман сафка бастырды. Сул яктагы калак сөягеннән алынган пуляны истәлеккә саклыйм. Күрсәтимме?.. Менә ул, немец «ядкаре»! Шул «ядкарь» аркасында миннән яраткан кызым баш тартты да инде.

—Ничек ул алай?

—Головач сугыш кырында бер аягын өздергән дигән ялган хәбәр таралган. Гарип белән яшәргә теләмим дип, минем вәгъдәләшкән кызым фронттан качып калучы, үзеннән шактый олы яшьтәге бер кешегә кияүгә чыккан. Шулай итеп, кыр госпиталеннән кызга язган хатым соңгысы булып чыкты. Белгәнемчә, синең дә авылда мәхәббәт тоткан кызың бар. Яраңны аңа белгерттеңме?

—Юк! Мин үземне яралы дип санамыйм ла.

—Санама да, белгертмә дә. Белгертсәң, гыйшык тоткан кызыңнан колак кагуың ихтимал. Шулай да, Җир-Ананың да колагы бар. Имамов белгерткән булса нишләрсең?

—Ничек?

—Хат язып, әлбәттә. Син госпитальдә чакта анарда мин сөйгән кызыңның фотосын күрдем. «Менә минем чибәркәем»,—дип масаеп йөрде. Мәйтәм, син аны чәлгәнсең, чөнки фотоның артында: «Сөеклем Кави, син мине онытма, мин сине онытмам»,—дип язылган иде.

—Ә Имамов ни дип җавап бирде?

—Ык-мык итте, чөнки ялган икәнлеге аның йөзенә чыккан иде.

—Ә мин ул фотосурәтне югалттым, Модель бандасы белән сугышып йөргәндә, яралангач, минем куен кесәсеннән алган ул аны. Госпитальгә эләккәч, юклыгын белдем.

—Кире алырга кирәк ул фотоны. Чакыртыйммы үзен?

—Хәзер кирәкмәс, башка вакытта...

—Анысы үз эшең... Әйткәнемчә, Сарныда машинистны вагоннан этеп төшергән ул Имамов. Часть командиры исеменә комендатурадан да рапорт килгән. Әҗәл белән ничә мәртәбә йөзгә-йөз килеп тә үземне мин «әҗәлче» дип санамадым. Ә Имамов үзен «әҗәлче», ди.

—Язмыштан узмыш юк,—дип әйтә иде минем әнием. Шулай булгач, сезнең ярагыз да немец «ядкаре» түгел, ә язмыш ядкаре.

—Фәйләсуф син, Латыйпов. Яраң тиз төзәлүенә мин шат. Ә капитан Федорчукка килгәндә: «Рядовой Латыйпов яраланды»,—дигән хәбәрне кайтып әйткәч, борчылды ул. Госпитальгә сине күрергә дип җыенып йөргәндә, аны, махсус задание белән, командование каядыр җибәрде. Үзеннән сорагач, ул: «Хәрби сер!»—диде кыска гына. Инде взвод өчен бар җаваплылык минем өстә... Бүген ял ит, мунча кер, ә иртәгә күз күрер! Ә мин яңа комбат Шәкүров янына киттем, Кременец урманнарында барган сугыш операциясендә безнең берләштерелгән батальон белән ул җитәкчелек итәчәк. Дневальныйга күз-колак бул, йоклап китмәсен. Әлеге Имамов ничә тәүлек инде тоташ шул вазифаны башкара. Гафу ит, әйтергә онытканмын, сиңа хат бар. Дневальный тумбочкасыннан кара. Иртәгә кадәр...

Икенче көнне сержант Головач мине үзенә чакыртты.

—Рядовой Латыйпов сезне тыңлый,—дидем мин, үрә катып.

—Вольно,—диде сержант.—Капитан Шәкүровның тән сакчысы буласың киләме? Теләсәң, тәкъдим итәм. Ләкин көчләмим, үз ихтыярың.

—Ә ни өчен пехота капитанын чекист сакларга тиеш? Инде «кыр патшасы»—пехота үз-үзенә хуҗа түгелмени? Югары командование штрафниклардан шикләнәме әллә?

—Юк, шикләнми, һөҗүм барышында командирны саклау таләп ителә.

—Анысы шулай, сакланганны Алла саклар.

—Йә, ризамы? Соңгы сүз синдә. Дөрес, синнән тыш, комбатны тагын өч штрафник яшерен саклаячак имеш. Шулаймы-түгелме, төгәл әйтә алмыйм.

—Чекистлар түгел, димәк, штрафниклар?

—Әйе, штрафниклар. Кылган гөнаһларын, жинаятьләрен аклар өчен алар үләргә риза. «Ил-Ватан хакына гомеребез дә жәл түгел!»—диләр. Диверсантлар белән бригаденфюрер СС Модель житәкчелек итә икән.

—Ничек ул алай, немецлар белән генерал житәкчелек итә, ә безнең белән капитан.

—Анысын генерал-полковник Аполлоновтан сора, НКВД наркомының урынбасары ул. Оператив гаскәрләр аның карамагында.

—Ә сез кемгә буйсыначаксыз?

—Сержант Головач киләчәктә генерал булачак капитан Шәкүровка буйсыначак, үзе дә, аның хлопецлары да. Дошман көчле, дошман мәкерле. Урманнарда яшеренеп хәрәкәт итүче диверсантлар тикмәгә генә «козгыннар» дип йөртелми. Күктән, биеклектән сикерүче авиадесантлар алар. Башлыкларының фамилиясе әлеге безнең иске таныш—генерал Модель!

—Генерал Модель—имансыз кяфер,
Чукындырыр сине капитан Шәкүр,
Булыр сиңа үр дигәнең гүр!—

дидем мин, шигъри юллар белән.

—Ә тәржемәсе ничегрәк?

—Гитлер капут! Татарга тылмач кирәкми, иптәш сержант.

—Әйе, «Бер адым да артка чигенмәскә!» Сер итеп кенә әйтәм, бу девиз аркасында безнең чекистлар бригадасыннан да югалтулар күп булды. Минемчә, әлеге девиз, юк, лозунг Верховный Башсәргаскәрнең 1942 елның 28 июлендә бирелгән 227 боерыгы белән бик тә тәңгәл. Заградительный отрядлар да шуннан башланды булса кирәк. Капитан Шәкүров та шулайрак әйтте. Ул хакта ул сиңа үзе дә сөйләр әле.

1943 елның февраль-март айларында, мәсәлән, без—чекистлар штрафниклар белән бергәләп, Харьков юнәлешендәге Мерефа божрасында батырларча сугыштык. «Райх», «Адольф Гитлер», «Үле баш» дивизияләренә каршы һөҗүмдә корбаннар күп булды, инде алар мәңгелек тынлыкта, туганнар зиратында—чекистлар да, штрафниклар да. Кременец урманында һөҗүм башланырга санаулы көннәр калды. Чекистларны да, штрафникларны да алдагы һөҗүмдә яшәүдән битәр, үлем көтә. Мин күрәзәче түгелмен, ә менә инанучы әбием әйтүенчә, өйрәтүенчә, адәм баласының язмышы галәм вә йолдызлар белән тыгыз бәйләнештә, адәм турында тик Аллаһы Тәгалә генә белә, бөтенесе аның кулында икән. Ләкин яшәү түләүле, бушлай бернәрсә дә бирелми. Игенче икән, Жир-ана күкрәгенсыйпа, бөртек шытсын дисәң, жир-туфракны мендәрдәй йомшарт. Йөзүче булсаң, энжене диңгез төбеннән, тирәннән эзлә. Сугыш ул иблислеге өчен адәм баласына Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән олуг бер жәза дип әйтә торган иде минем әбием. Католичка иде ул, мин бит Көнбатыш Украинадан, Ровно төбәгендәге бер авылда туып үстем. Сугыш башлангач, үзем теләп фронтка киттем. Бер ярлы крестьян малае идем мин. Кыскасы, немец гаскәрләренә каршы мин туган жирдә, туган төбәктә сугышам. Сугыша-сугыша Сталинградка тикле чигендем, сугыша-сугыша Полесьега, Кременецка кайтып життем. Инде үлсәм дә үкенмим, хәер, мин, әбием юравынча, туган жирдә үләргә тиеш. Ә син, рядовой Латыйпов, үлмә, яшә, синең, үзең әйтүенчә, Идел-йортка кайтасың бар. Имамов та, Кибек та кайтсыннар. Милләттәшең капитан Шәкүровны гаскәриләр тарафыннан «Алтын Украина» дип жырланган илдә калдырма! Сугыш бетеп, Шәкүров хохлушкага өйләнсә, нишләрсең?! Хәер, үз ихтыяры. Белгәнемчә, аның жан сакчысы бар икән инде. Рядовой Латыйпов, һөҗүм барышында комбатны саклап каласы иде. Юк, боермыйм, сорыйм. Якташың рядовой Зартдиновның башына фашист житте. Капитан Шәкүров шушындый фажигага дучар булмасын иде.

—Әйе, һәммәбезнең язмышы үр белән гүр арасында... Үрләр, гүрләр...

9

«Сугыш бетеп, Шәкүров хохлушкага өйләнсә, нишләрсең?!»— дип, сержант Головач тикмәгә генә әйтмәгән икән. Яна комбат үзе белән, чыннан да, бер чибәркәйне ияртеп килгәнлеге беленде. Аның исеме Галина, фамилиясе Дорогожицкая булып, штрафниклар батальонында хәрби фельдшер вазифаларын башкарачак, үзе офицер—кече лейтенант икән.

—Фельдшерицаны әйтәм, беләсе иде, ул кыз микән?—диде Рядовой—штрафник Штанько.—Әллә?..

—Нәрсә тукталып калдың? Ул хакта үзеннән сора,—диде икенче штрафник Зегерс.

—Дөресен әйтмәсә, тел бит ул адәм баласына серен яшерер өчен бирелгән.

—Ә, бәлки, комбат плюс фельдшерица—ир белән хатындыр?

—Нинди хатын бит, хикмәт менә нәрсәдә,—диде штрафник Ниязов, сүзгә кушылып.—Шәт фельдшерица комбатның ППШысыдыр?

—Күрәм, син, азиат, надан!—диде Штанько.—ППШы түгел, ә ППЖ. ППШ дип, урысча, конструктор Шпагин уйлап тапкан пистолет-пулемет әйтелә. Ә ППЖ—полевая почтовая жена дигәнне аңлата.

—ППЖ, әлбәттә,—диде Зегерс.—Ир-егетләрдә генә пистолет-пулемет була. Хатын-кызларда бөтенләй икенче нәрсә.

—Сүз боткасы бетсен!—дидем мин, мәгънәсез сөйләшүләргә нокта куюю ниятеннән.

—Тән сакчысы түземле булырга тиеш,—диде Штанько.—Терпи казак, атаманом будешь.

—Булмый гына торсын, тән сакчысы Латыйпов үзен бер яктан да күрсәткәне юк әле,—диде Зегерс.

—Он еще нам покажет кузькину мать!—диде Штанько.

—Кайчан?

—Һөҗүм вакытында, мин стажлы штрафник,—диде Штанько.—Латыйпов кебекләрне күп күрдем.

—Штрафбатта мин дә беренче мәртәбә генә түгел,—диде Зегерс.

—Алайса, сезнең арагызда мин шәкерт кенә,—диде рядовой Ниязов.—Штрафбатны ишетеп кенә белә идем. Инде менә мин—элеккеге чекист—шунда эләктем. Чыннан да, сезнең арагызда ангыра сарык кына. Ә сез, күрәм, бүреләр!

—Ангыра сарык булсаң да, әгъзаны бармактан аерасыңдыр әле,—диде Штанько.—Әйе, штрафбат ул—бүреләр өере.

—Һәммәбез дә адәм баласы: ике күзле, ике куллы, ике аяклы. Беребез дә мөгезле түгел. Бүренең дә мөгезе юк, әмма ул шакаллар токымыннан,—дидем мин.

Кинәттән генә окопта Головач күренде вә үзара барган гәпләшү өзелде.

—Нәрсә авызларыгызга су капкандай калдыгыз?—диде сержант Головач.—Махра бүлешәсезме әллә?

—Норма белән бирелгән махраны егетләр тартып та бетерделәр бугай инде?—дидем мин.—Хәер, мин тартмыйм.

—Песнең элеккеге укытучы тәмәке дә тартмый, аракы да эчми, кыслар пелән дә йөрми, итеальный шин[1]!—диде чуаш Кибек.

—Шин булгач, ул җендер инде?—диде Имамов.

—Үзең син җен!—диде чуаш.

—Шаяртып кына әйтәм, чуашча мин беләм.

—Белсәң әйт: сыерны чуашча ничек диләр?

—Белмәгәнемне беләм дип әйтә алмыйм,—диде Имамов.

—Сыер чуашча энә,—дидем мин.—Шунар бездә: «Бер энәгә бер

[1]Ш и н—кеше *(чуашча)*.

сыер»,—дип әйтәләр дә инде.

—Кызларга килгәндә, Латыйповның авылда яраткан кызы бар,— диде Головач.—Ә фотосы Имамовта. Бир син аны.

—Кемгә?—диде Имамов.

—Латыйповка, хәзер үк!

—Бирмәсәм, нишләрсез?

—Нишләрбез, имеш, егетләр җилкәнә менеп төшәрләр!

—Йә фотоны бирәсең, йә сержант рөхсәте белән, җилкәңә менеп төшәм!—дидем мин, Имамовның изүеннән тотып.

—Мә-ә!—диде Имамов, фотосурәтне җиргә ташлап.

—Бөгелеп ал!—диде сержант Головач.

—Алмасам?

—Алмасаң, үзеңә үпкәлә!

—Юк, алмыйм!

—Алайса, тезлән!

—Кем алдында?

—Кыз алдында.

—Окопта берниндн кыз юк.

—Кыз үзе булмаса, фотосы бар. Тезлән!

—Тезлән!—диделәр Штанько, Зегерс, Ниязов, Кибек—дүртесе дә беравыздан.

Имамов фотосурәт алдында тезләнергә мәҗбүр булды.

—Ә хәзер гафу үтен!—диде сержант.

—Кемнән?

—Кыздан!

—Нәрсә әйтим?

—Гафу итүегезне сорыйм диген.

Тезләнгән Имамов үз алдына нәрсәдер мыгырданды.

—Вот так, я тебе покажу, где раки зимуют! Любовью не шутят. Запомни на всю жизнь. Если пуля-дура на тот свет не пошлет... Рядовой Латыйпов, землянкада сине комбат көтә. Йөгер! Бер аягың бирелә, икенчесе тегендә!

—Слушаюсь!

10

Комбат, ярты сәгатькә якын үзара барган әңгәмәдән соң:—Капитан Федорчук сөйләвенчә дә, син, рядовой Латыйпов, тән сакчысы гына түгел, минем җан сакчысы да була ала торган кеше,—диде.

—Җан сакчыгыз бар дип ишеттем, иптәш капитан.

—Кем ул?

—Фельдшерица Галина Дорогожицкая.

—Аны әйтәсеңме, кече лейтенант Дорогожицкая дисәң, дөресрәк булыр. «Фельдшерица»,—дигәнне ишетсә, хәтере калуы ихтимал. Хатын-кызның күңеле бик тә нечкә була, ул халык, әйтер идем, бик тә үпкәчән.

—Кече лейтенант Дорогожицкая да шундыймы?

—Ул да женесе белән хатын-кыз ич... Без бөтенләй икенче темага күчтек...

Комбат утырган урыныннан торып, бүлмәдә арлы-бирле йөри башлады. Аннары тынлыкны бозып болай диде:

—Әҗәл тырнагыннан син җиңел яра белән котылгансың, мин моңа бик шатмын... Әйе, капитан Федорчук синең хакта бик тә әйбәт фикердә. Чекистларны мин яхшы яктан гына беләм. 1943 елның февраль-март айларында, без-генерал-лейтенант Лелюшенко җитәкчелегендәге гаскәриләр, чекистлар белән бергәләп, Харьков һәм Донбасстагы Ворошиловград-Мерефа шәһәрләрен яклауда оборона тоттык. Янәшәдә генә чехлар

батальоны белән полковник Людвиг Свобода житәкчелек итте. Мерефа ул дәһшәтле көннәрдә жәһәннәмне хәтерләтте.

—Сержант Головач та шулай дип сөйләде.

—Әйе, анда кичергән афәтне, югалтуларны онытасым юк. Ул чакта шәхсән мин житәкләгән бер рота штрафниклардан бары алтысы гына исән калды. Көлләре күккә очкан күпме штрафник-сугышчы хәбәрсез югалды дип игълан ителде. Әлеге һөжүмдә самолетлар, танклар, туплар, пулеметлардан тыш, «Катюша»лар да катнашты. Ә дошман дивизияләренең исемнәре дә, жисемнәре дә юкка чыкты. Мерефа өчен Людвиг Свобода—Ленин орденына, ә мин—Александр Невский орденына лаек булдык. Элеккеге лейтенант, хәзерге капитан Федорчук Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнде. Ул чакта эчке гаскәрләр генерал-майор Марченковка буйсынды. Кыскасы, Кызыл Армия гаскәрләре дә, чекистлар да бер йодрык идек. Андый тактика, юк, стратегия Сталинград өчен барган сугышта да файдаланылды. Инде Кременец урманнарында, тауларында маршал Жуков белән генерал-полковник Аполлонов әлеге сыналган ысулны тормышка ашырырга уйлыйлар булса кирәк. Шулай булмаса, минем ротаны фронттан чакыртып алмаслар иде. Хәер, батальон яна штрафниклар белән тулыландырылды. Сез-чекистларның ярдәмгә килүләре мине куандыра. Әйе, мин үзем «Кыр патшасы»—пехотадан. Сарытауда гомумгаскәрләрнең хәрби училищесын тәмамладым. Беренче сынауны Сталинград фронтында уздым, 62 армиядәге пехотада рота командиры идем. 1942 елның июлендә башкомандующий Сталинның «Бер адым да артка чигенмәскә!»—дигән мәшһүр приказы игълан ителде. Ә Сталинград һәм Көньяк-Көнбатыш фронтларының Хәрби Советлары Сталинның әжәл боерыгын сугыш лозунгысына әвереелдерделәр. НКГБның «Смерш» дип йөртелгән ОКР ягъни Отдел Контрразведка ярдәмендә, әлбәттә. Шул мәшһүр боерык нәтижәсендә Сталинград фронтында беренче тапкыр штрафниклар ротасы, батальоны, заградительный отрядлар барлыкка килде дә инде. Ике фронтта мина штрафниклар ротасы белән житәкчелек итәргә туры килде. Бусы өченчесе. Дөрес, бирегә мине повышение белән алып килделәр, үземне батальон командиры, комбат итеп билгеләделәр. Ә тәүге һөжүмнәр әле дә күз алдымда, күпме яудаш-коралдаш һәлак булды. Шәхсән мине саклаганда бар тән сакчыларым да жан бирде.

Мин—булачак тән сакчысы, бу сүзләрне ишеткәч, үземне аяз көнне яшен суккандай хис итсәм дә, гәпләшүне дәвам иттердем.

—Минем әтием фронтта хәбәрсез югалды,—дидем мин.—Ржев сазлыклары үзен тартып алды булса кирәк. Абыем исән, сезнең кебек Сталинград сугышында катнашты. Яралангач, Серпухово госпиталендә дәваланды. Инде яңадан немецларга сабак бирә. Дөресрәге, арткы сабакларын укыта. Тупчы, үзе пәһлеван гәүдәле. Ындыр табагында эшләгәндә, тулы ике капчыкны, куен астына кыстырып, арбага сала иде.

—Күрәм, син абыең кебек олы гәүдәле түгел. Хәер, хикмәт беләктә түгел, ә йөрәктә. Куркакларны женем сөйми.

—Сынатмам, иптәш капитан.

—Сыната торган булсаң, капитан Федорчук сине мина тән сакчысы итеп тәкъдим итмәс иде.

—Кайтканмы әллә?

—Кем?

—Капитан Федорчук.

—Кайткан, әмма ул яшерен задание белән мәшгуль.

—Ә мине ни өчендер үзе белән алмады?

—Милләттәшләр генә түгел, синең белән минем инде якташлар икәнлекне дә белгәч: «Ике якташ бергә булыгыз!»—диде ул. Яшерен булмаса да, безнең штрафбат алдында куелган задание дә жаваплы. Генерал Модель вә аның башкисәр иярченнәренә каршы, чекистлар, штрафниклар бер йодрык булып сугышачакбыз. Штрафникларның күпчелеге, тоткынлыктан котылу ниятеннән, үз теләкләре белән фронтта.

—Иптәш капитан, мин аларның кайберләре белән таныш. Аерым алганда, литвалы Зегерс, украинлы Штанько, таҗик Ниязов белән. Штрафбатка алар сездән алданрак килде. Качмагайлары дип шикләнеп тә йөрдем.

—Инде нинди фикердә?

—Начар егетләр димәс идем. Сөйләүләреннән шуны белдем: алар немецларны илбасарлар дип таныйлар. Штрафник Зегерсның әтисе белән әнисен фашистлар юк иткәннәр. Штаньконың сенелесен көчләгәннәр. Элеккеге чекист, хәзерге штрафник Ниязовның бертуган әсир абыйсын крематорийда яндырганнар. Кызыл Армия полковнигы булган.

—Ә бит батальонда өч йөзгә якын кеше. Син өчесе белән генә таныш.

—Юк, өчесе белән генә түгел. Рядовойлар Имамов белән Кибек—минем төбәктән. Хәер, алар икесе дә чекистлар. Имамов кайнар егет. Солдатка киткәнче, мин балалар укыткан авылда яшәүче бер кыз өчен сугышабыз да хәтта. Хәер, андый низаглар егетләр арасында авыл аулакларында да булып алгалый иде.

—Яраткан кызым өчен мин дә сугышканым бар. Дөрес, моны мин батырлык димәс идем. Минемчә, ул яшьлек шаяруы. Алай гынамы, ирегетнең шәхес буларак үзен раслау ысулы... Батальонда штрафниклар—күпчелек, сез-чекистларга уяу булу кирәк. Бик кирәк!

—Иптәш капитан, четерекле бер сорау бирсәм, ачуланмассызмы?

—Юк, әлбәттә. Берне түгел, икене дә бир.

—Фашистларга дигән пуляны берәр штрафник сезгә юнәлтмәсме?

—Яшермим, сугыш кырында андый очраклар булгалады, ләкин сирәк. Инде андый хәл була кала икән, батальондагы һәр штрафник та җавапка тартылачак. Яшерен шундый бер карар бар. Ул хакта син берәр штрафникка ычкындыра күрмә!

Ике кулы белән ике күзен беравык каплап утырганнан соң, комбат утырган урыныннан торып басты да болай диде:

—Шулай итеп, минем ышанычлы тән сакчым—син, рядовой Латыйпов!

Бу мине уйга калдырды: «Бар җаваплылык минем өстә булачак! Йә, Хода, көтелмәгән бәла-казалардан сакласана, ялварып сорыйм!»

Мин уйга талып утырганда, землянкага бер гүзәлкәй килеп керде, ул шинельдән булып, кызыл хачлы сумка аскан иде.

—Ә, Галина, син икән!—диде комбат.—Рәхим ит! Санитарлар белән инструктаж уздырдыңмы?

—Уздырдым, әлбәттә. Бер һөҗүмдә күпме кеше язмышы хәл ителә,—диде кече лейтенант, кар бөртекләре төшкән бүреген башыннан салып.

Аның мин алтынланып торган чәчләренә игътибар иттем. Ә күзләре зәңгәр. Кашлары кыйгач-кыйгач. Үзе алсу йөзле. Сөйләгәндә авызыннан гүя энҗе чәчә. Авыл аулагында очрашсак, үзен сөйләтеп кенә утырыр идем.

—Штрафниклардан ничә санинструктор катнашты?—диде комбат.

—Өчәү иде.

—Азрак түгелме?

—Мин дә шулай уйлыйм. Әмма нишләп тә булмый. Аларның санын арттырырга хакыбыз юк. Штаб начальнигы шулай, ди. Ә менә матәм командасыннан алты кеше катнашты... Капитан, солдат белән таныштырмадың,—диде кече лейтенант.

—Тән сакчысы рядовой Латыйпов!—дидем мин, үрә катып.

—Өлкән лейтенант Рюминныкымы?

—Юк, минеке,—диде комбат.—Ә син, Галина, минем җан сакчым.

—Синеке булмый, кемнеке булыйм. Ә «Смерш» Рюмин җан сакчысыз изалана икән. Уяу бул, капитан!

—Алайса, сиңа да тән сакчысы кирәк булачак.

—Ә минем җан сакчым да, тән сакчым да син, капитан Шәкүров!

Солдат алдында әйтәм, сугыш корбаны була калсам да, минем мәхәббәт корбаны буласым килми!

Китәргә рөхсәт алгач, мин җәһәт кенә, землянкадан чыгып киттем.

11

Тау итәгендәге гаскәриләр өченче тәүлек инде һөҗүм башлануын көтә. Ябалак-ябалак кар ява, апрель кары, соңгы кар. Таң вакыты. Тирә-якта үле тынлык. Бер генә җан иясенең дә авазы ишетелми. Терсәкләргә таянып, түш белән шуыша-шуыша, мин йокыга талганнарны уятам: йә кул-аягыннан тартам, йә гәүдәсен селкетәм. Алай гынамы, бар гәүдәсен кар өстендә аунатам.

Ниһаять, мин «КП»да, комбат янында.

—Кайда югалдың?—диде ул, мине күргәч.

—Берәм-берәм уятып йөрдем.

—Кемнәрне?

—Йоклаучыларны.

—Кем кушты?

—«Смерш» Рюмин.

—Үзе кайда ул?

—Йокыга талганнарны уята калды. Спиртны әйтәм, өлкән лейтенант Рюмин бер грамм да авызына алмады... Дошманга ут ачу озаккарак сузылды түгелме?

—Ашыккан ашка пешкән, ә монда, үзең беләсең, аш түгел, пуля... Йоклыйлар дисең...

—Йоклыйлар, сержант Головач та хәтта. Әллә спирт күбрәк биреллеме?

—Бәлкем... Син дә, мин дә йокламыйбыз ич. Хохол Головачтан, артык булмаса, ким эчмәдек. Айн момент, уятам мин аларны. Берәм-берәм түгел, барысын да берьюлы.

—Ничек?

—Хәзер белерсең. Кече лейтенант Дорогожицкая, тыңлыйсыңмы мине?

—Тыңлыйм, иптәш капитан.

—Быргыңны ал да, кычкырт.

—Есть быргы кычкыртырга!

Тау итәгендә «Ту-ту-ту!» быргы яңгырады. Тиздән «Смерш» та килеп житте.

—Комбат, бу нинди кәмит?—диде «Смерш» Рюмин.

—Колакларың ишетә, күзләрең күрә, ә сорыйсың.

—Сорарга әбәзең, вазифам шундый. Сугыш кырын син, капитан, тамашага әверелдермәкчеме?

—Ә бит сугыш ул, бер уйлаганда, тамаша!

—Мин алай димәс идем.

—Тамаша икән, тамаша! Кече лейтенант Дорогожицкая, кычкырт быргыны!—диде комбат.

Элеккеге артистка тагы быргы кычкыртырга керешге: «Ту-ту-ту!» Бу инде батальон уянды гына түгел, ә һөҗүмне башлады дигән сүз иде. Гаскәриләрен ияртеп баручы олы гәүдәле Головач күренде. Көчле шартлаулар, атышлар ишетелде. «Кыямәт көне житте түгелме?!»—дидем мин, башланган коточкыч һөҗүм турында уйланып. Тау башына менеп життеләр дигәндә генә, йә берәмләп, йә бергәләп, һөҗүмчеләр тау астына тәгәрәде. Гүя, алар әҗәл кубызына бии-бии егыла, жан бирә иде. «Смерш» һөҗүм барышын күзәтә. Күзләре ялт-йолт итә. Иңбашында ППШ, кулында «ТТ» пистолеты, тешләрен кыскан, үзе ачулы. Кемгә, билгесез: штрафникларгамы, чекистларгамы? Сугыш кырында «кәмит» оештыручы комбаткамы? Модель диверсантларынамы? Бу һөҗүм тынгач билгеле

булачак, имин-аман калса, әлбәттә. Калмавы да ихтимал. Сугыш—тамаша, ләкин уен түгел, юк, уен түгел!

Батальон һаман тауга менә алмый. Немецлар урнашкан биеклектән винтовкалардан, автоматлардан, пулеметлардан сибелгән пулялар «Фи-у-у-у! Фи-у-у-у!» йә рикошет ясап, жиргә килеп тия, йә тишеп, эченә керә. Тагын бер үлем коралы—минометтан атылган ядрә, бөтерчек сымак зыр-зыр әйләнә дә: «Ба-бах-х-х!»—дип шартлый.

—В-в-р-реш-шь!—диде гарьлегеннән жир тишеген дә керергә әзер булган комбат.—Өлкән лейтенант Рюмин, минем арттан! Рядовой Латыйпов, син дә минем белән бул! Кече лейтенант Дорогожицкая, синең урының—яралылар янында. Чекистлармы, штрафникларммы—минем өчен барыбер. Яудашларны гына коткар... Санинструкторларга комбат исеменнән шулай дип әйт.

«Смерш» кычкырып салды:

—Комбат, һөҗүм өчен башың белән жавап бирәсең! Кыскасы, йә «пан», йә «пропал»! Үз карьераң үз кулыңда.

—Фашистларга үлем!—диде комбат, кулындагы автоматын югары күтәреп.—Яудашлар, яуга! Тауга!

Тауга якынлашканда гына, бер-бер артлы көчле шартлаулар ишетелде. Немецлар минометлардан ата иде.

—Ло-жис-сь!—диде комбат.

Без, барыбыз да, шул исәптән комбат та, «Смерш» та жиргә ятарга мәжбүр булдык.

—Шартлаулар сул флангта,—диде комбат.—Анда өлкән сержант Головач взводы. Күпчелеге чекистлар, штрафниклар да бар.

—Чекистлар минем элеккеге яудашлар, сынатмаслар,—дидем мин.

—Ә штрафниклар?—диде «Смерш».

—Берничәсе белән танышмын, сыната торганнардан түгел,—дидем мин.

—Күрербез,—диде «Смерш».

«Үзе командир да түгел, бу Рюмин кешеләр белән өндәү вә сорау билгеләре белән генә сөйләшергә өйрәнгән»,—дидем мин, уйланып.

Бер ефрейтор йөгереп килеп, өлкән лейтенант Рюминның колагына нидер пышылдады.

—Сул флангта завал!—диде «Смерш».

—Үзең «Смерш», ә паника таратасың,—диде комбат.—Паникерларны женем сөйми!

—Минем элемтәче ялгышмас!—диде Рюмин, «ялгышмас»ка басым ясап.

—Шартлау тау ишелерлек түгел иде,—диде комбат.—Минем кул сәгате йөрүдән туктамады.

—Минеке туктады,—диде өлкән лейтенант Рюмин.

—Синеке бит ул,—диде комбат.—Андый кул сәгате ни пычагыма! Трофей кул сәгатеме әллә?..

«Смерш» жавап бирмәде...

Шул чакта сул флангта тагын бер көчле шартлау ишетелде.

—Головачка подмога кирәк,—диде комбат.—Рядовой Латыйпов, киттек сул флангка!

—Мин дә синең белән: комбат кайда, мин дә шунда!—диде «Смерш».

—Ребята, подтянись!—диде комбат.

—Все как один подтянемся!

—Значит, жив курилка!—диде комбат.—Минем арттан! Алдыбызда тау. Соңгы штурмны башладык. Головач взводы белән бергәләп, әлбәттә...

—Авиадесантлар!—дип кычкырып салды кемдер.

—Кемнәр, немецлармы?—дидем мин, үз-үземә сорау биреп.

—Нәрсә сөйләнәсең?—диде комбат.

—Ниндидер авиадесант,—дидем мин, тауга сикергән парашютчыларны үз күзләрем белән күреп.

—Бик мөмкин,—диде комбат.

Автоматлы парашютчының берсе минем янга килеп төште.

—Син кем?—дидем мин, парашюты белән маташучы әлеге парашютчыдан сорап.

—Чекист-разведчик,—диде ул.

—Нинди чекист?

—Генерал-полковник Аполлоновныкы. Ә ул вакытлыча маршал Жуковка буйсына.

—Ә сез кемнәр?—диде авиадесантчы.

—Капитан Шәкүров егетләре!

—Штрафниклар, димәк. «Тауда, ягъни ике йөз унөченче биеклектә, капитан Шәкүров штрафниклары хәрәкәт итә»,—диде безнең командир.

—Батальонның яртысы диярлек чекистлар.

—Ералаш икән...

Һавада нииндидер самолет күренде дә, бер-бер артлы бомба ташлагач, күздән дә югалды. Инде гади бер тау янартауны хәтерләтте, һөҗүм мәхшәргә әверелде. Кыскасы, бомбалар ташлау гауга гына кубарды.

—Сул флангта паника!—диде өлкән лейтенант Рюмин, бинокльдән күзәтеп.—Головач хлопецлары чигенә.

—Булмас!—диде комбат Шәкүров.

—Минем бинокльдән кара,—диде инспектор өлкән лейтенант Рюмин.

—Үземнеке дә бар,—диде комбат һәм үз бинокленнән жентекләп күзәтергә кереште...—Юк, Головач хлопецлары чигенми, маневр ясый. Биредә үр арты үр...

«Гүр арты гүр»,—дип мин чак кына әйтмәдем, тел очымда гына калды.

—Рядовой Латыйпов, нәрсә уйга баттың?—диде Рюмин.

—Болай гына, иптәш өлкән лейтенант.

—Уяулыкны югалтма!

—Есть югалтмаска!

—Кабатлап әйтәм, Рюмин. Сержант Головач чигенми, үр куяннары кебек, маневр ясый. Головач белән минем тарафтан алдан уйланылган тактика. Сугыш ул, әйткәнемчә, тамаша, хәйләле тамаша.

—Ә мин фашистларга хәзер үк ут ачар идем.

—Сабырлык, Рюмин. Сабыр иткән морадына житкән.

—Диверсантлар беренче булып ут ачсалар, нишләрсең?

—Нишләрмен? Җавап бирермен. Утка ут! Тупка туп!

—Сабырлык дип, син дә, мин дә җәһәннәмгә китүебез ихтимал.

—«Беттек, җәһәннәмгә киттек!»—дип, син тагын укына күрмә. Белеп тор, татарлар әйткәнчә, мыегына чорна: сугыш кырында беркемгә дә өстенлек юк!

—Мине бүрек кадәрле үр тирәсендә тукталып калу канәгатьләндерми, алга киттек!—диде «Смерш».

—«Алга, коммунистлар!»—дип, сөрән сала алмыйм. Штрафбатта коммунистлар юклыгын син үзең дә беләсең. Штатта замполит та каралмаган. Һөҗүмдә катнашучылар арасында бармак белән санарлык комсомоллар бар. Чекистлар, әлбәттә.

—Алайса, ни дип туктадык?

—Үзең сул флангка паника дидең ич. Шуны ачыклыйбыз.

—Смелость города берет, киттек алга!

—Юк, китмибез! Головач взводы маневрының төгәлләнүен көтәбез. Биш минут сабырлык!

—Нинди биш минут? Нинди бетмәс маневр?

—Диверсантларны чолганышка, ягъни утлы боҗрага алабыз: тылдан капитан Федорчук, уң флангтан минем урынбасар, үзәктән мин, сул флангтан сержант Головач...

—Алайса, «Бер адым да артка чигенмәскә! Алга! Ура!»—дип кычкырасы гына калды.

—«Смерш» Рюмин, әллә шобага салабызмы?
—Ты неисправимый! Да, горбатого могила исправит.
—Әйе, минем бөкрем—сугыш. Мин-бөкрене гүр генә төзәтәчәк...
—Әйтәм, тукталдык. Димәк, сина үр түгел, ә гүр кирәк...
Түземлелеге беткән өлкән лейтенант Рюмин: «Бер адым да артка чигенмәскә! Алга-а-а! Ур-ра!»—дип, атыла-бәрелә алга ыргылды. Анар сугышчылар да иярде...
Диверсантлар белән үзәктәге, сул вә ун флангларлагы безнен гаскәриләр—чекистлар, штрафниклар, ике сәгатькә якын, дуамал, мәгънәсез орыш алып барды. Комбат Шәкүров зирәклек вә командирлык осталыгы күрсәтмәсә, авиадесантлар, тылда капитан Федорчук ярдәмгә килмәсә, безнен батальонда корбаннар саны, минемчә, күбрәк булыр иде. Комбат та вә анын тән сакчысы—мин дә исән-аман калдык. Ә үзен комбатнын жан сакчысы дигән фельдшер Дорогожицкая, каты яраланып, һөҗүм тынганнан сон, милләттәше штрафник Штанько кулларында жан бирде. Өлкән сержант Головач, рядовойлар Имамов, Зегерс, Ниязов, Кибек, Князев вә тагын исем-фамилияләрен мин белмәгән, ишетмәгән яудашлар һәлак булды. Головачнын әбисе әйткәне рас булып чыкты. Сержант туган жирендә гүргә керде.
«Смерш» Рюминнын да дошман пулясеннән гомере өзелде. «Фашист шпионнарына үлем!»—диде ул, жан биргәндә.
Корбан ир-егетләрне тау итәгендәге бер калкулыкта жирләдек. Салютлар биреп бәхилләштек. Кече лейтенант Галина Дорогожицкая хөрмәтенә дә өч тапкыр салют янгырады. Әлеге салютларга, винтовкалардан, автоматлардан атып, капитан Федорчук житәкчелегендәге чекистлар вә генерал-полковник Аполлоновнын махсус заданиесен үтәүче авиадесантлар да кушылды. Ул отрядлардагы корбаннарны жирләгәндә, шулай ук, без—исәннәр, шәкүровчылар тарафыннан салютлар бирелде.
Кременец урманнарында орышлар беткәч, тән сакчысы вазифаларыннан мин азат ителдем. Үземне жилкәмнән тау төшкәндәй хис иттем. Ләкин бер уй тынгылык бирмәде, төннәрен йоклатмады: «Начармы-яхшымы, тән сакчысы буларак үземне исбат иттем кебек, ә менә жан сакчысы булыр өчен ниндирәк кешелек сыйфатлары кирәк икән?» Санинструктор кызлар да миннән шул хакта сорыйлар иде. Хәлбуки, бүгенге халәттә, вазгыятьтә үзем белән мин канәгатьмен: Аллаһы ярдәме, кодрәте беләндер инде, турыдан-туры фронт сәргаскәренә буйсынган штрафниклар командирын, капитан Шәкүровны саклап кала алдым. Үзе әйткәнчә, ышанычлы тән сакчысы булып чыктым. Ул һәлак булса, яшерен күрсәтмәләр раслаганча, һөҗүмдә катнашып та, яра алмаган—исән бар штрафниклар да жавапка тартылачак, төгәлрәк әйткәндә, хәрби тикшерүчеләр «фильтры-сөзгече» аша узачаклар иде.
Әлеге буталчыклы орышта катнашкан, фашист пулясеннән һәлак булган «Смерш» ул күрсәтмәләрне белгән, әлбәттә. Ә бит сугыш ул, чыннан да, тамаша: кемдер үргә тартыла, кемдер гүргә тартыла. Өлкән лейтенант Рюмин гүргә тартылучыларнын берсе булды. Тау итәгендә һөҗүм башланыр алдыннан сугышчыларга бирелгән спирттан да градусы көчле булган: «Бер адым да артка чигенмәскә! Алга! Ура»лар белән исергән Рюминны әлеге дә баягы бер ахмак пуля үлемгә дучар итте.

12

Әлеге сугыш операциясеннән сон, мине һәм тагын бернечә гаскәрине Карпат якларына күчерделәр. Инде безнен батальоннын командиры (ул аерым оператив батальон дип аталды) капитан Шәкүров түгел, ә майор Борисов иде.
Карпат тауларынын итәге. Югарыга, биеккә карасан, башыннан пилотка төшә. Тауда горур наратлар... Ә безгә, Дрогобыч, Львов, Станислав,

Трускавец төбәген диверсантларның оясы дип, юлда ук әйттеләр. Инде менә мин Карпатта. Шомлы, шикле, күләгәле, куркынычлы як бу. Казарма белән янәшәдә генә грек-католиклар костелы. Аның кыңгыраулары сугылган, чаң тавышлары көчәйгән саен минем күнелем тарая, гәүдәм, буй-сыным көчерәя кебек. Гүя, мин кеше дә, гаскәри дә түгел, ә бер бөҗәк кенә. Менә-менә мине басып-сытып үтерерлек шикелле. Чат саен, адым саен үтерүче, синең җаныңны алучы басып тора сымак. Бигрәк тә мөселман баласы өчен яшәү хәтәр бу якларда. Күзләрдәге караңгылык пәрдәсе, томан беркайчан да ертылмас шикелле. Мин күргән, белгән яктылыкны, аның нурларын караңгылык басып алган сымак. Аталар, асалар, җимерәләр, ваталар... Тирә-яктан халык казарманы җимерер, ватар, безне атар, асар өчен җыеладыр кебек миңа. Гыйбадәтханәгә дә безне соңгы юлга озату, матәм моннарын көйләү нияте белән киләләр кебек. Гүя, алар безнең рухка алдан ук гыйбадәт кылалар. Көн атышлар, төн атышлар: тау итәгендә, тау битендә, урманда, урамда, базарда, зиратта, тимер юлда... Винтовкадан, автоматтан, пистолеттан, пулеметтан, хәтта ки минометтан, туптан аталар.

Яңа батальонда мин минометчы итеп билгеләндем. Минем җилкәдә кырык сигез килограмм авырлыктагы чуен миномет плитәсе. Чекистлар батальонында шушындый корал-миномет көпшәсенең нигезе-плитәсе бер миндә. Урта белемле булгангамы, милләтем татаргамы, турысын әйткәнгәме?.. Турысын әйткән туганына ярамас, диләр. Хезмәт итә башлаган яңа батальонда татар баласыннан мин бер үзем. Әйе, мин Карпат тауларында. Батальон минометының снарядлары биеклекләрдәге нокта
ларга атар өчен ясалмаган. Биеклеккә атар өчен снаряд гильзасына шактый дары салынырга тиеш, ди комбат Борисов. Безнең миномет биеклектән атар өчен генә җайлаштырылган.

Карпат үзе ниндирәк соң? Карпат—зур бөкресе—үркәче белән мәһабәт бер дөяне хәтерләтә. Аңа беркем дә җайдак була алмас дип уйлыйм мин. Аннары мин бит миномет плитәсенә тагылганмын, җибәрми ул мине. Димәк, мин кол-буйсынучы. Буйсынмас идем дә, басып үтерәчәк ул мине. Даһи әйткәнчә, мин бер «шөреп» кенә, миномет плитәсенең бер «шөребе», шомарып беткәне. «Шөреп»не мин гел чистартам, ләкин күгәрә. Димәк, миндәге күгәргәнлекне, тутыкканлыкны бетереп булмый. Ә минем кебекләр бирелә бихисап. Алар да минем шикелле «шөреп»ләр. Чөнки биредә шартлар шундый. Көн-төн аяк өстендә, тауга үрмәләп менәбез дә, тау сыртлары буйлап, агачларга тотына-тотына, алга таба атлыйбыз. Ә кайчак шул килеш, аягүрә йоклап атлавыбызны дәвам иттерәбез. Шулай бервакыт аягүрә йоклап барганда, винтовканы төшереп калдырганмын. Уянгач, эсселе-суыклы булып киттем. Йөгердем эзләргә... Тапкач, мин кичергән сөенечне белсәгез иде!.. Урман яңгыратып, бер мизгелдә күңелемдә туган шигырьне кычкырып укый башладым:

Солдатларга җиңү юлы
таулар аша, яулар аша.
Карпат ягы кара урман,
кошлар сайраша, башлар адаша.
Сугыш бит ул шундый тамаша,
пуля алалмаса, таш баса...

Тирә-яктан пулеметлар тукылдый, баш очында немец самолетлары үкерә, алар яндыра торган бомбалар ташлыйлар: туфрак түгел, су да яна. Ахырзаман диярсең, әрнүле авазлардан Җир-Ана сыкрана...

Күзгә күренмәс караңгы төндә кулларым белән капшанам: үземнең кайда икәнлегемне беләсем, ачыклыйсым килә. Түш белән әле монда, әле тегендә шуышам. Әмма, һаман да, ниндидер каты бер «дивар»га килеп бәреләм кебек. Мин—бомба чокырында. Безнең батальон, эссэсовчылар белән бәрелешкәндә, Карпат тауларының бер битендәге окопларны дошман бик каты бомбага тотты. Тирә-юньдә атышлар ишетелә.

Безнең батальонга каршы рәхимсез һөҗүм инде ничәнче тәүлек барадыр, анысын мин төгәл әйтә алмыйм. Аллага шөкер, мин исән! Ә соңгы шартлау бик тә көчле, хәтәр булды: колач житмәслек имәннәр ауды, кыя ишелде хәтта. Ничекләр итеп шушы хәлдән котылырга, чокырдан ничек чыгарга, югарыга күтәрелергә? Кычкыр-кычкырма, беркем ишетмәс, синең аваз бер жан иясенә дә барып житмәс. Бу Көнбатыш Украина ич, әллә украин телендә: «Ратуйте! Ратуйте[1]!»—дип тавыш бирергәме? Карпат урманнары бит, бүре йә шакал килеп чыкса, нишләрсең? Шуышып-тырмашып ыңгырашып яткан берәүнең янына киләм дә, гәүдәсен селкетә-селкетә сорау бирәм:

—Син кем?

Җавап бирми.

—Ник дәшмисең?

Ниһаять, ул:

—Вассер-р-р[2]...—ди.

Бил каешын ычкындырып, фляганы алам да, аны ялваручының иреннәренә тидерәм. Әмма ул һаман үзенекен тәкрарлый:

—Вассер-р-р...

—Су бит инде бу, су!—дим.

—Вассер-р-р...

Алюмин фляганы кулларым белән капшыйм: өч урында бармак сыярлык тишек икән, бомбаның вак ярчыклары тишкән булса кирәк.

—Вассер-р-р...

Бик каты яраланганга охшаган бу.

Дөм караңгыда тегенең гәүдәсен капшыйм.

—Вассер-р-р...

Кинәттән тынып калды. Күкрәгенә башымны куеп, йөрәк тибешен тыңлыйм. Үлгән!

Карангы язгы төн. Ай да, йолдызлар да күренми, әмма жир өстендә ара-тирә атышлар ишетелә. Без икәүдән-икәү генә—мәет һәм мин. Үземне мин беләм. Ә бу мәет кем? Немецмы, әллә безнекеме? Безнең частьтән булса, «Вассер-р-р...» дип ыңгырашмас иде. Бәлки, мина шулай тоеладыр. Кем генә булмасын, ләкин аны мин әжәл тырнагыннан тартып ала алмадым, хәлемнән килмәде, көчем житмәде. Ана мин хәтта бер йотым су да таба алмадым. Менә шул гарьләндерә. Сугыш кырында кырык сигез килограмм авырлыгындагы миномет плитәсен күтәреп йөргән мин—татар егете шушындый мөшкел хәлгә калдым. Исәнлек, тазалык—солдат өчен дә зур байлык, олы бәхет икән. Яшьлегем белән исәнлек-сәламәтлекнең кадерен белмәдем. Соң булса да, шуны аңладым мин. Инде батальонның миномет плитәсен далаларда, яланнарда кем күтәреп йөрер, тауларга кем күтәреп менәр? Батальонда миндәй «җүләр» егет табылырмы? Ниһаять, көтеп алган көн яктылыгы чокырга төште.

—Исәнме, Күк йөзе!—дидем мин, чалкан яткан килеш.

—Син кем белән сөйләшәсең?—диде аваз.

—Синең белән, Күк йөзе.

—Анда, чокырда, нишләп ятасың?

—Җан бирәм, сугыш корбаннар сорый. Кайда бер корбан, анда икенчесе дә булырга тиештер. Әйт, Күк йөзе, минем янымдагы корбан кем ул? Корбан корбанның исемен, жисемен белергә хаклы.

—Ә син ана текәлеп кара. Тәгаен син үз командирыңны танырсың.

—Минем командирым «вассер» димәс...

—Кяфер ул.

—Чуашмы, мукшымы, урысмы?

—Урыс. Гафу ит син аны, ул сине немец дип уйлады булса кирәк.

—Күк йөзе, син аны минем командирым дисең. Шулай икән, мин

[1]Ратуйте! Ратуйте!—«Коткарыгыз! Коткарыгыз!» *(Украинча).*

[2]Вассер—су *(алманча).*

аны тавышыннан таныр идем.

—Әҗәл кочагында тавыш үзгәрә. Әнә синен үзеннеке дә танымаслык булып үзгәргән, бик тә зәгыйфьләнгән. Кабатлап әйтәм, син аңа соңгы тапкыр текәлеп кара. Җан бирергә җыенгансың икән, аның кем икәнлеген белеп үл. Аны да гөнаһлы итмә, үзең дә теге дөньяга языклы булып китмә.

Үрмәләп мәет янына килдем. Йөзенә кояш яктысы төшкән иде. Таныдым мин аны, шушы көннәрдә генә безнең взводның командиры итеп билгеләнгән лейтенант Тимошин икән ич. Аны мин исән чагында бары бер генә тапкыр күреп калдым.

Яшь лейтенантның сүнгән күзләрен яптым. Ә минем күзләрне кем ябар?.. Юк, минем күзләрем ябылмады, мең бәла белән булса да, әлеге кыя ташлы чокырдан чыктым. Ә яшь лейтенант мәете тирән чокырда калды...

Соныннан мин әлеге тирән чокырны туганнар каберлеге иткәннәрен белдем. Әлеге туганнар каберлеген кырык елдан соң барып күрдем. Иделнең сул ярында урнашкан Сарытау шәһәрендәге хәрби-сәяси училищега мин-фәкыйрегез укырга киткәчтән, ишеттем: әлеге батальон унике меңләп санлы диверсантлар тарафыннан соңгы сугышчысына кадәр юк ителгән икән. Шулай итеп, батальон сугышчыларыннан бер мин исән калганмын. (Моны Карпат таулары итәгендәге Сколе шәһәрендә яшәүчеләр—шаһитлары һәм архив мәгълүматлары раслады).

Үлемнәр мине шулай тетрәтте! Гүрләр аша—үрләр... Үр арты үр... Сугыш кырында һәлак булган яудашларга багышланган кыйссамдагы күп урыннар—юллар, каләм белән түгел, гүяки, пулялар белән язылды.

1999—2000 еллар.

Киләсе ярты еллыкта "Казан утлары"

Узып баручы гасырның соңгы еллары татар прозасында үсеш, күтәрелеш еллары булып саналырга хаклы. Татарстанның төрле төбәкләрендә яшәп иҗат итүче әдипләребездән дә, Рәсәйнең төрле өлкәләрендә гомер кичерүче якташларыбыздан да редакциягә яңа романнар, повестьлар һәм хикәяләр килү дәвам итә. Аларның иң яхшыларын сайлап алып Сезгә, укучыларыбызга, җиткерү бару—редакция хезмәткәрләренең изге бурычы.

Якындагы саннарда Сезне нинди яңа очрашулар көтә соң? Авторларның һәм аларның әсәрләренең исемнәрен санап чыгу гына да редакция хәзинәсенең шактый бай икәнен күзалларга ярдәм итәр. Журналның җиденче санына **Гөлчәчәк Галиеваның "Тулгак" повесте** әзерләнә, сигезенче саннан башлап Мәскәүдә яшәүче әдип **Рауль Мирхәйдәровның "Иртәләгән сагыш" романы** басыла башлый. Күренекле язучылар **Аяз Гыйләҗев, Әхсән Баянов, Илдар Юзеев, Радик Фәизовның** күләмле әсәрләрен, шулай ук **Айдар Хәлим, Фәнзаман Баттал** хикәяләрен дә журнал укучыларга инде быел ук тәкъдим итү күздә тотыла.

Журнал битләрендә, гадәттәгечә, шагыйрьләребезнең иң яхшы шигырьләре, заманның үткән темаларын күтәргән публицистик язмалар, әдәбият һәм тарих фәненең төрле катламнарына тирән үтеп кергән гыйльми мәкаләләр дә дөнья күрәчәк.

ШИГЪРИЯТ

Нәҗибә Сафина

КЕШЕ БУЛЫП ЯШӘҮ—ЯЗМЫШЫМ

Ачылу...

Сагышларны күләгәгә куып,
Күләгәгә җылы нурлар коеп,
Яз кояшы көлде.
Бөреләрнең биләүләрен чишеп,
Садә нурлар бар дөньяны кочып,
Яшел нурга күмде.

Күлләвекләр яшел көзге инде,
Шомыртлары ап-ак күлмәк киде,—
Алмагачлар шашты...
Шомырт чәчәкләрен генә үбеп,
Җылындылар җилләр,—киерелеп,
Дөнья җанын ачты.

Кайчак...

Башны куяр урын тапмый
йөргән чак була.
Җанга әллә күпме шом вә
шөбһәсе тула.

Тузаннан да кече булып
каласың шундый,—
Җанда кара көч уяна,
бүредәй улый:

Ник яшисең бу дөньяда,
яшәү—ни мәгънә?
Син әле тагы ниләргә
итәсең дәгъва?

Шулчак—ярый аңлап алам:
бар минем дәгъвам—
Җаннардан өметсезлекне
куарга вәгъдәм.

Өметсезлекне куалсаң,
син үз-үзеңнән,
Өмет нуры кабына икән
дөнья йөзенә!

Дулкын тарта

Дулкын хәле шундый: килә—китә...
Тотып калмакчымын шул дулкынны.
Җанга какты дулкын—җаным ачтым,—
Анда хәзер мәхәббәт упкыны...

Җанын ачмаганнар иминдер ул,—
Упкыннарда давыл хәтәр икән!
Мәхәббәт ул иске заманнардан
Дулкыннарга иңгән хәтер икән.

Дулкын тарта: әйдә, күрсәтәм, ди,
Борынгылар ничек яратканнар.
Мәхәббәтне алар дәрья итеп
Бөтен Җир шарына таратканнар.

Сагыш диңгезенә салдың мине,—
Күзем түгел, хәтта таңым сары.
Каф тауларын узып киталсаң да,
Киталмисең мәхәббәттән ары.

Сары дулкын булып килә уйлар,
Сагыш булып җанда тынар өчен.
Сөю булып килә җанга хисләр,
Безнең җанны шулай сынар өчен.

Беләм инде хәзер, беләм инде:
Бу мәхәббәт бары дулкын икән.
Шул дулкынны эзләп төшкән ярым
Йөзеп чыга алмас упкын икән...

Үземне...

Мин бит сине шулкадәрле
Яраткан идем, «җаһил»!..
Һәммәсе өчен кичердем,
Мин барысына да бәхил:
Зәмһәрир салкынына да,
Җәйләрнең ялкынына,
Күнегә алмадым бары
Җаннарның салкынына.

Тиктормастай тәгәрәткән
Өермә давылларны,
Мине туфрагыннан түккән
Кадерле авылларны,
Тәүге мәхәббәтем урлап
Башкага киткәннәрне,
Мине түгел, үз-үзләрен
Бәхетсез иткәннәрне—
Мин барысын да кичердем,—
Мәхәббәтем зур иде.
Дөнья гүя фани түгел,
Мәңгелек бер җыр иде!
Һәм син аны отып алдың,—
Җаныма кереттем шул...
Җаның боз иде, бәгърем,
Җылыттым, эреттем шул.

Җаннан чыккан җанга иңә,—
Белеп әйтәләр икән.
Салкыннар үтә җаныма,—
Куя алмыймын киртә...

Мин бит сине шулкадәрле
Яраткан идем, «җаһил»...
Сөю дәрьясы ясаган
Боз-жаныңа да бәхил.—
Мин барысын да кичердем,
Үземне кичерә алмыйм:
Җанымны сулардан алып,
Утларга күчерә алмыйм!

Язны чакыру

Күз сагышлы,
кышлар салкын диләр.
Яз ярсулы диләр,
җәй—чиллә.
Барысын да
бергә җыйган фасыл—
бишенчесе—
минем җаным әллә?

Көздә көрпәк,
Язда ләйсән яңгыр.
Җәйдә кырау,
кышта кырлачы.
Кыш салкыны киергән агачларда
әй, җил генәм,
бер көй уйначы!
Җан ярама
ташкын тулганчы,
уйначы...

Ярсу язның
ярсулары җитми.
Адаштырмый
кышкы бураннар.

Сары көзнең
сагышлары җитми—
Сине сагындыра
торганнар...

Җәйгор[1]ларның
чагу төсе җитми.
Коеп яумый
нигә яңгырлар?!
Җан янганда
салкыннары җитми,
Җан туңганда
җитми ялкыннар.

Барысы да
бергә кирәк миңа:
синең җанда
бар да бар иде...

Ачык җанга
кышкы кырлач үтте,
ә син башкаларга
яр инде...

Яратасым килә

Яратасым килә шундый итеп,
Ышанмаслар әгәр сөйләсәм:
Отып ала алмас сандугачы,
Җан ярсуым әгәр көйләсәм.

Яратасым килә шундый итеп:
Мәхәббәтем таңнар булып атсын.
Тотып кала алмас ярлары да,
Мәхәббәтем ташкын булып аксын.

Яратасым килә шундый итеп:
Давыл булып җирне гизәр идем,
Әгәр сөюемә тиң мәхәббәт
Кабынса бит, барыбер, сизәр идем.

Яратасым килә шундый итеп,
Шундый итеп яратасым килә!
«Мин дә шулай кабынган идем дә,
Ялгыз янам»—диеп, Кояш көлә...

Ә барыбер ... яратасы килә!

Көткәндә...

Әй, нигә сызгырып үттең,
искән җил?
Минем аңа хәбәрем бар,—
кире кил!

[1]Җәйгор - салават күпере.

Әй, нигә миннән көләсең,
Кояшым?
Аның карашларын килә
тоясым.

Әй, кагылма яфракларга,
җил генәм!
Серле куллар иркәли бит,
мин беләм...

Ни хакында пышылдыйсыз,
тирәкләр?—
Әйе, монда аны көткән
йөрәк бар.

Нишлисең, җил, ник китердең
болытны?
Әллә аның йөрәгендә
мин юкмы?!

Күк, елама, кер җаныма,
сыйдырам.
Мин еламыйм, мөлдерәмә
тик торам.

Әй, сөюдән түгелергә
җиткәннәр!
Мәхәббәттән миндәй газап
чиккәннәр!—
Тимәгез җилгә, кояшка,
болытка!
Дөнья моңсу, дөнья елый—
Ул юкка...

Ах, кояшым керер килә
ишектән!
Хәбәремне, хәлләремне
ишеткән!

Тәрәзәмне ачып керде
җил өйгә.
Бар дөньясы җырлап тора
бер көйгә.
Һәрбер яфрак сөю җырын
пышылдый:
чын мәхәббәт була диеп,
шушындый!

*

Җир, җыр, чорның—
бары берсе
булмаса үзеңнеке,
гомерләрең үтәр дауда,—
бир Хода түземлекне...

*

Вакытыңны сакла, диләр,—
ни файда?
Вакытны тотып калалган
зат кайда?

Син вакытны саклап торма,
кадерлә—
эзсез китмим дисәң җирдән
кабергә!

*

Әгәр җанга көя төшсә,—
көяләндерә.
Көя кортын җангынаңа
ияләндермә!

Кискәли, көрпә ясый ул,
тәмам он итә.
Җанны җан түгел, белеп тор,
сансыз ком итә.

*

Мәхәббәтне табып була,
Була, диләр, югалтып.
Үз-үзен алдый бит кеше
Әнә шулай юатып.

Мәхәббәт җанда ярала.
Ә җан инде мәңгелек!
Җансызларга мәхәббәт ул
Булмаган һәм мәңге юк!

*

Кулларыңда чигеш сөлге,—
Кара җепләр саплама!
Каенның гаепләре юк,—
Аңа үпкә саклама!

Каен үзе көтә-көтә
Картайган ак чәч бит ул.
Каеннар картайсалар да,
Мәхәббәт гел яшь бит ул.

Каен тузына язылган
Мәхәббәт кыйссалары.
Мәхәббәт—зур, сыйдыралмый
Фанилек кысалары.

*

Югалтканың әллә ниләр булсын,
тик булмасын шатлык.
Мәхәббәтне кабат таптык дисәк,
югалтулар таптык...

*

Киткән чакта: «Сагынырсың...—дидең.
Сагынырсың, дидең, мин булмам.»
Сагынуларың тартып кайтарыр да,
Кочагыңа кереп мин тулмам.

Сагынырсың... әмма мин булмам...

Музейда уйлану

Иң иске нәрсә дөньяда—
дөнья үзе.
Иң изге нәрсә дөньяда—
Коръән сүзе.
Иске—изге, изге—иске,—
Кешелекне тотып тора
шушы ике!

«Җайсыз»

Тамчы суга сусап яткан чүлгә
Ташкын булып килдем—будылар.
Ялгызлыктан моңга баткан күлгә
Аккош булып төштем—кудылар.

«Тукта! Акма!»—диеп тыйдылар.
«Дәшмә!»—телем бәйләп куйдылар.
Бу торгын су кемгә кирәк диеп,
Корытырга канал кордылар.

Тагы әзер юлдан акмадым,
Җир җанына якын атладым.
Корылманы сүтеп аттылар,
Миңа «җайсыз» аты тактылар.

«Җайсыз» дигән исем алсам алдым,
Җансыз дигән исем алмадым.
Инде күптән болай яшәвемнең
Зиндан икәнлеген аңладым...

Ләкин туган җирсез, туган телсез
Кеше булып яши алмадым...
Кеше булып яшәү—Язмышым!
Һаман әзлиләр шул ялгышын.

*

Күк шәмәхә. Кып-кызыл ай,
Тик урак кадәр генә.
Иссә җил, кузгалыр болыт,
Югалыр хәзер менә.

Кара болыт ертыклары
Кунганнар ак каенга.
Ап-ак шатлыкларны гүя
Батырганнар кайгыга.

Күк шәмәхә. Каеннар ак.
Ертык болытлар кара.
Ак каенның кәүсәсенә
Кемдер ясаган яра.

Таң. Күк алсу. Каен кызыл.
Кан ага ярасыннан.
Гаеплене эзләп йөрим
Кешеләр арасыннан.

Көн. Кояш нинди төстәдер?
Кояш кояш төсендә.
Газаплана шагыйрь җаны
Үле җаннар өчен дә.

Кич. Барыбер кара җиргә
Түшәлә ап-ак томан.
Кара җаннарны акларга
Тырышкан шагыйрь сыман.

Безнең язмыш...

Төн караңгы, җилле. Шыбыр-шыбыр
Сөйләп тора тупыл телләре.
Төн. Өй якты. Җилсез өстәлемдә
Бары аның гына гөлләре.

Тупылларга бәлки рәхәттер ул,
Җиде җилгә салып җаннарын,
Тузыналар, гүя әйткән сыман
Уйлашырбыз диеп, калганын.

Их, җил булсам әгәр, әнә шулай
Тарар идем тупыл чәчләрен.
Тупыл булсам, бәлки шашар идем,
Мин берсе дә түгел, дәшмәдем.

Кеше булганыма үкенгән мәл,—
Канат сорап кемгә ялварыйм?
Төн кошының бердәнбере диеп,
Ябалакка әллә мин барыйм?

Төн кошыдыр дисәм, синең күзләр
Карап тора кара урманнан.
Ярым ай күк гүя калкып чыга
Шәрә башың яшел юрганнан...

Әллә айга гашыйк булдыңмы син?—
Төн буена нишләп йөрисең?
Беркем йөрмәгән һәм йөрмәячәк
Сукмакларның карын күрисең...

Әллә аймы сине бәйләп тота
Кара урманының кайгысына?
Син гашыйкмы, әллә ул гашыйкмы?—
Ышанырга миңа кайсысына?

Тәрәзәмнән айны куа алмыйм,
Сине куа алмыйм язмышымнан.
Синсез, айсыз, төнсез яши алмыйм,—
Белмим, кайда, ничек ялгышынган?

Төн караңгы. Күктә аем йөзә.
Җилләр шаша, тупыл тузына.
Безнең язмыш, ахры, әллә кайчан
Язылгандыр каен тузына.

Дөнья әдәбияты үрнәкләре

ЯМАНЛЫКНЫҢ ЧЫГАНАГЫ НӘРСӘДӘ?..

Немец язучысы Бертольт Брехт (1898—1956) тарихка атаклы драматург, шагыйрь, прозаик, сәнгать белгече һәм театр режиссеры буларак кереп калган. Ул үзе кәгазь фабрикасы директоры улы була. (Сүз уңаенда, гомере буе кәгазьне бик саклап, «кысып» тота...) Ләкин Брехт әти-әнисе яшәгән мохитне ташлый һәм үз юлы белән китә. Бөтен гомере буена буржуаз мохиткә, фашизмга һәм сугышларга нәфрәт белән карый. 1933 нче елда ул фашистлар кулы астында калган Германиядән чит илгә чыгып китәргә мәҗбүр була.

Аның әсәрләрендә Кеше табигате һәм аның социаль мохит белән үзара мөнәсәбәте беренче планга куела. Ул социаль шартларның кеше рухына йогынтысын, аның бөтен табигатенә тәэсир итүен сурәтли. Брехтның пьесалары барлык илләрнең театрлары репертуарына кертелә һәм исеме бөтен дөньяга мәгълүм була.

Брехт әсәрләре шагыйранә-фәлсәфи характерга ия. Шул ук вакытта аларда шартлылык аеруча күзгә бәрелә. Күрәмсең, ул кайвакыт мондый алымның чынбарлыкны сурәтләүгә караганда, күпкә отышлырак булып чыгуын яхшы аңлаган. Аның пьесаларында вакыйгалар дөньяның теләсә кайсы почмагында барырга мөмкин. Әйтик, «Чысуаньның игелекле бәндәсе» дигән әсәре (1938—1940) борынгы кытай әкиятеннән алып язылган, һәм анда вакыйгалар Кытайның Чысуань дигән шәһәрендә бара. Әлеге чара аңа әйтергә теләгән төп фикерен киная белән белдерергә ярдәм итә. Исеменнән үк күренгәнчә, әсәрнең төп проблемасы—кешедәге игелекле сыйфатларның чыганагын чагылдыру. Ул беренче планга «Нәрсә ул яхшылык?» дигән сорауны куя.—Яшәп килгән мәгълүм социаль шартларда кеше изге күңелле булып кала аламы? Кеше яхшы булсын өчен, нәрсә эшләргә кирәк?—Әсәрнең төп асылы нәк шул сорауларга җавап эзләүдән гыйбарәт.

Пьесаның кыскача эчтәлеген искә төшереп үтәм: өч Алла, кешеләр яхшымы, әллә яманмы, дип үзара бәхәскә керәләр һәм шуны тикшерү өчен, җиргә төшәләр. Чысуань каласына килеп төшкәч, алар кунып чыгар өчен бик күпләрнең ишекләрен шакып карыйлар. Әмма байларның берсе дә аларга ишек ачмый. Бары тик Шен Де исемле ярлы бер кыз гына, аларны үзе шикелле үк фәкыйрь бәндәләр дип белеп, өенә кертә. Аллалар кызга рәхмәт әйтеп, акча бирәләр һәм бу кыз шул акчага тәмәке кибете ачып җибәрә. Шулай итеп үзенең тормышын җайга салмакчы һәм баеп китеп, ярлыларга ярдәм итмәкче була. Әмма аның кибетенә шунда ук бик күп танышлары, фәкыйрь дуслары һәм бөтенләй читят мохтаҗлар йөри башлый. Һәм барысы да Шен Деның ярдәменә өметләнә. Баштарак ул аларга булышып та карый: ашата-эчертә; әмма көннәрдән бер көнне үзенең акчалары җилгә очып беткәнен күреп, сагаеп кала. Ул, әгәр дә фәкыйрьләргә ярдәм итәргә теләсә, кибетне саклап калырга кирәклеген төшенә. Шуннан соң Шен Де, ирләр киеменә киенә дә, үзен туганнан туган абыйсы итеп күрсәтә һәм изгелеген «онытып», әрәмтамакларны куып чыгара. Бары тик шулай гына ул кибетен саклап калачагын һәм яңадан акча җыеп, кабат кемгә дә булса ярдәм итә алачагын аңлый.

Брехт, әнә шул рәвешчә, социаль тигезсезлек хөкем сөргән җәмгыятьтә яхшы кеше булып калу өчен киң күңелле булу гына җитмәвен, бәлки усал булырга да кирәклеген күрсәтә. Бозык җәмгыятьтә кешенең нормаль сыйфатлары үзеннән-үзе юкка чыгарга һәм бөтенләй капма-каршы төс алырга мөмкинлеген чагылдыра. Кыскасы, яхшылыкның йодрыгы да булырга тиеш икәнлегенә ишарә ясый... Күрәмсең, мондый парадокс буржуаз мөнәсәбәтләрнең үз асылыннан ук килеп чыгадыр.

Брехт Шен Дены төрле хәлләр алдында калдырып, сыный: аның кешелек сыйфатларын—изүче җәмгыять белән бәрелешкә кертә һәм бу ике күренешнең үзара

ярашып яши алмавын бик ачык чагылдыра. Аның мәхәббәте дә, ана булгач туган хисләре дә гаделсез җәмгыять кануннары белән кискен бәрелешкә керә һәм җимерелә.

Әсәр соңында аллалар җиргә кабат киләләр һәм Шен Дены акча бәхетле иткәндер, дип өметләнәләр. Әмма алар эшнең бөтенләй икенче юнәлеш алуын күреп, аптырашта калалар: табигате белән яхшы булса да, кеше дигәнең социаль шартларга карап, яманга да әйләнергә мөмкин икән...

Бу каршылыкны ничек җиңәргә соң?!. Шен Де аллалардан ярдәм итүләрен сорый. Әмма социаль кануннар алдында аллалар да көчсез булып чыга. Алар, Шен Дены ташлап, күкләренә очып китәләр...

Шулай итеп, Брехт тамашачыны да, укучыны да кискен проблема алдында калдыра һәм бердәнбер дөрес җавапны тормышның үзеннән эзләргә чакыра .

Пьеса ахырында сәхнәгә Актер чыга һәм үзенең соңгы җыры (зонги) белән кешеләрне уйга сала, бәхәскә кертә һәм җавап эзләргә чакыра. Зонги, димәктән, Брехт, гомумән, үз пьесаларында персонажларның сөйләменә төрле җырлар—зонгилар (немецчә) кертеп җибәрә. Бу исә аларның характерларын тагын да тулырак ачарга һәм автор әйтергә теләгән фикерләрне аеруча басым ясап аңлатырга ярдәм итә. Зонгилары белән ул тамашачы яки укучының аңына гына түгел, хис-тойгыларына да тәэсир итә. «Чысуаньның игелекле бәндәсе» дигән пьесадагы зонгилар да нәкъ менә шуңа хезмәт итә.

... Заманында, әле 70 нче елларда ук, миңа әлеге пьесадан бер 10-15 «зонги»ны тәрҗемә итәргә туры килгән иде. Мин аларны Казан театр училищесы студентлары соравы буенча эшләдем. Соңра ул пьеса училище сәхнәсендә диплом эше буларак куелды һәм анда әлеге зонгилар да яңгыраган иде.

Бүген мин сезгә шуларның аеруча кызыклы һәм уңышлы дип табылганнарын тәкъдим итәм. Бәлки, бу зонгилар укучыда кызыксыну тудырыр һәм әсәрне тулысы белән укып чыгу теләген уятыр. Барыннан да бигрәк, аны яхшылык белән яманлык турында уйланырга мәҗбүр итәр, дип ышанып калам.

Лена ШАГЫЙРЬҖАН

Бертольт Брехт

*

Сабыр бул син, икеләтә көчең артыр.
Әнә, чирәмгә дип иелгән йөк аты:
бармак аша гына моңа кара син—
ул тагын да шәбрәк тартыр арбасын.
Җәен бераз сабыр ит, чыда, түз:
мул җимешләр китерер юмарт көз.
Бер-береңә юл куймыйча,
яшәп буламыни бергә?
Сабыр иткән—морадына җиткән...

*

Җиңел генә кеп-кечкенә ялгыз көймә
бата башлый шунда ук, төпкә китә:
чөнки котылырга теләп тотынырга
теләүчеләр аңа шактый күпкә китә...

*

Ах, бу көчсез адәм!
Мәрхәмәтсез, ләкин кызганыч адәм!
Мохтаҗлык алдында—изгелекне күрми,
Хәтәр барында—күрми кыюларны.
Ах, көчсезлек, син яхшылыкка күз йомасың!
Ах, сез, бик тиз чыккан хөкемнәр!
Артык иртә, бик тиз килгән өметсезлек!.

*

Шәһәр халкы туңмасынга нәрсә кирәк?—
дип сорыйлар губернатор әфәндедән.
Нәрсә булсын—каплар өчен бөтен җирне
ун мең футлык бик зур юрган кирәк, дигән...

*

Безнең илдә
шыксыз кичләр була күрмәсен.
Һәм елгалар аша—биек күперләр дә...
Шулай ук таң алдыннан да куркыныч.
Һәм, гомумән, хәтәр була кышкы чор...
Эш шунда ки, ач-ялангач кешеләрне
хәлдән тайдырырга мөмкин җыен чүп-чар.
Һәм аларның газаплы бу тормышны
көтмәгәндә беркөн ташлап китүе бар...

*

Алар инде җавап та кайтармыйлар.
Кая кусаң, шунда баралар.
Китәргә кушсаң, хәзер китәләр.
Һичнәрсәгә китми исләре.
Бары тик аш-су исләре
тәэсир итә аларга
һәм мәҗбүр итә күтәрелеп карарга...

*

Җитәр инде!
Якын кешеләрегезне
бертуктаусыз рәнҗетмәгез, калдырыгыз!
Ничек һаман туймыйсыз? Саранлыктан
бүртеп чыккан инде маңгай тамырыгыз.

Чын күңелдән сузылган кул—
җиңел биргән, ансат алган...
Яхшы сүз бит—азык җанга!
Юмарт булу нинди рәхәт—
ишетәсең күпме рәхмәт...

Болытларга утырып күздән югалучы өч алла җыры

Безгә инде кайтып китәр вакыт җитте.
Бу дөньяга бик тиз ияләшеп киттек.
Җирнең бөтен шатлыклары, кайгылары
сөендерде безне һәм дә көендерде...
Тик барыбер йолдызларның арьягында,
Шен Де! Сине мактап искә төшерербез!
Безнең васыятьләрне дә онытмаучы
бар бит әле, диеп, җирдә бер кешебез:
Хуш, и игелекле бәндә, бәхетле бул!
Безгә теләрсең инде син хәерле юл!..

Төтен турында җыр

Чәчләремә чал кергәнче, уйлый идем,
акыл белән булыр дип, уңыш казаныл.
Хәзер инде беләм, коры зиһен белән
бик туйдырып булмый икән ашказанын.

Кушымта:

Шуңа күрә әйтәм: онып һәммәсен!
Әнә, кара соры төтенне:
барган җире салкыннан да салкынрак—
син дә шулай китәрсең бер төнне...

Өч кат тирең сыдырылыр гадел эштә.
Шуны күреп, сайладым мин кыек юлны.
Әмма безнең ишеләргә ул да ябык—
хәзер инде беркая да барып булмый...

Кушымта.

Өмет—картлар өчен түгел. Вакыт кирәк
өметләрне тудырырга, җимерергә...
Ачык ишек—яшьләр өчен. Әмма безне
бөтен юллар илтә инде тик бер җиргә...

Кушымта:

Шуңа күрә әйтәм: онып һәммәсен!
Әнә, кара соры төтенне:
барган җире салкыннан да салкынрак—
син дә шулай китәрсең бер төнне...

Яңгыр яуганда Су сатучы җыры

Яшен яшьни, яңгыр коя,
Шундый көндә су сат, имеш...
Сатып булмый бер тамчы да.
Ә мин ялварырга тиеш
Һәрбер үтеп баручыга.
Түзеп булмый, ачу чыга:
«Су алыгыз!»—Беркем алмый.
Димәк, минем кесәгә дә
Сукыр бер тиен дә таммый.
Су алыгыз, дим, эт җаннар!..

Әгәр менә тиле яңгыр
Бер җиде ел яумый торса,
Су сатып, мин баер идем—
Тамагыгыз кибеп корыса...
Су бир, тизрәк, су бир, диеп,
Бар да көяр-янар иде.

Бер тамчы су йотар өчен
Чиләгемне ялар иде!
Ә мин әле башта аңа
Карар идем өстән генә,
Ошамаса—әчми тор, дип,
Көләр идем эчтән генә...
Су алыгыз, дим, эт җаннар!..

Яңгыр һаман коя гына,
Әрәм була файдасызга.
Болыт җиленен бер тиенсез
Имәсез бит, имансызлар!..
Бер тамчы су сатып булмый,
Беркемне сусатып булмый.
Бу яңгырда нинди җүләр
Су эчәм дип акча түләр?!.
Су алыгыз, дим, эт җаннар!..

Аллалар һәм әйбәт кешеләрнең көчсезлеге турында

Безнең илдә файдалы кешегә
хуп күрәләр тизрәк аяк чалуны.
Бер терәге булса гына раслый ала
кеше үзенең файда китерә алуын...
Әйбәт кеше—үзе мохтаҗ ярдәмгә.
Ә аллалар көчсез. Юк шул бомбалары.
Залимнәрне кырып бетерү, ә шәфкатьле
бәндәләрне саклап калу өчен җирдә,
ник соң корал бирелмәгән аллаларга?
Булса икән—танклары, пушкалары—
безгә дә шәп булыр иде, аларга да.

Безнең илдә мәрхәмәтле кешеләр
миһербанлы булып калалмыйлар һич тә.
Табаклар буш—ә тамаклар сугыша.
Хәерчелек, ачлык бездә һаман бетми—
Аллаларның киңәшләре ярдәм итми.
Ник соң килеп чыкмый алар базарларга?
Утырсыннар иде бераз сөйләшеп,
һәммәбезгә икмәк, шәраб өләшеп.
Китсен иде алар безне юатып,
күңелләрдә изге хисләр уятып...

Кашык тотып тәлинкәгә үрелү өчен
рәхимсезлек кирәк—
империяләрне
тотып торган каты, көчле рәхимсезлек.
Таптап китми торып әүвәл уникесен,
унөченче хәерчегә шәфкать юк!
Ник соң күрә торып шуны аллалар,
безне яклап бер сүз дәшми калалар?
Яхшыларга—яхшы тормыш кирәк күптән,
Ник соң алар әйтми икән шуны күктән?
Ник кушмыйлар безгә туптан атарга?
Аллаларга ник соң түзеп ятарга?!

Кызыл кар яуган Көн турында җыр

Фәкыйрьлекнең бишегендә үскән бала
Гомер буе бер җырны отып кала.
Кечкенәдән ышана ул бәхеткә,
Ярлы мескен менәр, диеп тәхеткә.
Бу—кызыл кар яуган Көн булыр,
Кызыл кар яуган Көнне
Ярлы кеше тәхеткә утырыр...

Ул көнне изгелеккә сүз бирерләр,
Явызлыкка авызлык кидерерләр.
Хуҗа белән батрак икәү берләшеп,
Мәйханәдә утырырлар гөрләшеп.
Кызыл кар яуган Көнне
Елгаларда сулар үргә ага башлар.
Бөтен кеше начар гадәтләрен ташлар.
Ә ябыкны юан агай чакырыр ашка.
Ул көнне һичкем эшләп иза чикмәс,
Берәү дә беркемне дә эшкә җикмәс.
Кызыл кар яуган Көнне
Кешеләрнең оҗмахка да исе китмәс...

Син булырсың ул көнне генерал,
Ә мин очар идем күкләрне урап.
Ул көнне Ванның кулы төзәлер,
Балкып, көлеп карар синең күзләрең.
Кызыл кар яуган көнне
Хатын-кыз, алсуланыр иде йөзләрең...
Безнең инде бүтән түзәр чама юк,
Котылырга моннан бүтән чара юк.
Хәлдән тайган гади хезмәт халкына
Кызыл кар яуган көн—
Иркенләп бер сулыш алган көн
Килергә тиеш
аның бәхете хакына!..

Сигезенче фил турында җыр

Җиде филе булган бер әфәнденең.
Сигезенчесе дә бар өстәвенә.
Җиде филе—кыргый. Монысы—өйрәтелгән.
Күзәтә ул тегеләрнең өсләреннән.

Элдертегез, җәһәт, урманга!
Калдырмагыз бер агач төбен дә.
Бөтенесен актарып ташлагыз!—
Ә төн инде борын төбендә...

Җиде фил урманны таптый, тетә генә,
Сигезенче филдә—хуҗа биеп тора.
Корытыгыз тамырын, дип агачларның,
Сигезенче әмер генә биреп тора.

Тизрәк, җәһәт ташыгыз!
Калдырмагыз бер агач төбен дә.
Бөтенесен каерып ташлагыз—
Ә төн инде борын төбендә!

Җиде фил арый тәмам, хәлдән тая.
Тик урманның әле байтак төбе кала.
Әфәнде бик усал, һаман гайрәт чәчә.
Сигезенче филгә өстәп дөге сала.

Моны тагын ничек аңларга?—
Калдырмагыз бер агач төбен дә.
Бөтенесен актарып ташлагыз—
Ә төн инде борын төбендә!

Җиде филнең калмады бер казык теше.
Сигезенче филнең генә тешләр исән.
Ул филләрне котыртып, таптый, изә.
Моны күреп, көлә үлеп хуҗа үзе...

Тизрәк, тизрәк, җәһәт булыгыз,
Калдырмагыз бер агач төбен дә!
Бөтенесен каерып ташлагыз.
Ә төн инде борын төбендә!..

Шен Деның моңсу җыры

Сезнең миңа «Игелекле бул!» дигән әмерегез
яшен кебек икегә телде йөрәк алмамны.
Белмим, нигә бер үк вакытта мин
үземә дә, бүтәннәргә дә
яхшы булып кала алмадым?
Үзеңә дә, башкаларга да ярдәм итмәк
бик тә кыен икән—менә хикмәт!
Ах, бу дөнья—бигрәк мәрхәмәтсез!
Мохтаҗлык күп, калдым бер өметсез.
Кулың сузуың була ярлыга—
ә ул аны әзер каерып алырга.
Ит ашамаса, ул үлә икән...
Ә мин нишлим—шуны белә микән?
Кайдан табып бетерим бөтен кирәкне?
Бар да миннән эзли тернәкне.
Ә бу инде—бетү, һәлакәт.
Килер микән миңа бер рәхәт?
Аның каравы, намуссызрак булган саен,
Күбрәк ашадым мин итен-маен...
Ихтимал, бу дөнья мәңге шулай кала:
Ялган гына анда яши ала.
Ни өчен соң яманлык гел өстә,
ә яхшылык һаман аста кала?
Мин бит бик тә бәхет теләгән идем.
Күзләрем дә бик үткенләнгән иде
үги анам коендырган чакта канауда.
Нәфрәт туып калды шунда пычракта аунауга.
Фәкыйрь кешеләрне кызганудан,
бертуктаусыз газапланды минем җан.
Хәерчелек күрә-күрә, бүре кебек явызландым.
Сизеп тордым: тамак кайгысыннан
комсызландым, ерткыч авызландым.
Сүзләрем дә әйләнделәр көлгә,
юкса фәрештә булыр идем гел дә...

Бүләк итү—миңа ләззәт иде.
Бәхетле чырайны күрү—әйбәт иде.
Каһәрләгез инде, әйдә, мине.
Әмма сезгә шуны җиткерергә булдым:
бөтен җинаятьләрне мин кылдым
үз күршеләремә ярыйм, дип.
үз ярымны яратыйм, дип.
Улымны мохтаҗлыктан коткарыйм, дип...
Мин кечкенә кеше монда, и аллалар!
Теләсәгез, ярдәм итәрсез тик сез.
Сезнең бөек эшләр өчен мин көчсез...

Финал. Актер җыры

И, хөрмәтле тамашачым, ни әйтим?
Матур булып чыкмады әкиятем:
Ямьсез килеш тәмамланды бөтен хәл.
Артистлар да кызганыч, читен хәл.
Пәрдә төште—басып калдык аптырап,
Мәсьәләне хәл итүдән бик ерак.
Сезнең алда бурычлы без, билгеле:
Сез бит рухи азык эзләп килдегез.
Тамашачы яратмаса—эш харап.
Нишләргә соң? Ник торабыз без карап?
Җайсыз хәлдән чыгу юлын табыйк без.
Пәрдәне дә җавап тапкач, ябыйк без.
Акчаларга сатылмый шул чарасы...
Әллә башка герой куеп карасы?
Әллә үзгәртик микән аллаларын?..
Бәлки, кирәге дә юктыр аларның?..
Ягез, хәлебезгә безнең керегез,
Төпле берәр киңәш-акыл бирегез.
Яхшылыкка изге юллар бардыр ич,
Җавап тапмый, ашыкмагыз китәргә.
Һәм, безнеңчә, әкиятнең азагы
Тиеш,
  тиеш,
    тиеш әйбәт бетәргә!!

Лена ШАГЫЙРЬҖАН *тәрҗемәләре.*
1978—1979.

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Адлер Тимергалин

ИГЕЗӘКЛӘР

ПОВЕСТЬ

Керми киттем каен урманына,
Каен урманнары ак иде.
Керер идем, күңелемә минем
Кара уйлар тулган чак иде.

Керми киттем каен урманына,
Тыелып кына утырып еладым.
Ап-ак каеннарның йөзләренә
Сарылмады кара уйларым.

Фәнис Яруллин

—Нинди сөякләр ул, әти?—дип сорады почык борынлы малай, манараның яртылаш ачык торган ишегенә башын тыгып карагач һәм бераздан, курыккандай, кире чигенде. Каршыдагы Сөембикә манарасы кебек мәһабәт, нык бәдәнле әтисенә күтәрелеп баккан чакта бәләкәчнең баш түбәсендә чәч бөтеркәсе күренеп калды.

Әтисе салам эшләпә тоткан кулын селтәде, ә икенче кулына ул аркылы-торкылы жеп ураган саргылт кәгазь төргәк күтәргән иде:

—Теге ни... төрле ханнарныкы ул... Археологлар жир казыганда килеп чыккандыр... Әнә ич, кремльнең аргы башын актарып ташлаганнар. Күрәмсең, монда зират булган—хан төрбәләре, мавзолей...

—Мескенкәйләр...—диде малай, әллә ятим сөякләрне, әллә инде борынгы Казан ханнарын кызганып.

—Йә, булды, Рустик! Бүгенгә экскурсиябез тәмам. Киттек. Электричка көтмәс... Күрәсең бит, Сөембикә манарасы авам дип тора икән хәзер. Студент чагыбызда, иллешәр тиен түләп, Казанның бөтен әйләнә-тирәсен

карап төшкәнебез бар, тик фотоаппарат алып менәргә рөхсәт итмәгәннәр иде... Хәер, ул елларны безгә фотоаппарат каян килсен..?

—Ә нигә соң бу ишекне бикләмәгәннәр? Каравыл да юк...—дип һаман төпчендe улы, манараның нигез катындагы яртылаш ачык ишеккә төртеп күрсәтеп.

—Археолог абыйлар бикләргә оныткандыр. Аннары әбәт вакыты гына бит. Урлар нәрсә дә юк ич монда... Шул, почмакка өйгән конгырт сөякләр генә...

—Ә хәзер аларны нишләтәләр инде?

—Бәлкем зиратка илтеп күмәрләр.

—Ага. Син шылтыратып әйт аларга: күмсеннәр. Яме? Ну, башта кемнеке икәнен белсеннәр...

Малай баскан жирендә таптангалап торды, каерылып-каерылып манараның очына карады. Аннары алар—мәктәп формасы кигән каракучкыл малай белән анын зәңгәр болонья плащ һәм караңгы күзлек элгән әтисе—китеп тә бардылар. Бик ихтимал, бу минутларда малай киләчәктә авыш Сөембикә манарасын турайтачагы турында хыяллангандыр әле...

Алар китеп бардылар, ә минем тормышымның гүя тагын бер сәхифәсе ябылды.

Ә ул көнне, өр-яңа эскәмиядә утырганда, күңелемдә бер уй-теләк кузгалды: рөхсәт-мазар сорап тормастан, шушы манарага менеп тирәюньгә күз саласым килде, шуннан карап бөтен узылган юлларны күреп буладыр кебек иде. Кылган һәм кылмый калган гамәлләр, очрашкан һәм инде онытылган кешеләр күз алдыма килеп басар кебек иде... Дөрестән дә, тормышымдагы барлык куандырган табышларым һәм сагышлы югалтуларым шул Казан офыгы эченә сыеп бетәдер сыман. Әйтерсең лә, минем күз алдымда гамәл дәфтәрем ачылыр кебек иде...

Инде ике туларга да әлләни калмаган икән. Менә инде манараны рәтләүчеләр дә күренә башлады. Миңа Югары Совет бинасы эченә кереп, йомшак кәнәфидә утырып көтсәм дә зыян итмәс иде, тик керәсе килми. Гомер узды, шушындый "рәсми" бина бусагасын таптап йөрүгә мин күнегә алмадым. Эш буенча бер-ике тапкыр өлкә комитетына барырга туры килгәне бар-барын. Партия әгъзасы булмагач, вестибюльдәге милиционерга паспортымны калдырып, ниндидер бер рөхсәт кәгазе алу күңелне болгаткан һәм инде кабат бу тирәдә чуалмаска дип үз-үземә сүз биргән идем. Югыйсә мине бүген түрәләр "келәмгә" дә чакырмыйлар инде, пешекләү һәм кисәтү өчен дә түгел, ә үзләренчә олылау, хәтта Мактау грамотасы белән бүләкләү өчен дигәннәр иде... Шулай, бүләген бүләк, ә аяк, барыбер, тартмый...

Менә әлеге Югары Совет бинасының авыр ишеге тавыш-тынсыз гына ачылды да, аннан берәү чыгып, галстугын төзәткәләп торды, зәңгәрсу береткасын киде һәм, кая барырга белмәгәндәй, теләр-теләмәс кенә атлап, мин утырган эскәмия янына килде. Ул миңа нидер әйтте, ләкин сүзләрен аңышмадым. Тик тавышын ишетүгә сискәнеп, уянып киткәндәй булдым. Әллә нинди ерак өн, үземә бик тә таныш авазлар ишеткән кебек булдым мин. Хәер, мин күңелем белән әле һаман манара башында идем бит. Дөньямны—тормышымның археологик катламнарын—шуннан күзәтә идем, шуңа күрә ияк кагып кына җавап бирдем шикелле.

Ә ул урысчалап, ләкин сизелерлек—алманча дип әйтимме?—акцент белән әйтә куйды:

—Менә мин өйгә дә әйләнеп кайттым. Өйгә! Wunderbar! Искиткеч!

Шул чагында мин аңа текәлеп карадым.

—Сез бит татар,—дидем мин һичбер икеләнүсез.—Мин сезне таныйм да кебек... Сез... Сез Атна авылыннан түгелдер бит?

—Атна дисезме? Ja... Әйе, без кайчандыр Атна авылында торган идек,—диде бу, ярым татарчалап. Аның татар сүзләрен таба алмыйча гаҗиз булуы сизелә иде.—Күптән... Сугышка кадәр үк! Кырык еллар элек...

—Туктагыз әле. Сез... Сәйдәшев түгелдер бит? Азат Сәйдәшев?

Сулышыма төер килеп тыгылганга, тыным кысылып, тавышым пышылдап кына чыкты.

Без капыл торып бастык. Үзебез бер сүз дәшмәдек, күзләребез генә, бер-беребезнең йөз чалымнарында эзләнеп, әледән-әле очраштылар. Ниһаять, мин аны—үземнең әллә кайчан җуйган һәм сурәте инде күңел төпкеленең иң ерак почмагына хөрмәтләп күмелгән балачак дустымны —таныдым, таптым... Ул да таныды, мине төсмерләгән саен аның еллар сыеклаган яшькелт күзләре җылына, дымлана, яктыра һәм нурлана бардылар...

—Илдар! Синмени бу?—диде Азат Сәйдәшев һәм мин аның калтыравык тавышында тагын яшьтәшемне таныдым.

Азат бер адым артка чигенеп, мине янә күздән кичерде, модадан чыгып барган костюмыма игътибар итмәскә тырышты бугай. Аннары ул рәхәтләнеп, иркенләп елмайды, шул чагында аның ап-ак һәм артык тигез ясалма тешләре күзгә чалынды.

—Ә мин сине барыбер эзләп таба идем, дус!—дип өстәде ул.

Утырыштык.

—Мин дә сине ике тапкыр эзләтеп карадым...

—Азатны табарлык түгел иде шул... Мин, гомумән, башка фамилиядә йөрдем. Дөньяда татар малае Азат Сәйдәшев юк иде... Баштарак—Казанцев, аннары... Отто Клейн.

—Яшьти, йә, хәлләреңне сөйлә... Каян? Ничек? Туган якка нинди җилләр алып кайтты?

Азат башын чайкады.

—Минем сүз күп, Илдар, болай гына сөйләп бетерешле түгел... Мин бит Көнбатыш Германиядән үк кайттым. Ja, ja, Bundesrepublik—Алман иленнән... Бик озак көттергәннән соңында, ниһаять, үтенечемне канәгатьләндереп, СССР гражданлыгы бирделәр. Сезнең... Юк ла, үзебезнең Татарстанның Югары Советы Президиумында булдым. Әле генә рәисе мине котлап кулымны кысты, совет паспорты тоттырды. Менә, күр—Маяковский әйтмешли, "серпастый-молоткастый"! Ә Президиум рәисе минем әтине дә хәтерли икән әле! Искиткеч!

* * *

Күптәнге хәлләр инде бу.

Азат белән күршеләр без. Район үзәгенең Кызыл Октябрь урамына урнашкан кызыл калай түбәле һәм бер генә катлы озын нарат йорт урталайга бүленгән. Аның бер башында райкомның икенче секретаре гаиләсе, ә икенче башында райбашкарма комитеты рәисе яши. Ишегаллары уртак, ике гаиләнең ныклы абзар-курасы да бар— чөнки ул заманнарда әле "урындагы" кешеләр дә сыер асрый торганнар иде. Дөрес, печәнне кайдадыр, кемнәрдер чабып китереп сәндерәгә өя, кайчагында хәтта якындагы спирт заводыннан берәр мичкә "барда" дигән әчкелтем исле куе сыекча да китерәләр. Аны чөмергәч, безнең сыерларның кәефе шактый күтәрелгәне исемдә.

Азатның әтисе—секретарь, әнисе райкомның парткабинетында эшли.

Кыскасы, җирле номенклатура базарында Азат белән мин бер дәрәҗәдә исәпләнәбез. Беренче секретарьның курчактай киенә торган Светлана исемле кызы гына бездән югарырак, ләкин ул берәү белән дә аралашмый, борын чөеп йөри шунда сипкел тубалы.

Азатның берсеннән-берсе кече ике энесе бар: Айдар белән Роберт. Алар инде гел безгә тагылу ягын карыйлар, дөнья бетереп елап булса да арттан ияриләр. Робертны ярата идем мин. Ул да мине үз итә, сүземне тыңлый, хәтта ул өйдә көйсезләнә башласа, стена шакып кына мине дәшеп тә ала торганнар иде...

Ә безнең эш муеннан! Утын кисү, җәен көтүдән сыерны каршы алу, кышларын мал-туарга башак салу кебек вак-төяк мәшәкатьләр һәммәсе безнең өстә. Шулай да, авыл малайларыннан аермалы буларак, көн безнеке: туп тибәбез, кәшәкә сугабыз, шәмәйле уйныйбыз, балыкка йөрибез, китап укыйбыз, кышын чаңгы тагабыз. Кайчак Азатларда лото, Кытай биллиарды белән вакыт уздырабыз. Ниндидер бер татарча китаптан укып, "Дингез сугышы" дигән уенны да өйрәндек... Әлегә велосипед (аны минем әби Мөсәппиха дип йөртә) педале әйләндерергә аяк җитеп бетми, ләкин әтинең эшсез яткан көзгедәй ялтыравык кыршаулы велосипедын, мөгезеннән тотып, ишегалдына алып чыккалыйбыз инде.

"Чапаев" фильмын өч тапкыр карадык. Кулак әтисенең явыз ниятләре турында хакимияткә хәбәр иткән пионер Павлик Морозов—безнең өчен үрнәк, үз аэропланында күпер астыннан очып үткән Валерий Чкалов—идеал. Шулай да, курку белмәс чик сакчысы Карацупаны яратарак төшәбез бугай, чөнки ул гадирәк, безнең өчен аңлаешлырак. Райбашкарма атларын караучы агай биргән көчеккә мин, Карацупага ияреп, Индус исеме куштым, ә Азатның бәләкәй эте Музгарка исемле. Рус язучысы Мамин-Сибирякның "Суыксу буенда кышлау" дигән иситкеч тәэсирле, ул чор мәктәп дәреслегенә дә кергән хикәясеннән бусы. "Акбай", "Сарбай", "Дүрткүз", "Актырнак", хәтта Такташның "Караборыны" кебек матур-матур эт исемнәре безгә ул чагында артык гадәти булып тоелган, күрәсең.

Жюль Вернның "Серле утрау" романы татар телендә өч китап булып басылып чыккач, Азат үзенең Музгаркасын "Серле утрау"дагы акыллы эт исеме белән Топ дип атап маташкан иде дә, ләкин Музгаркабыз яңа исемне колагына да элмәде, хәтта холыксызланды, шулай Музгарка көенчә калды. Их, Музгарка, Музгарка! Нинди тугрылыклы эт иде бит син... Хәер, бусы турында соңрак әйтермен әле.

Тагын бер балачак хыялыбыз бар иде безнең. Мәскәүдә бөтен дөнья күләмендә иң биек бина—Париждагы Эйфель манарасын гына түгел, мактанчык американнарның "күкне капшый торган" йортларын да уздырачак "Советлар сарае" салыначагы турында ишеткәч, шул сарайның иң биек җиренә менеп, "Ура!" кычкырасыбыз килә иде. Бу хыялый ният бездән тормаган сәбәпләр аркасында, тормышка ашмыйча калды...

Без гаиләдә ир-ат тәрбиясе күрмичәрәк, хатын-кызның йомшак кулы астында үстек. Чөнки әтиләр районнан кайтып керми, аларның гомерләре бетмәс-төкәнмәс җыелыш-киңәшмәләрдә, әллә ниткән бюроларда уза. Алар эштән кайтканда инде радионың кара тәлинкәсе шыгырдап арган була, бала-чага күптән таралып ятып йокы сүтә, әниләр генә зур мичле кухня бүлмәсендә сүнәр-сүнмәс җыр сузган самовар янында, терсәкләренә таянып, "Совет әдәбияты" журналын укып утыралар. Без исә аларның шом эчендә, ут йотып, афәт көтеп яшәгәнлекләрен аңламыйбыз, ни генә әйтсәң дә, без—"ответработник" балалары—тормыштан шактый ерак шул, шактый...

Вакыт-вакыт пыяла шкафтагы аерым китаплар юкка чыгып, киштә бушабрак кала, кайбер китапларда без күрмәгәндә рәсемнәр, фамилияләр үзебезнең өйдәге шәмәхә кара белән буяп ташланган була. "Халык дошманы", "корткыч" дигән сүзләрне әледән-әле ишетәсең, әмма боларның барысын да бөек, хөр, бәхетле, данлы ватаның белән, безнең хакта гел кайгыртып торучы даһи юлбашчы—Сталин бабай белән чиксез горурлану хисе күмеп китә.

СССР ның төп законын
үзе язган Сталин.
Син яшәсәң безгә рәхәт,
мәңге яшә Сталин!—

дип җырлый идек без бөтен класс белән. Ә СССР конституциясен Бухарин

белән Рютин төзегәнлекне кем генә белә иде сон ул чакта?

Китап киштәсеннән "Корыч бабай"нын "Ленинизм мәсьәләләре" дигән саллы гына һәм корыч төсендәге китабы юкка чыккач мин аптырабрак та калган идем калуын, ләкин бик тиз анын урынына шул ук китапнын яңа басмасы пәйда булды, тик ул бу юлы ситсы тышлы түгел, гади катыргыдан иде—мине бусы тагы гажәпләндерде. Димәк, шулай кирәк булган... Ә беренче, матуррак басмасынын янып бетмәгән тышлыгын мин учак көле арасында күрдем... Димәк, шулай кирәк.

Малай-шалай халкы арасында: "Сталин—ашамасан, кыстамыйм" дигән сүзне дә ишеткәнебез булды, ләкин өлкәннәр, куркыныч чакта башларын комга тыккан тәвә кошларыдай, бу сүзне ишетмәмешкә салышалар иде. Менә бүгенге акыл белән шул дорфарак сүзләрнен рифма өчен генә әйтелмәгәнлеген чамалыйсын.

"Халыкара сәясәт" мәсьәләсендә без Азат белән бер фикердә инде. Ул негрларны җәллибез, ул эскимосларны... Мисыр һәм француз хәерчеләрен, капкорсак байгуралар золымыннан интегүче тагын әллә кемнәрне. Ә миллионерларнымы? У-у, без аларны...

Мәктәптә, әлбәттә, "яхшы" һәм "бик яхшы" билгеләренә генә укыйбыз, безгә башкача һич ярамый, безнең уку алдынгысы булуыбыз әти-әниләрнең абруй-дәрәҗәсе өчен мөһим.

Азат белән арабыз бозылган чакны хәтерләмим. Бәхәсләшү, ярышу-узышуларсыз түгел, билгеле, ләкин яшь әтәчләр кебек кыдрачланып сугышканыбыз булмады.

Алай да... Бер мәлне, язгы жепшек көнне урам малайлары ике командага бүленеп, сугыш уены уйнадык. Төрлебез төрле "халык" булганга, бүленгәндә такмаза әйтеп санап бүленү, сыйнфый яктан димме, дөресрәк булачак иде. Ялгышмасам, безнен такмаза мондый иде:

Сагалдырык сары тай,
тугылдырык туры тай,
жиккән атым алмачуар,
тарыллаган тор да чык!

"Тарыллаган" сүзе ни мәгънәле булгандыр,—хәтеремнән чыккан, ә бәлки сүзен үк оныткаңмындыр.

Сыйныфка карамыйча бүленү аркасында Азат белән мин төрле командаларга эләгеп, мин "кызыллар", ә ул "аклар" ягында калдык. Менә шул чакны мин өер дигән нәрсәнен нинди зур психологик көчкә ия икәнлеген аңладым. Аңлый яздым дисәм төгәлрәк булыр. Өер берләштерә, туплый, укмаштыра, кешенең ихтыярын, шәхесен чикләп һәм йөгәнләп, күмәклеккә буйсындыра. Соңыннан дөнья мине, гомумән, фирка-партияләргә бик сак карарга өйрәтте, чөнки алар кешеләрне берләштереп кенә калмыйлар, бәлки, башлыча, берәүләрне икенче берәүләрдән аералар да. Партия дигән нәрсәкәй, асылда, хайвани өер инстинктына хезмәт итә, минемчә. Ә теге көнне мин иң эре кар йомарламнарын, усалланып, Азат дустыма төбәп аттым, ул да миннән калышмады. Минем кар ераграк оча, анын каравы Азат, житезрәк булу өстенә, турырак та бәрә һәм, гадәттә, икебезгә дә бер чама эләгә иде.

Ничектер абайламый калганмын, саллы бер йомарлам кар сул күземә килеп тимәсенме! Ачыттырып күземне ачкач, яна яуган кар, бәс сарган агач ботаклары кызгылт төскә кергән кебек тоелды. Азатка аркан борылып, жиргә тезләндем дә, салкын учым белән күземне капладым.

Әле генә "ура!" кычкырып, акыра-бакыра сөрән салган яшьтәшем атылып килеп житте:

—Илдар!—дип дәште ул гаепле тавыш белән.—Ач әле күзенне... Кан сауган! Әйдә, чаптык! Әни янына, парткабинетка, анда аптечка бар!

Парткабинет якын гына, өч-дүрт минуттан без Азатнын әнисе Шәфыйка апа янында идек инде. Ул сорашып-нитеп тормады, безне ярты сүздән аңлап алды, тиз генә графиннан су агызып минем күз

тирәләрен сөртте дә, күз кабагымны күтәреп карагач, җинел сулап куйды.

—Хәзер больницага барыгыз, окулист карар, мин шылтыратырмын. Йөгерегез!—диде.

Врач караганнан соң, икебез дә тынычландык шикелле.

—Ну, Наполеоннар,—диде врач апа,—әлләни куркыныч юк. Берике атнадан рәтләнер. Көн саен иртә-кич менә шушы рецепт белән алган даруны тамызырсыз... Шулай да, уеннан уймак чыкмасын өчен, сак булырга киңәш итәм,— дип бармак янады ул, елмая төшеп.

Нәкъ менә елмая төшеп, чөнки аның елмаюында ниндидер бер киеренке ясалмалылык сизелә иде.

—Ә кан...каны бетәрме?—дип сорады Азат.

—Бетәр. Эреп таралачак ул.

Чыннан да, өч атнадан күз бәбәгемә төшкән кызыл тап юкка чыкты. Моны миңа көн саен иртә-кичләрен зур лупа тотып күземне карарга йөрүче Азат беренче булып әйтте. Ничек шат һәм бәхетле иде ул бу кичне! Ә Азатның үзен гаепле санап кайгырып йөргүен, төннәрен йокы аралаш ыңгырашуын Шәфыйка апа минем әнигә сөйләгән. Боларын мин соңыннан, инде Азатны югалтканымнан соң гына белдем.

...Сәйдәшевләрне сентябрь азакларында, төнлә алып киткәннәр. Мин сабый йокысы белән изрәп йоклаганда, ишегалдына өсте ябулы машина—халык телендәге "кара козгын"—килеп кергән. Алдан ук әзерләнгән пүнәтәйләрне чакырып, квартираларында тентү ясаганнар, байтак кына китапларын, кәгазьләрен алганнар, аннары барысына да җылы киенергә һәм иң кирәкле нәрсәләрен генә алырга кушканнар...

Иртән уянганда мине өйдәге гадәттән тыш тынлык аптырашка калдырды. Радио сөйләми, кухня ягында әнинең табак-савыт шылтыратуы да ишетелми. Сәерсенеп торып утырдым. Инде яктырган булса да, залда нигәдер электр уты яна иде. Барып карасам, әти белән әни шунда утыралар икән. Ялан кыр шикелле зур өстәл өстендә аларның аксыл куллары, урын һәм шөгыль таба алмыйча, салмак кына кыймылдый...

—Илдар, кил, утыр әле,—диде шунда әти, күтәрелеп карамыйча гына.

Мин, инде тәмам тәшвишләнеп, урындык читенә килеп утырдым.

—Сәйдәшев абыеңны кулга алдылар... Нәрсәдә гаепләүләрен белмим, һәрхәлдә органнар әйбәтләп тикшерер. Гаепсез булып чыкса, әлбәттә, яңадан арабызга кайтыр. Ә хәзергә... гаиләсе белән бергә... читкә алып киттеләр...

Әтинең бу өзек-өзек сүзләре аңыма барып ирешкәч:

—Ә Азат?—дидем.

—Азат та... Менә әтисе аклангач, тагын бергә булырсыз.

Мин моңарчы аклар һәм кызыллар дигән төшенчәләрне генә белә идем, аклар дигәндә күз алдыма иң элек күкрәк киергән патша офицеры килеп баса иде: погонлы, мыеклы, кылычлы, явыз... Шуңа күрә әтинең сүзен аңламыйчарак тордым:

—Аклангач? Ничек инде аклангач? Ак гвардин кебек булгачмы?

—Юк ла, юк... Намусы пакь, чиста, ап-ак булуы тәгаен беленгәч.

Әни, мөлдерәмә яшьле күзләре белән миңа карап, ияген какты. Миннән бигрәк үз-үзләрен ышандырасылары килгәндер дип уйлыйм мин аларны.

Мин гомерем буе Сәйдәшевләрнең аклануын теләп яшәдем. Чынлыкта исә Сәйдәшев абыйның пакълеге исбат ителәчәк ирекле заманны көтеп яшәлгән һәм, ихтимал, шул көнне якынайту өчен кадәри хәл тырышылгандыр да.

Бу иртәне мин бик озак аңы-мине булып утырдым. Ә бераздан әни көчләп бер тустаган чәй эчерде дә, "артык сүз ычкындырма" дип кисәтеп, мине мәктәпкә озатты. Ишегалдына чыккач, Азатларның сыеры мөнрәп тавыш бирде бугай, ләкин мин әле һаман айнып житә алмаган

идем, көтүгә куылмый калган мәхлүк турында мәктәптә генә уйлап куйдым һәм шундук: "Ә Музгарка?" дигән зәһәр сорау миемне бораулый башлады. Нигәдер, белмим, бу сорау мина иң әһәмиятлесе булып тоела иде. Әгәр мин шуна жавап тапсам, бөтенесе дә ачыкланыр, бөтен сорауларыма жавап алырмын кебек иде.

Бу көнне минем башыма укытучыларнын ярты сүзе дә кермәде. Классташларыма рәхмәт—күз карашларында һәм тел очларында олы сорау билгесе сизелеп-күренеп торса да, төнге вакыйгалар турында ник берсе төпченсен. Ә бәлки алар миннән күбрәк тә белгәннәрдер? Укытучылар да мине тактага чакырмадылар.

Дәресләр беткәч, мин өйгә ашыкмадым. Кирмәнгә илтә торган таш юл буйлап авылны чыкканчы берүзем генә бардым да бардым. Инеш аркылы әле Николай патша заманнарында ук салынган күперне үткәч, күнелем сизгәнне, эзләгәнемне таптым...

Юл читендәге канау төбендә ак мангайлы бәләкәй Музгарканын канлы гәүдәсе ята иде.

* * *

—Менә, күр—Маяковский әйтмешли, "серпастый-молоткастый"!—диде мина Азат, һәм өр-яна паспортын сузды. Мин Азат Нәжип улы Сәйдәшевнен паспортын ачып карадым.

Фоторәсемендә ул чак кына яшьрәк күренә һәм анын чыраенда әүвәлге, минем хәтердә калган Азат чалымнарын да, шул ук вакытта ир уртасы Нәжип абыйга охшашлыкны да шәйләп була иде. Ә бит, баксан, бүгенге Азат кичәге Нәжип абыйдан өлкәнрәк инде... Икебез дә өлкән кеше хәзер... Күпкә тәжрибәлерәк тә... Без хәзер әтиләребезнен коточкыч нык ялгышканлыгын, самими рәвештә иблискә хезмәт итүләрен беләбез һәм моны белү Азатны да, мине дә вакытыннан элек чаларткан.

Әйе, мин Азатнын кечкенә генә фотосына йотлыгып карадым: күзләре шул ук, тик аларда әйтеп бетергесез моң бар, сагыш бар. Мангай сыры артык нык сызылган, чигә чәчләренә кырау төшкән инде. Ияге генә бирешмәгән: буйсынмаслыгын белгертеп, алга чыгыбрак тора.

—Синен тору кайда соң әлегә? —дип сорадым мин, Азатнын кулына кагылып.

—Кунакханәдә. Юк, Казаннын үзендә түгел, Яшел Үзәндә. Бер бүлмәле фатир вәгъдә иттеләр, менә паспорт күтәреп баргач ордер бирәчәкләр. Шул ук шәһәрдә, бүлмәне барып күрдем инде... Дөрес, беренче кат, кояш кичен генә төшә... Ләкин мин канәгать, тирә-юне яшеллек кенә...

—Яшел Үзән ил күләмендә иң чиста шәһәрләр исәбендә йөри... Ялгышмасам, былтыр ана хөкүмәт бүләге дә тапшырылган иде... Үзен ялгыз гына инде алайса?

—Ялгыз.

Чит жирләрдә оя кора алмаган, күрәсен.

—Матди якларын..? Кысынкы булса, мин ярдәм итә алам, Азат.

—Рәхмәт, кирәкми. Бераз хәстәрләгән акчам бар...

—Нинди эшкә урнашырга ниятен?

—Мин бит шофер. Йөк машинасы белән бөтен West Europa юлларын гизеп чыккан кеше. Аннары Schlosser...слесарь инде. Автогенчы эшен дә беләм. Ә болай... хәзергә автобазада слесарь эше тәкъдим иттеләр. Шунда барырмын, мөгаен. Аннары күз күрер...

—Жайланыр шәт. Алайса, сине берәү дә көтми?

—Көтәр кешем юк,—диде Азат.—Дөньяда япа-ялгыз мин.

—Киттек мина! Такси тотарбыз, ун минуттан миндә булырбыз, паспортынны да котлыйсы бар!—дип тезеп киттем мин, Азатка авыз

ачарга да бирмичә, чөнки аның баш тартуыннан курыктым.

—Ә син үзең... бирегә ни йомыш белән килгән идең соң?

—Мина бүген Югары Советның Мактау грамотасын бирергә тиешләр иде. Бирегә күнелем тартмаса да, үземне әкрен генә җәяүләп килергә мәҗбүр итүем, хәтта алдарак килүем дә сине очрату өчен булган икән... Язмыш дәфтәренә язылган кебек, әйеме?

—Әйе! Ә грамота... алдыңмы соң?

—Анысы башка вакытта... Грамота качмас. Аңа мөһер сугылган, штемпель белән кул куелган ич инде. Мин сине очраттым бит, сине! Аңлыйсыңмы?

Азат аңлый иде. Һәм минем эчкерсезлегемә ул беркайчан да шикләнмәде.

—Киттекме?

—Киттек.

Кайтышлый иркенләп сөйләшеп булмады. Алгы пыяласына генералиссимус Иосиф Жугашвилиның төсле портретын ябыштырган таксист янында ничек иркенлисең ди?! Әйе, әйе, торгынлык чорында диктатураны сагынып, залим Сталинның абруен торгызырга омтылыш югары даирәләрдә генә түгел, гомер-бакыйга каты куллы тәртипне һәм вакыт-вакыт үзен чыбыркылауны сөйгән, аркасындагы камчы эзләрен рәхәтләнеп кашый торган гавәм арасында да күзәтелә иде инде. КПСС Үзәк Комитетының беренче секретаре Никита Хрущевны "тәгәрәтеп", аның урынына яңа түрә килгәч һәм әүвәлгечә генсек дигән атаманы кайтаргач, матбугатта һәм радиода иплән-иплән кенә Сталин исемен хуплап телгә ала башлаганнар иде.

Ләкин үткәнне барыбер кайтарып булмый, инде хәзер төннәрен илгә "кара козгыннар" хуҗа түгел, һәрхәлдә ачыктан-ачык законсызлыкка бармыйлар сыман.

Илле тугызынчы елда Сәйдәшевләрне эзләп каравым нәтиҗә бирмәгән иде: Дәүләт иминлеге комитетында "ни өлкән Сәйдәшевләр, ни аларның балалары турында мәгълүмат юк", дип кире бордылар. Ләкин алтмыш беренче елгы тырышлыгым бушка китмәде. Мина Сәйдәшев Нәҗип Гәрәевичнең 1942 елның февралендә бөтенләй башка шәһәрнең төрмә больницасында дистрофиядән үлгәнлеген, аның хатыны Сәйдәшева Шәфыйканың 1941 нең көзендә үк йөрәк авыруыннан вафат булганлыгын әйттеләр. Ә Азатка һәм аның энеләренә килгәндә, төксе чырайлы КГБ вәкиле аларның кояшлы Украинадагы махсус балалар йортына озатылган булып, ул районның вакытлыча фашист оккупантлары кулында калуын әйтте. Шунда малайларның эзе юкка чыга... Үзебезнең Минзәләдә дә андый йорт булган югыйсә, ләкин нindидер серле мәнфәгатьләрдән чыгып, балаларны туган туфрактан аеруны кирәк санаганнар...

Бу вакытларда инде мин "Черек күл" тырнагына эләккән кешеләрнең нинди җәһәннәм сынаулары үткәнен яхшы белә идем. Кешенең маңгаена тимер кыршау кигезеп, шул эскәнҗәне миләрең колагыннан чәчрәп чыгарлык итеп боргычлауга, ишеккә кыстырып бармак сындыруларга, аягың гөбедәй шешенгәнче бастырып тотуларга, атна буена йоклатмауга түзә алсаң, акылдан язмасаң, үз-үзеңне белешмәстән, шашып, кансыз следователенә ташланмасаң,—шушы газаплардан соң да исән калсаң, гайярлегеңне, ихтыярыңны, шәхесеңне җуйдырганчы изәчәк этапларда һәм йомшак бәндәләрне көл вә тузан итә торган лагерьда да ник туганына, ник исән калуына үкенмәссең, дип сөйләде мина Колыма тәмугыннан котылып чыккан берәү, әдип кеше.

Сәйдәшевләрнең төрмәдә үк һәлак булуы, бәлкем, бәхетләредер? Кем белә? Һәрхәлдә әле яшьлек чибәрлеген саклаган Шәфыйка апа бер өер вәхшинең кешни-кешни мәсхәрә итүеннән котылгандыр.

Юк, бер-ике тамчы хәмер каба-каба тамак ялгап алгач, шыгырдавык диваныма утырып әңгәмә корганда мин боларны Азатка әйтеп бетермәдем, ләкин күреп торам: ул бөтенесен дә аңлый һәм тәфсилләп тормаганым

өчен рәхмәтле иде. Ул чакны минем сүзләрдән соң без озак кына дәшмичә утырдык.

* * *

Азат сөйләгәннәрне магнитофон тасмасына язып калмавыма хәзер үкенеп бетә алмыйм. Яшермим, ул вакытта мин Азат шикләнмәгәе дип тә курыктым, чөнки Черек күл шымчылары—сексотлар тагы баш калкыткан, активлашкан вакыт иде бит. Үземнең тирәдә дә Мурзаев фамилияле берәү, аннары әрсез журналист кисәге әйләнгәләп йөрделәр. Боларга каршы дәвасын таптым шикелле—һәр икесенә шымчылар турында бер үк анекдотны сөйләдем һәм—алланың фәрманы!—мине күргәч урамның икенче ягына чыга торган булдылар. Күптән түгел, шуларның берсен китап кибетендә туры китергән идем. Пенсиядә икән инде. Буйны табигать саранланып биргән булса да, кыяфәте генералныкы. Үзеннән, нигәдер, канәфер исе анкый. Дөньясы түгәрәк күренә. Кулына төргәге белән сәнгать альбомнары күтәргән. Андый төсле альбомнарны 120 сум совет пенсиясенә яшәүче кеше ала алмый... Димәк, каяндыр өстәмә акча килә мона. Беләсе иде, әле күпме икән безнең арабызда шундый алтын тешле елмаючан пенсионерлар?

Шулай да мин Азатка үз башыннан кичкәннәрне кәгазьгә төшерергә, тарих өчен сакларга киңәш иттем. Тарих сәхифәләренә кереп урнашырга лаек иде аның башыннан үткәннәре. Тиеш иде!

Ул чаларган башкаен чайкады.

—Ай-һай...—диде.—Нинди телдә языйм? Күрәсең ич, ана телемне онытып бетерә яздым, вата-җимерә сөйләшәм, русчам тагын сай, ә дойче... немец телендә язасым килми... Юк, туган, ят телдә озак, бик озак сөйләштем инде мин— туйдырган... Бәлки менә киләчәктә... Ана телемә күнегә төшкәч... Халык белән бераз аралашкач...

—Татарча матбугатны укырсың, татар әдәбиятын... Беләсеңме, бүген бит без яшь чакта тыелган һәм китаплары утта яндырылган әдипләрнең дә әсәрләрен баса башладылар. Галимҗан Ибраһимовны әйткән дә юк инде...

—Хәтерлим...—дип куйды Азат шул чагында,—Ибраһимовны хәтерлим мин... Аның китапларын кухняда ботарлап утка якканда әнинең—китапханәче бит!—ике күзе тулы яшь иде... Шул күз яшьләре кипкәнче эссе учак каршысында утырды... Ну, ватанга кайту ниятенә кергәч, мин мона ике-өч ел әзерләндем. Вакытлы матбугат соратып алгаладым, пластинкалар... Милли моңнарны яратам мин. Ә Илһам Шакировны... ничек диләр әле?.. үлеп яратам. Көн саен радио тыңладым.

—Казан начар ишетелгәндер бит?

—Юк, Казан анда ишетелми, кыска дулкыннарда Мәскәүне тыңладым. Natürlich, "Азатлык" радиосын. Кызганыч, бу радиостанциянең дикторлары татарча чиста сөйләшмиләр. Моны хәтта мин дә сизәм. Ләкин ана телен искә төшерү өчен ярап торды.

Озын кыйсса сөйләде миңа Азат.

Үзләрен, ягъни әтисе белән әнисен һәм йокылы-уяулы өч баланы "кара козгын"га төяп алып киткән мизгелдән башлады ул.

Таш юлда машина дырык-дырык сикерткәләп район үзәген чыгып киткәч, ул замандагы техникага хас булганча, мотор ике-өч тапкыр төчкергән дә сүнгән, машина ялан кырда шып туктаган. Сәйдәшевләрне һәм ике якта утырган ике сакчыны дөм караңгыда калдырып, фургон түшәмендәге бәләкәй лампочка да сүнгән. Зәңгәр фуражкалы агайлар, сукрана-сукрана, кесә фонарьларын кабызганнар. Кабина эченнән өлкәннәренең шоферга:

—Под трибунал захотел?—дип ырылдавы колакка чалынган.

Шофер, машинадан төшеп, калай капотны күтәреп, нәрсәдер майтарып маташканда кинәт кузовтагылар ярсып-ярсып эт өргәнен

ишеткәннәр. Музгарка! Азатның бәләкәч Музгаркасы, күрәсең, хуҗаларын алып киткән машина артыннан томырылып чапкан һәм менә хәзер аларны куып җиткән.

—Әти!—дип пышылдаган шунда Азат.—Музгарка бит бу!

Нәҗип абый Азатның иңбашыннан тоткан:

—Дәшмә, улым...,—дигән.—Дәшмә...

Шофер белән бергә кабинада утырган "опер"ның тагы аты-юлы белән сүгенгәне ишетелгән. Аннары опер машинадан төшеп, әткә: "П-шол!"—дип җикергән. Балалар әтиләре белән әниләренә елышканнар. Револьвердан аткан тавышка Музгарканың ачыргаланып чинавы кушылган. Икенче пулядан соң эт инде тавыш бирмәгән. Сәйдәшевләр Музгарканың ничек итеп бер урында бөтерелгәнен күрмәгәннәр...

—Музгарка шунда, басуда күмелгән...—дип бүлдерергә кирәк таптым мин Азатның сүзен.

—Син..?

—Мин аны үзем... җирләдем, Азат. Әрекмән яфрагына төреп... Шул көнне үк, дәресләр беткәч тә.

—Рәхмәт.

Тагы дәшми утырдык.

Машина иртәнге якта Кирмән шәһәрчегенә килеп кергән. Урамнарда тулганып йөри торгач, ниндидер ишегалдына кереп туктаганнар. Фургонның арткы ишеге ачылып, түшәмдәге тычкан уты урынына күзгә кояшның күз камаштыргыч яктысы ургылып кергән һәм оперның:

—Арестованный Сәйдәшевләр! Балалар белән саубуллашыгыз!—дигән карлыккан тавышы ишетелгән.

Шәфыйка апа шунда гына елап җибәргән. Нәҗип Сәйдәшев бер кулы белән хатынын, икенчесе белән бер-бер артлы малайларын кочкан.

"Шушы минуттан мин үземне энеләрем өчен җаваплы итеп тойдым,—дип сөйләде Азат.—Мин инде ятим икәнебезне, әти белән әниебезне беркайчан да, беркайчан да күрмәячәгебезне аңладым..."

"Мин Робертның күшеккән бармакларын Айдарның чак кына зуррак учына салдым..."

"Колак төбемдә әнинең үкси-үкси елавы һаман ишетелеп тора. Әтинең: "Бирешмәгез! Өметегезне җуймагыз!" дигән әллә боерыгын, әллә васыятен онытасым юк."

"Идәненә бер илле былчырак каткан коридор һәм тәрәзә пәрдәләренә тәмәке исе сеңгән кысан бүлмәләр, керле гимнастеркалар, кыршылган портупеялар, бетмәс-төкәнмәс кәгазьләр тутыру, кешечә елмаюны оныткан һәм теш аралаш кына сөйләшә торган бәндәләр, көне буе ач тору..."

НКВДшникларның телефоннан сөйләшкән өзек-өзек сүзләреннән Азат үзләрен каядыр еракка, махсус балалар йортына озатырга җыенуларын аңлый. Чыннан да, чолан шикеллерәк бер бүлмәдә, өсләренә майда катып беткән телогрейка ябып, бик астында кундырганнан соң, икенче көнне иртүк балаларны, "кара козгынга" утыртып тимер юл станциясенә алып китәләр.

Юк, аларны гомуми вагонга, иректә граждан-нар арасына утыртмыйлар. Товар поездына паровоздан соң ук тәрәзәләре тимер рәшәткәле өч вагон тагылган була, аларның баштагы икесе ЗЭК лар өчен, ә иң соңгысы арестантларны озата баручы каравыл өчен икән. Балалар шушы вагонга эләгә. Шушы вагонда алар әтиләрен кулга алган оперны кабат очраталар. Байчурин Шәрәф Низаметдиновичны.

Малайларны дүрт урынлык купенең бер өске сәндерәсенә торткали-торткали менгерәләр һәм йомыш булганда гына төшәргә рөхсәт итәләр. Бармак янап кисәтәләр, аяк салындырып утырмаска кушалар, ә калган өч урында күрше вагоннарда "эшләп" арып кайткан каравылчылар чиратлап гырлый. Алар шушында ашыйлар, эчәләр, кәрт сугалар һәм,

әлбәттә, тәмәке тарталар. Ин әшәке сүгенү сүзләрен һәм, ничек кенә гаҗәп тоелмасын, "антисовет" анекдотларны Азат шулар авызыннан ишетә.

Поезд Казанга, каравылчылар әйтмешли, багана төбе саен туктый-туктый, көне буе бара.

Кичкә таба купега таныш опер килеп керә. Конвой белән чагыштырганда тышкы яктан интеллигент күренсә дә, шакшы телле кеше икәнлеге аның да чыраена, зур авызы тирәсендәге эре жыерчыкларга язылган. "Ул кергәч, кәрт сугып утыручылар өстәлне тиз-тиз генә жыештырдылар, ләкин яртылаш бушаган шешә белән сынар стаканнары шунда калды",— дип сөйләде Азат. Әмма бу юлы опер сыйланып-нитеп маташмаган.

—Иминлекме? Тәртип бозмыйлармы?—дип сораган ул, балалар яткан киштәгә ымлап.

—Детенышлармы? Тыннары да чыкмый.

Шул вакытта Роберт буыла-буыла ютәлләргә тотынган, укшый башлаган.

—Карагыз аны, исән-имин килеш тапшырасы аларны...

—Ничего... Түзәрләр... Бер кышка куян бүрек тә чыдый...

Юк, балта элеп куярлык һаваны сулый торгач, Робертның түзәр әмәле калмаган, күрәсең. Ул, башын сәндерәдән сузып, тегеләрнең өстенә косып жибәргән...

—Ах син, эт баласы!

—Юри коса ул, дуңгыз!—дип бакырышканнар купеда.

Кирәк бит, нәкъ оперның көзгедәй ялтыратылган хром итеген һәм коверкот гимнастеркасын пычраткан Роберт. Тегенең интеллигентлыгыннан жилләр искән:

—Ну, засранец!—дип, келәшчәдәй бармаклары белән сабыйның колагын эләктереп алган.

Калганнарын Азат бик үк хәтерләп тә бетерми. Ул, тезләнеп утырган жиреннән очып барып, опер Байчуринның жилкәсенә килеп кунган, аның ялтыр күнитеге кебек үк көяз фуражкасын бәреп төшергән дә, чытырдатып чәченә ябышкан. Ул ара да булмаган, Айдар сикереп төшеп, үзенә ягылган беренче явыз кулга тешләрен батырган... Роберт та тик ятмаган, әле быел гына сатып алган ботинкасын, кай арада салып, бәләкәй өстәлдәге шешәгә тондырган.

—Миндә ниндидер бер кыргый көч, ерткыч хайван уянды,—дип сөйләде Азат.—Мин хәтта үземне типкәләгәндә тәнем авыртканны да тоймадым башта. Инде кулларымнан каерып алгач та, кайсысыныңдыр чыраена төкердем, үзем бертуктаусыз: "Гады вы, гады..",—дип кабатладым.

Менә шулай бер минут эчендә гамьсез һәм кан күрү белән коелып төшә торган жыбытты малайдан үзен һәм энеләрен яклау өчен бөтенесенә әзер торучы ир-егеткә әйләнгән ул. Азат кына түгел, соңгы ике көн эчендә авызларыннан ярты сүз дә чыкмаган энеләре дә баш калкытканнар. Бала күңеле өчен күтәргесез авыр тормыш тукмагы китергән психологик шоктан аларны шушы бер мизгел чыгарган. Дөньяның асты-өскә килгән һәм... бөтенесе үз урынына утырган. Кемнең дошман булуы ап-ачык хәзер! Ә кая соң дуслар?

Азатның кулларын артка каерып каеш белән бәйләгәннәр дә тәрәзә янына утыртканнар, ә Айдарны кабат өскә ыргытканнар.

—Алма агачыннан ерак китми...,—дип, фуражкасын каккалаган Байчурин.

—Үсеп кенә житим, киләгенне билелем!—дип йодрык төйнәгән ана Роберт.

Бу каләр үк үжәтлекне көтмәгән опер тешләрен шыгырдаткан:

—Ничава, үсеп житмәссен, манкалавыч...—дигән,—Не вырастешь!

—Бүре баласын бүреккә салсан да урманга карый...—монысын Айдар тешләгән бармагын ялап утыручы надзиратель әйткән.

Дөрес әйткән төрмәче. Шул көннән абыйлы-энеле Сәйдәшевләр бүре балаларына әйләнгәннәр, чөнки шакаллар арасында башкача исән

калып булмаячагын акыл белән түгел, бәлки ниндидер бер эчке тоем, кеше күңелендә гасырлар буе йоклап ята торган һәм ятарга тиешле хайвани инстинктлары белән аңлаганнар алар.

Баш кутәрүнең файдасы озак көттермәгән. Берәр сәгатьтән купега конвой башлыгы, күрәсең, боларның иң зур түрәләре, кереп чыккан, фетнәче балаларга сөзеп-сөзеп карап торган да:

—Кулын чишәргә. Бик астында тотарга!—дип боерган.

Шуннан соң конвой купены бушаткан һәм малайлар үзләренә хуҗа булып калганнар. Әмма, чекистлардан берсе, урта яшьләрдәге мыеклы абзый, инде чыгып барган җиреннән капыл туктаган да, рюкзагын чишеп, өстәлчеккә шап итеп бер буханка кара ипи бастырып куйган, шуңа кул яссуы кадәр сало өстәгән һәм:

—Ну, хлопчики, сау булыгыз!—дигән.—Бывайте...

Тегеләр ишекне тышкы яктан махсус ачкыч белән бикләп маташканда, бәләкәй Роберт беренче тапкыр елмайган кебек итенгән. "Ләкин аның елмаюы җинүче, тантана итүченеке кебек куанычлы түгел иде, бу самими үчле көлемсерәүнең суыгы минем йөрәкне өшетте,"—диде Азат әкрен генә.

Роберт аны тагы бер сабыйларча соравы белән аптырашка калдырган.

—"Бывайте"—ни ул татарча?—дип сораган ул, чөнки балалар бакчасында гына откан русчасы житәрлек булмаган әле.

—Ишеттең ич, ул безнең сау булуыбызны теләде,—дигән аңа абыйсы.

Сабый башын чайкаган: "Юк, ул безнең булуыбызны теләде...,"—дигән. Робертның бу сүзгә нинди мәгънә салганлыгын хәзер инде белеп тә булмый...

Балалар иркенләп, ләкин рәшәткәле тәрәзәдән генә карап, күзге ямансу, үзенә бер бәйрәмчә булган чуар табигатьне күзәтеп барганнар. Инде Казанга ерак калмаган. "Дәрвиш" дигән жирдә озак кына туктап торганнар. Монда аларга татлы тәм килә торган жылымса чәй эчергәннәр.

Казанда озак юанмаганнар. Вагонны каядыр тупикка илтеп керткәннәр. Балаларның документлары төрле инстанцияләрдә йөргән, ә үзләре салкын купеда язмыш дәфтәренә язганны көтеп утырганнар. Мыеклы агайның арыш ипие белән тозлы салосы шунда бик тә ярап куйган.

Вагонны каравыллап калган надзиратель сәгать саен ишекне ачып:

—Ну, кролики, живы? Ладно!—дип боларны барлап торган.

Шулай да ике-өч тапкыр туалетка алып барган.

Кичкә таба вагонга кабат җан кергән. Вагон янына ук өсте ябулы машина китереп туктатканнар. Башта кузовтан шинель кигән ике хатын, аннары ике ир сикереп төшкән. Шуннан соң исемлек буенча кычкырып, һәркайсы бәләкәй генә төенчек тоткан тугыз кыз баланы төшергәннәр, вагонда барачак каравыл аларны үз исемлеге буенча тикшереп кабул иткән. Кыяфәтләренә, үзләрен ничек тотышларына караганда, бу кызчыклар һичшиксез "халык дошманнары гаиләсе"ннән инде. Күзләрендә биниһая куркудан башка берни чагылмаган гөнаһсыз, гыйффәтле, пакь кыз балалар... Аларны вагонга кертеп, күрше купега тутырганнар. Ахырда машинадан төрлесе төрле яшьтәге бер дистә малай төшкән. Болары инде тererәк. Болары инде тешләк булырга тиеш!

* * *

Ике атнадан Азат миңа телефоннан шылтыратып фатирга ордер алганлыгын, бүген үк шунда күчәчәген, аннары таксопаркка автослесарь булып урнашуын әйтте. Мин аны котладым, әгәр мөмкин булса, рөхсәт итсә, барып чыгармын, дидем.

—Шушы якшәмбедә үк киләсең!

Ул төгәл адресын әйтеп, координатларын күрсәткәч:

—Табармын, шәт!—дидем.

—Юк, юк! Мин сине вокзалда каршы алам, чөнки шактый ерак, автобуска утырырбыз, ул безнең йортка каршы базар янында гына туктый,—дип аңлатты Азат.

Шулай килештек тә.

Якшәмбе көнне, Азат әйткән автобустан төшкәч, беренче эш итеп мин аңардан өй өчен нәрсә кирәклеген сорадым. Ул инде кухнясын җиһазлаган, иркен генә бүлмәсенә сары фанер гына булса да, зур көзгеле шифоньер бастырып куйган икән. Мин аңа бүләккә стена сәгате алырга тәкъдим иттем. Ул баш тартмады, елмайды гына:

—Гомер узганны санасын дисең инде..?

—Санасын... Хәтерлисеңме, сезнең бик матур суга торган сәгатегез бар иде?

—Бар иде шул... Ул сәгать кая китте икән?—диде дә уйчанланып калды Азат.—Беләсеңме, циферблатына "Густав Беккер" дип язылган иде аның. Донбасста өйләнешкәч, әтинең беренче сатып алган малы шул булган...

—Сезнең бар мөлкәтне комиссиягә куеп саттылар... Сәгатегезне "Потребсоюз" рәисе бик ошаткан дип сөйләгәннәре хәтеремдә. Калганын белмим. Безне дә тиздән башка районга күчерделәр, аннары өенчесенә... Шуңа күрә минем туган-үскән авыл дип әйтерлек җирем дә юк... Мин туган унбиш йортлык авыл колхозлашу елларында ук юкка чыккан...

Белгәнемчә, Азат Сәйдәшевнең дә туган авылы юк иде. Ул Донбасста, соңыннан Шахты шәһәренә күчеп киткән бер шахтерлар поселогында дөньяга килгән. Аннары әтисен укырга җибәргәннәр, укуын тәмамлагач, җитәкче кадр буларак Татарстанга кайтарганнар...

Азатның фатирын котларга сәгатьне базардагы кибеттән таптым. Шуңарга өстәп, яңа ачылган китап кибетеннән калын гына "Татарча—русча сүзлек" сатып алдым.

Кайтып кергәч тә, бүлмәдә түр почмакта уңай урын табып, Чиләбедә эшләнгән шактый зур сәгатьне элеп куйдык, аннары инде ярты сәгать үткән саен аның тырышыпмы-тырышып, нәрсәләрендер җуылдатып, шыгырдатып, ашыкмыйча гына, чак кына сакаурак тавыш белән сукканын тыңлап утырдык, шул чакларда бик тә канәгать булып, балаларча куанып, ни өчендер бер-беребезгә күз кысыштык...

Һәм менә без кабат кырык елны (бу вакыт эчендә Азатларның "теге" моңлы сәгате чит-ят кешеләр өендә ничә тапкыр суккандыр? аның моңын аңлаучы булгандырмы?—боларын уйлавы да куркыныч!) кире чигереп, дөньядагы барча халыкларның юлбашчысы даһи Сталин җитәкчелегендә, ярыша-ярыша, көннән-көн ишәя генә баручы дошман өерен җинә-җинә, корбан арты корбан бирә-бирә, "коммунизм кыры күренә" башлаган әкәмәт заманаларга әйләнеп кайттык.

Азат хикәясен узган атнада өзелгән җиреннән башлап дәвам итте.

...Балаларны каядыр көньякка алып китәргә тиешле вагонга кичкә таба җан кергән. Башта күрше купега кыз балалар кереп урнашкан, аннары чират "Сәйдәшевлар купесы"на җиткән. Төрлесе төрле яшьтәге, төрле милләттән булган малайларны өчәр-өчәр итеп башта ике сәндерәгә, аннары тагы өчесен аска—Азатларга каршы урнаштырганнар. Иң ахырда кергән калкурак буйлы малай, ишек ябылуга ук, монда кемнең хуҗа икәнлеген күрсәтмәкче булган:

—А ну, ыбыр-чыбыр, марш өскә!—дип башта Айдарга, аннары Робертка төртеп күрсәткән.

Азат әкрен генә торып баскан:

—Ә син кем?

—Һо-о! Бусы ниткән камыр батыр тагы?—дигән әлеге малай.—Нәрсә, күз төбеңдәге бер фонарь гына җитмәгәнмени? Тагы бирәү кирәкме? Мурзаев абыең ипи шүрлегенә дә менеп төшәр, күп сорамас!

“Мин мона уйлап-нитеп, әзерләнеп торырга вакыт калдырмадым,— дип сөйләде Азат Сәйдәшев.—Үзен Мурзаев дип күкрәк төйгән бу малай актыгы миннән гәүдәлерәк иде, ихтимал көчлерәк тә булгандыр. Мин чак кына иелә төшеп, ун аягымны утыргычка терәп, башым белән аның күкрәк турысына кадалдым... Мурзаев каршы яктагы утыргычка капланып төште, арт чүмече белән стенага бәрелде, ә мин аңа менеп тә атландым.”

—Биреләсеңме?—дигән Азат хужа булырга яратучы малайга, тавышын булдыра алган кадәр усалландырып.

Тегесе хырылдаган гына.

—Биреләсеңме?

—Җибәр...

—Ну?

—Биреләм...

—Абый дип әйт!

Арттан Айдар тавышы ишетелгән:

—Абыкаччаем дип әйтсен!

“Илбасар”ны шулай тәмам хурлыкка төшергәч кенә купега надзирательләр кереп, тәртип урнаштырырга тотынганнар. Сораштыра башлагач, купедагы малайлар беравыздан Азатны яклап чыкканнар. Күрәсең, ялт та йолт күзле, атаманлыкка омтылган үсмер боларга электән таныш булган, каннарына тоз салып өлгергән инде.

Ни гаҗәп, Мурзаевны шундук җилтерәтеп алып чыгып киткәннәр һәм, әйтүләренә караганда, “изоляторга” япканнар. Хәер, моның изолятор түгел, хәтта җәза да булмаганлыгын балалар соңыннан гына белгән...

Төнлә вагонны ниндидер бер составка такканнар. Ләкин Казаннан китеп бер әр сәгать үтүгә “Васильево” дигән җирдә туктап торганнар. Азат биредәге такта вокзалны, биек-биек тупылларны, шулардагы бихисап һәм чуман кебек зур карга ояларын истә калдырган.

Идел аркылы салынган тимер күпернең озынлыгы авыл балаларының исләрен китәргән.

Аннары, Саранскида ахрысы, тагын бер ялыктыргыч тукталыш. Монда янә бер купега балаларны утыртканнар. Аннары Пенза шәһәре... Тагын ниндидер шәһәр-шәһәрчекләр... Вагон бала-чага белән тулган. “Халык дошманнары” бер Татарстанда гына мыни?

Поезд балаларны туган туфрактан көннән-көн ераграк алып китә. Көньякка, көньякка! Әле генә торналар торкылдашып киткән җылы якларга... Җылы микән анда, күнелләргә җылы керер микән? Нигә соң паровоз кычкырткан саен йөрәк талпына, алгысына икән? Нәкъ торналар тавышын ишеткәндәге кебек тыпырчына...

Көннәр тыныч узган. Купедагы малай халкы беренче минуттан ук Азатны бәхәссез лидер итеп таныганга, арада бернинди каршылык килеп чыкмый. Иртән ипи телемнәрен бүлешкәндә, алама одеял өчен тартышканда, гомумән, андый-мондый ризасызлык туа калганда, һәммәсе күз карашы белән генә булса да Азатка мөрәҗәгать иткән. “Мин берәүне дә рәнҗетмәдем,—дип сөйләде Азат.—Кемне дә булса кимсетергә, кеше өлешенә керергә дә юл куймадым. Беләсеңме, мин үземне ниндидер бер кыргый африкан кабиләсенең юлбашчысы итеп тойдым. Миндә хәтта башкалар өчен кайгырту, җаваплылык хисе туды. Шулай, без—күбебез совет номенклатурасы балалары—изләшеп киттек шикелле.”

Ахырда Киевкә килеп житкәннәр. Киевкә дип, монда да алар тарихи шәһәрнең үзен күрмәгәннәр, төнге карангыда вагонны Киев каласының “абзар артында” туктатып, балаларны исемлек буенча санап төшергәннәр, санап кабул иткәннәр, санап дүрт “полуторка”га төягәннәр. Гади йөк машинасында утыручыларны кеше күзеннән яшерү өчен чекистлар бик ансат юл уйлап тапканнар: ян-як бортларга, алга һәм артка табаклы фанер кадаклап куйганнар. Әлбәттә, кузовка икешәр кораллы конвой утырган. Аларның артсыз урындыклары булган, ә балалар юка гына итеп түшәлгән кылчыклы саламга тезелешеп ятканнар.

Шул рәвешле малайлар кич буе дүрткел күктә атылган йолдызларны санап барганнар. Һәрхәлдә Азатның күзенә йокы кермәгән.

Ярты юлда тукталыш ясап, малайларны уятканнар һәм, берәм-берәм машинадан төшереп, юл буендагы куак төпләрендә йомышларын үтәргә кушканнар. Шулай да Азат Робертны үзе белән алып төшкән.

Малайлар бер хәл, ә алгы машинадагы кызлар аерым-аерым төшүдән баш тартканнар ахрысы. Шуна аларга өчәр-дүртәр булып төшәргә рөхсәт ителгән, оялчан кыз балалар бер-берсен әрсез ай яктысыннан каплабрак торганнар.

Аннары машиналар колоннасы юлын дәвам иткән. Баш очында күренгән йолдызлар да үзләренең мәңгелек юлларында булганнар. Таң яктысы сызыла башлаганда Азатны борчулы, саташулы йокы баскан. Менә шул тынычсыз йокысында ул сәер бер төш күреп өлгерә. "Имеш, үзебезнең зал бүлмәсендә көзге каршына килеп басканмын. Ни гаҗәп: көзгедә берни күренми! Анда хәтта минем арттагы тәрәзә дә, чуар пәрдәсе дә чагылмый иде,—дип сөйләде Азат әчке бер калтырану белән.— Бушлык...упкын...томан... Мин, аптырап, көзгегә якынрак килдем һәм шунда гына, эремәгә салган фотокәгазьдә сурәт ачыла барган кебек, көзгедә миңа бик таныш йөз пәйда булды... Ышанасыңмы, ул син идең... Һәм син миңа кулларыңны суздың... Мин уянгач та дөньяда дустым бар икәнен, синең кул җылысын тоя идем әле. А, нинди шифалы, нинди сагышлы, нинди авыр тойгы бу..."

Шул чагында, әйтерсең лә безнең төкәнмәс гәпкә кушылгандай, Чиләбе сәгате тавыш биреп куйды.

...Күрәмсең, килеп җитүләре булгандыр, башта хәрбиләрчә өзек-өзек сөйләшкән тавышлар ишетелгән, шалтыр-шолтыр тимер капка ачылган һәм, машиналар туктагач, Азат торып утырган. Башкалар да уянып, киерелгәли һәм күзләрен уа башлаганнар.

—Ну, малайкалар, приехали! Җыеныгыз!—дигән надзирательләрнең берсе, Татарстаннан ук килгәне.—Па-адъ-ем!

Халык дошманы дип игълан ителгәннәрнең балалары өчен махсус оештырылган ятимнәр йортындагы тормыш шулай "подъем"нан башланган.

* * *

"Номер 3" дип кенә билгеләнгән бу учреждениене, урта гасыр кальгалары көнләшерлек итеп, ярга бүрәнәләрдән өйгән ике метр ярым биеклектәге тоташ коймa белән әйләндереп алганнар һәм аның өстеннән бала йодрыгы хәтле фарфор изоляторларга беркетеп ике буй чәнечкеле чыбык сузганнар. Бу чыбыклар электр тогына ялгана дип кисәтсәләр дә, малай халкы моның алай ук түгеллеген, куркыту өчен генә әйтелгәнен бик тиз ачыклый, ләкин, әлбәттә, хәйләләп, белми торуның бәлки кирәге чыгар дип, ышанган булып кылана...

Мона каләр бу урын өлкә җитәкчеләренең ял итү урыны булган икән. Биредә торак биналар, хуҗалык каралтылары, ат абзары, водокачка, зур мунча, бассейн, фонтаннар, чәчәклекләр, медпункт, кибет, ашханә, китапханә, радиоузел, кино залы, бию мәйданчыкларына кадәр булган. Өлкә комитеты секретаренең дачасы ике катлы, ике верандалы, балконлы, анда хәтта ике өстәлле биллиард уйнау бүлмәсе дә каралган. Ваграк дәрәҗәле түрәләрнең йорты, әлбәттә, тыйнаграк, гадиерәк, тәрәзәләре дә бәләкәйрәк сыман. Коймага килгәндә, ул да элеккедән калган, номенклатур агайларның хосусый һәм шәхси тормышын халык күзеннән яшерү өчен корылган икән.

Ил беркадәр аякка баскач, совет кенәзләренең аппетитлары да көчәя, рәхәткәияләшкән саен, зәвык-ихтыяҗлары да үсә. "Ял база"сын күрше өлкәдәге матуррак җиргә, Днепр буена күчерәләр һәм акпулатларны

шунда төзиләр, бу территорияне үзләренә яшь алмаш әзерләү өчен пионер лагерена бирергә карар чыгаралар, ә ахырда, ихтыяҗ тугач, ул "Спецдом"га әйләнә. Түрәләргә хезмәт күрсәтүче персоналның кулай дигәннәре, ышанычлылары яна урынгаияреп китә. "Түбәнрәк сортлы"ларын да гел бетереп ташламыйлар, шушында төрлесенә төрле шөгыль табалар...

—Бер-ике айдан тормышлар үз эзенә төште кебек,—дип сөйләде Азат.—Кышка безгә җылы кием бирделәр. Иртән ишегалдына чыгарып тезеп, физзарядка ясаталар иде. Өстә әллә кемнән калган бушлат, аякта олтан салынган киез итек, ә без тырышыпмы-тырышып физзарядка ясыйбыз. Бәләкәчләрнең бушлат чабуы җирдән өстерәлә, җиннәреннән куллары да күренми бичаралларның. Ул кызларның ничек интегүен күрсән... Тамаша... Мин менә хәзергә тикле шуны аңлый алмыйм: мондый физкультураның кемгә кирәге булды икән? дим. Җитмәсә әле, физкультура укытучысы, Наливайко фамилияле бәндә, җикеренә, сүзен тыңламаганнарны алып калып "по-пластунски" үрмәләтә иде... Без аңа "Чумак" дигән кушамат тактык, чөнки ул эпилепсия белән авырый һәм кайчагында авыруы безнең каршыда "тота"—кинәт яман ачы тавыш белән кычкыра да җиргә егыла, бәргәләнә башлый иде. Хәтта бер мәлне, по-пластунски шуышкан җиремнән торып, Чумакка ярдәм итәргә туры килгәне дә бар. Югыйсә ул телләрен тешләп бетерә, астын юешли иде, мәхлук. Чумак кайчандыр оста парашютчы булган икән дигәннәре исемдә.

Иртәнге яктагы тәрбия сәгатьләрендә байтак вакытны политинформация ала иде.

Политинформаторыбыз—завуч Петр Митрофаныч Петух—шагыйрь кеше булып чыкты. Һәр бәйрәмгә Иосиф Виссарионович Сталинны мактап бер шигырь яза да, шуны безгә ятлата иде. Ә үзе ул "Евгений Онегин"ны тулысынча яттан бикләгән һәм җае чыккан саен безгә укый иде.

"Мин Пушкинны шул Петух аркылы гына беләм,—дип елмаеп куйды Азат,—Кыш, яз турындагы гүзәл шигырьләрен әле дә булса хәтерлим. Шунар азмы-күпме рәхмәтлемен..."

Мондагы тагы бер истә калырдай кеше культмассовик Соня булган. Ат караучы мыеклач Вася дәдәй Соняны "Ял базасы"нда эшләп йөргән чагыннан ук белә икән. Ул бирегә массажистка булып килгән. Кыска җиңле ап-ак халат киеп, таза, көчле, матур беләкләрен күрсәтеп йөргән җиләктәй кыз булган әле. Якындагы хуторда туып үскән. Әмма Өлкә комитетының беренче секретареннан башлап гади бүлек мөдирләренә кадәр матрас булып ята торгач, түбәннән-түбәнгә тәгәрәгән Сонечка. Таушалган. Базары төшкән. Эчүгә бирелгән. Аннары аны кинозалга беркеткәннәр, чәчәкләр өчен дә җаваплы иткәннәр бугай. Азатлар заманасында инде "детеныш"ларның культуралы ялын тәэмин итүче массовик дәрәҗәсенә күтәрелгән һәм иртәдән алып кичкә кадәр кызмача йөри торган Соняны балалар "Нормальный ход" дип атаганнар. Әллә исереклеген сиздермәскә тырышып бәдәнен гел киеренке тотып атлаганга, әллә башка бер сәбәптәнме—монысын Азат хәтерләми инде.

—Системаның тагын бер корбаны..,—дип әйтә куйдым мин.

—Әйе. Ләкин кыз балалар "Нормальный ход" безне күздән яшь чыгарлык итеп чеметә дип зарланалар иде...

—Массажистка гадәте..? Садистка?

—Белмим. Массовик буларак, ул "ватык телефон" уеныннан башканы белми иде, әлбәттә...

Декабрь башларында, "Сталин конституциясе" көненә туры китереп, балалар йортына "Павел Корчагин" исеме бирелә. Бу турыда урындагы хакимият карарын тантаналы линейкага тезелгән балалар каршысында яңгыравыклы тавыш белән, зәвыклап, илһамланып завуч-шагыйрь Петух укый. Аның белән янәшә пионер галстугы таккан мәгърурәнә Сонька, җиңенә кызыл бәйләгән физкультура укытучысы "Чумак" басып торалар. Ахырда балаларны кул чабарга мәҗбүр итәләр. Аның каравы кичке чәйгә

"борын саен" берәр ябышкак карамель эләгә.

Шул көнне Азат төш күрә. Имеш, ул Павлик Морозов икән. Имеш, әтисе—халык дошманы турында Азат әләк язып, ялтыр күнитекле оперга тапшыра... һәм шабыр тиргә батып уяна. Нәкъ шушы көнне ул Робертка гомерендә беренче һәм соңгы тапкыр суга, чөнки сабый күңелләрне агулый торган "политәнгәмә"дән соң әтисен "халык дошманы" дип атый. Аннары Азат энесен кочаклап жылый, икесе дә, юк—өчесе дә—маңгайларын маңгайга терәп жылыйлар. Роберт абыйсын юатырга тотынып: "Юк, әтиебез дә, әниебез дә халык дуслары!"—дигәч кенә Азат белән Айдар елмаеп жибәрәләр...

Спецдомда күпчелек балаларга яңа фамилияләр бирелә: Советский, Уральский, Казанцев, Москвин, Комиссаров һәм тагын әллә нинди ләр. Шул рәвешле Сәйдәшевләр Казанцевларга әйләнә дә куя. Янәшә корпустагы Ганжә исемле кызга да Казанцева фамилиясе тагалар.

"Ганжә—Галя, Галка..."

Ганжәне Азат яхшы хәтерли. Әнә ничек матур итеп елмайды ул Ганжә—Галя исемен әйткәндә. Күрәмсең, спецдомда Ганжәне Галя—Галка дип йөрткәннәр...

Ганжә вагонга Казанда ук утырган тугыз кызның берсе икән. Аның әтисе Татарстан башкаласында утызынчы еллар башыннан ук зур "Авиастрой" төзелешендә инженер булып эшләгән, ел саен мактау грамоталары алып килгән, партконференцияләрдә делегат булып катнашкан. Ләкин 1932 елда Саба дигән авыл жирендә, социалистик ярыш жәелдереп, "Авиастрой" төзелеше өчен ун мен кием чабата житештерелүен тәнкыйтьләп, "Авиастрой"га ботинкалар кирәк дип сөйләгәне өчен аны берничә ай таш капчыкта яткырып чыгаралар. Аның бу "гөнаһын" органнар инде беркайчан да онытмыйлар, жиде елдан соң, янә дошман эзләү кампаниясе кузгалгач, НКВД козгыннары аны төнге сәгать икедә алып китәләр...

Бирелдәге кызлар әле бала гына булганга, бәдәннәре тулышып, түгәрәкләнеп житмәгән. Аларны Сонька "утын пүләннәре" дип үрти. Ә Азат Ганжәнең матурлыгын,—ә бәлки иртәгә генә чәчәк атасы матурлыгындыр,—тоя инде. Кызганыч, аларга аралашырга туры килми, шул кино караганда, үзләре оештырган концертларда гына малай шомырт кара күзле, озын толымнарын ике уч төбе хәтле аркасына салган бу кызчыкны читтән генә сокланып күзәтә. Сөйләшкәннәре булмаса да, исәнләшеп йөриләр, ни әйтсәң дә якташлар һәм, өстәвенә, адашлар, ягъни фамилиядәшләр бит.

Язга таба алар танышып киткәннәр. Бусы болай булган.

Балалар колониясендә Мурзаев дигән юньсез малай да бар бит әле. Поездда бәргәләшеп алганнан соң Азатның Мурзаев белән юллары бүтән кисешмәгән. Алар төрле корпусларга эләккән, бригадалары да төрле булган, ә очраклы рәвештә күзгә чалынса, Мурзай "Азат абыкаччаен" күрмәмешкә салышкан. Үч тота торгандыр, әлбәттә. Андыйлар үлгәнче үч саклый, диләр бит. Ни сәбәптәндер әүвәлге фамилиясендә калган Мурзаев үз тирәсенә алты-жиде үсмер малайны туплап өлгергән. Алар инде кечкенәләр өлешенә дә кереп, хәтта ашка салынган барлы-юклы ит кисәкләрен талап ала башлаганнар. Жаен туры китереп, кызларны да рәнжетәләр икән.

Беренче Май бәйрәме алдыннанрак, Ленин бабай туган көнне, территорияне жыештыру буенча "коммунистик өмә" игълан ителә. Өмәдә "Спецдом"ның күзлекле һәм чахоткалы начальнигыннан алып ихата почмакларындагы дүрт каланчада каравыл торучы әрәмтамакларга кадәр, барлык тәрбиячеләр, педагоглар, хәтта Вася агай белән аның инвалид карчыгы да катнашканнар. Чыннан да, үзе бер бәйрәм төсле булган бу өмә. Ачлы-туклы йөргән балаларга физик эш нинди бәйрәм булсын инде югыйсә?

Менә шушында Азат фәлсәфәгә дә бирелеп алды: "Күмәклек тойгысы—адәми сыйфат түгел, ул безгә көтү-көтү булып йөргән хайвани

заманаларыбыздан калгандыр..,—диде ул.—Әлбәттә, өердә без үзебезне көчле тоябыз..."

Мин Азат белән бәхәсләшмәдем.

Өмәдә Азатка төп корпус каршындагы инде берничә ел эшләми яткан ташландык фонтанның чәрдәкләнеп беткән бетон бассейнын чүп-чардан чистартырга һәм шуңа су тутырырга кушканнар. Суны төп территориядән бераз читтәге буадан атлы мичкә белән дядя Вася китерә торган, көянтә-чиләкләп кызлар да ташыганнар. Чумак Азатка кемнең ничә чиләк китергәнен кәгазьгә язып барырга кушкан. Һәр кыз исеме янына Азат икешәр артык сызык сызган, ә Ганҗәне яклап торасы да булмаган, ул болай да өч көянтә суны артык китергән. Әйләнеп килгән саен бер-ике сүз алышырга өлгерәләр икән...

Ахырда Ганҗә оялып кына:

—Минем үтенечем бар, Азат... Әйтимме?—дигән.

—Әйт.

—Мурзаев шайкасы кызларны бүлешә башлаган...

—Ничек инде ул... бүлешә..?

—Килә дә: "Син, кызый, минеке" дип игълан итә... Карулашсаң, җаен табып, күмәкләшеп көчлибез дип куркыталар икән. Риза булсаң, сиңа башка берәүнең дә хокукы юк, имеш...

—Шуннан?

—Бүген кичке аштан соң клуб янында, кино алдыннан безне Мурзай көтеп торачак... Мин аңа җавап бирергә тиеш.

—Җанын алам мин ул хәшәрәтнең!

—Алар анда бишәү-алтау була, Азат. Куштаннары җитәрлек аның. Кесәсендә үткер кадак та йөртә...

—Мин аңардан курыкмыйм, бер сызгырсам, ярдәмгә дистә ярым малай килеп җитәчәк!

—Беләм анысын. Ләкин сезгә сугышырга һич ярамый... Мурзай монда махсус җибәрелгән шпик ул. Әләкче. Аның әтисе Казанда авиазавод төзелешендә эшләгән, аны улы белән цемент урлаганда тотканнар... Алар сәяси гаепләнмәгән, караклар алар...

—Каян беләсең?

—Әтием сөйләгән иде. Бу турыда гәзиттә дә яздылар.

—Яхшы... Юк ла, яхшы түгел инде... Болай итәбез: кичке аштан соң мин дә шунда булам, ә син тот та минем янга килеп бас. Калганына борчылма. Ышанасыңмы?

—Ышанам. Мин сиңа ышанам, Азат.

Кичке вакыйгалар нәкъ Азат әзерләгәнчә килеп чыга. Клуб болдырында басып торган кызлар янына койрыкларын ияртқән Мурзаев килә. Биеп-биеп кенә атлый, куллар кесәдә, сәләмә кепкасын кырын салган, эре генә сызгырынган була. Маймылланып, әллә кайсы кинофильмдагы хулиганга ошарга тырышуы.

—Йә, хур кызлары, ни әйтәсез?—дигән шамакай, кулларын уыштырып.

Шул мизгелдә Азатныкылар—һәрберсе бер кыз янына—килеп басканнар. Ганҗә Азатка елышкан.

—Падлы...—дип ысылдаган Мурзай теш аралаш һәм уң кесәсенә тыгылган.

—Артыңа борыл,—дигән аңа Азат тыныч кына,—Без унбиш, сез алты бөртек. Измәңне изәчәкбез! Бер очтан Казанда цемент урлаганың өчен дә әләгер... Аңлашылдымы? Ашханә тәрәзәсеннән керергә йөрүегезне дә начальникка җиткерербез, чөнки син безнең өлешне ашамакчы буласың. Йә, йә, боргаланма—мин бөтенесен дә беләм. Ә үткенләгән заточканы хәзер үк җиргә ташламасаң, үзеңне инвалидка исәплә, әләкче! Шылдымы?

—Син нәстә..? Нишләгән әле без? Кызлар белән шаяртканга ...

—Заточканы ташла, хәшәрәт!

Мурзаев як-ягына каранган, ярдәмгә өметләнеп, иярченнәренә күз

төшергән. Тегеләре, борыннарын җыерып, читкә борылганнар.

Заточка, чалбар балагы эченнән шуып төшеп, баскычтагы аяк киеме кыра торган тимергә бәрелгән.

—Хәзер ычкыныгыз моннан!

Иярченнәре берәм-берәм болдырдан төшеп корпусларына таба киткәннәр. Мурзаев аларга иярмәкче булгач, берсе—карсак кына бер малай—артка таба төкергән дә:

—Якын килмә, сасык!—дип ырылдаган.

* * *

Бу көнне мин Яшел Үзәндә куна калдым.

Тәвәккәллек. Сугышмыйча калу мөмкин түгел икән—беренче булып ор! Күрәмсен, Азатның девизы шундый булган. Тайга кануны... Җәһәннәмнең үзенә үк булмаса да, Азатлар тәмугның алдына, ишек төбенә үк килеп эләккәннәр ич! Ә без... Ә без, алар белән чагыштырсаң, оҗмах бакчасында үскәнбез мени? Сталинчыл-мичуринчыл җәннәт бакчасында?

Менә шушы уй белән йоклап кителгән.

Яшел Үзәндә әтәчләр бар икән әле. Мин ялгыз әтәч кычкырган тавышка уяндым. Казанда да шулай, этләр ләңгелдәшә башласа уянам мин.

Азат эшкә төштән соң гына барасы булганга, безнең вакытыбыз байтак иде әле. Табак-савытларны юып, кичтән әзерләгән ризыкларны җылытып капкалап алгач, иртәнге базарга чыгып, кичә күреп калган җирдә авылдан бер әби тутырып китергән бик матур һәм йомшак ике мендәр кыстырып кердем. Азат каршы килеп маташкан иде дә, "Мин кабат баш астыма таш салып йокларга разый түгел" дигәч, бәхәсләшмәде, елмайды гына. Ул үзе, гомер буе күчмә тормыш алып бару аркасында, һәртөрле унайсызлыкларга күнегеп беткән һәм аларга бик игътибар итми иде шикелле. Аның бәдәне тимер кебек ныгыган, каткан, ә сөякчел кулларын ул көн саен кирпечнең тар ягына суга-суга чыныктыра икән. Соңыннанрак, мин бик кызыксынгач, ул өр-яңа кызыл кирпечне уч кырые белән сугып, урталай ярып күрсәтте.

Димәк, Азат үзен шулай чыныктыруны кирәк санаган. Чит илләрдә, горбәттә йөргәндә, бәлки кирәге дә чыккандыр.

Теге көнне Мурзаевны хур итеп клубтан сөреп җибәргәч, кино караганда Азат озын эскәмиядә Ганҗә белән янәшә утырган. "Мин Ганҗәнең тән җылысын, чәчләренең исен тоеп исереп утырдым,—дип сөйләде Азат.—Мин үземне бәхетле хис иттем... Менә хәзер шул язгы кичтә нинди кино караганыбызны үтерсәң дә хәтерләмим! Ниндидер патриотик фильм иде бугай..."

Ә "Нормальный ход" залда эскәмияләр арасында йөреп тамашачыларны барлаганда боларга сөзеп-сөзеп кенә карап киткән. "Хисләрем ташыгангамы, мин Соня түтинең зәңгәр күзләрендә усаллык күрмәдем,"—диде Азат.

"Спецдом"да чын мәгънәсендә мәктәп программалары буенча уку булмаган. Роберт һәм аның белән бер тирәдәгеләрне хутордан мөгаллимә апа килеп укырга-язарга, хисап башлангычларына өйрәткән, хәтта журналга "яхшы", "урта", "начар" билгеләре дә куя торган булган. Ә өлкәнрәк балалар кул хезмәте һәм көндәлек политинформация дәресләре белән чикләнгәннәр: тарих та, география дә шул булган. Дингә каршы дәресләрдә исә әз-мәз төрле фәннәрнең нигезләреннән "авыз иткәннәр". Айдарга килгәндә, дәресләрне Азат аңа үзе биргән—исендә калганнар буенча гына инде, чөнки бирелә уку ярдәмлекләре һәм дәреслекләр булмаган. Дөрес, колония начальнигы "киләсе уку елыннан җиде класс ачачакбыз,

без сездән коммунизм төзүче каһарманнар—Чкаловлар, Гризодубовалар, Стахановлар, Мичуриннар, Чапаевлар, хәтта актриса Любовь Орловалар тәрбияләячәкбез", дип вәгъдә иткән һәм, ышандырырлык булсын өчен, арык йодрыгы белән өстәлгә дә сугып куйган.

Хыялый начальник... Борын астындагыны да күрми торган романтик. Әллә соң гап-гади кыланчыкмы, артистмы?

—Германиянең СССР га басып керүе турында без—тоткын балалар—22 нче июньнең бөркү кичендә генә белдек, чөнки иртән үк, ару гына сөйләгән жиреннән, радионы капыл өзделәр. Тәрбиячеләрнең һәм форма кигән надзирательләрнең чыш-пыш килүе, тәшвишле ыгы-зыгысы безне, әлбәттә, шомрайтты. Өстәвенә көпә-көндез бүлмәләребезгә куып керттеләр. Нииндидер гадәттән тыш хәл булган—без шуны гына шәйләдек. Ләкин нинди хәл? Нинди афәт? Сугышмы? Кем белән?

Ак финнәрне күптән түгел генә тукмадык дип беләбез. Хәсән күле буенда япон самурайларының арт сабакларын укыттык. Бичара төрек Босфор белән Дарданелл бугазларын тартып алмагайлары дип кан калтырап яши. Һитлер безнең белән дус хәзер. "Без жиңәлмәгән дошман тумаган!"—дип күкрәк киереп жырлыйлар иде туган якларда, шулай бит? Хәзер жырлыйлармы?

—Хәзер бик ишетелми. Музыкасы яши...

—Ә бит бу жыр ул чордагы карашларны бик дөрес чагылдырган... Хәтта без дә, ни рәнжетелгән һәм кимсетелгән булсак та, нәкъ шул рухта тәрбияләнгән, шуңа инанган идек. Ышанасыңмы, тормышымның иң авыр минутларында мин авыз эчемнән генә: "Без жиңәлмәгән дошман тумаган!" дип кабатлый торган идем. Бөтен татарчам һәм бөтен догам шул булды минем. Крематорий миче авызында да колак төбемдә шул жыр янрап торды, шул коткарды сыман...

Әйе, кичкә бөтенесе дә ачыкланды. Безне линейкага тезеп, начальник фашист Германиясенең хыянәтчел төстә илебезгә басып керүен хәбәр итте. Чик буенда авыр сугышлар бара. Кызыл Армия илбасар һөҗүмен туктаткан. Күп тә үтмәс, без дошманны тез чүктерербез. Аны үз өнендә дөмбәсләрбез! Хыянәтчеләргә, фашист ялчыларына, шпионнарга үлем!

Ахырда безне "ура" кычкырттылар. Сыеграк чыкты безнең "ура", сыеграк...

Атна үтте... Көтәбез. Ун көн дә үтте... Күрәсең, фронттан жылы хәбәрләр килмәгәндер, политинформация сәгате унбиш минутка гына сузыла башлады, завуч Петух сүзгә бик саранланды, артык сүз ычкындырмагаем дип курка иде, ахрысы. Шулай да көн саен һава һөҗүменә каршы артиллериябезнең ничә фашист самолетын бәреп төшергәнлеген әйткәч, үз ялганыннан үзе кайнарланып, берәр яңа шигырен яңгырата иде.

Көннәрдән бер көнне аяз күктә көнбатыш тарафыннан ап-ак эз калдырып нииндидер бер самолет очып килгәнен күрдек тә, бассейн янына жыелыштык. Мондый әкәмәтне элек беребезнең дә күргәне булмаганга, әзрәк шүрли калдык. Бер без генә түгел, ихата почмакларында, каланча башында торган мылтыклы каравыл да күзләрен күктән алмады. Самолет күкне кап урталай ярып очып үтте дә, бер утыз минуттан, әүвәлге эзе инде эреп югалгач, кире көнбатышына юл тотты...

—Германныкы,—дип нәтиҗә ясады хутордан азык-төлек алып кайткан Вася дәдәй, арбасыннан төшеп.—Ярапланның янасын ясаганнар, каһәр суккырылар. Киевне карап китте бу... Ай-һай, мондый биек оча торган аждаһаны ничек бәреп төшермәк кирәк? А ну, егеткәйләр, бәрәңге капчыкларын чоланга кертик әле! Чөгендер катыш, бик бәргәләмәгез!

Капчыкларны ашханә чоланына кертеп урнаштыргач, Вася агай Азатны ат тугарышырга чакыра. Азат атны әйбәтләп тугара (чөнки беренче тапкыр гына түгел), дирбияләрнең һәркайсын лапас астындагы тиешле чөенә элеп куя, бахбайның ашарына сала, эчертә, ә Вася агай карт сөякләрен ял иттереп, чүлмәк төребкәсен пыш-пыш суыргалап утыра.

—Йә, кил әле бирегә,—ди ул, Азат эшен бетергәч.—Җитди сүз бар...

Азат картлач янына килеп чүгәли.

—Эшләр шәптән түгел...—дип башламакчы була да карт, сүз җаен таба алмагандай, озак кына дәшми тора. Аннары кинәт сорап куя:

—Энекәшләрең икәүме әле?

—Икәү.

—Әйбәт малайлар сез, Азатко... "Аллах"ыгыз сезгә бәхет-тәүфыйклар бирә күрсен... Ә дөньялар... дөньялар яман!

Шуннан соң гына Вася агай, абзар капкасын ябып, үзенең хуторда ишетеп кайтканнарын Азатка пышылдап кына сөйли.

Немец ажгырып килә икән. Инде күрше өлкәгә кергәннәр. Танк, мотоциклларга каршы кадими Буденный кавалериясе ни эш кыра алсын?! Адәм көлкесе... Немец кулында автомат, бездә—патша ясаткан штыклы мылтык, анысы да җитми икән... Ялан кул белән атакага җибәрәләр, һәммәсе шунда ятып кала, ди...

Хуторда ир-ат күзгә чалынмый икән. Яшьләрне кырып-себереп армиягә алганнар. Ветфельдшер Михаил үзе теләп язылган... Аңа нәрсә? Дуадак каз шикелле япа-ялгыз. Елап озатыр кешесе юк... Шул, безнең Сонька еласа гына инде...

—Ә Сонька аңа кем тиеш?—дип бүлдерә картны Азат.

—О-о... Ничек яратышалар иде алар! Ничек пар килгәннәр иде...

—Ә ни булды?

—Ни булсын?! Хезмәт алдынгысы комсомолка Соняга бер шәһәр түрәсенең күзе төшкән. Райкомол секретарена әйткән: бу чибәр кызны ял базасына эшкә алсаң, райкомга утыртам үзеңне, дигән. Тегесе ниләр белән кызыктыргандыр, алла белсен, ләкин тиздән Соня шушында массажистка булып эшкә урнашты... Михаилы, әлбәттә, аяк терәп каршы торган, егетнең күнеле сизгән, күрәсең... Соня-Солнышкосына ялынган: киләсе елны техникумны бетереп кайтам, гөрләтеп туй итәрбез дигән... Әйдә, бүген үк язылышыйк дип караган. Ә Соньканың үз планы—син кайтуга туйлык акча әзерләп куям, фәлән дә фәсмәтән...

Ә киләсе елны соң булган инде, соң... Тәҗрибәле җитәкчеләр, карт төлкеләр, комсомолка Соняны тәмам кулга ияләштереп бетергәннәр. Айлы, сандугачлы бер Украина төнендә Сонька анадан тума килеш фонтан әйләнәсендә биегән... Аны ач күзле, азгын, исерек дистәләгән кызыл айгыр тамаша кылган... Ихахай да михахай... Аннары кул-аякларыннан тотып суга ыргытканнар... Алай да айнымаган Сонька, үрмәләп чыгып тагын биергә тотынган...

Василий агай инде эре шәһәрләрдәге халыкны һәм мөһим заводларны күчерү башланганын әйтте. "Спецдом"ны да каядыр Себергәме, Казагыстангамы күчерергә тиешләр икән. Кичә бирегә район вәкиле килеп, персоналның гомуми җыелышында нәкъ шушы мәсьәлә каралган. Тик шунысы бар: станциягә илтү өчен фәкать өч йөк машинасы биреләчәк, шуна күрә беренче чиратта документларны, кыз балаларны һәм тәрбиячеләрне алып китәчәкләр, малай-шалай икенче чиратка каласы икән. "Өлгерсәләр...—дип башын чайкый Вася агай,—өлгерсәләр... Немец инде, артык каршылык күрмичә генә, машинада сыбызгысын сызгырта-сызгырта, "Über alles"ын җырлый-җырлый килә икән..."

Вася агай Азатка кичә үзе шаһит булган тагы бер вакыйга турында сөйләгән. Әлеге вәкил белән Соня арасында коточкыч ызгышны күзәтергә туры килгән аңа.

Мунчалдында камыт ремонтлап утырганда, ишек ярыгыннан күрә бу: ат абзары янындагы агач эскәмиягә башта район вәкиле, аннары Соня килеп утыралар. "Нинди яшерен сүзләре бар икән боларның?"—дип уйлый карт һәм ишек янынарак килеп колак сала.

—Мине беренче чиратта китәчәкләр исемлегенә керт!—дип таләп итә Соня.

—Юк, кертә алмыйбыз,—ди аңа вәкил.—Жирле халыктан булган персоналны гомумән алмаска боердылар, мин менә, элекке танышлык хакына, сезне, гражданочка, исемлеккә теркәп, югарыдан килгән күрсәтмәне болай да бозам әле... Иске дуслык хакына...

—Дуслык, пычагым! Синең "дуслык" бөтен гомеремне пыран-заран китерде минем... Йа раббым, син кабихнең тасма теленә ышанып килеп каптым бит мин бу бардакка... Син бит мине зина юлына бастыручы! Син бит мине шәнкерле түрәләренә саттың, хәшәрәт! Ничек дус булыйм ди мин сиңа? Бу дөньяда бер генә дустың да юк синең! Булырга тиеш түгел!

—Үлчәп сөйләргә киңәш итәм, гражданочка. Юкса...

—Нәрсә—юкса? Советка каршы дип, сәяси "илле сигезенче"не чәперсеңме, Дзержинский? Курыкмыйм! Мина монда барыбер көн күрсәтмәячәкләр, минем кемлегемне районда белмәгән кеше юк, аңлыйсыңмы—миннән җирәнә халык, җирәнә! "Фиркале матрас" минем кушаматым, аннары гына "Нормальный ход"... Әнкәем, мине бәхилләмичә, акылыннан язып гүргә керде... Адәм күтәргесез гөнаһлы мин, ә сез, ялган фирка әгъзалары, мең кат гөнаһлы!

Соня кызганнан-кыза һәм ахырда вәкилнең түгәрәк чыраена төкереп, элеккеләренә тагы бөрчек-бөрчек юеш шадралар өсти....

Тегесе сикереп тора, бер җине белән битен сөртеп, икенче кулы белән кобурасына ябыша.

Чыгырыннан чыккан Соня инде һич тыела алмый:

—Атасыңмы? Мә, менә шушында төбәп ат!—дип, чигүле ак кофтасын ике якка умырып төшерә.—Күрәсеңме? Күкрәкләремне күрәсеңме? Бик кызыгып йөрсәң дә, сиңа бит алар тәтемәде... Ләх исерек чагымда да мин синең кемлегеңне онытмадым... күтләк! Обком секретаре белән икәүләшеп нинди кети-кети уен уйнаганыгызны белми дисеңме? Шакшы хайван сез, педерастлар...

Менә шул чагында, йөткергәләгән булып, мунча ишеген шыгырдатып ачып, камыт тоткан Василий агай чыга.

—Нигә дип тавышланасыз әле болай?—дигән аларга картлач.—Соня, доча, кайгырма, менә алашаны җигеп бирермен, утыр да кит, бахбай бетерешкән булса да, станциягә тикле түзәр, шәт... Монда инде атның кирәге калмый бит, дөрес аңлаган булсам?

—Дөрес аңлагансың, Фомич,—дигән вәкил, Вася агайның атасын искә төшереп,—дөрес аңлагансың.

Соня бер сүз әйтми генә, куллары белән шәрә күкрәген каплый да, алпан-тилпән атлап, төп корпуска таба китеп бара.

—Фомич, дәшәсе булма!—ди шуннан соң вәкил.—Ләм-мим!

* * *

Ганҗәләрне икенче көнне үк алып китәләр. Кызлар һәм персонал утырган машиналарны озатырга малайлар җыйнаулашып чыга. Җылыйлар кызлар, шушы сәләмә киемле, инде ярым кыргыйлашкан, усалланган, якты дөньяга каш астыннан гына карый башлаган малайларның монда калуына кайгырып, үксеп-үксеп җылыйлар... Әйтерсең лә үз балаларын җуялар... Хәтта ни кырыс тәрбиячеләр дә күз яшьләрен сөрткәли. Аларның да, җылы урыннарын ташлап, билгесезлеккә таба китүләре бит. Малайлар Пушкин булу турында хыялланган уңгылыксыз завучларын да, Чкалов данынннан мәхрүм калган бәхетсез һәм зәгыйфь Чумакларын да соңгы тапкыр күрәләр.

—Мине онытма,—дип пышылдый Ганҗә, үзе кузовтан Азатның кулларына таба үрелә.—Син исән калачаксың!

—Син дә онытма.

—Онытмам!

Бөреләнеп кенә килгән хисләр—самими, яшь, ганжә мәхәббәт шушында өзелә.

Бу көн вакыйгаларга бай булган.

Ин элек Мурзаевның, бер-ике куштанын ияртеп, "спецдом"нан качып киткәнлеге ачыклана. Буш кул белән китмәгәннәр, әлбәттә, ашханә тәрәзеннән кереп, каты-коты ризык чәлдергәннәр. Әмма администрация шау-шу куптармый. Качканнар һәм вәссәлам! Сукбайларны эзләп маташыр чакмыни?

Төштән соң хутордан почтальон килеп, сәерсенгән һәм ап-аек Сонькага ике хат тоттыра. Фронт хатлары. Берсендә кызылармеец Михаил Журавельнең батырларча һәлак булуы турындагы рәсми хәбәр, икенче хат—Михаилның үзеннән. Ул аны контратакага барыр алдыннан язган. Кәгазьгә төшерергә нинди үтемле сүзләр тапкандыр Михаил—анысы караңгы, ә Сонькаң Ленин бюсты өстенә үк портреты да эленгән кызыл почмакта—фикус гөле янындагы яшел постаулы өстәлгә капланып бәргәләнә-бәргәләнә җылаганын Азатның энесе Айдар күргән.

Колониянең барлы-юклы администрациясе һәм калдык-постык каравылы, каяндыр машина юнәтеп, соңгы документларны һәм көрән төстәге сандык-сейфны төяп, начальник житәкчелегендә, төнлә "спецдом"ны язмыш кочагына ташлап тавыш-тынсыз гына киткән дә барган. Иртәнгә инде монда өч дистә малайдан һәм барыннан да хәбәрдар Вася агай белән аның чукрак карчыгыннан башка бер жан да калмаган. Инде малай-шалай белән дуслашып беткән нәселсез, ләкин гәүдәле һәм гөбедән чыккандай калын тавыш белән өрә торган Полканны да алмаганнар-алуын... Өстә мылтыклы шәүләләре булмагангамы, каланча башлары да күңелдә әллә нинди шомлы, каршылыклы уйлар уята—каравыл юклыгы шатландыра, ләкин шул ук вакытта кошлар киткәч ятим калган сыерчык оясы шикелле кызганыч та сыман... Аңламассың бу күңелне.

Ирек исе килә... Дары исе килә... Икесе дә исертә...

Ә Сонька? Ә Сонька беркая да китмәгән. Аның гәүдәсен Вася агай иртән иртүк багор белән буа төбеннән эзләп тапкан һәм малайлар торгалаганчы такта-токтадан табут, аннары агач тәре дә әмәлләп өлгергән була инде.

Культмассовик Софья Татаркинаны буаның аргы ягында кашлак урында малайлар казыган тар кабергә жирлиләр. Женазага хутордан кеше чакырып тормыйлар, табут өстендә Вася агайның карчыгы гына нидер быдырдый, укына. "Ә Соня табутта тыныч кына йоклаган кебек ята иде, борынгы мәрмәр алиһә кебек гүзәл...,"—дип пышылдады Азат, ничә еллар үткәч, мина сөйләгәндә.

Әлбәттә, Соня үзе суга ташланган. Юк, ташланмаган, моны Василий карт Азатка болай сөйли. Төнлә белән, күпме үгетләсәләр дә, Соня машинага утырудан баш тарткан. "Минем урыным монда,"—дип кырт кискән.

Машина китеп баргач, бөтен колониягә һәм ятим малайларга бердәнбер химаяче булып калган Василий Фомич тимер капканы үз кулы белән дөмбердәтеп яба, хәтта бикләп куя. Шулчагында Соня калитканы ачтырып, ныклы адымнар белән буа ягына таба юнәлә.

Берничә минуттан Василий карт аның артыннан китә.

—Башкайларыма тагын бер гөнаһ алдым,—дип сөйли ул Азатка, чөнки, дөресен әйткәндә, күңелен бушату өчен бүтән сөйләр кешесе дә булмый.—Куак артына посып, Сонянын башта кыек яулыгын, чүәген, ахырда оекбашын салып, яр буендагы яссу ташка ничек иләп һәм тәртипләп тезеп куйганын, чишенеп маташмастан, ялан аяклары белән әкрен генә суга кергәнен әсәрләнеп карап тордым...

Итәге суга тигәч тә туктамаган Соня, кулларын салындырган килеш, һаман тирәнгәрәк атлаган... Менә су аның биленнән кочкан, күкрәк турысыннан, муенына сарылган... Менә аның әллә сары, әллә инде ай

яктысыннан агарган чәчләре башта су өстенә таралганнар да әкренләп-әкренләп күмелгәннәр, күмелгәннәр... Аннары су бер чупырдап ала, бераздан чал чәчләрне йоткан түгәрәк дулкыннар да тына, тынычлана...

Кычкырмаган, коткарам дип суга да атылмаган Василий Фомич. Тәнредән ингән бу дәһшәтле үлемнең күзенә чекерәеп караган көенчә, үзләренең һәркайда яраклы "Отче наш"ларын укыган: "Гөнаһларыбызны ярлыка, без дә бурычлы булганнарны кичергән күк... Яманнан коткар безне... Амин."

—Син мине бәгырьсез икән дип уйлама, Азатко... Менә хәзер дә, үзем сина сөйлим, ә йөрәгем сыкрый... Соня дөрес итте. Моны алла ана үзе кушкандыр дим мин. Үзе кушкач, колына оҗмах капуларын да ачар. Соня... апаң Мишкасы белән, ниһаять, ахирәттә кавыштылар... Авыр туфраклары җинел булсын.

—Ә менә безгә алла биргән чаклысын яшәргә кирәк,—дип очлаган ул сүзен.—Малайларны җый—Ленин почмагына. Сөйләшегез, нишләргә икәнен уйлашыгыз, чөнки сез хәзер үз иркегездә, балакайлар. Дүрт ягыгыз кыйбла... Әмма ләкин малайларны бер син генә тота аласың. Берәр сәгатьтән мин дә керермен.

Азат сонгa кала язган. Югыйсә тагы биш-ун минуттан бер өер малай, ашханә белән буфетны тазартканнан сон, азык-төлек келәтен дә туздырып ташлыйсы булган. Азат күренүгә, һәммәсе туктап, тынып калганнар.

—Стоп!—дип кычкырган Азат.—Ни кыланасыз, бандюгалар! Вәхшиләр! Атагыз кем, анагыз кем?

Гадәттәге кебек, тәртипне тиз урнаштырган.

Василий Фомич кинәш иткәнчә, бөтенесен уртага салып сөйләшергә булганнар. Ленинның арзанлы гипстан койган һәм кат-кат ак буяу белән буяганга күз төпләре чак кына шешенкери төшкән бюсты янына утырып, Азат мәсьәләне кабыргасы белән куя:

—Вася агай бүген-иртәгә хуторга фриц керәчәк, әлбәттә, безне дә әйләнеп узмаячаклар, ди. Нишлибез, биштәрләп капчык асып, көнчыгышка, Рәсәйгә юл тотабызмы, таралышабызмы, әллә шушында калып торабызмы?

—Монда калып нишлик? Әллә немчура үзебезнең Чумактан аруырак булыр дисенме?

—Немецләр безне азиат дип, түбән сортлы раса дип чутлыйлар икән—дөресме? Алар безне чебен урынына да күрмәячәк!—диючеләр күбрәк булса да, арада:

—Көтик бераз. "Спецдом"нын яшелчә җире бар, буадагы балыкның бетәсе юк. Үзебезнекеләр әйләнеп кайтканчы җан асрарбыз әле,—дип санаган утрак тормыш яклылар да җитәрлек булган.

Шулчакны бүлмәгә Василий Фомич кереп, ишек янындагы табуреткага утырган. Түрдән урын алырга чакырсалар да, карт мондый хөрмәттән баш тарткан, "Без президиумда утырып өйрәнмәгән,"—дигән.

Ахырда мондый фикергә килгәннәр. "Кем тели—бәйләп тотучы юк, юллык ризык та алсыннар, әмма бүгенгә шушында калу акылга муафыйк,—дигән Василий Фомич.—Бергә-бергә булу хәерле... Мир күзендә булсаң, әҗәл дә хәләл."

Китәргә җыенган унбишләп тәвәккәл малайны тизрәк юлга әзерләгәннәр, чөнки фронт сызыгы күзгә күренеп якынайган, инде кичке шәфәкъ баткач та көнбатышта шомлы ут шәүләсе сүнмәгән.

Азат берсе-берсеннән кече энекәшләре белән беркая да кузгала алмаган, әлбәттә.

Ике көннән тимер капка каршысына немецләрнең беренче мотоцикллары килеп туктый. Капканы, билгеле инде, автомат түтәсе белән төя башлыйлар.

—Оффен! Ачарга!

Капканы Василий Фомич ача. Башка кем ачсын? Төптән караганда,

бу жирләрнен, бу урман-суларнын һәм хөкүмәт дачаларынын чын хужасы Фомичлар түгелмени?

Немецләр, картны ияртеп, ярты сәгать эчендә барлык биналарны әйләнеп, барлап чыканнар.

—Комендант кайда?—дип сорый өлкән офицерлары яхшы ук чиста рус телендә.

—Начальникмы? Эвакуациядә. Менә дистә ярымлап үксез бала китәргә өлгерми калды... Ә мин простой ат караучы гына...

—Яхшы. Балаларнын барысын да кече корпуска күчерергә. Мина "һерр офицер" дип мөрәҗәгать ит—анлашыламы?

—Анлашыла, һерр офицер.

—Бередә хәрби госпиталь урнашыр. Лазарет. Анлашыламы? Келәт-амбарларнын ачкычын ефрейторга тапшырырга. Өлкән малайларны вакытлыча санитар итеп билгелим! Иртәгәгә иданнәр, тәрәзәләр ялт итеп торырга тиеш. Туалетларны тәртипкә китерергә! Бу мичкәләргә су тутырыгыз. Капка нигә шыгырдап ачыла? Майларга! Анлашыламы? Ну?

—Анлашыла, һерр офицер.

Ничек кенә женнәре карышмасын, малайларга жиненә чатлы-чотлы әвернә-свастика таккан офицернын боерыкларын үтәргә туры килә. Ул үзе бүгенгә мотоциклын тырылдатып китеп барса да, "Спецдом"да камыт аяклы ефрейторын калдыра. Малайлар ана шундук "Чумак II" кушаматын чәпиләр һәм ул бу исемгә чынлап та лаек була.

Малайларга әлеге эшләр электән дә таныш-танышын, ләкин фашист килмешәкнен ялчысы булу, алар өчен әбрәкәй чистарту... Юк, бусы инде малайларнын жен ачуларын чыгара, бусы инде, валлаһи, жирәндерә. Моны инде, завуч әйтмешли, бернинди "югары материяләр" белән дә аклый алмыйсын... Ә Азат "Чумак II"нен көзге шикелле ялтыраган күнитеген ошатмый. Мондый күнитек кигән бәндәләрне гомумән өнәми, күнитеген шулчаклы кадерләгән кеше башкаларны аяк астындагы чүпкә дә санамый дип белә ул. Шулай да эшем кешеседәй, бөтенесенә кысылып, ашханә һәм амбар ачкычларын чылтырата-чылтырата, тыз-быз йөргән ефрейторнын җәзбә белән сызып ясагандай кәкре балтырларына карап, мона күнитекне ничек үлчәп тегә алдылар икән дип, елмаеп та куя.

Кич белән, инде күз бәйләнгәч, йорттан тагы ике горур малай зимагурлыкка чыгып китә, анын каравы элек озатып жибәргән малайларнын өчәвесе, тәмам ачка бетенеп, кире әйләнеп кайталар. Алар адашып-тулганып йөргәндә туган-үскән илгә илтер сукмакларын фронт сызыгы кискән була инде.

Камыт аяклы ефрейтор икенче катта, элекке начальник кабинетында, ишек-тәрәзәләрне ныклап ябып, шторларны төшереп, урындыклардан баррикада корып, ак чехоллы кин диванда урнаша. Ул-бу була калса дип күнитеген салып тормаганга, диваннын бер култыксасын тәмам эштән чыгара Чумак II.

Йокысы ничек булгандыр, малайларны бик иртә уятып, быргы кычкыртырга, барабан кагарга куша бу. Бөтенесен жиренә житкереп эшләргә күнеккән немец, кабинеттагы телефон аша элемтәгә кереп, Киев шәһәренен бөек герман армиясенә бирелгәнлеген ишеткән икән. Бу көнне ул бәйрәм дип игълан итә.

Киевнен алынуы турында Николай Фомич та хәбәрдар, шуна ул сөмсере коелып йөри.

Очлы күзле ефрейтор буада балыкнын шәп чиертәсен дә чамалаган икән. Хәер, амбар почмагындагы әүвәлге фирка секретарьларыннан мирас булып калган бамбук кармак сапларын һәм бауга эленгән ятьмәне күрү өчен әлләни очлы күз кирәкми инде. Ефрейтор дүрт-биш малайга, Азат житәкчелегендә, бәйрәм табынына житәрлек балык тотарга куша. Малайлар, белгән-белмәгән немецчәләре һәм төрле ишарәтләр белән, буада әле генә кеше батып үлгәнлеген анлатырга тырышып карыйлар,

аптырагач ярдәмгә Фомичны чакыралар. Герман сугышы беткәч тә әсирлектән егерменче елда гына әйләнеп кайткан Фомич немецчәсен онытып житкермәгән була әле.

Үжәт ефрейтор барыбер үзенекен тукый:

—Gut, gut,—ди.—Мин малайларга бер километр югарырак жирдән тотарга рөхсәт бирәм. Ә син, картлач, марш хуторга. Шнапс тап, аңлыйсыңмы, шнапс! Горилка тап! Спирт! Бәйрәм! Sieg heil! Жину!

Көлгән чагында аның тигезле-тигезсез сары тешләре күренә.

Башыннан алып аягына тикле бу кадәрләр ямьсезлекне табигать каян һәм ничек табып бетергәндер дип уйлый Азат.

* * *

Азат Сәйдәшевнең хәтерендә уелып калган коточкыч яман көн бу. Азат һәм берничә өлкәнрәк малай үзләре өчен бик үк таныш булмаган култык жиргә күтәрелеп, кармаклары белән текә генә яр буена чирәмгә тезелешеп утыралар. Сирәк булса да чиертә балык, гади елга чабаклары, әлбәттә, ваграклар инде, әмма шулпа өчен ярап тора...

Көн үзәгенә таба, балык чиртми дә, капмый да башлагач, бамбук саплы, кем әйтмешли, "жилле" кармакларын жыештырып, ярты чиләк чамасы чабакны икешәр малай кармак сабына элеп алмаш-тилмәш күтәреп кайталар.

Ачык калиткадан кергәндә гадәттә булганча энеләре йөгереп килеп каршы алмагач, Азат сәерсенебрәк китә. Ә башка малайлар шушында, ләкин алар күзләрен яшерәләр, читкә борылалар... Азатның йөрәге "жу!" итә.

Ул, балыкчы иптәшләрен калдырып, үзләре яшәгән корпуска чаба.

Монда да тынлык. Тәрәзәдә генә бер көзге чебен чәбәләнә.

Бүлмә түрендәге тимер караватларның берсендә мендәргә капланып Роберт ята. Аның сөякчел иңбашлары калтырап-калтырап куя, Роберт тавыш-тынсыз гына жылый.

Абыйсы малайны торгызып утыртып та карый, ләкин юкка... Робертның күзләрендә ник бер нур чагылсын. Аның күзләре Азат күптән түгел төшендә күргән тонык көзге шикелле бушап калганнар. Сабый берни әйтми, әйтә алмый, чөнки телдән язган була.

Азат ишегалдына йөгереп чыга.

Үзен-үзе белешмәстән, беренче очраган малайның якасыннан тотып ала:

—Әйт, монда ни булды? Минем Айдар кайда?

Ниһаять, малайлар фажигане бәйнә-бәйнә сөйләп бирәләр.

Айдар белән Роберт, яшьтәшләре белән бергә, елга буенда уйнап йөргәндә, гөнаһ шомлыгына каршы, болар янына немец ефрейторы килеп чыга. Әле Фомич хутордан әйләнеп кайтмаган булса да, ефрейтор шактый төшереп өлгергән, кулында ике башланмаган шоколад та була моның. Күрәсең, колония начальнигының кабинетында яшерен "хәзинәгә" тап булгандыр, чөнки шоколадка рус хәрефләре белән "Мокко" дип язылган... Ә "Мокконы" гади халык белеп бетермәсә дә, жаваплы урында эшләгән "халык дошманнары"ның балалары белә, чөнки сирәк-мирәк татып караганнар...

Борын төпләрендә шоколад плиткаларын болгап, күз кыздырып, "шнель, шнель" дия-дия, сабыйларны үз янына жыйган исерек фриц. Аннары ул, буага төртеп күрсәтеп, малайларны суда йөзү буенча ярышырга котырткан. Билгеле инде, мондый татлы приз хакына ярышуга малайларның олысы-кечесе әзер булган, ләкин фриц буйлыраклардан биш малайны гына сайлаган. Малайлар чишенгәч, ул ишарәләр белән үзенең теге як ярда көтеп торачагын аңлаткан.

Ваграк малайлар, шул исәптән Роберт та, тамашаны яхшырак күрү

өчен, яр буендагы юан тупыл ботагына менеп кунаклаганнар.

Ефрейтор дамба буйлатып кәкре адымнар белән карышлап теге якка чыга һәм, иңенә аскан автоматын күтәреп бер болгый да, "Старт!" дип аваз сала. Ярышучы малайлар дәррәү суга ташланалар. Айдар чак кына соңгарак калып кузгалса да, ун-унбиш колачтан соң башкаларны куып житә. Бу якта калган балалар, тәмам спорт чиренә бирелеп, "Әйдә, әйдә!" дип кычкыралар, тегеләргә көч-куәт биреп торалар, "Мокко"ның тәмен тойгандай иреннәрен ялыйлар...

Каршы яктагы фриц тәмам иләсләнгән, "Шнель-шнель!" дип бакырына, үзе вәхши кебек очына, бии.

Ярышучы малайларга биш-алты колач салырлык кына ара калгач, сәрхүш ефрейтор, автоматын суга төбәп, озын очередь бирә...

Ике пуля эләккән Айдарны нинди гайре табигый көч ярга кадәр китереп житкерә алгандыр? Ул шунда, нәзек балтырлары әле судан чыгып та өлгермәгән килеш, йөзтүбән капланып жан бирә.

Айдарны икенче көнне Соня Татаркина белән янәшә жирлиләр. Азат бөтен женаза эшләрен үзе ерып чыга, чөнки Вася агай хуторга киткән жиреннән кире әйләнеп кайтмый, ул гына да түгел, аның карчыгы да, ишекләренә йозак элеп (гомер булмаган хәл!), каядыр китеп барган. Карт алаша белән жинел тарантас та юк. Колония штатында хисапланган кара борынлы Полкан да Вася агайдан калмаган ахрысы...

Акылын жуйган ефрейторны исә мотоцикл коляскасына салып алып киткән булганнар. Бер-ике көннән аларның жимерек машинасын таш юл буендагы куаклар артында күрәләр. Монда нинди хәлләр булганлыгы турында гоман итәргә генә мөмкин, ә фашистларның итәкләренә ут капкан чак була—алар Киевтән кире чигенеп маташалар. Бу чигенү вакытлы гына булса да, малайлар күнелендә өмет чаткысы кабынсын өчен житә кала: димәк, дошман ул кадәр үк көчле түгел, димәк, аны чыннан да тукмарга була!

Фашистлар янадан һөжүмгә күчеп, совет армиясен тагы кысрыклый башлый... Хутор аркылы Киев юнәлешендә аларның эт чирүе кебек яна гаскәрләре уза...

Азатның миен һаман бер сорау бораулый. Нишләргә? Нишләргә хәзер? Кая гына барып сыенырга? Инде өч төркем малай, тәвәккәлләп, юлга чыгып киткән. Роберт һаман дәшми. Бөтенесен аңлый, нидер әйтмәкче булып ымсынып та карый, ләкин аның табигатендә нәрсәдер бозылган, нindидер бик нечкә пружинасы өзелгән...

Ләкин барыбер моннан ычкынырга кирәк, ычкынырга! Кыякларга! Монда калырга ярамый. Немецләр айныячак, кабат бу йортны искә төшерәчәк бит. Аннары юләрсу ефрейторның һәлакәтендә казына башларлар. Шикләре беренче нәүбәттә Азатка төшәр...

Ахырда Азат энесе каберенә куелган тактага аның исем-фамилиясе язылган калай кадакларга ниятли. Бу аның монда соңгы эше булачак. Ул абзар тирәсендә кул яссуы кадәр жиз калай кисәге дә табып ала һәм шуңа без белән төртке-төртке эз ясап, "Сәйдәшев Айдар Нәжип улы. 1934—1941" дип яза.

Менә шушы язуны Айдар кабере өстенә бастырып куелган тактага кадаклап маташкан вакытында аның янына качып-посып кына Вася агай килеп чыга.

—Исәнме, сынок,—ди ул шыпыртлап.—Матур итеп жирләгәнсең энеңне. Рәхмәт...

—Вася агай, сез... каян?

—Син сорама, мин әйтмим, Азатко. Миңа теге мотоцикл авариясеннән соң яшеренергә туры килде. Ә хәсисләр... ефрейторлар тиешлесен алдылар, жәһәннәм кисәве алар хәзер.

Вася агай Азатны күрергә дип кенә килеп чыккан икән. Хәзер инде ул малайларга "Йорт"тан тизрәк таралышырга киңәш итә. "Сугыш

өч-дүрт елга сузылырга охшаган,—ди карт.—Сина мин бер адрес бирәм, аны минем алдымда ятла да, аннары кәгазьне юк итәрбез."

"Гродно өлкәсе, Довбучишки авылы, Сөләйман Богданович."

—Татар кешесе ул үзе,—дип аңлата Вася агай.—Авыллары да татар авылы, хәтта хан заманыннан калган мәчетләре дә бар, ихтимал, бөтен Рәсәйдә андый борынгы мәчет юктыр да әле... Үзләре белорусча сөйләшәләр, әмма диннәрен тоталар, тик Коръәннәре дә белорус хәрефләре белән язылган... Сулейман белән без дүрт ел Германиядә әсирлектә булдык, бер сыныкны икебезгә бүлеп, бер табактан ашадык, инде сугышлар тынып беткәч кенә, рәхмәт төшкере Финляндия булышлыгы белән, илебезгә кайтырга насыйп булды. Юл уңаенда туктап, мин аларның авылында төн кундым, рәхәтләнеп мунча чабындым. Елга бер-ике тапкыр булса да хат алышкалап тордык шулай картайганчы... Менә син шуларга барып чык—ярдәм итми калмаслар, искиткеч кешелекле халык... Миннән сәлам диярсең.

Вася агай кайсы тарафка һәм ничек барырга икәнен тәфсилләп аңлата. Бала адымы беләнрәк барганда дүрт-биш көнлек юл икән. Димәк, берәр атналык ризык алырга кирәк булачак.

—Аллага тапшырдык!—ди Василий Фомич.—Хәерле сәфәр сезгә! Бүген азык-төлек хәстәрен күр. Эссе дип тормагыз, җылырак киенегез! Аяк киемнәрегез тазамы?

—Ярый инде..,—ди Азат.—Кышка тикле түзмәсме...

—Яхшы. Безнең өй йозагы бик ансат ачылыр: анда кружкадыр, кашыктыр табарсың. Солдат котелогы... Әзрәк ипи дә булыр, аннары кечерәк банкада варенье, каражимеш, кәгазьгә төргән чәй... Кучкарда кап ярымлап кына шырпы бар. Башланмаганын ал. Юлда энә-җебең булсын... Ну, бывайте... Биргән булса, күрешербез,—ди дә, ничек килгән шулай шыпырт кына китеп бара Фомич.

Василий Фомич сурәте Азатның күңел түрендә якты бер истәлек булып, миһырбан һәм гуманлык өлгесе булып калган.

Азат озакка сузып тормый, шул кичне үк юл хәстәрен күрә. Капчыкка, Фомич әйткән әйберләрдән тыш, инде шактый вакланган сохари, ярма ("шрапнель"), куш уч тоз, бәрәңге, ике шешә кое суы һәм үзләре киптереп маташкан берничә балык та сала. Фомичның әйберләре арасында матур гына пәке дә табыла. Ләкин Азат соңгы вакытларда үзе ясаган бәләкәй финканы да ташламый—дөньяны кем белә?

Иртән бик иртә торып, энесе белән юлга чыгалар. Тизрәк, тизрәк! Тизрәк мәчетле авылга, кардәшләр арасына барып җитәргә! Кызык, алар бирегә—кояш баешына каян килгәннәр дә, ничек шушында төпләнгәннәр, тамыр җибәргәннәр икән? Бүгенге кебек сугыш давыллары китереп ташлады микән әллә? Туган туфрагыннан кешене тагын нинди афәт аерсын!

Фомич Азатны олы юллардан читтәрәк, урыны-урыны белән яшел чирәм дә борын төрткән гади авыл юлларыннан барырга өйрәтә, шуңа күрә чит-ят кеше, хәрби машиналар очратмыйлар. Сугыш һәм һәлакәт эзләре дә күренми. Тын һавада пәрәвезләр оча.

Басуларда сирәк кенә әле күмәк хуҗалыклары таркалып бетмәгән (чөнки аны таркатып нишләсеннәр?) колхозчыларга—чалгы-тырма күтәргән карт-корыга, хатын-кызларга юлыгалар, ләкин алар белән сөйләшеп озак юанып тормыйлар, бу ялгыз хатыннарның биниһая кызганулы карашларын аркалары белән тоеп, адымнарын кызулаталар.

Аннары бер инеш буенда туктап, ялгыз агач күләгәсендә ял итәләр, инде җылынып беткән кое суы эчеп, тамак ялгыйлар. "Кич ботка пешерербез,—ди энесенә Азат.—Көлгә бәрәңге күмәрбез. Чәй эчәрбез. Ә хәзер корсакны бик тутырмыйк, гәүдә җинелрәк булыр, ярыймы?"

Роберт, абыйсының күзләренә мөлдерәтеп карап, ияген кага...

Бераз хәл җыйгач, инештән бер котелок су чумырып алалар да, тагы юлга кузгалалар.

Бәхетләренә каршы, юлда инде табак хәтле салынкы башлары караеп торган көнбагыш басуына тап булалар. Кеше-кара күрмәсен өчен эчкәрәк кереп, шактый көнбагыш уалар, туйганчы ашыйлар, кесәләренә тутыралар. Яшь бәдәннәре кирәклесен алгач, малайларның кәефе күтәрелә: их, дөньялар гел шушылай гына булып торсачы!

Тузанлы юлда үзләреннән-үзләре барлыкка килеп биешә, тузгый башлаган нәни "җен өермәләре" генә ничектер күңелгә тәшвиш сала. Беләсе иде, нинди җанлы көч, нинди әкәмәт хәрәкәт тудыра икән аларны?

Азат офыкта күкселләнеп күренгән урманда төн үткәрербез, шунда ут ягарбыз дип ниятли. Әмма язмыш балаларга мәрхәмәтлерәк караган: урман авызында ук алар "Спорт базасы" дип язылган ике такта йорт янына килеп чыгалар. Ишекләре шәрран-яра ачык, хәтта бер тәрәзәсен дә кубарып алып киткәннәр. Илдә каты куллы хуҗа калмагач, халык, гадәттәгечә, иясез нәрсәләрне,—барыбер әрәм булалар дигән сылтау белән,—өенә ташыган...

Әнә сыңар чаңгы таягы аунап ята, сынык бәҗрасы да янында гына. Әнә ике әлүмин граната. Әнә Робертны да елмаерга мәҗбүр иткән җип-җиңел агач мылтыклар—янәдәмесе винтовкалар—өелгән... Дошманга каршы сугышу өчен Рәсәй кадәр Рәсәй шушылар белән уйнап әзерләнгән икән.

Агач мылтыклар һәм чыра штыклар учакта бик әйбәт яналар, кызу. Ботка да пешә, бер иске чиләктә чәй дә кайнаталар, аннары көленә алты бәрәңге күмәләр. Азатның: "Ах, ул кайнар бәрәңгеләр! Кулларны, иреннәрне пешерә-пешерә ашадык без аларны, минем корымланып беткән битемә карап, Робертым тавыш-тынсыз гына көлде, ә мин аның адәм рәтле көлә дә алмавын күреп, жылый яздым,"—дигән сүзләре хәтеремдә.

База сәкеләре каты булса да, малайлар ышыкта, куркынычсыз җирдә рәхәтләнеп йоклыйлар. Шулай да Азат энесенең вакыт-вакыт ыңгырашканын ишетеп ята. Шуңа да куана ул: ыңгыраша икән, димәк, дөньяны тоя, хәтерли, аңлый, сызлана, борчыла, тавыш бирә... Ихтимал, киләчәктә теле дә ачылыр әле.

Бу төн балаларның әти-әниләреннән башка үткәргән өч йөз дә алтмыш бишенче төннәре була.

Ә мин—Азатның дусты, Робертның да бертугандай күргән күрше абыйсы—бу төнне ничек йокладым, нинди төшләр күрдем икән? Саташмадыммы икән?

Мин, әлбәттә, боларны белмим. Йокым тыныч булмагандыр дип кенә уйлыйм.

* * *

Азат белән еш очраштык. Ул айга икешәр тапкыр килеп миндә куна кала иде. Татар театрында да өч-дүрт тапкыр булдык. Русныкын да читт итмәдек, хәтта курчак театры белән дә таныштык. Опералардан Азат "Алтынчәч"не ошатты шикелле, тик анда да ул аның тарихи нигезе, Җикмәргән турындагы риваять белән күбрәк кызыксынды. Казан циркына Кио килеп чыккан вакыт иде, әлбәттә, анда да бардык. Ләкин Кио картайган, бирешкән, номерлары кызыклы чыкса да, үзе артист буларак тамашачыларны җәлеп итә алмый иде инде. Берәздән аны аренада ике улы алмаштырды.

Юк, мин Азатны театр белән мавыктыра алмадым. "Фальшь күп, озын-озак сөйләшәләр, көлдерергә дип көчәнәләр, бер дә кирәксезгә кәмит ясыйлар, тамашачы мәгънәне үзләштереп өлгерсен өчен зәвыклы һәм фәлсәфи пауза юк. Көнкүреш баткагыннан чыга алмый автор... режиссер... актер... Гап-гади натурализмнан арына алмый, иң садә хисләрне мененче кат сурәтләү белән чикләнә...,"—дип, үзенчә, шөребен-шөрепкә таркатып, ярып салды ул. Мин бик төпченгәч, кабат йөдәтмәслек итеп:

“Ә нигә мулла ролен театр сәхнәсен балаган белән бутаучы шамакайга тапшырганнар?”—дип тә өстәде.

Азат белән бәхәсләшәсем килсә дә, каршы дәлилләремне мин әлегә үземдә калдырып тордым, чөнки ни генә әйтсәң дә, гаибтән кайтып төшкән Азат Сәйдәшев безнең театрга көнбатыш аршыны белән якын килә иде, татар театрын, аның тарихын һәм үзенчәлеген, бигрәк тә совет чорының кысаларын белеп бетерми иде. Аңлап житмәгәч, ул безнең сәнгатьнең кимчелекләрен дә гафу итә алмый иде.

Ләкин... Фәлсәфи тирәнлек житмиме? Ә бәлки тамашачы шуны—бик үк тирәнгә китмәүне сорыйдыр? Ә бәлки без халыкны дөньякүләм әһәмиятле нәрсәләрдән, чын фәлсәфәдән биздереп бетергәнбездер? Ә бәлки татар телен тел итеп үстергән шәрык алынмаларыннан арына торгач, чын фәлсәфәгә кирәрлек, “гали матдәләр”, ягъни “югары материяләр” турында гәп куертырлык телебезне үк җуя башлаганбыздыр? Сәнгатьтә көнкүреш мәсьәләләре белән генә шөгыльләнүебез дә телебезнең һәм, димәк, фикерләвебезнең хәерче хөкемендә калуыннан киләдер? Арзанлы опереттадан, кәмиттән биздерү өчен, тамашачыга каршы барырга, аяк терәп каршы торырга кирәктер бәлки? Тамашачының зәвыгын үстерә алмаса, театрның киләчәге юк. Алгарыш кирәк театрга, алгарыш... Ә моңа Казандагы сыңар театр белән генә—бернинди ярышусыз, конкуренциясез—ирешеп буламы?

“Сәнгатьнең теләсә кайсы төрендә иң мөһиме—чаманы белү”,— дигән иде Азат. Монысы белән ул хаклы, әлбәттә.

Музейларны яратты Азат Сәйдәшев. Чөнки ана биредә күп нәрсә яңа иде, жан азыгы иде. Республика музеенда егерменче еллардагы Татарстан байрагы янында озаклап басып тордык. Ә колхозлашу чорында авылларга кайткан зур тимер көпчәкле тракторны күргәч, Азат балачагына кайткандай булды, куанды, тракторның бөтен нәмәрсәләрен капшап чыкты. Тора торгач, шушы җансыз, зур, алагаем авыр, гарип тимер кисәге минем күңелдә дә җылы дулкыннар кузгатты бугай.

Сәнгать музеенда Азат үзе генә булды. Нинди тәэсирләр алуы турында сорагач, ул иңбашларын җыерып көлемсерәде генә. Театры театр инде, ә менә сынлы сәнгатьне слесарь кеше бу кадәр нечкәли торгандыр дип башыма да килмәгән иде, ә ул, баксаң, Европа музейханәләрен йөреп чыккан икән.

—Безнең рәссамнар арасында да... теге кем әле?—бунтарьлар юк икән,— диде Азат.—Гыйсъянчылар, кыюлар, башсызлар юк...

Мин текәлеп караганны абайлагач, болай дип өстәде:

—Хәер... Бер картинада мин нидер сиздем бугай... Беләсеңме, анда көзге табигать фонында бер нефтьченең мәһабәт сыны сурәтләнгән... Ачы жил, яңгыр сибәли, аяк асты үзе катканак, үзе былчырак, ә ул шушы кырыс стихияне, асылда бөтен табигать-ананы тез чүктергән әкияти каһарман... Мондый гына уңайсызлыкларга төкерә ул! Үз бурычын үтәгән, планны тутырган, яңа жиңүләрне яуларга атлыгып тора. Примитив? Әйе, башта миңа шулай тоелды да. Ләкин, жентекләбрәк карагач, мин картинада бөтән бер нәрсәне дә тотып алдым—рәссамның яшертен көлүен дип әйтимме? Көлемсерәвен генәме? Мин моны аңлап ук бетермәдем, ләкин шушы сизелер-сизелмәс Мона Лиза елмаюы хакына авторны гафу иттем...

Ул картинаны мин дә хәтерли идем:

—Килешәм,—дидем.

Чыннан да, рәссам бу картинасында фиркале рецензентларны һәм “совет чынбарлыгы шушындый-шушындый булырга тиеш” дип тукып, Рим папасын чукынырга өйрәткән шикелле өйрәтеп торучы түрәләрне төп башына утырта, ул чынлыкта аларга нәкъ киресен сурәтли... Партшколада укып, сәнәктән көрәк булган “житәкчеләр” сәнгать әһеле сизгәнне, ул тойганны күрмиләр, чөнки күңел күзең күрмәсә, маңгай күзе—ботак тишеге.

Ләкин Азат белән мин, социалистик реализм сазлыгына кереп батмас өчен, бу хакта да артык сүз куертмадык.

Әдәби музейлар белән танышкан вакытта мин Азатны Казанның иске, Маяковский әйтмешли, "кәкре" урамнарыннан адашканчы йөреттем һәм, гаҗәпләнүемә каршы, ул нәкъ менә шушы кәкре-бөкре урамнарыбызны үз итте. Яңа Бистәдә кыйшык хосусый йортлар капкасы төбендә утырып азмы гәп куертканбыздыр...

Бер вакытны мин Азатка укырга "Намус" романын биреп җибәрдем. Янәсе, заманы һәм рухы буенча безнең буынга якын, аңлаешлы булыр, телен дә яратыр дип уйладым. Телен яраткан, әлбәттә, ләкин шулай да ул мина китапны яртылаш кына укыган килеш кире кайтарды. Монда вакыйгалар программалаштырылган, бөтенесе алдан ук билгеле димәкче булды.

Шунда мин, бераз үпкәләбрәк тә, анар "Туган ягым—яшел бишек"не китереп тоттырдым. Шикләнебрәк алса да, бу юлы Азат китапны өч атналап тотты. Юк, ул аны өстәлдә яткырмаган, бәлки кат-кат укыган булып чыкты.

Шуннан соң Гамзатовның "Дагыстаным" китабын табып укыган Азат. Бу ике әсәрне чагыштырган. "О, безнең Бәширов көчле, чөнки чыннан да намуслы, төчеләнми. Ә "Дагыстан" шома язылган (бер баскыч югары күтәртеп, чибәрләп тәрҗемә ителгән), шигъри бизәкләр күп, нәкышьләр, ләкин шуннан артык түгел,"—дип, кыю һәм саллы нәтиҗә ясады Азат. Аннары ул Фатыйх Хөснинең "Утызынчы ел"ын яратып укыды...

Шагыйрьләрдән аңа бөтен ягы белән Туфан охшый иде. Гомумән, Туфанның лирикасы белән танышканнан соң ул, әйтик, Такташны татар шигъриятендә аргы урыннарга чигерә башлады кебек. Миндә Туфанның егерменче еллар азагында чыккан китабы да сакланган иде. Гаҗәбемә каршы, Азат шагыйрьнең яңа басмасы белән искесе арасындагы вак кына аермаларны да тотып алган. Мәсәлән, бер шигырендә Туфан жил турында "төрки таныган күк" кәгазь актара, ди. Яңа басмасында әллә автор үзе, әллә йомры башлы бүгенге мөхәррирләр моны "хәреф таныган күк" дип "дөресләләр"... "Төрки тану" өчен "хәреф тану" гына житсәче!

Туфанның бер мөхтәрәм шагыйребез турында: "Әлләкемнәр белән сөйләшә ул" дигән юлы гына Азатка аңлашылмый торды. Мин әлеге шагыйребезнең, заман чиренә бирешеп, "Күнелем Ленин белән сөйләшә" дигән шигырь язуын әйткәч, ул көлеп үк җибәрде: "Ничек шәп әйткән!"—диде.—Үзе шелтәли, үзе ярата, иеме? Шагыйрь күңеле әлләкемнәр белән сөйләшмәскә тиеш, аңа Хакның үзе белән сөйләшү хокукы бирелгән бит...

Азатның тагын бер сүзе истә калган. Нәрсә унае белән әйткәнен хәтерләмим. "Сәнгатьчә фикерләү, сәнгатьчә аңлау күп белгәннән түгел, бәлки житәрлек белмәүдән килә. Житмәгәнен сәнгать һәм интуиция гүзәллек белән тутыра,"—дигән иде ул.

Бераз соңрак, сөйләшә торгач кына, мин Азат Сәйдәшевнең тик кенә ятмаганлыгын, илленче елларда Көнбатыш Берлинда сәнгать академиясен тәмамлап чыкканын белдем. Гомумән, ул философ иде, минемчә. Ә шоферлыгын ташламавына килгәндә, Азат дөнья гизәргә ярата икән. Хобби? Хобби гына түгел. "Юл йөргәндә мин бөтен кайгыларымны онытам,—дип аңлатты ул мина.—Күз алдымда ачылган яналанъяна манзаралар арасында мин Бәширов язган "яшел бишегемне" дә табар төсле була идем..."

Кыскасы, юл йөрү аның йөрәгенә үзе бер шифа, бәлзәм кебек икән, ягъни тәкъдир аңа мөсафир булырга кушкан...

Мин Азатны аңлыйм. Моннан утыз биш еллар элек тә жәяүләп ил гизгәндә ул туган жирләрен эзләмәгән мени? Менә хәзер дә, үзе дә аңламастан, язмыш тарафыннан аяусыз сызып ташланган балачагын эзли ул.

Сәяхәтче сәфәрдә жирсенә, жылы гаиләсен сагына, өенә кайтып мич башында ятканда юл газаплары турында хыялланып ләззәт таба, диләр.

Утрак тормышка күчә алыр микән Азат? Мөсафир булып яратылган кеше Ватанын табар микән? Ә бит психологлар ностальгиягә дәва юк диләр... Шундый зәһәр уй чагылып китте дә, мин аны тизрәк куалап жибәрергә тырыштым.

Кашки балачагына кайтыплар булсачы...

Балачак хатирәләрен кайтарып була-булуын. Менә мин тагы Азатның башыннан кичергәннәре турында авыр хикәятне тынлап утырам.

Белоруссиядәге татар авылын күрү Азатларга насыйп булмаган.

Инде бар өметләрен баглаган мәчетле авылга күп булса ярты көнлек ара калгач, малайлар урманда партизаннарны эзәрлекләүче эсэсовчылар төркеменә юлыгалар.

Алар кулында ниләр татыганын Азат жәелеп сөйләмәде, бу вакытта аның агарынган яңакларында каты төерләр йөргәнне, бүрткән чигә тамырлары ничек типкәнне күреп, мин дә артык сорашасы итмәдем.

Берәр айдан Азат белән энесе Рига тирәсенә, Майорига ир балалар ятимханәсенә килеп эләгәләр.

Биредә алар өч ел яшиләр.

Заяга үткән өч ел... Азатның бер тотам чәче менә шушында, үзенә ундүрт яшь тулар-тулмас вакытта агарган.

Бу өч ел эчендә ниләр генә булмый! Ятимнәр йорты сак астында булса да, балалар дөнья хәлләреннән хәбәрсез калмаганнар. Ленинград блокадасының өзелүе һәм жинелмәс герман гаскәренең чигенүе, Сталинградта фашист генералы Паулюсның әсир төшүе, Киевнең азат ителүе... Юк, болар гына түгел, күктә көнбатышка таба төркем-төркем очып үткән һәм бомбаларын ташлаганнан соң тәртип белән тезелешеп кайткан кызыл йолдызлы самолетларны да бөтен халык күрә бит! Балалар да самолетларны барышлый һәм кайтышлый саныйлар. Үзалларына елмаялар. Әйе, берничә самолет житми кайткан чакта... Ләкин берничә генә бит!

Кеше жәһәннәмгә дә күнегә. Анда да жайлырак урын эзли, чөнки жәһәннәм утының сәкарь дигән салкынчарак төше дә бар, имеш.

Азатның пөхтәлек һәм тәртип яратуын бу йортта да күреп алалар. Тиздән үзен кече яшьтәгеләр бүлегенә төнге санитар итеп билгелиләр. Роберт та шунда булгач, Азат моңа бик теләп алына. Өстәмә рәвештә бирелгән сыныкларын энесе белән бүлешә, ә ул порцияләр көннән-көн кими, авызга да йокмый башлый—шул, яланып кына каласың. Фашист Германиясенең ресурслары тәмам бетеп килә...

Икенче елны балаларга үзара да немец теленнән башка телдә сөйләшүне тыялар, көн саен ике-өч сәгать немец теле һәм Германия тарихы, аннары нигәдер логика укыту кертелә. Һөнәр дәресләре дә немец телендә алып барыла. Слесарьлыкны Азат, күрәсең, шунда үзләштергәндер.

Малайлар иң башлап алманча сүгенергә өйрәнәләр, әлбәттә. Чөнки ана телендә аты-юлы белән сүгенеп авыз пычратасы килми, ә чит телдә моның бер кыенлыгы да юк, нәтижәсе әйбәт—ачуларың басылгандай була, ничектер бушанып каласың. Төптән карасаң, кеше дигәнең юкка сүгенми бит. Сүгенә икән—димәк, аның эчке дөньясы тыныч түгел, димәк, ул тышкы дөнья белән яки хәтта үз-үзе белән низагта, конфликтта. Тыелган сүз әйтү менә шул тынычсызлап торучы тойгыларны да кире үзе белән алып китеп, күңелнең аргы, караңгы почмагына илтеп күмә ахрысы. Артык парны чыгара да диләр.

Бер мәлне балалар йортында йогышлы тире авырулары, кырчын тарала.

Администрация хатын-кыз туалеты урнашкан почмак бүлмәне изолятор итеп жайлаштырырга мәжбүр була һәм Азатны шунда санитар итеп күчерәләр.

1944 нченен язында бирегә Робертны да салалар, ләкин тире авыруы белән түгел. Робертта ул заманнар өчен иң хәтәр хасталарның берсе—туберкулез башланган була.

—Роберт терңәкләнеп китә алмады. Көннән-көн ябыкты, буыла-буыла ютәлли башлады, күзләре генә утырып калды,—дип сөйләде Азат.—Ә дәва нәрсә? Аспирин белән балык маеннан башка берни юк... Соңгы сәгатендә Роберт телгә килеп: "Абыем, без бит Сәйдәшевләр,—диде.—Мин сине яратам... Мин әтиемне, әниемне дә, Айдар абыемны да яратам... Ерак-ерактагы Илдар абыемны да... Тагы Ганжә апаны..."

Робертның бу дөньядагы иң соңгы сүзе: "Нигә..?" дигән гап-гади сорау булган. Бу сорауга берәү дә җавап бирә алмый. Бу сорау күбәүләрнең чәчен агарткан. Әнә Азатның да...

Азатка кече энесенең кабере билгесез, чөнки немец администрациясе җеназасын озата барырга рөхсәт итмәгән. Галифе кигән әзмәверләрдән ничек кенә инәлеп сорамасын, Азат катгый "Найн!" дигәнне ишетә.

Берничә көннәр ул үзен кая куярга да белмичә аңгы-миңге йөри. Изоляторга керсә, элек Роберт яткан койкага карый алмый, күзләрен чытырдатып йома, колагында энесенең соңгы сүзе яңгыраган кебек була: "Нигә?"

Нигә мин бу дөньяга килдем? Нигә китәм? Нигә сүнәм?

Исәнгерәп йөри торгач, йокысызлыктан һәм чарасызлыктан Азат үзе дә авыруга сабыша. Бу авыруның исеме—дөньядан бизү, битарафлык, өметсезлек, рухи төшенкелек. Бу авыру кешенең җан асрау инстинктларын юкка чыгара. Ул рухи спид кебек коточкыч...

Ә ятимнәр йортында, шөрепләрне тыгызлап, режимны тагы да көчәйтәләр, тышкы дөнья белән элемтәләр тәмам өзелә. Бүлмәләрне төнгелеккә бикләп куя башлыйлар, ишекләргә төрмә камераларындагы кебек "күзләр" ясыйлар. Аның каравы ашау ягы яхшыра, ара-тирә маргарин һәм какао да биргәлиләр, көчли-көчли балык мае эчерәләр. Ни өчен микән?

Көннәрдән бер көнне балаларның тулы исемлеген төзиләр. Ялгыш кына күреп калган кәгазьдә Азат сабыйларның исем-фамилиясе янында җәя эчендә яна исемнәр язылганын абайлый. Күбесенең милләте эстон яки латыш дип куелган... Бусы тагы уйландыра. Ни хикмәт бу? Бирелә бит башлыча рус балалары, Азат кебекләр дә бар. Аннары балаларны бик җентекләп медицина комиссиясе карый, кан анализлары алалар. Шик тә юк, оккупантлар ниндидер этлек эшләргә җыеналар. Һокус-покус.

Һокус-покус озак көттерми һәм немецлар аны гадәттән тыш өлгерлек һәм төгәллек белән тормышка ашыралар.

1944 елның 4 октябре көнне балалар йорты ишегалдына биш зур хәрби автобус килеп керә. Җиде яшькә кадәрге 133 сабыйны һәм аларга хезмәт күрсәтүче өлкәнрәк яшьтәге малайларны бер сәгать арасында автобуска төйиләр дә туп-туры Рига гаванена китерәләр. Бирелә аларны узган гасырдан калган куласалы дингез пароходы көтеп тора. Балалар, каз бәбкәләре кебек тезелешеп, автобуслардан алып трапка кадәр ике яклап торучы жандармнар арасыннан трюмга үтәләр. Пароход минутына кадәр төгәллек белән кузгалып китә.

Төнлә Кенигсберг порты. Пирста сигнал утлары гына яна, чөнки бомбага тотудан куркалар. Хәер, бу вакытка америкаң һәм инглиз авиациясе шәһәрне бомбалар белән сөреп чыккан була инде.

Караңгыда пароходны артык нык бәрдермичә генә китереп туктату штурманнан һәм матрослардан үзе бер осталык һәм тәҗрибә сорый. Шулай да причал белән орынышкан мизгелдә бөтен пароход тетрәнеп, шыгырдап, җан ияседәй ыңгырашып куя һәм аның бер дә кирәксезгә чыгырдан ычкынган авыр якоре суга чума. Өзек-өзек командалар һәм тыелып кына сүгенгән тавышлар ишетелә. Матрослар борындагы якорьны байтак кына вакыт кул чыгыры белән күтәртеп азапланалар.

Ниһаять, пароходны юан арканнар белән чуен букәннәргә чалып

куялар һәм энгердә кулга-кул тотынышкан йокылы-уяулы балалар чылбыры ярдагы инде моторлары әкрен генә гөрләп торган автобусларга таба сузыла...

* * *

Бу көннәр турында Азатның хәтере уенчык фильмоскоп лентасындагы кебек аерым-аерым сурәтләрне генә саклый, ләкин ул телсез сурәтләр шулкадәр мәгънәле, кисәтүле һәм шомлы, тәшвишле.

Клингенберг, Мессен, Ролшдорф—болар Любек шәһәре тирәсендәге авыллар. Сугыш чоры булмагандай төзекләр, матурлар. Автобуслар шушы авылларның һәрберсендә тукталып, ак халат кигән ниндидер ханымнар һәм әфәнделәр балаларның үзләренә охшаганнарын,—"Бусы", "Бусы" дип төртеп күрсәтеп,—сайлап алалар.

Азат әллә кайсы ягы белән Робертка тарткан бер ак чырайлы малайның Клингенбергта калуын гына хәтерли. Шулай итеп, сабыйлар шушы авыллардагы ятимханәләргә бүлеп таратыла. Бу вакытта, үзләрен мал базарындагы кебек "сатканга", ник бер сабый җыласен яки уфтансын... Алар инде бөтенесенә битарафлар, күз карашлары ук боздай салкын, төксе, өметсез, хәрәкәтләре җансыз һәм салмак. Кая дип ашыгырга?

Унөч-ундүрт яшьлек үсмер малайларны исә бер автобуска утыртып башка җиргә алып китәләр. Болары—Казанцев Азат кебек "үз" фамилияләрендә калган балалар.

Аларны бүтән язмыш көтә.

Борынгы, университетлы Мюнстер шәһәре читендә урнашкан үсмерләр лагере балалар йортына һич тә охшамаган.

Агачлык эчендә дүрт-биш карсак бина, бараклар... Тәрәзәләргә тимер рәшәткәләр тотылган, ә территорияне ике кат чәнечкеле чыбык белән уратып алганнар. Бер читтә, йөзьяшәр наратлар арасында, алардан да биегрәк дүрткел кирпеч морҗа тырпаеп тора.

Монда режим катырак булса да, малайларны еш кына саф һавага чыгаралар, туп тибеп уйнарга рөхсәт итәләр, гомумән, физик күнегүләрне хуплыйлар. Чисталыкка да әһәмият бирелә. Тырнагын киселгән булсын. Колагына шалкан чәчәрлек булмасын. Якаң керләнмәсен. Югыйсә унтер Вальтерның юан бармагы маңгай тирәңдә уйнаячак. Каты чиртә фашист, әйтерең бармы! Монда атна саен мунча кертәләр һәм иң мөһиме—сабынны җәлләмиләр, анысына да рәхмәт.

Атнага бер тапкыр зур палатада сугыш турында киножурнал күрсәтәләр. Журнал саен кул күтәргән совет солдатлары, йончыган әсирләр... Тик шулай да соңгы журналларында "Мәскәү—капут" дигән сүз күренми инде.

Кайчагында Азат Вася агайның: "Бу сугыш афәте өч-дүрт елга сузылыр әле" дигән сүзләрен искә төшерә. Карт пәйгамбәр хаклы булган. Менә аның өч-дүрт ел дигәне коточкыч авырлыклар белән булса да үтеп бара. Чыннан да, сугышның ахыры күренә инде. Ләкин ул нинди булыр? Азатларга нинди азатлык алып килер? Кем белә, бәлки Азатка әти-әнисе белән кавышу да язгандыр? Ләкин күңел көзгесендә аларның сурәтләре тонык.. Уйланып, татлы хатирәләргә бирелеп яткан чакларында Азат әнисенең алманча сөйләшә башлаганын тоеп сискәнеп китә, чөнки ул үзенең алман телендә фикерли башлаганын чамалый.

Шулай да Азат әкренләп аякка басуын, тернәкләнеп килүен, ягъни фани дөнья һәм иртәгесе көн белән кызыксына башлавын сизә. Бар, кайдадыр яктылык чишмәсе бар, тик Азатны чакырып, әйдәп торган Рушан йолдыз гына күренми—аны болытлар каплаган.

Күктән, болытлар арасыннан еш кына авыр бомбардировщикларның гөрелтесе инә, хәтта бу гөрелтедән барак түбәсенен мүкләнгән чирәбе кубып төшкәли. Бу гөрелте иннәренә басып, сине сыгып төшерә, җир куенына кереп сыенырдай буласың... Авыр очкычларның гөрелтесеннән җир инри... Мескен Германиянең индустрия үзәкләрен хәрабәгә әйләндереп, кире Англия ягына кайтып барышлый, самолетларның тавышы да бүтән, инде алар хәзер пар күгәрченнәр кебек тыныч кына гөрлиләр. Лагерьның каравылы һәм персоналы шуннан соң гына подвалдан чыгып, яңадан көндәлек вазифаларына керешә һәм малайларны да ирекә чыгара, чөнки тревога-аларм вакытында аларны палаталарында бикләп куйган булалар. Хәер, Азатлар бу подвалның бомбадан саклый алуына бик ышанмыйлар да. Йөзәр кило авырлыгындагы бомбадан зонтик белән сакланып маташтың ни дә, агач йортның идәне астында качып яттың ни дип, батырайган булалар.

Әлегә лагерьга һөҗүм булганы юк. Унтер Вальтердан ычкынган сүзләргә караганда, бу тирәдә хәрби объектлар гомумән юк икән, хәтта американнар белән инглизләрне бутау өчен бер җирдә ялган аэродром корып, фанер самолетлар ясап куйганнар. Алдарсың американны! Беренче көнне фоторәсемгә төшереп алганнар да, иртәгесен сынар самолет килеп, боларның фальшь-аэродромына "агач бомбалар" ташлап киткән. Шулай, американнар фашистлардан ачыктан-ачык мыскыллап көлә башлаганнар хәзер...

Лагерьга урнашып бер ай үтәр-үтмәс, малайларны территориянең түр почмагындагы лаборатория бинасына унар-унар бала чакырып китерә башлыйлар.

Баксаң, лаборатория дигәннәре кан ала торган пункт икән.

Башта, әлбәттә, әңгәмә үткәрелә. Сәяси әңгәмә. Шагыйрь күңелле Петр Митрофанович Петухның политинформациясе кебек үк ясалма, өстәвенә, математиклар әйтмешли, минус тамгасы белән. Өстәвенә, әңгәмәне китель йә гимнастерка кигән кеше түгел, бәлки ап-ак халат кигән карт табиб үткәрә.

"Сез үзегезнең каныгыз белән ятимханәләрдә авырып яткан балаларга, бичара туганнарыгызга, яралыларга, Бөек Германиягә ярдәм итәсез, Җиңү сәгатен якынайтасыз. Без сезне ашатабыз-эчертәбез, тәрбиялибез, җил-яңгыр тидермичә, һәртөрле авырулардан саклыйбыз. Германия тиздән үтә куәтле, чын мәгънәсендә дәһшәтле яңа корал кулланачак һәм бөтен дөнья аның каршында тез чүгәчәк. Сез сау-сәламәт килеш шул Җиңү көнен күрәчәксез! Хайль!"

Шнейдер фамилияле бу табибның улы көнчыгыш фронтта хәбәрсез югалган. Менә ул үзе дә, карт башы белән, халкы һәм ватаны файдасына эшләвен дәвам итә икән. "Юк,—дип уйлый Азат,—бу пенснэле мөлаем карт йә үзе алданган, йә күз дә йоммый ялганлый."

Кан биреп кайткан беренче төркем малайларда башта әлләни шикшөбһә тумый әле. Кан алганда авырту-мазар сизелми, бөтенесен бик чиста эшлиләр икән. Ягымлылар, ибен-ипкә китереп, җайлап, йомшак кына сөйләшәләр, "күгәрченкәем" дип эндәшәләр, башыңнан сыйпыйлар... Тик каннары агып төшә торган пыяла банкалар катыргы тартмалар эченә яшерелгән була.

Кан биргәч үк малайларга татлы сөт эчерәләр, кулларына берәр алма тоттыралар. Башлары әйләнеп куя куюын, әмма йоклап торгач, иртәнгә, бөтенесе нормага кайткан кебек була. Соңгы вакытларда малайларның тамаклары тук булганга, яшь организмнары тиз генә бирешми.

Азат чират буенча дүртенче төркемгә эләгә.

Соңгы елларда төшкән тукмаклар аны һәр нәрсәгә, һәр кешегә сак карарга өйрәтеп өлгергән инде. Һәм бу шикчеллек анарда бик озак дәвам итәчәк әле. "Мин бу шикчеллектән, туган илгә кайтып сине күргәннән соң гына котылдым,—дип сөйләгән иде Азат.—Рәхмәт сиңа... Күңелемдәге ниндидер бер агудан арындым..."

Кан ала торган лаборатория барагы да зурлыгы белән башкаларыннан кайтыш түгел. Коридорының ике ягында сигез ишек бар. Икесенә "Палата 1" һәм "Палата 2" дип язылган. Иң аргы башта яшелгә буяган тимер ишек, анысы кая алып чыга торгандыр? Ирекка түгел, билгеле—тимер ишек куйганнар икән, монын бер-бер хикмәте дә булмый калмас.

Менә малайларны койкаларга яткырып, инде резин көпшәләрне дә тоташтыралар, әнә Шнейдернын чукрак-телсез кебек сүз дәшмичә, ияген генә кага торган "шәфкать туташы" алагаем зур инәле шприцын тотып, Азатка таба килә...

Шушы мизгелдә колак пәрдәләрен ерта торган ачы сирена улавы ишетелә. Тревога! Аларм!

Шундук электр яктысы сүнә.

—Балалар! Тик кенә урында ятыгыз! Бу—ун-унбиш минутка гына...,—дип вәгъдә итә Шнейдер һәм шәфкать туташларын ияртеп ашыгып палатадан чыгып китә. Гадәттәгечә, алар күрше бакнның подвалына таба элдертергә тиешләр.

Ике-өч минуттан янәшәдә генә бомба шартлый. Баракны күтәреп бәргән шикелле була. Чылтырап тәрәзә пыялалары коела, үзеннән-үзе түшәмдәге электр лампалары кабына. Аргы башта кайсыдыр ишекнең тупсасы чыелдап, ишек үзе зыңгылдап куя...

Сирена улый.

Азат сикереп тора да тиз генә ботинкасын аягына элә, шнурын да бәйләп тормый.

—Малайлар, мин күз салып керәм,—ди ул койкада ятучыларга.—Тагын шартлый калса, бернигә карамый торыгыз да, резин көпшәләрегезне йолкып атыгыз... Котылу җаен карагыз. Аңладыгызмы?

Малайлар тиз-тиз ияклэрен кагалар.

Коридор буп-буш, әлбәттә. Ләкин монда да лампочкалар кабынган. Шартлау дулкыны электр линиясен тоташтырган булыр. Ә аргы баштагы тимер ишек яртылаш ачылып киткән. Аннан ниндидер механизм эшләгәндәге кебек шыгырдаган тавыш ишетелә.

Азатны аяклары шунда таба алып китәләр.

Тузан баскан тәрәзәсез-нисез бүлмә. Уң якта тәгәрәтеп йөртмәле биек носилка тора. Сул якта, чаштыр-чоштыр килеп, ямаулы транспортер лентасы шуыша. Лента стенадагы уемнан чыгып, наратлар арасындагы биек морҗалы сарайга барып керә икән. Ләкин сарайның морҗасы күренми инде, америкаң бомбасы нәкъ шунда килеп төшкәнгә охшый.

Азат бер мизгелдә барысын да аңлап ала. Бу бүлмә каннарын суыртып бетергәч үлгән балаларны крематорийга озата торган җир икән лабаса! Аларның суынып та җитмәгән мәетен менә шушы кат-кат ремонтланган калын брезент тасма крематорий учагына илткән, илтергә тиеш!

Азатның башында: "Алайса, бу җәһәннәм машинасы мине шушы минутта ук моннан алып чыксын әле!"—дигән уй чагылып китәргә дә өлгерми, тәвәккәл малай әкрен генә шуышкан транспортер тасмасына менеп ята.

Йөрәге доп-доп тибә, тасманы йөртә торган уклау-роликлар аның кабыргаларын саный. Бер, ике, өч...ун...унбиш... Тукта, кешегә шулкадәр кабырга каян килсен!

Хисап утызга җиткәндә транспортер Азатны әлеге шыксыз кирпеч бина эченә алып кереп, алагаем зур авызлы мич каршына китереп ташлый. Ялмавыз мич кабат кабынмаслык булып җимерелгән, аның арткы ягыннан шәрә нарат кәүсәләре һәм зәңгәр күк елмаеп-көлеп тора. Ирек шунда, шушы җәһәннәм миче аркылы үткәч башлана: биек морҗа ишелеп төшкән дә, чәнечкеле киртәләрне сытып изгән һәм азатлыкка күпер салган!

Һәм Азат крематорий миченә аяк баса.

Бу җимерек, үле крематорий сурәте һәм андагы төчкелтем ис Азатны гомере буе эзәрлекләр, төшләренә кереп йөдәтер әле.

Ә хәзер аның күп булса ун минут вакыты бар. Шушы ун минут арасында ул бу тирәдән булдыра алган кадәр ераграк китеп өлгерергә тиеш.

Колак төбендә, үлән арасындагы вак чикерткә шикелле әкрен генә челтерәп, музыка кабатлана: "Без җиналмәгән дошман тумаган! Дошман тумаган! Дошман тумаган!" һәм хәтер төпкеленнән актарылып чыккан бу зәгыйфь авазлар сирена улавын басып китәләр.

Азат үзенең кая чапканын да белми һәм моны белүнен кирәге дә булмый, чөнки ул дәһшәттән кача, чөнки аның артында тагы бомба гөрселдәп җирне тетрәтә.

Малайның битен куаклар тырный, бер ботинкасы төшеп калгач, ул икенчесен дә салып ыргыта. Абынып егыла. Торып тагы чаба. Үрмәли. Нindидер канауга тәгәрәп төшә. Тагы тора... Җан саклау инстинкты аны һаман арырак өстери...

* * *

Фрау Эльза Фридрих-Клейн.

Бу дөньяда Азатка ярдәм кулы сузган тагын бер изге җан шушы тузганактай ап-ак чәчле алман карчыгы була. Болай, өрдең исә саны санга таралып китәр сыман үзенең, әмма тора-бара Азат бу чирләшкә карчыкның иситкеч нык ихтыярлы булуын күргән һәм аны сокланып искә ала.

Фрау Эльза Азатны үзенең сыер абзарында печмактагы салам өстендә йоклаган хәлендә "таба". "Кешеләр балаларын кәбестә яфрагы арасыннан табалар, ә мин менә, балакач, сине салам арасыннан таптым,"—дип көлеп сөйли ул соңыннан, инде үзләшеп беткәч. "Син минем Коткаручым,—ди.—Иисусны да әнисе аранда тапкан,"—дип өсти.

Фрау—моннан бернечә ел элек вафат булган мәшһүр профессор фон Фридрих-Клейнның хатыны икән. Арийлар канының иң затлы кан булуын исбатлаган ире өчен ул исемле пенсия алып яши. Дөрес, сугыш вакытында Фрау Эльзага авыл җирендәге кечкенә генә хуҗалыгы белән тормыш күтәргә туры килә. Бердәнбер якын кешесе—оныгы да һәлак булгач, Фрау Эльзаның рухиятенә зыян килгән: вакыт-вакыт, авыруы көчәйгәндә, ул дөньядагы маякларын җуя, үзенең кемлеген дә оныта торганга әйләнә. Мондый көннәрне фрау Эльза Азатны үзенең оныгы белән бутый, ана "Отто" дип эндәшә.

Аңы чуалыр алдыннан фрау Эльза караватына менеп ята да, күзләрен йома, кипшергән иреннәре генә кыймылдый. Якынрак килсәң, аның нindидер югары фәлсәфи хакыйкатьләрне пышылдаганын ишетәсең: "Табигать фирка дигәнне белми,"—гап-гади бакчачы Лютер Бербанк сүзләре. "Кешене хезмәт тудырган һәм аны үзенә кол иткән". "Кичегеп килгән хаклык ялган түгелмени?" "Бу ләгънәтле заманда галәмнәр дә, гавәмнәр дә бер-берсеннән ераклашалар"... Аннары авыру карчык: "Nacht und Nebel"—"Төн һәм томан" дигән сүзләрне кат-кат пышылдый да тирән йокыга тала, аны ачы "аларм" сиренасы да уята алмый.

Икенче көнне фрау берни булмагандай торып, хуҗалык эшләренә ябыша.

Бер-ике атнадан, инде тәмам ияләшеп, йорт эшләрендә булышкалап, гаилә әгъзасы булып беткәч һәм өстенә фрауның оныгыннан калган нафталинлы киемнәрне киеп алгач, Азатка профессорның китапханәсендә казынырга, хәтта кабинеттагы йомшак кәнәфигә күмелеп утырырга да рөхсәт ителә. Язу өстәлендә фон-Клейнның кара күн тышлы куен дәфтәре ята. Фрау кичләрен, дөньясын онытып, шул дәфтәрне актарып утыра һәм әлеге "хакыйкатьләр"не дә ул шушы калын дәфтәрдән откан икән.

Хуҗа карчык Азатның кем икәнлеген бик яхшы аңлый һәм малайны хакимияттән саклау өчен чарасын күрә башлый. Ул анардан коеп куйган "немец малае" ясарга ниятли. "Моның өчен син беренче нәүбәттә немецчә

бернинди акцентсыз сөйләшергә тиеш,"—дигән таләп куя ул. Аннары, карап тора-тора да: "Юк, син югары дойч акценты белән сөйләшергә тиеш!"—дигән карарга килә.

Әлбәттә, шулай. Чеп-чи югары дойч шивәсендә сөйләшкән сары чәчле, яшькелт күзле малайны арий канлы түгел бу дип кем шикләнсен?

Дөрес, Азатка үз-үзен тотышындагы кимчелекләрдән арыну җинелдән булмый. Соңгы елларда анарда тешләк "бүре баласы" комплексы тотрыклы тамыр җибәргән бит. Кайчандыр, яшьлегендә үзен театр сәхнәсендә дә сынап караган тәҗрибәле фрау Азатны янабаштан елмаерга өйрәтә. Аристократларча аяк кагып кына баш ияргә, нәзәкатьле ханымнарның кулын үбәргә, патефон музыкасы астында баш әйләнгәнче сихри вальста бөтерелергә...

Бөтен күңеленне кара кайгы баскан бер вакытта елмаеп кара ди син! Ә фрау чарасын таба. Азатның ифрат ясалма итеп, көчәнеп елмаюын күрүгә үк җылый башлый. "Иң матур бер мизгеленне искә төшер! Йом күзләреңне!"—дип боера ул, аяк тибеп. Әллә шушы кеп-кечкенә әбинен, гасабиланып, күз яшьләрен йота-йота аяк тибеп кычкыруы тәэсир итә инде, әллә Азатның хәтерендә кинәт калкып чыккан Ганҗә адәм акылы ирешмәслек ераклыктан аңа матур итеп елмаямы,—икенче мизгелдә Азат каршында басып торган фрау Эльза шатлыгыннан көлеп тә җибәрә.

Чәнечкене сул кулыңа тотып ашау, үтмәс пычак белән ризык кисеп азаплану һәм, гомумән, табында утыру әдәбе—болары ансат, ул кагыйдәләр, акылга муафыйк булганга, җиңел үзләштерелә.

Шулай да иң кыены алман теле булып чыга. Фрау Эльза кышкы кичләрдә Азатның башын "дойче грамматик" белән катыра. Татар телендәге алты килеш урынына барлы-юклы дүрт грамматик килешләре белән түгел! Инде немец телен өйрәнеп беттем дигәч тә, аның синтаксисында "кондиционалис" дигән бер нечкәлек кала икән әле, хәерсез.

Тырышсаң, аны да җиңеп була икән ләбаса.

Сәләтле шәкертенең һәр унышына фрау балаларча куана, аңа карап Азат та ихластан елмая...

Ни хикмәт, малай шушы чит-ят һәм, ни әйтсән дә, үзенә дошман халык теленең аһәңен тоя башлый. Бигрәк тә брадәр? Гриммнарның әкиятләрен бирелеп укый. Шундый самими әкиятләргә кирпеч калынлыгы роман фәлсәфәсе ничек сыеп бетәдер... Әллә соң калын-калын роман авторлары чын иҗат сәләтеннән мәхрүмнәрме икән? Кирәк микән андый романнар? Күп сүз—юк сүз ди бит татар да.

Ялыктыргыч кышкы кичләрдә электрны сәгатьләп-чаклап кына бирә башлаганга, туңмай шәме яктысында Азат озын-озын шигырьләр ятлый, аларны таләпчән фрау каршысына басып, үзе дә әсәрләнеп, ләззәт алып сөйли, сөйләм телен чарлый. "Lorelei"... "Су кызы" шигырен укыганда аның күз алдына су буенда чал чәчләрен тарап утырган Соня Татаркина килеп баса. Аның тарагыннан көмеш балык тәңкәләре коела, ул тәңкәләрнең бер ягында СССР гербы, икенче ягында свастика... Аннары Соня янына кыяга Айдар менеп утыра да, күз яшьләренә чыланган тәңкәләрне учына җыя башлый...

Бу елны Азатның тагын бер казанышы— сыер саварга өйрәнү була. Чөнки фрауны кызгана: бәләкәй генә куллары белән сыер савып кергәч, фрау Эльза, карт буыннары сызлауга түзә алмыйча, бармакларын уыштырып йөри, кулын әллә нинди эремәләргә тыгып утыра.

Профессор фон-Клейнның фәнни китапларына Азатның теше үтми, әлбәттә. Ләкин малай, фрау Эльза кебек, галимнең куен дәфтәрен кызыксынып укый. Бу кешегә фашистларның ни өчен унай караганлыкларын да аңлыйсы килә. Дөресен әйткәндә, фрау Эльзаның ире фашист ялчысы дигәнгә ул ышанмый, ышана алмый.

Һәм моңа ничек ышанмак кирәк? Искиткеч матур, төзек, вак итеп яза торган бу ыктыматлы кеше үзенең яшертен дәфтәренә "Фюрер һәм Иосиф Сталин—бер үк медальнең ике ягы гына" дигән фикерен теркәп

куйган. Андый кеше фашист та, коммунист та түгел инде—моны ундүрт яшьлек малай яхшы аңлый.

Яки менә бусы: "Мине җир йөзенә тынычлык алып килгән дип уйламагыз, мин тыныч алып килмәдем, мин кылыч алып килдем,"—ди Иисус (Изге "Инҗил" китабыннан)."

Фон-Клейн ислам дине белән дә кызыксынган һәм Иисусның кылычына каршы Мөхәммәд пәйгамбәрнең тыныч сүзләрен язып куйган: "Теш казналары һәм бот арасындагы нәрсәләрен тыя алучыга мин җәннәтләр вәгъдә итәм". Мангаен җыера торгач, Азат монысына да төшенгән һәм мен дә дүрт йөз яшьлек хәдисне исендә калдырган, аны ватанына тикле алып кайтып, түкми-чәчми миңа сөйләде.

"Сандугач иң матур җырларын читлектә өйрәнә." Монысының авторын Азат хәтерләми инде.

Аның исендә калганнар буенча гына да мин бу немец галименең хөр фикерле кеше булганлыгын, тоталитар идеология, золым богавы салынган илдә үзенең эчке дөньясын кара тышлы дәфтәренә яшерергә мәҗбүр ителгән "эчке качак" кебек яшәгәнлеген аңладым. Беләсе иде, бездә чын генетиканы аяк астына салып таптый башлагач, Лысенко кебек җаһилләр дәрәҗәгә ирешеп, бакчачы Мичуринны даһи биолог дип игълан иткәч, профессор Клейн дәфтәренә ниләр язып куйды икән?

Фрау Эльза бер кешелек паек алып туклана, шуна үзенең "натураль хуҗалыгы" биргәнне дә китереп кушкач, ризыклары Азат белән икесенә, такы-токырак булса да, җитеп бара. "Эрзац-ипи" һәм "эрзац-кофе" кебек ризыкларга да күнегәсең. Шулар янында фрауның токымлы мүкләге биргән чын сөт һәм өйдә ясаган татлы чөгендер сиробы да бар.

Фрау язга таба тәвәккәлләп, Азат Сәйдәшевны үзенең "остарбайтер"ы итеп рәсмиләштергәннән соң, болгавыр көннәрдә малайның каян пәйда булганлыгын берәү дә төпченеп тормагач, борчулары басыла төшә. Бу вакытта ир-аттан бушап калган Германия басуларында һәм заводларында йөз меңнәрчә остарбайтерлар—оккупацияләнгән илләрдән куып китерелгән халык эшли. Кызганыч, Азат күрше хуҗалыкларда ярым иректә яшәгән якташлары белән танышырга өлгерми, моңа бик үк омтылмый да, ләкин ерактан гына аларны күргәли. Әгәр алар белән аралашып киткән булса, кем белә, бәлки малайның язмышы башка якка борылыр иде. Яхшы яккамы, әллә начаргамы—анысы икенче мәсьәлә.

Дөньяны тетрәндергән һәм кан елаткан Һитлер хакимлегенә нокта куелыр көннәр якынлаша.

Апрель ахырларында көнчыгыштан килгән совет солдатлары белән көнбатыш илләрнең гаскәре бергә очрашалар.

Сигезенче май. "Һитлер капут". Дөрес булса, аның үле гәүдәсен бензин сибеп яндырганнар. Киноларда күреп Азатлар буыны гашыйк була язган Ева Браун да юк икән инде, ул үзенең Һитлеры белән бергә агу эчеп үлүне артык санаган.

Шулай итеп, сугыш тәмамлана, ә Азат инглиз зонасында—Бөекбритания хәрбиләре кулы астындагы территориядә бүленеп кала.

Оккупация башта сизелми дә. Тормыш әүвәлгечә дәвам итә, чак кына яхшыра, җиңеләя әлбәттә, паеклар да арта, авызда эреми торган маргарин һәм тәвә йомыркасы порошогы биргәлиләр һәм Азат мондый тормышны үзгәртергә уйлап та карамый, бөтенесен үз агымына калдыра. Чөнки аның күңелен шик-шөбһәләр кимерә... Фрау берничә тапкыр Азат белән җитди сөйләшергә тырышып карый-каравын, ләкин аның үзенең дә тормышка үзгәрешләр кертәсе килми шикелле.

Көннәрнең берендә Эльза ханым күршеләреннән берничә гәзит тотып кайтып керә. Җирле типографиядә басылган кече форматлы русча һәм хәтта татарча гәзитләр. Фрау аларны остарбайтерлардан алган икән.

Фрау Эльза Азатны каршысына утыртып күптән көтелгән сүзләрен әйтә.

—Синең сереӊ бар,—ди ул туп-туры.—Илендә син... нindидер бәлагә тарыган булгансың... Мин боларын сорашмыйм, балам... Мин сине гаепләргә дә җыенмыйм. Аллам сакласын! Син инде балиг булып киләсең, барын да үзең хәл ит. Менә бу гәзитләрне синең ватандашларың чыгарган. Укы. Үз бизмәненә салып үлчәп кара. Аннары уйлашырбыз.

Азат кич буе шул гәзитләрне актарып утыра. Остарбайтерлар үзләренең профессиональ оешмаларын төзегәннәр, милли телле гәзитләрен булдырганнар, үзләре концертлар куеп, төрле бәйгеләр оештырып яшиләр икән. Гәзит мәкаләләре арасында төрлесе бар. Күбесе, әлбәттә, тизрәк ватанга кайту яклы һәм хәрби хакимияттән шуны таләп итәләр. Азат фикеренчә, матур гына шигырьләр дә күзгә чалына...

Шулай да бер тешләк автор: "Сталин концлагерьларында биш миллион тоткын эшли. Син биш миллион да беренче булачаксың,"—дигән фикерне күтәреп чыга.

Болар малайның җитлекмәгән аңын бутыйлар гына. Хәзер ул кемнең дошман икәнен аермый, ә дуслары күренми... Кая соң ул дуслар?

Көнбатыш илләрендә Кравченко дигән бер качакның "Мин ирекне сайлыйм" исемле китабы дөнья күрә. Бу усал китап күпсанлы мисалларда совет чынбарлыгын һәм Сталинның җинаятьчел режимын гаепләп чыга. Китапны төрле кеше төрлечә каршылый.

Күренекле рус язучысы Константин Симонов, мәсәлән, Кравченконы эт итеп сүгә, аның китабын ялганга, ә үзен дошманга сатылган исерекбашка чыгара. Кравченконың гаепләүләрен Парижда оештырылган халыкара судта карыйлар. Көнбатыш коммунистлары СССР дагы каты режимны гүзәл киләчәк хакына көрәшкән вакыттагы сәяси зарурлык белән аңлатып маташалар, ләкин чынлыкта андагы коточкыч явызлыклардан хәбәрдар булмыйлар. Чөнки ул явызлыклар адәм башына сыярлык түгел, нормаль кеше аларны күз алдына да китерә алмый. Совет лагерьларында үлгән кешене күмәргә алып китәр алдыннан, контроль тәртибендә, мәетнең күкрәген лом белән тишү кагыйдәсе нинди колекска сыйсын? Әлеге судта Кравченко китабында телгә алынган һәм очраклы рәвештә генә исән калган кешеләр шаһит сыйфатында катнашалар һәм Кравченконың хаклы булуы раслана. Дөрес, ирекле дөньядан тимер чаршау белән аерылган СССР халкы боларны белми дә кала һәм "Безнең кебек иркен сулый торган Башка илләр әле җирдә юк" дигән искиткеч матур бишек җырын җырлый бирә.

Бервакытны фрау Эльза Кравченконың шушы китабын табып алып кайта, ләкин эчтәлеге белән танышкач та аны Азаттан яшереп куя. Изге карчык малайны Ватаны турындагы яман сүздән саклый. Азат бу китапны еллар үткәч кенә, Солженицынның "Гулаг архипелагы" белән бергә укый.

* * *

Тагын кыш уза. СССР һәм Көнбатыш дәүләтләре арасында Германиягә килеп эләккән "совет гражданнарын" ватаннарына кайтару турында бәхәсләр өзелми, радио һәм вакытлы матбугат гел шул турыда гап куерта. Азат кебекләрне "күчерелмеш шәхесләр" ("перемещенные лица") дип атыйлар. Берәр адәмчәрәк сүз тапсалар иде әле! Әйтерсең лә Азатлар дүрт аяклы мәхлук яисә урындык-шкаф шикелле генә бер нәрсә, аларны гүяки ничек телисең шулай күчереп йөртергә ярый!

Ниһаять, сәясәтчеләр бер карарга киләләр. Совет хөкүмәтенең таләбе буенча, әлеге "шәхесләр" оешкан тәртиптә СССР вәкилләренә тапшырылырга тиеш була.

Фрау Эльзаны һәм Азат Казанцев-Сәйдәшевне инглиз хәрби комендатурасына чакырып язу килә. Менә шул чагында гына карчыкның аяклэре дерелди башлый... Ләкин, ничек кенә булмасын, Азатны хакимият

белән очрашырга әйбәтләп әзерли ул. Кайчандыр онығына бүләккә дип алып куелган зәңгәр костюмны һәм бөрчекле галстукны Азат бүлмәсендәге урындык аркасына китереп элә. Аннары Азатны җилтерәтеп ваннага алып керә дә анын сул як чигәсендәге гайре табигый чал чәчләрен ромашка эремәсе белән мана.

Ахырда фрау Эльза, театрдагы гримерша кебек, үзенен иҗат җимешенә карап тора-тора да:

—Йа раббым... Балам... Майн готт..,—дип пышылдый.

Икенче көнне комендатурада—мәхшәр. Баксан, Германия остарбайтерлар белән тулган икән. Халыкнын күбесе хатын-кыз, әлбәттә. Кайберсе чемодан, кәрзин тотып, биштәр асып килгән—шушыннан туп-туры туган илгә юлыбыз дип өметләнәләр. Күнелләре күтәренке, вөҗданнары борчымый, бөергә таянып сөйләшәләр. Арада икенче төрле кешеләр дә күзгә чалына—болары басынкы, кайгылы, күзләрен яшерәләр. Нигә куанмыйлар икән алар? Нидән шикләнәләр? Ватан каршында нинди гөнаһлары бар? Бар, бар гөнаһлары! Фашист армиясе өчен икмәк үстерүчеләр шулар түгелмени? Ә заводларда,—сак астында булса булсын,—шушы остарбайтерлар бомба ясамаганнар мени?! Әлбәттә, бу бомбалар арасында шартламаслык итеп эшләнгәннәре дә булгандыр. Тик әчке сәясәттә Сталиннын ун кулы исәпләнгән Берия ялчылары кем гаепле, кем гаепсез икәнен тәгаенләп маташмаячаклар. Бер гаепләне юк итү өчен алар мең гөнаһсызны кырачаклар.

Азат белә, сизә: Германиядән кайткан тоткыннарны туган илдә колач җәеп каршы алмаячаклар.

Кабул итү бүлмәсенен ишеге ачылганда Азат түрдә ике өстәл торганын, ун яктагы өстәл артында купшы инглиз офицеры һәм күзлекле тәрҗемәче хатын утырганын күреп кала. Ә сул яктагы урындыклар әлегә буш—совет вәкилләре сонгарак калган ахрысы, һәммәсе дә шуларны көтә.

Чирек сәгатьләп көттергәч, ниһаять, тышкы ишектән өч совет офицеры килеп керә.

Коридордагылар дәррәү аягүрә баскач, Азат та, хәтта фрау Клейн да урындыктан торалар.

—Исәнмесез, гражданнар!—ди беренче булып кергән яшь-яшь лейтенант һәм арттан килүче каракучкыл подполковникны алга уздыра.

—Здравствуйте! Исәнмесез!—дип гөҗләп җавап бирә коридор.

Туп-туры алга, хәтта борынын чөебрәк өскә караган подполковникнын йөзендә ник бер мускулы тибрәнсен. Ул ватандашларын күрми дә кебек.

Артларыннан кабул итү бүлмәсенен ишеге ябылгач кына:

—Бик текә бәндәгә ошый бит әле бу! Сәламебезне дә кабул итмәде..,—диешәләр.

Азат белән янәшә утырган бер хатын:

—Ну, монардан җылы сүзне келәшчә белән дә тартып чыгара алмассын,—дип нәтиҗә ясый.

—Фрау Эльза...—дип пышылдый шунда Азат.—Минем күнелем болгана... Мин бер генә минутка, туалетка...

—Бар. Ни ярамады икән эченә?—дип борчыла беркатлы фрау.

Моннан җиде ел элек сабый Робертны рәнҗеткән, аннары энесен яклаганы өчен Азатны—бөер тирәсен чамалап—дагалы күнитеге белән типкәләгән опер Байчурин, ромбиклар урынына хәзер погон тагып алган, тырыш хезмәтләре өчен подполковник дәрәҗәсенә ирешкән икән. Юка, усал иреннәр. Шоп-шома итеп кырылган чыгынкы янаклар. Ялтырап торган күнитек. Азат аны менә шул хром күнитеген ялтыраткан вакса исеннән таный.

Күзалларын томалый торган нәфрәт хисен җинә алмыйча, Азат Сәйдәшев комендатурадан чыгып китә. "Юк, юк,—дип пышылдый ул,—кеше язмышын Байчурин кебек шакаллар хәл итә торган илгә мин кайта

алмыйм..." Көчсезлегән тойганга гына пышылдый Азат Сәйдәшев, ә үзенең бөтен дөнья күзенә карап кычкырасы, җанвар булып үкерәсе килә.

Шушы көннән Азат әти-әнисенең исән калу ихтималына да ышанмый һәм аны бу дөньяга бәйләп тота торган пәрәвездәй нечкә җепләр дә, вакыт-вакыт колак төбендә уйнап күнелне җылыта торган Сәйдәш әһәннәре да өзелә. Азатның яшисе килми, бу кадәр гаделсез дөньяны күрәсе килми!

Комендатурадан чыгып качкан көнне Азат соңгы тапкыр җылый— язмыш тарафыннан үз өлешенә бүлеп бирелгән күз яшьләрен шулай сарыф итеп бетерә.

Шулай да Азат Сәйдәшев исән калган.

Тик ул иртә-кичләрен кулы, йодрыклары белән берәр каты әйберне төеп, ярсуын басарга өйрәнә, шуна күнегә. Атна саен бер кирпечне кулы белән сугып икегә яра. Шул вакытта, үзе дә сизмәстән, усал итеп елмая әле: бу кирпечтән крематорий миче дә, төрмә дивары да сала алмаячаклар! Тегеләр дә, болар да...

Азат Сәйдәшевнең Отто Клейнга әйләнү тарихы да табышмак түгел.

Ике көн буе Мюнстерда кая барып бәрелергә белмичә каңгырап йөргәч, ана "өйгә"—фрау Эльза янына кайтып күренергә туры килә. Ә фрау аны зар-интизар булып көтеп торган: рюкзакка бөтен кирәк-яракны тутырып куйган һәм иң мөһиме—ниндидер бик үк тугры булмаган юллар белән ана оныгы Отто Фридрих-Клейн исеменә рәсми таныклык әмәлләп өлгергән. Таныклыкка Азатның рәсеме дә ябыштырылган, бу өйрәнчек фотоны ул профессор Клейнның аппараты белән үзе үк төшергән була.

Фрау Эльзага рәхмәт дими ни дисең? Ул Букстенхаузен шәһәрендәге ахирәтенә хат та әзерләп куйган һәм Азатка шунда барып сыенырга киңәш итә, ихтимал, ахирәте аңа үзенең букинист кибетендә эш тә табар дип өметләндерә.

Шул рәвешле Азат Сәйдәшевнең бормалы тормыш юлында Отто Клейн сәхифәсе ачыла һәм утыз ел дәвам итә.

Утыз ел—үзе бер гомер.

Бу утыз ел эчендә анын Ватанында ниләр генә булмады. Дөньяга мәңгегә килгәндәй тоелган Иосиф Сталин вафат булгач, үзе белән тагы йөзләгән корбаннарын алып китте (җәсәден озатырга килгән гражданнар иске Мәскәү үзәгенең кысан урамнарында берсен-берсе таптап һәлак булдылар). Дөньяда иң биек Советлар сарае салу планы онытылды... 1961 елда Сталинның мумиясен мавзолейдан чыгарып, шул ук Кызыл мәйданда җирләделәр. Юлбашчының кызы (Светлана), илне ташлап, яңа ире белән Һиндстанга китте, анын вафатыннан соң АКШ ка юл тотты. "Корыч бабайның" улы Василий Джугашвили, Казанга сөрелеп, генерал пенсиясен ипподром тотализаторына, ә сәламәтлеген хәмергә һәм сөяркәсенә исраф итеп бетерде. Көннәрнең берендә уяулыгын җуйган Никита Хрущевны да тәхеттән төшерделәр (байтак еллардан соң, җае чыккач, анын да улы Америкага барып төпләнде). Хрущев башта басу-кырларны кукуруз белән тутырып, авыл хуҗалыгын "текә күтәреп" карады. Аннары ярты илгә борчак чәчтергән иде... Илгә ипи чиратларын кабат кайтарган Хрущевтан соң авыл хуҗалыгын "интенсивлаштыру"га керештеләр. Тора-бара ул да онытылды һәм СССР җитмәгән икмәкне капиталистлардан сатып ала башлады. Торгынлык... Тынчу заман... Илдә эшсезләр юк, эшлексезләр генә калып бара... Брежнев адәм көлкесе булганчы бетереште. Ана хәтта татар экстрасенсы, күренекле сәнгатькяр, рәссам, скульптор Илдар Ханов та ярдәм итә алмаган. Ләкин берсен-берсе калейдоскоптагы кебек алыштырган чирләшкә генсеклар һәм "тизләнеш" дигән яңа төшенчә белән танышканчы шактый сулар агасы бар әле...

Азат җирле матбугат һәм радио аркылы СССРдагы вәзгыятьне күзәтеп барган һәм, әлбәттә, объектив мәгълүматлардан мәхрүм булган, чөнки көнбатыш матбугаты күбесенчә шау-шулы низагларны, ызгыш-талашларны ярата...

"1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында оккупантлар белән хезмәттәшлек иткән совет гражданнарын амнистияләү" турында СССР Верховный Советы Президиумының 1955 ел 17 сентябрь карары шәхсән үзенә кагылмаса да, Азат Сәйдәшев (Отто Клейн) бу мәсьәлә белән үтә кызыксына, чөнки әлеге карар совет хакимиятенең сәясәте чыннан да демократиягә таба борыла башлаганлыгын күрсәтә.

Сугыш вакытында яраланып, фашистларга әсир төшкән татар шагыйре Муса Җәлилнең Шпандау төрмәсендә 1944 елда җәзалап үтерелүе турында ишеткәч, ул Җәлил шигырьләренең немецчәгә тәрҗемәсен табып укый. "Моабит шигырьләре" аны тагын уйга төшерә. Шагыйрьнең язмышына карата кайбер шик-шөбһәләре калса да, Отто Клейн—Азат Сәйдәшев үзенең татар булуы белән горурланып та куя...

1957 елда СССРда Җир планетасының беренче ясалма иярчене җибәрелеп, борын чөяргә яраткан американнарны артта калдыргач, Азат үлчи торган бизмән тагы әле аска, әле өскә чайкала башлый. Житмәсә, хыялый Циолковскийның автобиографиясен укып, ул аның әнисе татар кызы булганлыгын белә, монысы ана тагы горурлык өсти...

Әгәр Солженицынның совет концлагерен тасвир иткән коточкыч әсәре ("Иван Денисовичның бер көне") басылып чыгып дөнья шаулатмаган булса, Азат Сәйдәшев ватанга кайту турында вакыт-вакыт кузгалып куйган татлы хыялын, бәлки, тормышка ашырган да булыр иде. Әлеге хикәяте өчен Ленин премиясенә тәкъдим ителгән Солженицынга каршы дәррәү күтәрелгән коммунистлар үз дигәннәренә ирешәләр. Солженицын әле генә кергән Язучылар союзыннан чыгарыла. Кызганычка каршы, аны әдипләр исемлегеннән сызып ташлау өчен тавыш бирүчеләр арасында күренекле һәм нечкә хисле бер татар шагыйре дә була... Аннары Солженицын илдән сөрелә, хәтта аны Ленин премиясенә тәкъдим итүчеләргә дә эләгә—аларны эштән куалар.

Чит илдә шул ук әдипнең тагы да хәтәррәк "Гулаг архипелагы" нәшер ителгәннән соң, табигый, Азат кебек күчерелмеш кешеләр гумансыз совет чынбарлыгына кара күзлек аша карый башлыйлар—Ватан алардан ераклашканнан-ераклаша.

Еллар үтә тора, Көнбатыш Германия, хәрабәләрдән башын калкытып, аякка баса, ә завод-фабрикалары, нигезләренә кадәр кубарылып, көнчыгыш тарафка алып кителгән Германия Демократик Республикасы исә тезләнгән килеш кала.

Яшь букинистның матди яклары ныгый. Сугыш вакытында юк кына бәягә сатып алынган борынгы фолиантлар яна хуҗаларын тапканга кадәр кече сатучы Отто Клейн бу тузанлы томнарны актарып, укып, өйрәнеп вакыт уздыра. Урта белем алганда, аннары сәнгать академиясендә укыганда букинист кибетендәге гакыл байлыгы ана—сары чәчле татар малаена ифрат нык ярдәм итә.

* * *

Азат бер ай чамасы мина килмичәрәк торачагын алдан ук әйтеп, кисәтеп куйды.

Ана таксопаркта бер искерәк автобус биреп, шуны ремонтларга кушканнар һәм киләчәктә Казан—Яшел Үзән арасында шушы автобуста пассажирлар ташырсың дип вәгъдә иткәннәр икән.

—Ерып чыгарсың бит? —дип белештем мин.

—Өр-яңа итәм!—диде ул үз көчләренә ышанган кыяфәттә кулларын уыштырып.—Тик минә шимбә-якшәмбеләрдә эшләргә туры килер, югыйсә җәйге сезон башланганчы өлгертеп булмас. Аннары автомобиль йөртүгә имтихан биреп, "права" аласы да бар...

Аны күтәренке рухлы итеп күрү минем өчен үзе бер шатлык иде. Чыннан да, көнозын тимер-томыр белән эш итәргә күнекмәгән иде ул. Аңлавымча, Азатны киңлек-иркенлек, хәр табигать үзенә тарта һәм

иң мөһиме: аңар адәми зат арасында элек-электән очраштыра торган сәер кешеләр—илгизәрләр каны тынгы бирми, күңелен кытыклап, юлга, сәфәргә, офык артына әйдәкләп тора иде.

Азатның хезмәт хакы һәм, гомумән, матди хәле белән берничә тапкырлар кызыксынып караган булсам да, ул кулын селтәп кенә җавап бирде. "Миңа житә",—диде ул һәм мин дустымны кабат бу сорау белән борчырга базмадым. Соңыннан гына мин Азатның дәүләт саклык кассасында шактый зур суммада акчасы ятканлыгын һәм аның шул акчага бер генә тапкыр да кагылмаганлыгын белдем. Ә бит аның кулында ничәдер машиналык сумма булган, ул үз автомобилендә рәхәтләнеп ил гизеп йөри алган... Һәм, нотариуста расланган васыятьнамәсенә караганда, ул бу акчасын тиененә кадәр Атна авылындагы балалар йортына мирас итеп калдырган булып чыкты.

Мин инде Азат белән атна саен күрешергә ияләнеп беткән идем, ун-унбиш көн үткәч түзмәдем, тоттым да бер шимбәдә Яшел Үзәнгә киттем. Аның өйдә түгел, бәлки эш урынында булырга тиешлеген белгәнгә, туры автопаркка юл тоттым. Проходнойда бер карчык калын свитер сыман нәрсә бәйләп утыра иде.

—Миңа слесарь Сәйдәшев кирәк иде...Ул ял көннәрендә дә ремонтта... Шуны чакырып булмасмы?—дидем.

—Һы... теге интеллигент иптәш кирәк инде сезгә алайса,—диде жылы шәлгә төренгән дежур карчык, үзе калын күзлеге аша миңа текәлеп-текәлеп карады, ә бармаклары үз җайларына һаман хәрәкәтләнә иде.—Чакырырга анда телефон юк...Ә пропускысыз кертә алмыйм. Бүген контор эшләми.

Аптырабрак калдым.

—Урам якта капкадан уңга таба барып борылгач та коймада тишек бар. Бездә күбесенчә шуннан кереп-чыгып йөриләр...,—диде әбкәй үзалдына, гүя мине бирелә юкка хисаплаган кебек.—Дөрес, Сәйдәшев безнең аркылы йөри, чөнки кибеткә шешәгә йөгерәсе юк—эчми дилэр, дефицит детальләр дә ташымый... Сәер иптәш,—дип быдырдады ул.

—Рәхмәт.

Чыннан да, коймадагы ачыклык якын гына икән. Аннан кергәч, кем әйтмешли, дүрт ягың кыйбла.

Мастерскойны озак эзләп маташасы булмады, беренче очраган шофер ук сүзсез генә озын һәм биек бинага төртеп күрсәтте. Сорамасам да булган икән, чөнки кар көртләре арасындагы сукмак койма тишегеннән туп-туры шунда таба сузылган иде.

Ремонт цехында кайберләре тәмам сүтеп ташланган, кайберләре инде буяп та куелган биш-алты автобус тора, ә иң аргы башта кулына ачкычтыр, чүкечтер тоткан Азат шакы-шокы килеп йөри иде.

Мине күргәч ул артык гажәпсенмәде шикелле:

—Гомерле булырсың, әле генә сине искә төшергән идем,—диде.

Куллары майлы булганга, мин аның җиңенә генә кагылып күрештем:

—Арумы?—дидем.

—Ару дисәң дә була. Моторны сүтеп жыйдык. Карданны алыштырдык. Трансмиссия әр-яңа. Электр хужалыгы тәртип. Тик менә автобусны автобус итә торган нәрсәләр белән эшләр койтырак. Ишекләр ачылса ябылмый, ябылса ачылмый дигәндәй—тәмам какшатып, чалшайтып бетергәннәр, ә яңалары юк. Шулай да сүтеп алып турайтып карарга исәп, урынында килеш кенә булмый...

Автобусның арткы ишеген икәүләп кубарып алдык. Азат слесарныйда ишекне кыстырып турайту өчен берничә домкратлы җайланма әмәлләп куйган булып чыкты. Аңлавымча, аның беренче карашка гап-гади бу җайланмасын баш механик белән бергәләп рационализаторлык тәкъдиме итеп рәсмиләштергәннәр, хәтта премия дә вәгъдә иткәннәр. Техник ягын бик үк аңлап бетермәсәм дә, җайланмада бөтен хикмәт ишекнен

яки бүтән бер чалшайган яссылыкның, бер җире дә беркетелмәгәнгә, домкратларны эшкә кушкач, кирәкле якка таба шуыша алуында икән. “Өстәвенә аны яссы нәрсәне кирәгенчә бөгү өчен дә көйләп була,”— диде Азат.

Ишекнең күз алдымда турайганын күргәч, уйлап табучыны хуплап кул чаптым:

—Эдисон икәнсең,—дигән булдым.—Әйдә, элеп тә куешам.

—Юк, бүген элмибез. Металл шушы хәлендә төн кунсын әле.

—Нигә?

—Анысын үзем дә белеп бетермим. Ләкин алгы ишекне шундук элгәч, беркадәр чалышлыгы кире кайтты. Кабат турайттык, ә баш механик берәр көн җайланмада торсын әле диде. Шунда торса, металл әкренләп яңа халәтенә буйсына имеш...

—Шуннан?

—Баш механик хаклы булып чыкты.

—Әкәмәт. Алайса рационализаторлык тәкъдименә бер дә юкка катнашмаган икән.

—Хакы юк түгел...

Берәр сәгатьтән Азат бүгенге эшен түгәрәкләде, комбинезонын салып гадәти киемнәрен киде. Гадәти дип, үзгә фасон белән тегелгән демисезон пальтосы һәм мехсыз бүреге дә Азатны безнең кебек провинциаллардан аерып тора иде.

Проходнойдан чыгышлый икебез дә дежур карчык белән саубуллаштык. Ә Азат аны исеме белән атады, русчалап:

—Хушыгыз, Софья Матвеевна!—диде.

—Хушыгыз,—дип, матур итеп елмайды дежур карчык.—Бүген озак эшләдегез, ял итегез.

—Беләсеңме, Софья Матвеевнаның исеме дә, елмаюы да Соня Татаркинаны исемә төшерә...,—диде Азат, инде урамга чыккач һәм авыр итеп көрсенеп куйды.

Гәпне күңелсез хатирәләргә таба бормас өченме, мин бүгенге көн темасыннан читкә китмәскә тырыштым.

—Бер кызык сорау биримме?—дидем.

—Биреп кара.

Шунда мин, кырык сигезенче елда булса кирәк, Казанда беренче троллейбус юлы ачылуны искә төшердем. Линияне ачу тантанасы хәзерге “Божра” мәйданында үткәрелгән иде. Кызык күрергә без, студент халкы да, җыелып киллек. Чыгышлар булды, тәбрикләүләр... Кызыл тасманы кем кискәнен инде хәтерләмим. Шаулатып кул чаптык та беренче троллейбуска Казаныбызның хөрмәтле кешеләрен утыртып җибәрдек...

Кышкы кичләрнең берсендә соң гына студент иптәшем фатирда торган Кәҗә Бистәсеннән троллейбуска утырып үзәккә кайтып килешем. Троллейбуста кеше әз, һәм мин нәкъ кабина артындагы йомшак утыргычка җәелеп утырдым. Түшенә эреле-ваклы билет рулоннары аскан кондуктор килеп җитте. Түләдем. Үзем йокымсырыйм, аннары дерт итеп уянып киткәндәй булам. Шул чагында салон белән троллейбус йөртүче арасындагы тәрәзгә кабина ягыннан эленгән көрән төстәге пәрдәгә күзем төште.

Шушы ясалма күн пәрдә шахмат тәртибендә тип-тигез итеп үткен пәке белән кискәләнгән иде. Нигә кискәләделәр икән моны? дип уйладым да онытым, чөнки сугыштан соңгы ач-ялангач заманда башка кайгыларыбыз да җитәрлек иде. Ләкин берничә көннән соң әле заводтан күптән түгел генә чыккан һәм шалтыр-шолтыр трамвай белән чагыштырганда уенчык шикелле троллейбуста барганда мин янә шулай кискәләнгән пәрдәгә игътибар иттем. Кыскасы, өзек-өзек паралелль кисентеләр ясалган пәрдәне күргән саен бер мизгелгә генә башымда әлеге дә баягы “Нигә микән?” дигән сорау чагылып китә торган иде.

Азатка менә шуларны сөйләдем.

—Әйе, андый пәрдә бар,—диде ул.—Кирәге чыкса, шторны күтәреп

салонга күз саласың... Ә нигә дип кискәләгәннәр соң аны? Максат?

—Бу сорауны сиңа мин үзем бирмәкче!

Азат барган җиреннән туктап калды.

—Ә минем андый кисек пәрдәне күргәнем юк,—диде.

—Дөрес, юктыр. Алтмышынчы еллардан бирле минем дә күргәнем булмады шикелле...

Байтак ара сөйләшмичә генә бардык. Инде кайтып җитәрәк, ул бирелергә мәҗбүр булды:

—Мин—пас,—диде.—Биреләм.

—Бел алайса, дустым Ватсон: ясалма күнне урламасыннар өчен!

Азатымның телсез калуына караганда, ул да нәкъ минем төсле беркатлы икән.

Бүтән эшкә яраксыз хәлгә китерелгән пәрдәләрне башкалар да күреп йөргәндер бит югыйсә. Ләкин ник берәвесе әлеге самими сорау белән баш катырсын! Ихтимал, мондый гына нәрсәләрне белеп туганнардыр.

Ә безнең беркатлылык... бәхетсезлекме ул, әллә бәхетме икән? Ә һәрнәрсәдә этлек һәм җинаять эзләүче бәхетлеменi? Ул бит үзен шакшы дөньяда яшим дип белә һәм дөньяга шакшы өсти.

Минем бу табышмагым Азат өчен файдага булыр дигән идем. Ул үзе ремонтлый торган автобусның утыргычларын саргылт материал белән тышлатырга ниятләп куйган булган, хәтта ялына торгач материалын да таптырган. Кара яки көрән төсләр кирәкми, салон эче кояш кебек елмаеп-көлеп торсын янәсе. Мин ана безнең шартларда мондый матурлыкның күп булса бер атнага гына җитәчәген аңлатып маташтым. Күр дә тор, үсмер вәхшиләр, гадәттә елдан-ел ишәя баручы дебиллар, утыргычларны телгәләп бетерәчәкләр. Нәкъ шушы елларда трамвай-троллейбус һәм электричка тукталышларында, алла белсен күпме миллионнар түгептер, пассажирлар өчен аквариум кебек тоташ пыяла нәрсәләр төзеп куйганнар иде. Тимер скелетлары гына утырып калгач, икенче елны ук аларны шыксыз бетон йә калай тартмалар белән алмаштырырга мәҗбүр булдылар...

Азат минем дәлилләрне тыңлап бетерде дә, кинәт:

—Ә бит, Илдар, син минем барыбер үземчә эшләячәгемне беләсең!—диде.

—Беләм анысы,—дидем мин, көрсенеп.—Беләм, чөнки үзем дә нәкъ синеңчә үҗәтләнер идем.

Шулай итеп, бу кичне без Азат белән көндәлек хәлләр, тормыш мәшәкатьләре, җыен вак-төяк турында сөйләшеп уздырдык, үткәннәргә кагылмадык. Шулай да мин Азатка тормышта әчесен-төчесен татыган бер таныш агайның: "Өч күлмәк гомереҥ калган булса да—җефетлән,"—дигән киңәшен әйтеп, гаилә төзү мәсьәләсендәге ниятләрен белергә тырышып, кылларын тартып карадым. Ачыктан-ачык сорасам да, Азат туры гына җавап бирмәде, читенсенде, ләкин аның оялчан елмаюында ниндидер сер бар сыман тоелды.

Булсын. Никах—үзе сиррият түгелмени? Эчемнән генә: "Күнеленә ошаган кеше тизрәк табылсын иде,"—дигән теләк теләдем. "Һәркемнең туган иле бар, ә кешегә Ватан кирәк. Аннары кешегә җылы фатир гына аз, аңа өй җылысы кирәк,"—дип уйладым. Баксаң, Азат Ватанын һәм өй җылысын сагынып кайткан бит.

Ничектер җае чыгып, мин бу мәсьәләне тагы бер кузгаткан идем, Азат фрау Клейнны исенә төшерде. Инде матди яктан аякка басып, үзенең үги әнкәсенә вакыт-вакыт ярдәм дә иткәли башлагач, инде бик картайган немец карчыгы да Азатка гаилә кору турында киңәш биргән һәм нәкъ минем дәлилләрне китергән икән.

Бу юлы Азат мине автовокзалдан туры Казанга утыртып җибәрде. Инде автобуста кайтышлый, кинәт Азатның квартирындагы яңа тәрәзә челтәре күз алдыма килде. Мин аны күргәнмен, ләкин, гәп белән мавыгып,

игътибар итмәгәнмен. Гардины да яна иде бит... Эре чәчәкле гардин һәм шуның белән аваздаш тюль сайлаганда, автобазадагы Софья Матвеевна әйтмешли, иптәш Сәйдәшев бер-бер хатын-кыз белән кинәшмичә калмагандыр әле дигән уй күнелемне тагы жылытты.

* * *

Язга таба Азат бераз бушады һәм без тагын атна саен күрешә торган булдык. Бу вакытка инде ул ГАИда имтихан тотып өлгергән, барысын да шаккаттырып һәм, ихтимал, көнләштереп, беренче класслы шофер хокукына ия булган иде. Аны төрле четерекле сораулар биреп, "на полную катушку" сынаганнар, юл йөрү кагыйдәләрендә тота алмагач, автомобиль төзелешенә кереп караганнар, алай да булмагач, халыкара кагыйдәләргә үк барып житкәннәр...Бөтен Европаны әйләнгән шофер өчен болары уен гына булгандыр. Ә практик сынауларны да тел тидергесез үткәннән соң, ГАИ начальнигы карт курсантны үзе котлаган.

Азатның яна таныклыгын шампанский белән юдык.

Бу юлы Азат Казанга автозапчастьлар карарга да килгән иде, шуна күрә автокибеткә һәм базарларга үзе генә китте. Анлавымча, кайбер дефицит нәрсәләрне ул үз акчасына алырга ниятләгән иде.

Май бәйрәмендә Азатка Казанда демонстрацияләрнең ничек үткәнен күрсәтәсем килгән иде. Мактану өчен дә, хурлау өчен дә түгел, әлбәттә. Беренчедән, инде үземнең дә күптән андый нәмаешта катнашканым юк һәм, сизәм, Сталин чорыннан калган мондый "ихтыяри-мәжбүри" демонстрацияләрнең гомере бетеп килә, инде заводларда бу "мероприятиегә" аерым кешеләрне билгеләп, транспарант күтәргән һәр күндәмгә бишәр сум акча да бирә башлаганнар иде. Шуна күрә соңгы большевистик нәмаешларны күреп калыйм дидем. Икенчедән, Азатның тантана итүче пролетариатка, гавәмгә карашын беләсем килде.

Иртән юл йөреп мәшәкатьләнмәс өчен Азат кичтән мина килеп кунды.

Бәйрәм көне иртәдән үк матур булмады. Янгыр яумаса да, төньяктан әче жил исә иде һәм без плащ эченнән жылы свитер кияргә мәжбүр булдык.

Иртәнге сигезләргә без үзәктә, Матбугат йорты янында идек инде. Бу район бәйрәм колоннасының койрыгында булганга, безгә урамда байтак кына көтәргә туры килде. Эчкә салкын үтә башлагач, халык чарасын тапты: арка сугышлы уйнарга керештек һәм, чыннан да, жылындык. Дөрес, кайберәүләр каядыр барып килеп, эчтән жылыну әмәлен дә таптылар.

Арка сугышлыны Азат тәмам оныткан булган икән. Жылына торгач, үзе дә тотылды. Аны бик озак интектерделәр—кем сукканын һич кенә дә белә алмады. Әзмәвер бәдәнле, кызгылтрак борынлы берәү (грузчик булса кирәк) аеруча оста алдашты: йомшак кына, жинелчә генә суккан кебек итә дә, шундук бер читкә атлап, кулларын кушыра һәм гөнаһсыз кыяфәттә Азатның күзенә карап тора. Ахырда грузчик түзмәде—алагаем зур кулы белән Азатның аркасына саллы гына итеп кундырды. Башка берәү, ихтимал, сыгылып та төшкән булыр иде, ләкин Азат Сәйдәшевнең ник бер буыны калтырасын. Тиз генә турайды да, "рәнжетүчегә" төртеп күрсәтте.

Грузчик иелеп, кулын аркасына куйгач, без барыбыз да Азатка карап, сугу чиратын анар бирдек.

Азат беркавым уйланып торды, аннары мина күз кысты да, әлләни кизәнмичә генә, теге әзмәвер гәүдәле наянның алыптай кулына сугып жибәрде.

—Ну, мать честная-а-а...,—диде әзмәвер, әкрен генә тураеп һәм бу

вакытта аның бил турысы шыгырдаган кебек тоелды.—Кайсыгыз ул күсәк куллана?

Азат аңа кулын күрсәтте:

—Күсәк түгел, гап-гади кул.

Тегесе шулай да Азатның кулын капшап карасы итте. Аннары кыска гына:

—Таныш булыйк. Элекке цирк артисты, хәзер кара эшче Крыймов...

—Сәйдәшев. Слесарь.

—Әйтәм җирле кулың эскәнҗә кебек... Эшендә сина тиски-мазар кирәкми дә торгандыр, ә?

Көлештек.

Ул арада алдагы халык кузгала башлады һәм без үзебезчә сафка тезелгән булдык.

Хәзерге "Божра" мәйданында демонстрация сулга таба борылып, туктый-туктый, Пушкин урамыннан өскә күтәрелде һәм Ирек мәйданына кул сузымы гына калып, аннан таркау һәм ялкау "ура" авазлары ишетелә башлагач, унга каерып, Горький урамына борылды.

Демонстрациядә үткән бер-ике сәгать арасында бихисап анекдот, мәзәк сөйләнгәндер. Анекдотларның көнкүрешкә кагылган тозлы-борычлысы күбрәк, ләкин ачыктан-ачык сәясиләре дә житәрлек иде. Беренче секретарь Хрущев турындагылары инде онытыла төшкән, ә генсек Брежнев катнашкан анекдотлар әлләни үткен дә, жор да түгелләр иде. Шик тә юк, карыйлыкка житеп, өшәнгәнче картайган генсек турында мәзәк сөйләүчеләргә карата махсус күрсәтмә дә булганга, халык, Сталин чорындагы кебек, телен тыебрак сөйләшә... Хәер, төп сәбәп башкадыр дип уйлыйм мин. Анекдотның каһарманы шәхес буларак күрексез икән, анекдот та төссез чыга—халык чыпчыкка атып туп ядрәсе әрәм итми шикелле. "Әрмән радиосы"ның көлкеле җаваплары да сирәгәйгән, аның каравы төп рольне "чукча" уйнаган үткен мәзәкләр күбрәк иде. Башкаларны белмим, мин ул томана һәм мескен чукчаны "житлеккән социализм" архитекторы кашлач Леонид Брежневның үзе дип кабул итә идем...

Азат, гавәм арасына беренче тапкыр чыккангамы, бу мәзәкләрне исе китеп, йотлыгып тыңлады шикелле. Әмма ул шаркылдап көлми, тыенкы гына елмая, бөтенесен дә аңлый иде. Күрәсен, бездәге анекдот жанры аның көнбатыштагы төреннән мәгънәлерәктер, тирәнрәктер, ихтимал, нечкәрәктер дә. Ул бит еш кына безгә тешсез сатирик әдәбиятыбызны алмаштыра, халык өчен үзенә бер төрле үч алу, "пар чыгару" чарасы булып та хезмәт итә. Алдавыч, әлбәттә! Тик, бүтән әмәлен булмагач, шуна да юанасын... Кыскасы, бер яктан ул безнен системаны тәнкыйть итә, хәтта дегеткә мана, ә икенче яктан шуңа ук буйсынырга, аның белән ризалашырга мәҗбүр итә. Шуңа күрә мин икеләнеп тә калам—анекдот ул көчлеләрнен авыз еруымы, әллә сон зәгыйфьләрнен күз яшеме? Ә бәлки аны көчлеләр уйлап чыгара, зәгыйфьләр исә тынлап юаныч таба торганнардыр? Дарумы ул, әллә агумы?

Атлый торгач, без әкренләп Казанның иң озын урамнарыннан берсе—Карл Маркс буенча Ирек мәйданына төшә дә башлаганбыз икән. Йөрешебез шактый кызуланды һәм тиздән без Ленин һәйкәле яныннан уздык. Инде һәйкәл төбендәге трибунада республиканың беренче житәкчеләрен икенче-өченче дәрәҗәлеләре алмаштырган һәм карлыккан радиодинамиклар аларның хезмәт ияләрен яңа жинүләргә чакырган авазларын мәйданга янгыраталар иде. Ә һәйкәл артында өлкә комитеты бинасы өстендә "КПССка дан!" дигән үлемсез һәм жансыз лозунг кәбирләнеп тора.

Иң койрыкта килгәнгә һәм тәмам арылганга, безнен районның "ура" кычкыруы үзебезгә генә ишетелде бугай. Шуңа күрәме, радиодан кабат "Сәйдәш маршы"н тоташтырдылар. Мин Азатка күз төшердем.

Һәм мин Азат Сәйдәшевнең күзләрендә ике бөртек яшь ялтыраганын

күрдем. Ул яшь бөртекләренең мәгънәсен бер мин генә аңласам аңлагандыр.

Мәйданны үтүгә үк демонстрантлар, байракларын сабына урап һәм печән өмәсеннән кайтучылар чалгы-тырмаларын күтәргән шикелле иңнәренә салып, кайсысы кая таралыша башладылар. Без Азат белән Черек Күл бакчасын кыеклап кисеп чыктык та, кире Матбугат йорты тирәсенә юл алдык. Әлеге баһадир гәүдәле Крыймов артыбыздан килгән булган икән, "Кафе-мороженое" янына житкәч, безгә ым кагып, бугазына чиертеп тә күрсәтте. "Кәкмибезме берәрне?" янәсе. Без ана ашыгуыбызны әйтеп, баш тарттык. Крыймов үпкә-мазар белдермәде, кафе ишек төбенә сөяп куелган нәүмиз байракны күреп алды да:

—Ихтыярыгыз—салават,—диде.—Ну, шулай да мин бу ачык авызларны акылга утыртыйм әле!—дип, кулларын уа башлады.—Бер ярты куйдыртам дек куйдыртам мин болардан! Профком кабинетында торырга тиешле мөбәрак байракны шушылай кадерсезләгәннәрне өчен!

Аннары байракны әләктерде дә, аның "хужалары" кафедан кәефләнеп чыккалаганчы, жәһәт кенә бер ишегалдына кереп югалды.

Без бу уенга катнашмадык, баш китә торган бәла түгел дип, мондый гына вак этлеккә кул селтәдек. Шулай да Азатның йөзенә караңгы күләгә төшеп алганын сиздем.

Көн инде жылытып жибәргән иде һәм безгә плащларыбызны салырга туры килде.

Көндезгене "Татар ашлары" рестораныңда ашадык. Беренчегә өй токмачы, икенчегә пәрәмәч алдык, чөнки Азат ашханә макароннарыннан, ипи катыш котлетлардан, суда пешкән бәрәңге боткаларыннан, ә Бөтенсоюз күләмендәге "Балык көннәре"ндә томатлы килькадан туеп беткән һәм ара-тирә без Никита Хрущевның корсагын хушландырып Ленин ордены алган аш-су остасы Юныс Әхмәтжановның милли ашлары белән сыйлана торган идек.

Мин стакан белән китерелгән катыктан бер калагын ашка катып жибәргәч, Азат, нәрсәдер исенә төшкәндәй, сискәнеп куйды.

—Минем әти дә ашны шулай авылча ашарга ярата иде бит...—диде Азат Сәйдәшев әкрен генә.—Ә мин шуны оныткандыр... онытканмын...

Ул, берничә минут дулкынлануын баса алмыйча утыргач, кинәт тәлинкәсенә үз стаканыннан ике калак тутырып катык салды да:

—Өлкән Сәйдәшев ике кашыкката торган иде!—диде.—Ана ияреп башта мин, аннары Айдар, аннары бәләкәч Роберт та шулай итә идек... Ә әни безгә карап күзләреннән яшь чыкканчы көлә иде...

Мин иягемне генә кактым, чөнки бу минутта үзем дә чамасыз дулкынлана идем. Күңел төпкелләрен актарып, яшен яшьнәгәндәй итте һәм минем күз алдымда Атна авылындагы номенклатур йортта иске генә клеенка жәйгән табын янында тезелешеп утырган Сәйдәшевләр гаиләсе пәйда булды. Аһ, нинди афәт, нинди давыл йотты бу бәхетле гаиләне?! Нинди имансыз чалгы кыйды бу гомерләрне? Нигә? Нәрсә хакына? Ә андый хак бармыни?

Шул вакытта кухня ягыннан ак халатлы юантык Юныс Әхмәтжанов чыгып, безне авырсу хатирәләр ташкынынан йолып калды:

—Исәнмесез, мөхтәрәм кардәшләр!—диде ул, барыбызга берьюлы мөрәжәгать итеп.—Яз бәйрәме котлы булсын! Ашларыгыз тәмле булсын!

Халык:

—Рәхмәт!

—Тәмле, бик тәмле ашың, Юныс! Әфарин! Маладис!—дип жавап кайтарды.

—Бәтәч, танышлар да бар икән...,—диде Әхмәтжанов, мина күзе төшеп.—Сәлам сезгә, каләм әһелләре!

Бу игътибарга мин хәтта бераз ирәеп тә куйдым.

Шулай итеп, тамагыбыз туюу өстенә, Азатның демонстрациядән

соң чак кына кырыла төшкән кәефе күзгә күренеп яхшырды. Ирек мәйданында мәҗбүри лозунглар ишетеп гарык булгач, гап-гади бер адәми затның яз бәйрәме белән тәбрикләве, ихласлылыгы мина да шифалы тәэсир итте.

Һәм бу көн безнең өчен чыннан да бәйрәм булды дип әйтә алам. Азатны электричкага утыртып җибәрдем.

* * *

Безгә кабат андый бәйрәмне күрергә язмаган икән.

Азат ремонтын Җинү бәйрәме көненә төгәлләп, аның машинасын комиссия кабул итәргә тиеш иде. Шуннан соң мин аның шылтыратуын көттем, исәбем буенча без хәзер, Азат автобус руленә утыргач, Казан автовокзалында да очраша алачак идек. Мин хәтта җәй көне, Азат белән янәшә утырып, Яшел Үзән белән Казан арасында берничә рейс ясарга планлаштырып куйдым.

Ләкин Азат тугызынчы майлар үтеп берәр атнадан соң гына шылтыратты. Аның тавышы ук башка, үзгә иде.

—Минем проблемалар килеп туды әле, Илдар,—диде ул, сүзен озынга сузып тормастан.—Шушы бер-ике көндә хәл ителер дип уйлыйм... Хәзергә сорашмый тор, яме?

—Кайчан күрешәбез соң? Бәлки мина килеп чыгаргадыр?

—Юк, юк! Тик син борчылма—шәт, бөтенесе дә рәтләнер.

—Яхшы. Бирешмә!

—Бирешмим.

Арабызда телефоннан менә шундый гына сөйләшү булды.

Нинди проблемалар микән ул? Эш буенчамы? Көнкүрештәме? Шәхси пландамы? Уйлап карасаң, боларның һәммәсенең ихтималы бар иде. Азатның гаепле булуын мин башка да китерә алмый идем.

Ремонтланган автобусны комиссия тоткарлыксыз кабул иткән. Рульгә ике-өч кеше утырып, машинаның берәм-берәм барлык системаларын тикшереп чыкканнар. Алар сынар кимчелек тә таба алмагач, бәйләнчек комиссия башлыгы машинада территорияне үзе ике тапкыр әйләнгән.

—Чыннан да, "как часы" эшли бу уенчык!—дигән ахырда комиссия житәкчесе.—Двигатель тел тидергесез... Педальләр сизгер, ишекләр тынлаулы, сигнализация нормаль... Ә салон... теге ни... дизайн диләрме әле? Зәвык белән эшләнгән, чурт возьми! Нинди фикерләр бар?

—Гадәттәгечә, "Яхшы" билгесенә кабул итәргә!—ди бер комиссия әгъзасы, Акулов фамилияле шофер.

—Килешәм. Ләкин Сәйдәшевнең ремонт бригадасы премиягә лаек, минемчә. Оештырырбыз. Начальствога үзем кереп ялынырмын.

Автобусның документларын бик тиз карап, иртәгесен яңа номер элгәннәр, ә менә югары квалификацияле слесарь Сәйдәшевне шофер итеп рәсмиләштерү өчен бер көн генә җитмәгән һәм тәүге рейска автобусны бөтенләй башка кеше—профсоюз активисты әлеге Акулов алып чыккан. Хәер, Азат моны белмичә дә калган, чөнки, яңа машинасына утырыр алдыннан ял сорап, әйбәтләп мунча кергән, парикмахерда чәчләрен төзәттереп, кием кибетләрендә күнеленә ошарлык костюм эзләп йөргән, пассажирлары каршында автобусы кебек чиста һәм пөхтә буласы килгән...

Икенче көнне эшкә килгәч, Азат Сәйдәшевне автопарк территориясенә керүгә үк сул яктагы чирәмлектә торган җимерек автобус каршылый.

Аның автобусы! Ярты ел буена бөтен күнелен биреп төзәткән, һәр шөребен кулыннан үткәргән һәм, асылда, яңадан тудырган автобусы!

Азат машина тирәли әйләнеп чыга һәм, ташыган ачуын җинә алмыйча, кыйшаеп ябылмыйча калган алгы ишекне ике йодрыгы белән —төя башлый. Ул арада автобус янына башка шоферлар да җыелалар.

Акулов машинаны юл буендагы бетон баганага бәрдергән икән. Автобусның алгы уң як почмагы яньчелеп, пыялалар чәлпәрәмә килгән, багана да түзмәгән—бәргән җирдән сыгылып төшеп, автобусның түбәсенә ауган.

Ярый әле, корбаннар булмаган. Хәтта Акуловның үзенә дә, берике тырналган җирен исәпләмәгәндә, һичбер зыян килмәгән.

—Бәхете бар икән, ничек күкрәге изелмичә калгандыр...,—диешәләр күпне күргән шоферлар.—Мондый чакта рульдән дә куркыныч нәрсә юк...

—Ни сөйли соң үзе? Аварияның сәбәбен әйтәме?

—Тормоз... Тормоздан күрә имеш.

Шофер халкы кырын-кырын Азат Сәйдәшевкә карап куя.

Ә Сәйдәшев, бер сүз дә әйтеп тормастан, туп-туры кадрлар бүлегенә китә һәм эштән азат итүләрен сорап гариза яза.

Кадрлар бүлеге мөдире, бүгенге татарныкына охшамаган Бикбау фамилияле кеше, карап торышка инде күптәнге пенсионер (әүвәлге номенклатура әһеленә дә тарткан, димәк, совет куласасының әле астында калып, әле өстендә булып чыккан дип уйларга кирәк) Азатка ашыкмаска киңәш итә.

—Аннары,—дигән ул,—бүген кич профсоюз җыелышы булырга тиеш... Турысын әйтәм: көн тәртибенә кичәге авария мәсьәләсе куелачак.

—Яхшы. Мин җыелышта булырмын,—дигән Азат.—Ләкин гаризам сездә калсын.

Азат Сәйдәшевнең йөрәге гомеренә беренче тапкыр шушы минутларда зәгыйфьлеген, арыганлыгын сиздереп ала. Мөдирнең күзе очлы (дөресрәге—тәҗрибәле) икән: Азатның агарынганын күреп, ул аңа кичекмәстән медпунктка барырга куша.

Медпунктта Азатка башта валидол каптыралар, аннары, йөрәк авыртуы җибәрми торгач, укол кадыйлар.

Бераз тынычлангач, Азат мина шылтыраткан.

Җыелышта беренче сүз Акуловка бирелә. Хатын-кызлар ирексездән күз сирпеп ала торган чибәр кеше икән ул. Уртачадан калкурак буйлы һәм, кырыкларга житеп килсә дә, яшь чырайлы бу шофер эшендә алдынгылыкка омтылмый, әмма түрәләр каршында абруе бар, чөнки ипле итеп сөйләшә белә, конфликтка керәскә тырыша, гомумән активистлардан исәпләнә. Казаннан комиссия-мазар килеп төшсә, йә кунаклар булганда, түрәләр белән янәшәдә, эшчеләр сыйныфы вәкиле буларак, шушы Акулов тора. Аны, ихтимал көнләшебрәктер, "Күз көеге" дип йөртәләр, чөнки президиумда да ул утыра, "Мактау тактасы"н да аның сурәте бизи, район газите генә түгел, хәтта республика газитендә дә фоторәсеме басылган икән.

—Иптәшләр...—дип сүзгә керешә ул.—Иптәшләр...Үзегез беләсез, ремонттан гына чыккан бу автобус руленә мин очраклы рәвештә генә утырдым, чөнки үземнең автобус профилактика үтә иде. Рейска чыгарырга бүтән машина да, буш шофер да табылмагач, автобусны бер көнгә мина тоттырдылар... Шикләнебрәк булса да, алындым мин бу эшкә...

—Ә нидән шикләнден?—дип сорау бирә шунда арттан бер таксист.

—Нидән дип... Автобусны яна бригада ремонтлаган... Сәйдәшев бригадасы. Ә Сәйдәшев, гомумән, коллективта яңа кеше, үзен унай яктан күрсәтеп өлгермәгән әле дип әйтимме?

—Мәсьәләгә якынрак кил!—ди әлеге тавыш.—Казанга ничек барып життең? Нормальномы?

—Нормально.

—Тормоз ничек иде?

—Мин аның эченә кереп карамадым.

—Ә Казаннан кайтышлый ясаган аварияне шуңа сылтыйсың бит...

—Чөнки башка сәбәп юк,—дип теләр-теләмәс кенә җавап бирә

Акулов һәм артка борылып:—Ә нигә миннән сорау ала ул?—дип президиумга мөрәҗәгать итә, ярдәмгә өметләнә.

—Сез, иптәш Акулов, җавап бирергә тырышыгыз. Чөнки бу сораулар барыбызны да кызыксындыра.

—Әйтәм ич, кинәт тормоз киреләнде...

Җыелыш рәисе өстәлендәге кәгазьләргә күз төшереп ала да:

—ГАИ актыннан күренгәнчә, авария булыр алдыннан сезнең алда да, артта да машина булмаган... Юлда бернинди комачау юк, ә сез, нигәдер унга каерып, көпә-көндез кюветка төшкәнсез һәм машинаны баганага бәрдергәнсез... Автобусның тормозы төзек, иптәш Акулов! Комиссия аны җентекләп тикшерде. Фактлар шундый, аңлыйсызмы?

Акулов ык-мык килә. Шул чагында иң алда утырган түм-түгәрәк гәүдәле бер карчык торып баса. Софья Матвеевна.

—Дөресен сөйлә, Акулов,—ди карчык тыныч кына.—Кичә минем күршем, гөнаһ шомлыгына каршы, синең автобусыңа утырып Казаннан кайткан.

Акулов, тәшвишләнеп, Софья Матвеевнага текәлә.

—Син бит рульдә йоклап киткәнсең, Акулов! Ә үзең кешегә нахак яла ягасың! Синең үзеңнән тормозың эшләмәгән дим мин, беләсең килсә. Аккош күле буенда тукталгач, "Ак каен" кафесына кереп чыкканыңны да сөйләде күрше хатын, чөнки ул үзе дә шунда бер стакан минераль су эчкән. Ашказаны авырулы ул... Ә синең ни эчкәненне мин әйтимме, гөнаһыңны үзең таныйсыңмы?

Калганнарын Азат тәфсилләп тормады. Акулов, әлбәттә, акланып маташкан, ахырда исә аның ике көн буена улының һәм хатынының туган көнен бәйрәм иткәнлеге, аңа кичә гомумән руль тотарга ярамаганлыгы ачыклана.

Икенче көнне кадрлар бүлеге мөдире Бикбау белән Азат арасында бик җитди сөйләшү була. Мөдир Сәйдәшевне гаризасын кире алырга үгетли, администрация исеменнән гафу үтенә, чөнки автобусны башка шоферга тапшыруны ялгыш булган дип саный. Тиздән ике яңа автобус кайтырга тиеш, һәм администрация шуларның берсен Сәйдәшевка бирергә дип карар иткән икән.

Азат көчәнеп кенә елмая, ләкин сүзеннән кире кайтмый.

Мөдир психологик дәлилләр китереп карый:

—Сез бит, иптәш Сәйдәшев, инде коллективка ияләшеп беттегез, сезне бирәдә һәркем ихтирам итә,—ди.—Сез Акуловка карамагыз, берәү генә ул... Хәер, башка җирләрдә дә бар алар барын...

Сәйдәшевнең дәшми торганын күргәч, Бикбау ага, нәрсәдәндер шикләнгәндәй, ишек янына барып, аны тиз генә ачып карый да, соңгы дәлилен ачып сала:

—Азат Нәҗипович,—дип эндәшә ул шыпыртлабрак.—Миңа сезнең тормыш юлыгыз билгеле... язмышыгыз... башыгыздан кичкән хәлләр... Мин ул авыр елларны яхшы хәтерлим, чөнки үземнең дә якын туганнарым репрессия корбаннары булды. Фашистларга әсир төшеп исән калган гарип абыебызны кырык җиденчедә барыбер Колымага озаттылар, ул шуннан кайтмады. Кырык тугызынчыда студент энемне сәяси гаепләделәр. Утыз җиденчеләр булса, миңа да җиле тигән булыр иде, ә болай... ачыктан-ачык кагылмадылар, әмма хезмәт буенча үсәргә юл бирмәделәр. Мин гомер буе баш инженер урынбасарлыгыннан уза алмадым... Партиягә Егерменче съезддан соң кердем. Анда да райкомдагы бер акыллы баш: "Нишләп сезнең фамилия морзаларныкы сыман янгырый?"—дип җанга тигән иде.

Боларны сөйләгәнем өчен гафу итегез... Мин аларны сөйләргә дә тиеш түгел идем... Мин сезгә, Азат Нәҗипович, лагерь тузаны булган абыема караган күк карыйм һәм үземне сезнең каршыда бурычлы итеп тоям. Сезне төрле... катлауланулардан саклыйсым килә. Аңлыйсыздыр,

кайбер сәбәпләр аркасында мин барысын да әйтеп бетермим... Үтенәм сездән: әйдәгез, хәзергә гаризагызны бер читкә куеп торыйк, теләсәгез, бер айлык ял рәсмиләштерербез. Янәшәдә генә үзебезнен Васильево санаторие бар, анда йөрәкне әйбәт дәвалыйлар, бирегә бөтен Союздан авырулар килә...Путевканы профсоюз бирер...

* * *

Җылы сүз жанны эретә. Һәм карт хезмәткәрнең ихластан әйткән сүзләре Азатны тагын бер кат уйланырга мәҗбүр иткән.

Берничә көннән соң мина килгәндә ул инде шактый тынычланган иде, шулай да мин дустымның йөзе суырылыбрак китүен абайладым. Азат моны сонгы вакытларда начар йоклавы белән анлатырга тырышты. Ул, кадрлар бүлеге мөдиренең киңәшен тотып, бер айлык ял алган иде.

Азат миңа автобус кыйссасын бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Күрәләтә гаделсезлеккә нык рәнҗегән иде Азат һәм моны миннән яшерүне кирәксенмәде дә. Аны бигрәк тә Акулов кебек вак хәшәрәтләрнең иркенләп алдашуы һәм безнең системаның аларга каршы корал таба алмавы гаҗәпкә калдыра иде. Бу мәсьәләне бик куертасым килмәсә дә, батырчылык итеп, болай дидем:

—Заманында үзенә очраган теге йолкыш Мурзаевны исенә төшер. Бүгенге Акулов әнә шул Мурзаевтан яралган бит... Ә менә кадрлар бүлеге мөдире Бикбау мине, чыннан да, гаҗәпләндерә. Барысын да әйтеп бетерә алмыйм дигәнме әле?

—Әйе, шулайрак диде.

Бикбау, әлбәттә, күбрәк белә торгандыр, чөнки, шөбһәсез, дәүләт иминлеге комитеты Азат Сәйдәшевнын тормыш-көнкүрешен күздән ычкындырмас. Эштәге хәлләрен, әлбәттә, кадрлар бүлеге аша да даими контрольдә тоталардыр. Әгәр шулай икән, мөдир, чыннан да, Азатка яхшылык тели, бәлки әле аны яклап та кала торгандыр. Мин Азатка шуларны әйттем.

—Үзем дә шулайрак уйлыйм,—диде Азат.—Ләкин мин дуамал адым ясамаска тырыштым кебек. Кем әйтмешли, ата казны котыртмыйм, мораль яктан тотнаклы, эчмим, тартмыйм, анеклот сөйләмим...

Азатка ияреп мин дә елмайдым:

—Ну, бу күркәм сыйфатларың Черек күл агайларын сагайта гынадыр әле,—дидем.—Совет стандартына бик туры килми бу диярләр. Валлаһи, шикләнерләр. Тымызык күлдә корт уйный дигән сүз бар...

Азат шундук житдиләнде.

Мин ана сәламәтлегенә игътибарлы булырга киңәш иттем, кыш буе алсыз-ялсыз эшләвен исенә төшереп: "Безнен яшьтә йөрәк белән шаярырга ярамый,—дидем.—Санаторий турында да уйла."

—Ял итеп карыйм әле, аннан күрербез,—диде ул ничектер ваемсыз төстә.—Бер атна-ун көнне тик кенә урманнарда йөреп, сәйран кылып уткәрергә исәп. Фотоаппарат асып. Аннары мин бит начармы-яхшымы рәссам да әле. Эскизлар эшләрмен. Иртәгәгә дә планым бар.

—Нинди план?

—Беләсеңме, "яшел бишегем" дип атап булмаса да, Атнаны кайтып күрәсем килә.

Чамалап карадым да, Атна авылыннан әйләнеп кайту өчен бер көн генә житмәячәген әйттем. Хәзер ул район үзәге түгел һәм анда автобуслар йөрмидер, юллары да асфальт түгелдер дип кисәттем. Азатның моңа исе китмәде, йөк машинасына утырырга да риза икәнлеген, поездан сон егерме-егерме биш чакрымны җәяүләп тә бара алуын әйтте. "Ә төн кунуга килгәндә, фатир бетмәс әле,"—диде.

—Ихтыярын салават,—дидем мин,—жилләнеп кайт алайса. "Автомо-

биль юллары" китабына күз салсаң да әйбәт булыр.

—Әйе, карармын, андый атласым бар минем.

Азатның "балачакка сәяхәте", нәкъ мин уйлаганча, ике көнгә сузылды.

Бу сәяхәтне уңышсыз булган дип әйтергә минем телем бармый, әмма ул бик үк өметле башланмаган.

Атнага иң якын тимер юл станциясенә Азат иртәнге электричка белән барган, аннары, олы юлга чыгып, Атна ягына баручы "ЗИЛ"га утырган. Атнага борылган юл чатында аннан төшеп калган да, канау буендагы чирәмгә кырын ятып, тагы берәр жай чыкканын көтә башлаган.

Байтак көткәннән соңында аның янына сөт ташучы бер машина үзе килеп туктый. Шоферы кабина ишегеннән ялан башын тыгып:

—Атнагамы? Булса, утыр—бер тәңкәнне әзерлә!—дип, бөтенесен бер сулуда әйтеп бетерә.

Азат тиз генә сумкасын һәм плащын алып, кабинада шофер янәшәсенә кереп утырган.

—Кая барыш, шеф?—дип сорый шофер, кузгалып киткәч тә һәм "бардачок"тан яшел каплы "Шипка" сигаретын алып кабыза.

—Атнаның үзенә.

—Алай икән. Импортный сумкаңа караганда, Казаннан гына түгел кебек үзең?

—Юк, Казаннан дисәң дә була. Яшел Үзәннән.

—Таныш жир. Ә безнең алла каргаган шүрәле якларында ни йомыш?

—Кайчандыр Атнада торган идек. Бер күреп кайтыйм дидем.

—Турист, значыт. Сәяхәтче, ягъни мәсәлән—Юрий Сенкевич,—дип, шофер бер минутта Азатның кемлеген ачып сала.

Шофер "син" дип кенә эндәшкәч, Азат та шул әшнәлек теленә күчә:

—Ә син, значит, колхоз шоферы?

—Точно. Молокозаводка сөт ташыйм. Ике меңенче елга кадәр азык-төлек проблемасын хәл итүгә өлеш кертәм дип тырышу.

Шофер төпчеген яртылаш ачык тәрәзәдән чиертеп кенә ыргыта да, сораштыруын дәвам итә:

—Шулай да безнең як кешесенә ошамагансың, син... абзый,—ди.—Мәскәү генә түгел, Балтыйк буе кешесенә тарткансың... Сугыш вакытында бездә эвакуациядә булган идеңме әллә? Татарчаны да шунда өйрәнгәнсеңдер әле. Дөресме?

—Дөрес түгел.

—Алайса... ГДРмы?—дип һаман төпченә әрсез шофер.

Качышлы уйнауны өнәмәгәнгә, Азат турысын әйтүне кирәк таба:

—ФРГ.

—Китсәнә!

—Китмим,—ди Азат.—Мин бит аннан былтыр гына кайттым.

Шофер сызгырудан да төплерәк жавап тапмый. Шулай, байтак кына сөйләшми баралар. Уйга чумгандырмы, шофер юлга житәрлек игътибар бирми башлый, сикәлтәле жирләрдә машинаны нык кына сикертеп ала.

—Юлны онытма,—ди аңа Азат.—Сөтеңне дә...

—Хы...—дип мыгырдана шофер һәм башын чайкап куя.—Хы... Шулай да, абый кеше, ФРГда кем булып һәм күпме хезмәт хакы алып эшләдегез микән дип кызыксынам әле... Ә? Секрет түгелдер ич?

—Сер түгел, энекәш. Мин анда трейлер да йөрттем, фургон да...

—Шофер инде алайса?

—Точно.

—Түләү яклары?

—Дөресен әйткәндә, анда мулрак түлиләр. Ну... мондагы уртача эш хакыннан биш-алты тапкыр күбрәк чыга торгандыр.

—Да-а... Ә "сулга" эшләп буламы соң? "Налево"?

—Андый гадәт юк аларда... Кабул ителмәгән димме?

—Алай икән... алай икән...

Берничә чакрымнар баргач, гравий түшәлгән "олы" юлдан сул якка гади авыл юлы аерылып китә. Сөт ташучы шул казылып беткән юлга борылып керә дә, машинасын бәләкәй генә инеш буенда көянтә-чиләкләре янында утырган ике хатын кырыена китереп туктата.

—Мин башта анламыйчарак тордым,—дип сөйләде миңа Азат, исе китеп.—Шоферым кабинадан төште, цистерна басмасына менеп басты. Теге хатыннар чиләкләрен мона бирә тордылар, ә ул аларны цистернага бушата торды. Ин гаҗәбе шул: дүрт тулы чиләк белән килгән хатыннар көянтәләренә дүрт тулы чиләк асып китеп тә бардылар. Ә чиләкләре әүвәлгечә марля белән капланган иде...

—Без ФРГда яшәмибез, аллага шөкер, ТАССРда яшибез.

Кабинага кереп утыргач, "сөтче" шоферның беренче сүзләре шул була. Шунысы гаҗәп, ул бу сүзләрне кесәсенә "сул акча" кергәнгә канәгатьләнеп кенә түгел, туган иле белән чын мәгънәсендә горурланып та әйтә шикелле.

Шофер, машинасын чигендереп, кабат олы юлга чыга.

—Суны каян алганнар алар?—дип сорый, ниһаять, Азат, бераз тынычлана төшкәннән соң гына.—Шул шакшы инештәнме?

Шофер моны белмәгән булып кылана:

—Бәлки берәр чишмә бардыр,—дигән була.

—Ә сөтне нишләтәләр?

Сөт карагы кызып ук китә:

—Нишләтәләр, нишләтәләр! Бала-чага соравы биреп маташасың! Теләсә нишләтәләр. Теләсәләр, каймак ясап саталар, теләсәләр—эремчек. Теләсәләр, дуңгызларына эчерәләр. Пүнәтәйме, сакаллы сабый?

Ни түзем Азат Сәйдәшев тә шунда чыгырыннан ычкына:

—Машинаны туктат, сволочь! Дуңгыз!—дип йодрыгын йомарлый.

Бераз шиккә калса да, шофер исе китмәгәндәй кылана:

—Пажалларымсты! Тиенең үзенә булсын. Әнә бара юлың!

Ул, Азатны утыргыч аркасына кысрыклап, кабинаның уң ишеген үзе ача. Азат бер кулына сумкасын тотып төшкәч, бер дә кирәкмәгәнгә, кабина ишеген ябарга дип тоткага үрелгән чакта шофер теш аралаш:

—Син үзең—"су алып эч", фашист килмешәге!—дип зәһәрен чәчә.

Үзен тыя, шоферга тырнак белән дә кагылмый кала Азат, ләкин кабина ишегенең тоткасын җен көче белән каерып ала да, "Мә, истәлегем булсын!" дип, тегенең ишеккә сузылган йөнтәс кулына тоттыра. Теге, күзләрен акайтып, бер Азатка, бер тимер сыныгына карый, агарынган юка, усал иреннәре калтырый башлый. Аннары ул куркусыннан кинәт алга элдертә, Азат чак-чак чигенеп өлгерә.

Шулай итеп, Азат өченче машинага утырып кына Атнага барып житкән.

* * *

Эләкке салам түбәле Атна авылы танымаслык булып үзгәргән, заманча төзекләнгән.

Кызыл Октябрь урамы бөтенләй янарган икән хәзер. Заманында төбәкнең мәшһүр мәдрәсәләрен һәм Архангельскига сөрелгән мулла-мунтагай йортларын бүсеп салган райком һәм райбашкарма биналары юк икән инде. Районнарны эреләндергән вакытта аларны кабат сүтеп яна район үзәгенә алып киткәннәр, без яшәгән йорт урынында шифер түбәле авыл советы һәм колхоз идарәсе биналары тора. Каршыдагы саман кирпечтән төзеп акшарлаган "Коммунар" гәзите редакциясе һәм

типография бинасын тора-бара амбар иткәннәр. Андагы кулдан әйләндереп сынар битле гәзит баса торган кадими американ станогы әллә кайчан домна мичендә эретелгәндер инде... Клуб яңа икән, ул силикат кирпечтән, ике катлы, архитектурасы чибәр генә—"Дом культуры" дип атала. Аның каршысында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл тора: мәрмәр тактага алтынлап йөздән артык исем-фамилия язылган.

Азатка нараттан салынган иске мәктәп бинасы тәмам кечерәеп калгандай тоела һәм ул аны фотога төшергәндә йөрәгенен ашыгыбрак тибә башлавын, шушы иске бүрәнәләрнең күнеленә ифрат якын булуын да сизә...

Ә күпер башындагы кайчандыр без икенче класста укыган таш мәчет хәрабә хәлендә, манарасыз түбәсенең рәшәткәләре генә исән, тәрәзә уемнары да җимерелә башлаган... Авыл уртасында калган зиратның ничәмә-ничә гомер көзгесе булган язулы ташларын бер почмакка өйгәннәр, зират урынына киләчәктә банк һәм тагын нидер саласылар имеш.

Азат боларны миңа сөйләгәндә соңгы вакытларда гәзиттән укыган бер хәбәр исемә төште. 1913 елда Романовлар династиясенең өч йөз еллыгын бәйрәм иткәндә, Сенаттан килгән күрсәтмә нигезендә, мәчет манараларына Рәсәй байрагын эләргә мәҗбүр иткәннәр икән.— Совет чорында башбаштак җитәкчеләр моңардан да арттырып җибәргән: Атна авылында, мәсәлән, мәчет манарасының аен алып, чаң элеп куйган булганнар... Хәер, болары безгә тикле булган эш инде...

Азат авылның урамнарын, нәрсәсе беләндер үз игътибарын җәлеп иткән йортларын, бизәкле "урыс капкаларын", "Изге чишмә" буйларын фотога төшереп йөри. Аңлавымча, аны койма-капкаларның хәрби ныгытмаларныкына тартым булуы, хуҗаларны әйләнә-тирә дөньядан тәмам аеруы гаҗәпләндергән, турысын әйткәндә халык психологиясендәге мондый аерымлануны ул һич тә өнәмәгән, моны ул элекке, үзе белгән күмәклектән һәм ачыклыктан урта гасырларга таба чигенү дип исәпли иде.

Арьякта бердәнбер салам түбәле йорт калган икән әле. Дөрес, янтайган капкасына һәм ишегалдын баскан әрекмәннәргә караганда, монда байтактан бирле торучы юк дип уйларга туры килә. Баксаң, тарихи йорт инде үзе. Авыл күләмендә генә түгел, бөтен Татарстан күләмендә хәтердә калырга тиешле салам башлы йорттыр ул, бәлки?

Бу өйне Азат өч-дүрт яктан рәсемгә алган.

Сөт заводы дигәннәре озынча таш бинада икән. Аның янында машина-мазар күренми. "Сулагай шофер", үзенең майлылыгы шактый кимегән сыекчасын дәүләткә тапшырып, китеп баргандыр инде...

Төштән соң Азат Каран очындагы буада су коенган, аннары "туплау" дип йөртелә торган төштә ял иткән, каты-коты белән тамак ялгаган.

Габдерәшит Маликов дигән кешене Азат менә шушында очрата. Танышкан чакта Азат, үзе дә аңышмастан, иртәнге "сөтче шофер" билгеләмәсеннән файдалануын сизми дә кала һәм үзен турист, һәвәскәр фотограф дип атый.

Утыз биш яшьләрдәге Габдерәшит Маликов исә тарих укытучысы икән. Ул үзенең үсмер улы белән чират буенча килгән көтүче вазыйфасын үтәргә чыккан. Быелтыр авырып чиратны үткәргәннәре өчен, штраф тәртибендә, алар инде икенче көн көтү көтәләр, ягъни тәҗрибә туплап өлгергәннәр. Көтү шушы вакытларда туплауга төшә һәм сыерлар берике сәгатьне су буенда үткәрәләр икән. Әлбәттә, аталы-уллы Маликовлар әүвәлге көтүчеләргә охшамаганнар, кулларында озын чыбыркылары да юк, таяклар гына, ләкин авыл көтүе элек-электән урнашкан һәм гадәтләнгән тәртипне буыннан-буынга саклый. Көтүнең үз психологиясе бар, аның эчендә үзара мөнәсәбәтләр беренче атнада ук урнаша, һәр сыер үзенең көчен һәм дәрәҗәсен белә, имеш. Шуңа күрә җәйге матур вакытларда көтүчеләр артык кыенлык күрмиләр икән. Аннары Маликов тагын бер кызыклы нәрсәгә игътибар иткән.

—Халыкта "мал иясенә ошый" дигән сүз бар. Дөрес ул. Көтүче-

ләрдән чыккан сүз булырга тиеш,—дип сөйли укытучы Маликов.—Кызрач хуҗаның мал-туары да чәүчәләк, пырдымсыз, ялкауның—әкертен, усалның—сөзгәк, юбалгыныкы шапшак булуын психология күзлегеннән анлатып та була торгандыр. Күбәүләр мал белән аның хуҗасы арасында килеш-килбәттә дә охшашлык табалар. Монысы инде сафсата, минемчә... Ә менә минем улым Фәрит яшь сыерларны хуҗасының үзеннән бигрәк шул гаиләдәге балага охшата... Шулаймы, Фәрит?

—Ие,—ди Фәрите.—Чын. Әнә югары оч Сәкинә апаның сыеры тач малае Рәис инде. Алагаем куркак... Шәрипов абыйларның ала сыеры артыннан килеп сөзәргә дә күп сорамый. Безнең класстагы Шәрипов Марат кебек астыртын явыз.

—Ә икенчесе, мүкләк сыерлары ничек?—дип сорый "өлкән көтүче".

—Анысы юаш, басынкы... Ну, бит мүкләкне алар Тауасты Сабыр Сабираттәйләрдән сатып алдылар. Шуңа ул сыер тыйнак, мина да юл саба...

Укытучы Маликов Азаттан үзләрен күшәп яткан сыерлар арасында фоторәсемгә төшерүен үтенә. Ул Азатны фотокорреспондент дип анлап калган ахры һәм:

—Гәзиттә чыгарсагыз да каршы түгелмен,—ди.—Хәзерге заманда чабан дефицитка әйләнде, хурланырлык ягы юк...

Азат көтүчеләрнең сүзен тынлый, биш-алты кадр "черт"ләтеп ала һәм төсле фоторәсемнәрен мәктәп адресы белән җибәрергә вәгъдә итә. Азат абыйсы белән бик тиз үзләшеп киткән Фәрит автомат япон аппаратын бик кызыксынып тоткалап карый һәм телен шартлата:

—Моның каршында минем "Смена" бер мескен генә икән,—дип, муен артын кашый.

—Үскәч, синеке дә булыр әле,—ди ана әтисе.—Шулай бит, иптәш Сәйдәшев?

—Әлбәттә!—дип, өлкән Маликовның сүзен җупләгән Азат. Аннары малайның түземсез күзкарашыннан аңлап, аңа үзен һәм әтисен бер мүкләк янында япон аппараты белән рәсемгә алырга да рөхсәт иткән.

Мал ашап кыркылып беткән жылы чирәмгә утырып сөйләшә торгач, Атна авылының тарихына кереп китәләр. Маликов мәктәптә тарих музейы оештырган һәм аның өчен байтак экспонат туплаган икән. Класс бүлмәсе кечкенә булганга, ат дирбияләре кебек эрерәк нәрсәләрне аңа үз амбарында тотарга туры килә. Нәсел айгыры тәмам картайгач, инде алашага әйләндерелеп үз үлеме белән үлгәннән соң, аның алыптай камыт-ыңгырчаклары бүтән бер атка да ярамый һәм Маликов аларны музейга дип сорап ала. Колхоз рәисе утырып йөргән соңгы "крантас"ның нәфис тәгәрмәчләре дә тарихчының амбарында урын таба. Беренче колхоз хисапчысының чуты да, хәтта электрон-калькуляторлар кайткач кирәксезгә чыккан чытырчытыр санаучы "Феликс" машинкасы да анарда. Бер әбидә ару гына сакланган киндер сугу станын ул әйбәтләп сүтеп, кыйтгасын кыйтгага аерып, сызымын сызып һәм ничек-ничек жыярга икәнлеге турында инструкция язып, шул ук таш амбарына урнаштырган.

Маликов авылның тарихын да язып ята. Атнаның борынгы тарихы, әлбәттә, риваяткә генә нигезләнгән. "Алып бабайның чабатасын каккан жир"дән башлана, чөнки язма истәлекләр сакланмаган. Шулай да соңгы гасырларга карата республика архивларында шактый мәгълүмат табыла, аерым фактларны тарихчы Ленинград һәм Мәскәү архивларына барып казып чыгара.

Шунысы комачаулый, унжиденче ел вакыйгаларыннан соңгы чор турындагы документлар жиде пичәт белән пичәтләнеп, аерым фондта сакланалар, махсус рөхсәтен булмаса, кулга бирелмиләр икән... Татарстанда сәнәкчеләр кузгалышы, егерме беренче елгы ачлык, колхозлашу еллары, кулакларны сөрү, утыз жиденче ел афәтләре, мәчет манараларын кисү турында материал табу кыен...

—Колхозлашу чорын гына алыйк,—дип сөйли тарих укытучысы,

мавыгып китеп.—Ул елларны күпме хата, күпме фаҗига булган... Колхоз рәисләрен дә зыялылар арасыннан түгел, ярлы-ябагай арасыннан куеп караганнар. Бездә менә кулакларның, ә гадәттә урта хәлле тырыш крәстиәннәрнең, җиргә нык басып торган чын хуҗаларның малын тартып алуда һәм үзләрен авылдан сөрүдә актив катнашкан Таҗетдин исемле батрак бер ел чамасы рәис була. Ул үзе яңалифчә кул да куя белмәгән һәм, әлбәттә, авыл кадәр авылны идарә итә алмаган. Ниһаять, "күмхуҗ" фермасы тавыклары: "Таҗ-таҗ-таҗ... ашарга бирмәй, бирмәй, бирмәй..."—дип такмазалап җырлый-җырлый кырыла башлагач, Таҗетдинне алып ташлаганнар. Аннары Таҗетдин абзый байтак еллар ат менеп кыр каравылчысы булып эшләгән, яшел борчактан авыз итәргә йә киндер орлыгы уып ашарга барган берничә буын малайларның кан дошманына әйләнгән, чөнки камчысы, ай, зәһәр иде дип сөйлиләр. Үлеме дә шул киндердән булган имеш. Бер эссе көнне, атын тышаулап җибәреп, киндер арасына кереп йоклаган да, шуннан уянмаган. Җир зәхмәте кагылганмы, әллә киндер наркотигының исеннән исергәнме—белүче юк. Себер киткән сабыйлар каргышы төште дип тә уйлаганнар.

—Мин боларны шуңа сөйлим,—дип, утырган җиреннән кузгала Маликов, ләкин сүзен һаман бетерә алмый.—Бездә җитәкчеләр билгеләү сәясәте бик тә үзенчәлекле... Таҗетдин абзыйлар белән авызлары пешкәч, рәисләрне һәм райком секретарьларын читтән китереп куя башлыйлар. Теге... урысларның тәртип урнаштырырга варяг кенәзләрен чакырып китергәннәре төсле. Имеш, шулай булганда халык буйсына... Дөрес түгел! Халык тешен кысып түзә генә! Килмешәк кешегә синең җирең-суың изге була алмый, ул үзенең биредә вакытлыча гына икәнен яхшы белә. Әнә, күрегез теге китек тауны! Таза ат сырты шикелле йомры тау иде заманында. Дуңгыз фермасы салганда бульдозер белән казытып, тауны ишеп, таш чыгардылар аннан. Читтән килгән рәискә: "Тавыбызның яме китә бит, башка җирдән чыгарыйк,"—дип карадык. Кул гына селтәде! Хәер, читтән килгәннәрнең дә төрлесе булган-булуын...

Улы Фәрит малларны торгызгалап йөргән арада Маликов, Азатка якынрак килеп, туп-туры мондый сорау биргән:

—Сез, иптәш Сәйдәшев, Атнада утызынчы елларда райкомда эшләгән Сәйдәшевнең... кардәше түгелме? Әйтергә яраса инде?

—Ник ярамасын. Мин Нәҗип Сәйдәшевнең улы булам. Гаҗәп... Сәйдәшевне монда хәтерлиләрмени әле?

—Өлкәннәр хәтерли. Ә мин үзем Сәйдәшев фамилиясенә райком архивында казынган чакта юлыккан идем. Беләсезме, утызынчы еллар уртасында, дингә каршы көрәш белән мавыккан атеистлар,—ул вакытта алар алласызлар дип аталган әле,—таш мәчет манарасына чаң куйдырганнар. Менә шул чаңны төшертүче сезнең әткәгез булган бит. Һәрхәлдә халык шулай дип истә калдырган.

—Рәхмәт...—дигән шунда Азат Сәйдәшев. Бу минутларда ул үзен шушы сүзчән укытучыга рәхмәтле итеп, чыннан да туган туфрагына, кардәшләре арасына әйләнеп кайткан кеше итеп тойган...

Ахырда Азат Атна авылында кунарга ниятләве турында әйтеп, монда кемдә төн үткәрергә мөмкин икәнлеген белешә.

—Фатир эзләп интекмәссез,—ди ана укытучы Маликов.—Базар урамында кем дә кертер... Ин иркен өй, әлбит, сөзгәк сыерлы Шәриповларныкы... Калай белән япкан шатрун түбәле, балконлы йорт булыр. Кайчандыр икенче гильдияле сәүдәгәр Үтәмишевнеке булган ихата. Капкалары тимердән, гаражлары бар. Чәй дә эчсәгез, берәр яртылык бирерсез—бездә, кем әйтмешли, таксасы шундый. Әгәр андый-мондый кыенлык килеп чыкса, кичен мәктәпнең ун ягындагы йортка рәхим итегез—мин шунда торам.

—Рәхмәт. Бер атна-ун көннән конверт көтегез.

—Хат та язгыз, иптәш Сәйдәшев. Мин көтәрмен, якташ!

Көтү тау ягына менеп китә.

* * *

Азат икенче көнне төш вакытларында кайтып керде. Иненә аскан кырык кесәле сумкасыннан башка, ул бер кулына зур гына озынча төргәк тә күтәргән иде. Аның яшьләрчә жинел, очынкы йөрешен һәм яшькелт күзләренең иртәнге чык шикелле елтыравын күргәч, мин иркен сулап жибәрдем, чөнки күнелемне кичәләп бирле нидер тырнап, борчып торган иде.

Ул үзенең юлда күргән мажаралары һәм яна танышлары турында сөйләгәнче үк, сары төстәге калын, кыштырдавык кәгазен сүтеп, төргәген ачып күрсәтте.

—"Густав Беккер" сәгате,—диде Азат, мәгънәле итеп.

Әйе, чыннан да, өстәлемдә Сәйдәшевләрнең әйтерсен лә теге дөньядан әйләнеп кайткан зур сәгате ята иде: чебен пычратып бетергән тузанлы пыяласы аша да аның жиз теле һәм циферблатының кыршавы ялтырый, ә калын пыяланың кыйгачлап эшкәрткән кырыйларында салават күпере төсләре уйнаклый.

—Каян? Ничек?

Шунда мина Азат барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Атна авылында ул төн кунарга Шәрипов дигән кешеләрдә туктаган. Теге афәтле елларның сентябрь төнендә кинәт юкка чыккан Сәйдәшевләрнең сәгатен үзләре куйиган арзан гына бәягә сатып алган талымсыз түрәгә бу Шәрипов кардәш тиешле икән. Сәгать анар ничек күчкәндер, монысын Азат сорашып тормаган, ләкин фатир хужасының ифрат әрсез, комсыз булуына карап, ул да сәгатькә артык акча чыгармагандыр дип уйлый.

Сәгать төрле очраклы кунаклар өчен дип тоткан бер тәрәзәле почмак бүлмәдә эленеп тора һәм күптәннән йөрмәгәнгә охшый, чөнки элэнеше үк туры түгел—ул үле бер декорация генә булып калган. Кем белә, бәлки аның бу йорттагы хәрам тереклек мизгелләрен саныйсы килмидер?

Электричкага ашыкканга, Азат иртән бик иртә тора. Хужалар да инде күптән көнне башлап жибәргән, ишле мал-туарларын карап көтүгә озаткан булалар.

Азатны чәйгә дәшәләр. Сәгать турында сүзне Азат шунда кузгата:

—Үзем йоклаган бүлмәдәге сәгать кызыксындырды мине... Ул күптән йөрмиме?

—Байтактан... Ун ел гына бардыр, санап карасан...,—ди хужа һәм түшенә тамган вареньены калак очы белән кырып алып каба.—Ә нигә? Сәгать мастеры түгелсез бит? Әгәр...

—Түгел. Әмма берәр иске сәгать күрсәм, гомер агышын тоя башлыйм... Шундый бер сәгать булдырасым килә.

—Алай диген... Хуш, мондый сәгать күпме тора, сезненчә? Сәгате борынгы бит, ә? Мимечнеке, ялгышмасам. Әгәренки бәясен килешә алсак..? Үзем дә, әллә мәйтәм, музейга илтеп сатаргамы дип уйлап куйгалыйм. Жәлке... Ул сугулары... Ие, тавышы бик матур сәгатемнең. Ә?

—Сәгать ул кадәр борынгы түгел. Ихтимал, унтугызынчы гасыр азакларыныкыдыр.

—Борынгы булмаса да, карт инде, карт... Йөз илле тәнкә генә тора торгандыр дим.

Азат йөз илле тәнкәгә хәзерге заманда эшләнгән ике стена сәгате алып булуын уйлап куя да:

—Алай күп була...—ди.—Сәгатьне төзәттерәсе дә бар бит...

—Анысы шулай-шулаен... Йөз тәнкә инде алайса.

Азат йөз тәнкәсен шушында, табында ук санап бирә, кунып чыккан өчен тагын бер бишлек өсти.

Иң беренче эш итеп, Азат белән икәүләп "Беккер"нын тузанын сөрттек. Эчендәге жизләрне спиртка манчылган мамык белән чистарткач,

ул ярты гасырга яшәреп киткәндәй булды һәм сәгать белән бергә без дә еллар тузаныннан арындык шикелле.

Әлбәттә, сәгатьнең эченә кермәдек, техника мәсьәләсендә остарак булган Азат та аның механизмына кагылмады, күз йөгертеп кенә чыкты һәм, бәхеткә каршы, бөтен кыйтгалары үз урынында булуын әйтте. Боргалаган саен сәгать чынлап, ыңгырашып, җаны барлыгын белгертеп куя иде. Чистартып азапланганда мин сәгать тартмасының эчке ягында карандаш белән тырналган язуга игътибар иттем. Анда: "1929. Донбасс" дип язылган һәм латин хәрефләре белән кул куелган иде. Анысын, укудан бигрәк, Азат танып алды, чөнки бу кул аның әтисе Нәҗип Сәйдәшевнеке иде. Димәк, Нәҗип абый ул ярлы елларда сәгать кадәр сәгать сатып алгач, бу күренекле датаны онытылмаслык итеп билгеләп куйган...

Бу минутларда ниләр кичергәнебезне тасвирлап тормыйм.

Болай хәл иттек. Азат үзе өчен кыйммәте тагын да арта төшкән "Беккер"ны вакытлыча миндә калдыра, аны шушында —Казанда —ремонтлатабыз. Бәлки әле мастерны өйгә чакырып та булыр.

Сәгатьне әлегә зал бүлмәнең түренә, кәефе килгәндә ару гына күрсәткәли торган "Рекорд" телевизоры өстенә элеп куйдык. Ни гаҗәп, шушы йөрми торган сәгать тә безгә күңел тынычлыгы биргән, киләчәк көннәребезгә өмет уяткан кебек иде. Сәгать дигән нәрсәгә мизгелләрне айбалтасы белән чабып үтерүче җәллад дип караучылар бар, әмма без Азат белән андый ук пессимист түгел. Табигать безне яратканда кичәге минутларны да кадерләп күңелдә саклаучылар итеп тудырган, ул минутлар безнең белән бергә генә үләчәк.

Азатның фотоаппаратында әле буш кадрлар да калган иде, һәм мин дустымны үзләренең гаилә сәгате алдына бастырып төшереп тә алдым, аннары, автоматка көйләп куеп, икебез берьюлы рәсемгә төштек.

Азат миндә тулы ике кассета калдырды, мин аларны шушы ике-өч көн арасында бер танышымнан фотолабораториядә эшкәртеп алырга сүз бирдем. Шуннан соң Азат пленканы карап чыга да, кайсы рәсемне ничә данә басарга икәнен билгеләп, кабат лабораториягә илтәбез. Исәбебез буенча, Азат Атна авылындагы укытучыга вәгъдә иткән рәсемнәрне, чыннан да, бер ун көннән җибәрә алачак иде.

Ә хәзергә аның планы борынгы Болгар хәрабәләрен карап кайту иде. Анда ул ике көн булырга һәм эскизлар ясарга ниятләде. Соңгы вакытларда сатып алган төрле әсбапларга, буяу һәм лак, төрле зурлыктагы пумала кебек нәрсәләргә караганда, Азатым рәсем сәнгатенә чынлап тотынырга уйлый иде ахрысы. Монысы минем күңелгә аеруча хуш килде. Әгәр Азат иҗат эше белән мавыгып китсә, аның ватанын, туган җирен, туган туфрагын табачагына һәм шунда тамыр җибәрәчәгенә мин шикләнми идем. Ә инде оя корса, бәлки әле үзенә бала тибрәтергә дә насыйп булыр дип уйладым. Атна авылын әйләнеп кайту гына да аңа ничек шифалы тәэсир ясады бит...

Фотолабораториядә миңа ике көннән төсле фотонегативларны эшләп тә бирделәр. Сәгать төзәтү мастерскоенда гына тоткарлык килеп чыга язды. Ремонт бәясен арттыру өчен булса кирәк, кабул итеп утыручы чибәр кыз ун көн вакыт билгеләп маташты да, мин, сәгатьне күтәреп, мастерның үзе янына кереп сөйләштем. Фамилиясе Каратун булса да, бакыр чәчле рус егете булып чыкты ул. "Густав Беккер"ның тарихы турында әзрәк мәгълүмат биргәч, егет үзе дә кызыксынып китте һәм, сәгатьне караштырганнан соң:

—Лады,—диде.—Ватык-сынык җирләре күренми, бик нык чистартасы булыр. Ихтимал, көчсезләнгән пружинасын алмаштырасы... Аннары берәр тәүлек йөртеп тикшерү кирәк. Өч көндә эшлибез—акчасыннан тормассыз.

—Әлбәттә.

Сәгать төзәтүче өстәле янында идәндә торган күрексез генә кәрзингә күзем төште. Кәрзин шушы бер-ике көн эчендә ремонтланган яшел, зәңгәр, кызыл будильниклар белән тулган, аларның һәрберсенә хуҗасының

квитанциясе каптырып куелган иде. Йа раббым, күпме халык эшкә һәм укуга сонга калмас өчен будильник куеп ята һәм, күрәсең, йокы аралаш аларны болгап ата икән...

Кинәт кәрзиндәге бер будильникка җан керде дә, аның бии-бии калтыравыннан икенчесенең дә нәрсәседер ычкынып, таң әтәчләре шикелле, бергәләп чылтырарга тотындылар. Көлмичә кала алмадым, мина ияреп мастер да:

—"Кузгал, уян, ләгънәт ителгән..,"—дип, әллә кайчан онытылган һәм КПСС съездларында фонограммага ияреп, авыз кыймылдатып кына җырлана торган "Интернационал"ны искә төшерде.

Кайчагында кеше белән бер мизгел эчендә үзара якынлык урнаша. Каратун белән минем арада да шулай булды. Чыгып киткәндә мин:

—Син инде, энекәш, безнең сәгатьне идәнгә куеп кадерсезләмә...—дидем.

—Лады, абый кеше!

Өч көннән соң Азаттан хәбәр-хәтер булмагач, мин әзер сәгатебезне үзем генә барып алып кайттым, бер очтан Атна авылы төшерелгән кайбер кадрларны кәгазьгә басарга заказ калдырдым, чөнки Азатның тарихчы Маликовка һәм аның улына биргән сүзе аяк астында калырга тиеш түгел иде.

Азат гадәттә мина төштән соң гына килә торган иде, ләкин бу юлы иртәләде. Мин аны кыңгырау кнопкасына басуыннан ук таныйм, аның ишек кагуы да дустанә һәм тыныч була.

—Озак йөрдең Болгарда...—дидем мин аңа, кул кысышканда ук.—Әллә борынгы хәрабәләребезне ошаттын инде?

—Анысы да хак,—дип җавап бирде Азат.—Биш кассета төшердем, эскизлар...

—Күңелең булды, димәк?

Азат ияген какты. Мин ана үзем майтарган эшләр турында хисап бирдем һәм әүвәлге урынына элеп куелган сәгатькә күрсәтеп:

—Йөртеп җибәрү хокукы синеке,—дидем.

—Рәхмәт.

Шунда гына без сәгать эченә ике шөреп белән беркетелгән яна җиз түгәрәккә игътибар иттек. Аңа оста гравер кулы белән "Мастер Каратун" дигән сүзләр сырланган һәм сәгатьне төзәтү датасы куелган иде.

Шулай итеп, Сәйдәшевләр сәгате тарихына билгесез бер мастерның тормыш сәхифәсе дә килеп кушылды һәм, ихластан әйтәм, мин бу кешегә чиксез рәхмәтлемен. Минемчә, ул үзенең фирма тамгасын беренче тапкыр кулланырга җөрьәт иткәндер әле.

Азатның кәефе юклыгы күзгә ташланып тора иде. Болгарда йөреп йончыганмы, борыны очлаеп калган, күз төпләрендә куе күләгә... Сөйләшүе салмак, бер ел эчендә татарчаны "су кебек эчә" башлаган булса да, сүз эзләп интегә сыман, хәтта тагы "йа" һәм "найн"нарын ычкындыра башлады. Ләкин мин сәбәбен сорашмадым, Азатның үзенең әйткәнен көттем. Ул миннән яшермәячәк, ул бит ачылырга, чишелергә, бушанырга килгән—мин моны сизәм инде.

Чәйләп утырганда ул әйтә куйды:

—Илдар, минем тагы проблемалар килеп туды...

—Берничә үкмени?

—Берничә... Хәер, алар бер-берсенә бәйле шикелле...

Мин Азатка ярдәмгә килдем:

—Хатын-кыз турындагысыннан башла,—дидем, елмаер-елмаймас кына.

—Әйе... Галия... Ул безнең автобазада эшли... Бухгалтериядә. Кыш көне таныштык. Ире икенче ранглы капитан булган, Төньяк Җир утравы белән ике арада йөзгән. Аңлавымча, анда атом сынаулары үткәрелә

икән... Кыскасы, радиация... Ире өч еллап элек нур авыруыннан вафат булган, шуннан соң Галия Мурманскидан туган илгә кайткан... Минем кебек үк ялгыз, чөнки балалары булмаган...

—Еш очрашасызмы?

—Галия атнага бер өйне жыештырып, керләрне уып китә иде... Минем квартира ачкычы аңарда да бар. Аның кинәше белән ишеккә шактый бәяле яңа йозак куйдым.

Мин Азат квартирасындагы тәрәз шторларын искә төшереп, Галия исемле ханымны күз алдыма китерергә тырыштым. Китерә алмадым. Галияне икенче ранглы капитанның тоныкшәүләсе каплап тора иде.

Азат сүзен дәвам итте:

—Кичә Болгардан кайтып кергәч, квартирам мине ятсынып каршы алгандай тоелды. Инде үзләшеп, ияләнеп беткән бүлмәм үзен шулай озакка ташлап китүемә рәнжегән кебек иде... Юк, син көлмә, чыннан да бүлмәдә ниндидер бер үзгәреш, алмашыну сиздем. Шуны беләм, бу көннәрдә Галиянең килеп чыгу ихтималы юк, ул Минзәлә якларына абыйсына кунакка китте. Дөресен әйткәндә, ул туганнарына үзенең кияүгә чыгарга ниятләве турында әйтергә тиеш иде... Аннары без никах мәсьәләсен хәл итеп, сиңа килеп чыгарга уйлаштык. Минем сиңа нәни генә сюрприз ясыйсым килгән иде.

—Нәни түгел!—дип каршы төштем мин.

—Синең ни уйлаганыңны беләм,—диде Азат.—Рәхмәт... Шулай да бүлмәм ят тоелды миңа, Илдар. Бу тойгыны акылга муафыйк итеп аңлата алмыйм... Алтынчы тойгы бу... Бүлмәдә миннән башка кемдер булып киткән сыман һәм... вәссәлам!

Шуннанмы? Шуннан, бернигә кагылмастан, диван-кроватька утырдым да бүлмәнең һәр сантиметрын күздән үткәрдем. Бөтен нәрсә үз урынында иде. Чыгып киткәндә өстәл почмагында онытылып калган фотокассета да шул килеш ята. Укып утырган китабым да шунда, туктап калган битенә катыргы кыстырылган—аңысы нәкъ кирәк кадәр чыгып тора. Шторның бер почмагы радиатор белән урындык аркасына эләгеп калган килеш...

Язу өстәленә килдем. Син аны беләсең инде. Комиссионный кибеттән алган зур, сырлы-сырлы юан аяклы, тугыз тартмалы өстәл. Өстәлдә тәртип. Беләсеңме, мин һәр нәрсәне билгеле бер урынга куярга яратам. Карандаш, авторучка, бозгыч, кайчы ише нәрсәләрне күземне йомган килеш тә үренеп кенә алырга күнеккәнмен. Үзем өчен мәгънәсен ачыклыйсы татар сүзләрен теркәгән дәфтәремнең "әшкярә" сүзе язылган бите ачык тора, ул шулай булырга тиеш тә, чөнки мин китапханәдә Ленин томнарын актарып, "гласность" дигән сүзнең татарчасына килеп төртелгән идем.

Язу өстәлемнең бер секреты бар... Аңысы нигә кирәк булды дисеңме? Юк, Илдар, мин аны үзем ясамадым, ләкин кибеттә өстәл тартмаларын ачып-ябып караганда яшерен бүлкәсен күреп алдым, чөнки профессор фон-Клейн өстәленең дә шундый секреты бар иде.

Картаеп, кыршылып беткән бу өстәлне мин шуңа күрә генә сатып алдым да. Революциягә кадәр берәр нотариусныкы булгандырмы? Ә өстәлнең секреты ярап куйды. Мин анда... беләсеңме нәрсә тотам?

Шунда Азат коридорга чыгып, үзенең сумкасыннан калын блокнотын алып керде:

—Менә шушыны...

Мин профессор фон-Клейнның кара күн тышлы дәфтәрен искә төшердем:

—Профессор Клейн дәфтәре кебекме?

—Мине үлем тырнагыннан йолып калган фрау Эльза дәфтәре кебек. Мин үземнең уй-фикерләремне шушы блокнотка төшереп барам, кайчагында ул көндәлеккә дә әйләнеп китә бугай. Кыскасы, анда теләсә кемгә укырга ярамаган шәхси нәрсәләр бар... Юк, юк, син бу исәпкә

кермисен! Шуңа күрә блокнотны мин атна-ун көнгә синдә калдырмакчымын, каршы булмасаң...

Мин, әлбәттә, каршы түгел идем, ләкин Азат сүзен әйтеп бетермәде бит әле. Аның аңлатып биргәнен көттем.

—Минем өйдә урлап чыгарлык нәрсә юктыр да. Электроника белән мавыкмыйм, иң кыйммәтле нәрсәм—япон фотоаппараты, ә аны мин үземнән калдырмыйм. Гади карак кергән булса, бөтен нәрсәне туздырып ташлаган булыр иде. Димәк, миндә башка нәрсә эзләгәннәр...

—Нигәле алай бик ышанып әйтәсең, Азат? Эчке тоемлауга, гөманфаразга гына таянасың түгелме? Матди дәлилләрең юк бит.

—Алай түгел, Илдар. Мин төгәл вакыт исәбенә таянам, беләсең килсә.

—Аңлат.

—Иң ахырда мин стена сәгатенә игътибар иттем. Ул минем кул сәгатем кебек үк төп-төгәл көндезге уникене күрсәтә иде.

—Төгәл йөри Чиләбе сәгате, ә?

—Аның боруы ун көнгә житә, ләкин соңгы ике көнне ул берәр минут артка кала башлый. Кыскасы, аны атна саен борырга кирәк. Болгарга киткәндә мин сәгатьне вакыты житкән булса да бормаган идем, димәк, мин кайтуга ул ике минутка соңга калырга тиеш иде.

—Һәм..?

—Сәгать соңга калмаган иде, Илдар. Кемдер аны дөресләгән.

Аңлап житмәгәнгә, мин инбашларымны жыердым.

—Мин болай фараз иттем. Квартираны тентегән вакытта, әлбәттә, сәгатьне дә ачып караганнар. Минемчә, элгән жирдән алып, механизмы белән циферблат арасына күз салганнардыр. Ә бу вакытта сәгать туктап тора, әлбәттә.

—Шуннан?

—Сәгать эчендә яшергән нәрсә юклыгына ышангач, аны кире стенага элгәннәр дә, дөрес вакытны куеп, йөртеп жибәргәннәр.

—Син ялгышмыйсыңмы?

—Ялгышмыйм. Мин сәгатьне махсус бормыйча тордым. Иртәнгә ул бер минутка соңга калып туктады, чөнки боруы бетте. Мин әле тагы бер нәтижәгә килдем,—диде Азат.—Мин кайтып төшкәндә сәгать дөрес вакытны күрсәткән булгач, тентүне кичә төнлә, инде иртәнгә таба гына ясаганнар булып чыга. Югыйсә, Чиләбе сәгате сизелерлек артка калган булыр иде, шулай бит?

Азатның фикере белән килешмичә мөмкин түгел иде.

Кем? Нинди максат белән?

Азат белән икәүләшеп, берсе-берсеннән хыялыйрак фаразлар корып, баш ватарга тотындык.

Иң беренче фараз, әлбәттә, бу тентүне "органнарга" япсару иде. Органнарның Азатның эчке дөньясы белән кызыксынуы табигый хәл. Атна авылына кайтып йөрүләре дә аларга мәгълүмдер, күрәсең. Болгарга мөстәкыйль экскурсиягә чыгып китүе дә иминлек саклау органнарында шик тудырырга мөмкин, чөнки шпиономания чире безгә ана сөте белән кергән. Рәсми пропаганда ничәмә-ничә еллар буе һәммәбездән Карацупалар ясарга тырышты һәм күбәүләрдән ясады да. Ерак Көнчыгышта старшина Әсгать Жиһаншин һәм берничә матрос давыл вакытында баржалары белән юкка чыккач, иң беренче эш итеп, аларны ачык океанда ярсу дулкыннар арасыннан ныклап эзлисе һәм коткарасы урында, Идел буена, Жиһаншинның әти-әнисе өенә килеп казына башлаганнар иде. Ярый әле, кырык тугыз көннән соң, ачыгудан үләр дәрәжәгә житкән тәжрибәсез, яшь дингезчеләрне американнар коткарып калды.

Яки менә Горький шәһәренә сөрелгән академик Сахаров. Үзе берәр яры чыгып китү белән, аның өендә тентү үткәреп, язмаларын оятсыз рәвештә алып китә торган булганнар. Боларны без "радиоавазлар"дан ишетеп белә идек.

Ишек ачкычы Галия ханымда гына булгач, шик анарга да төшә. Һәрхәлдә йозакның Галия ханымдагы ачкыч белән ачылган булуы ихтимал. Бәлки ул аны урлаткандыр? Яисә үз кулы белән тапшыргандыр? Кемгә?

Мин хәтта шофер Акулов вариантын да исәптән чыгармадым. Бу бәндә, үч итеп, Азат квартирында компромат эзләргә мөмкинме-юкмы? Ул бит моның өчен кеше дә яллый ала.

Янә китереп, Азат Сәйдәшевны Көнбатыш Германиядән буш кул белән кайтмагандыр, өлешкә керсәк тә гөнаһ булмас дип уйлаучылар табылырга бик мөмкин. Аның пөхтә һәм безнен халык карашынча купшы киенүе, хәтта иненә аскан биш-алты "молния"ле сумкасы да күз кызыктыра ич! Ул чагында каракны беренче чиратта алтын әйберләр һәм акча кызыксындырырга тиеш. Ләкин мондый карак сәгать эчен актарып маташырмы? Нигә маташмасын? Әгәр вакыты житәрлек икәнен белсә, иркенләп, ашыкмый-кабаланмый эзләячәк ул. Әйтик, төн уртасына кадәр квартирда кеше юклыгын күзәтеп торсалар, төнге уникедән соң хужаның кайтып керү ихтималы юк чамасында.

Күршеләр кем? Нинди ерәк кешеләр? Моны Азат тәгаен генә әйтә алмады. Ул беренче каттагы ике күршесен генә якыннан белә, йомыш белән кергәннәре бар. Берсе мөлаем елмаючан керәшен хатыны, подъездны Азат чираты булганда да юып чыгара икән. Пасха бәйрәмендә шикелле, Азатка кызыллы-яшелле ике манган йомырка кертқән. Янәшәдәге ике бүлмәле квартирда пенсиядәге укытучылар яши—карт белән карчык. Урамга чыксалар, култыклашып түгел, житәкләшеп йөриләр. Йөрәкләргә сагыш өсти торган борынгы эчкерсезлек, самимилек, гаделлек өлгеләре. Педагогларны бөтен квартал белә, бу аерылмас парга һәркем әллә кайлардан сәлам бирә...

Без, ике һәвәскәр детектив, ышанычлы нәтижәгә килә алмадык-алуын, ләкин каракның гади бер мужик түгеллеге, ифрат сак, үзенчә пөхтә һәм зыялы булуы шиксез иде. Ә сәгатьне артык дөреслэп куюга килгәндә, бер генә адәм баласы да хатадан хали түгел. Күрәсең, мондый "эштә" тырышлыкның да чиге булса әйбәттер. Шуна күрә эшләребез тәмам көрчеккә терәлде дип әйтмәс идем.

Галия ханым кайткач, кайбер нәрсәләр ачыкланачак булганга, Азат хәзергә берни булмагандай эш итәргә, шау-шу кубармаска, үзенең планы буенча Татарстан табигатен сәйран кылып йөрергә тиеш. Ике кешелек кинәшмәнең карары шундый булды.

Азат кечерәк кенә палатка сатып алган, Болгарга баргач та, Идел буена төшеп, шул палаткасында кунган икән. Кичке тип-тигез Идел янында әллә кайлардагы тавышның да аермачык ишетелүен тынлап яткан. Димәк, урманнарда ул куна-төнә йөреп, жаны теләгән кадәр эскизлар ясый алачак.

Азатны троллейбус тукталышына тикле озаттым. Саубуллашканда ул озак кына минем кулымны жибәрмичә үзенең көчле, кытыршырак учында тотып торды.

Күнелем тыныч түгел иде.

* * *

Әие, минем күнел тыныч түгел иде.

Азат булып киткәннән соң бер атна узды. Мин анардан көн саен хәбәр көттем.

Әмма юкка гына.

Көн уртасындарак якындагы кибеттән, гадәттәгечә, бер кап эремчек һәм каймак алып кайтып килешем. Мин ярты юлда ишегалдындагы балалар мәйданчыгында утырып ял итәргә күнеккәнмен. Кайчагында бала-чага кайнашканны күзәтү, хәтта сабыйлар чыр-чуын тынлап утыру да күнелле. Кайбер көнне, сулыш китереп кыскан булса, ярты сәдәп

теофедрин даруын да мин шушында кабам.

Ике бетон бүкәнгә беләк юанлыгы агач рейкалар беркетеп мәңгелеккә дибрәк ясалган "эскәмиям" буш түгел, аның уртасында утыз бишкырык яшьләрдәге каралҗым күзлекле ир кеше хуҗа булып утыра иде. Кыска җинле күлмәктән, бер кырыена яшькелт плащын төреп куйган. Шоп-шома итеп кырынган, чәчләрен әллә майлап тараган, әллә лак белән катырган көяз бәндә. Мин утыргычның икенче башыннан урын алдым да, бизәкле полиэтилен сумкамны ике арага куйдым. Бу кеше кымшанып та карамады, ләкин мин аның күзлек пыялалары артына поскан кысык күзләренен чәнчеп-чәнчеп, үтәли тишәрдәй булып караганлыгын бөтен тәнем белән тойдым. Шуна күрә аның:

—Исәнмесез, Илдар Хәлилович,—дип эндәшүе дә артык исемне китәрмәде.

—Гафу...—дидем.—Мин сезне танып җиткермим...

—Без таныш түгел, Илдар Хәлилович. Мине комитеттан дип кабул итегез.

Һәм ул әллә кай төшеннән таныклык кенәгәсен чыгарып, фокусчы Акопян кебек, сыңар кулы белән генә аны ачып бер мизгелгә күрсәтеп тә алды. Мин, әлбәттә, моның фамилиясен дә укырга өлгермәдем.

Ачуым килде. Соня Татаркинаны искә төшердем дә:

—Ни йомыш, Дзержинский?—дидем.

—Ишембаев,—диде бу, югалып калмастан.

—Шуннан?

—Сез артык кызмасагыз иде... Турысын әйтәм: безне Азат Сәйдәшев кызыксындыра. Без ана фәкать яхшылык кына телибез, аны хәвефхәтәрдән саклыйбыз, Илдар Хәлилович. Аңлавыбызча, ул сезнең якын танышыгыз. Соңгы көннәрдә без Сәйдәшевны күздән җуйдык. Сезгә аның кайдалыгы билгелеме? Гомумән, Сәйдәшев турында информация бирсәгез иде.

Башыма нәрсәдер китереп органдай булды.

Мин өнсез калып, ни әйтергә белмичәрәк, телемне авыз эчендә әвәләдем. Аннары гына Ишембаевның импортный күзлегенә карап:

—Ә мин сезне әйбәтләп кенә... фәлән җиргә "озатсам"?—дидем.

Юк, ул оятсынмады, күзен яшермәде, чөнки вазыйфасы һәм тәрбиясе буенча ук андыйлардан түгел иде:

—"Озатып" карагыз...—дип, тешен күрсәтеп маташты.

Һәм мин аны тозлап-борычлап "озаттым". Авыз пычратмас өчен урысчалап. Пар чыгару өчен. Кинәт күтәрелгән кан басымын киметеп булмасмы дип.

Мин аны торып китәр бу дип көткән идем. Юкка гына. Шуна күрә үзем кузгалдым. Малай чаклардагы кебек, сынау тәртибендә, кулымны кисәк кенә күтәргән идем, Ишембаев күзләрен ирексездән йомды һәм башын читкәрәк алды.

Аның чалышайган, җимерек чыраен күргәч, мина гаҗәеп күңелле булып китте һәм мин бәләкәй Робертның поездда Сәйдәшләрне рәнҗеткән төрмәче агайлар чигенгәч нигә елмайганын аңладым. Шул сабый да аларның асылда куркак икәнлегенә төшенгән... Чөнки алар төптә үзләренең имансыз эш белән шөгыльләнүләрен тоялар һәм җаваплылыктан, халык хөкеменнән куркалар.

Ләкин безнең тамаша моның белән генә бетмәде әле.

Эскәмия артындагы куак арасында "өч борынга" кереп утыручылар булган икән. Аннан кәефләнеп кенә безнең кооператив йортның слесаре Рафик һәм тагы ике "колхозчы" килеп чыктылар. Күрәсең, теге "сөйкемле" сүзләрне мин кычкырыбрак әйтеп ташлаганмындыр, Рафик элдереп алды:

—Нәрсә, дәү абый, әбиҗәйт итәме әллә?—дип сорады да Ишембаевка таба борылды.—Син нәрсә безнең йортныкыларга бәйләнәсен?—диде һәм шундук:—Бассейнга манчып чыгарыйкмы әллә үзен, дәү абый?—дип, миннән рөхсәт сорады.

Мин яхшук кызмача слесарьны тынычландырырга ашыктым:

—Юк, юк!—дидем.—Без бит болай гына... дусларча... Бөтенесе—нормально.

—Дусларча булса ярар. Мать якасына. Ну шулай да, бу гастролерны мин кичә дә шушында абайлаган идем,—диде Рафик, муен артын кашып, һәм:—Фатир басарга йөрми микән, паразит?—дип, шаркылдап көлеп җибәрде.

Рафикның шешәдәш дусларыннан берсе:

—Йөриләр шунда... Аннары безнең кәлүшләр югала,—дип мыгырданган булды.

Бу кадәр күпсанлы тупас көчкә каршы тора алмаячагын аңлап, Ишембаев торып китү җаен карады.

"Ике—ноль",—дидем мин эчтән генә һәм Ишембаевның ирексездән бөкшәя төшкән һәм шундук егетлеген җуйган гәүдәсен күзәтеп калдым.

Спорт исәбендә нык ялгышу белән ялгышканмын икән! Кичкә таба минем кан басымы күтәрелеп, гипертония кризы башланды. Иртәгесен врач чакырырга туры килде һәм мин өч көн караватта, өч мендәргә аркамны куеп, ярым ятып, ярым утырып торырга мәҗбүр булдым.

Көн үткән саен исәп Ишембаевлар файдасына үзгәрде, чөнки Азат Сәйдәшевтан хәбәр-хәтер юк иде.

Аягыма басу белән мин Яшел Үзәнгә чыгып киттем.

Шундый тын һәм тыныч шәһәрчек ул. Тарихы да кызыклы гына. Монда узган гасыр урталарында "кабак"лары бик күп булганга "Кабачище" дип аталган авыл барлыкка килгән. Мәйханәчеләр бире дә бурлак-буралгы өерләренең баржа тартып җыйган тиеннәрен алып калганнар...

Шәһәрчекнең исеме җисеменә туры килгән—яшеллеккә күмелеп утыра. Дөрес, шәһәрнең төп өлеше хәзер үзән җирдә түгел, тау башында. Монда "Оргсинтез"нын кызгылт төтене дә, Волжски шәһәренең кәгазь комбинаты исләре дә килеп житми, шуңа яфраклар да үз вакытларында саргаеп, үз вакытларында коела, чыршы-нарат инәләре дә озын гомерле. Кояш якка караган тау битләвендә бакчалар, андагы түтәлләр баскыч-баскыч итеп, террасалап эшләнгән. Алмагачлар һәм чия чәчәк атканда тау битләвенә кабат ап-ак кыш әйләнеп кайткандай була.

Советлар Союзы вакытында Иосип Броз Титоны һәм кайбер башка чит ил коммунистларын Сталин бабаң шушы шәһәрдә тоткан диләр. Мәҗбүри кунаклар өчен бик әйбәт урын. Соңыннан, кирәге чыкканда, "Юк, ул сөрген түгел иде, ял итү зонасы иде" дип тә боргаларга була. Чакырып китерим дисәң—Мәскәүгә бер көнлек юл. Уйланган саен Иосиф Сталинның коточкыч сак һәм хәйләкәр булуына таң каласың. Ул, чыннан да—гигант. Шайтани хәйлә һәм мәкер гиганты! Ә бу тымызык шәһәрчектә Берияләр иминлек саклау өчен тиешле системалар һәм аулар корып калдырганнардыр...

Азат яши торган йорт ишегалдында мине колак ияләнмәгән тынлык каршылады.

Иртәрәк булганга, балалар күренми. Уйный торган комлыкларында кичә онытылып калган кечкенә соскы аунап ята. Шунда ук бер тәгәрмәчен җуйган уенчык йөк машинасы. Ана түбәләмә ком төялгән, ул бүген үк рейска чыгып китәргә әзер.

Беренче подъезд төбендә генә җан иясе очраттым. Бик бәләкәй ала көчек иде ул. Аклы-каралы йомгак шикелле тәгәрәп аяк очыма килде, шыңшый-шыңшый, туфли башын ялап алды. Аны ничек кирәк алай аралап, ишекне ачтым да, мәэмай ялгыш кысылмасын өчен, сакланып кына яптым.

Кояштан кергәч, ярымкараңгыга күз ияләнгәнен көтеп тордым.

Азатның квартиры сул яктагы өченче ишек.

Бу ишекнең йозак турысына управдом пичәте сугылган кул яссуы кадәр кәгазь ябыштырылган иде.

Кәгазьне күргәч, артка чигенеп, баскыч култыксасына таяндым.

Шул чагында урта ишектә ачкыч борылганы ишетелде. Сискәнеп, шунда карадым.

Ишектә башына борынгычарак итеп чуар яулык каплаган хатын күренде:

—Сез... кемгә?—дип сорады ул әкрен генә.

—Сәйдәшевкә... Ни булды монда? Ишеге нигә пичәтле?

Яулыклы хатын, имән бармагы белән ишарәләп, мине үз янынарак чакырды.

—Сез Илдар исемлеме?

—Әйе.

Хатын як-ягына каранып алды һәм ишеген каерыбрак ачып:

—Үтегез,—дип пышылдады.

Кухняга үттек. Хуҗа хатын миңа урын тәкъдим итте һәм каршыма килеп утыргач кына мин куркып көткән авыр хәбәрне әйтте:

—Азат Назипович вафат булды,—диде.—Өч көн элек... Йөрәктән, диделәр. Мәрхүм каяндыр авыр рюкзак күтәреп кайткан иде ул көнне, ләкин бер дә авыру төсле түгел иде башта... Гафу итегез, мин Катерина булам, Васильевна. Үзебезчә Кәтернә була инде.

—Екатерина Васильевна... Зинһар, барын да сөйләгез. Кайчан җирләделәр? Кайда?

—Туктагыз, мин тәртибе белән сөйлим... Азат Назиповичның кайтканын мин менә шушы тәрәзәдән күрдем. Керәшенчәләп эремчек пилмәне пешереп йөри идем. Бер ярты сәгатьтән ишеген шакыдым. Тәлинкә белән пилмән керттем, юлдан ачыгып кайткандыр, мәйтәм... Ә, әйтергә онытканмын, Азат Назипович бер ятим көчек ияртеп кайткан икән бит әле. Көчеге коридорында чәй тәлинкәсеннән сөт эчеп азаплана иде... Аннары, койрык димәсән хәтере калырлык кәкришкәсен болгый-болгый, яныбызга килде.

Екатерина Васильевнаның тәфсилләп сөйләвенә караганда, ул чыгып киткәч озак та үтми, күршесенә элек тә күренгәләгән бер чибәр ханым килгән. Ләкин бу юлы аның өй җыештырып, тузан суыргыч җуылдатып йөргәне ишетелмәгән, кичкә таба ханым кәефсез генә китеп барган. Бу вакытта инде Екатерина Васильевналар, күрше-күләннәр белән гәп сатып, подъезд төбендәге эскәмиядә утырганнар.

Телевизорда “Время” программасы барган чагында Азат Сәйдәшев Екатерина Васильевнага үзе кергән. Бер очтан, рәхмәт әйтеп, тәлинкәсен дә калдырган. Ләкин керүенең сәбәбе башкада булган: аның чыраенда кан әсәре калмаган кебек тоелган, үзе ничектер төртелә-төртелә генә, авыр сөйләшкән. “Мин аңа валерианка эчердем, хәле бераз җиңеләйде шикелле”,—диде күршесе. Менә шунда Азат минем хакта сүз кузгаткан: “Дөньяны белмәссең,—дигән.—Әгәр минем белән бер-бер хәл булса, менә шушы нәрсәләрне Илдар Хәлилович исемле кешегә тапшыра күрегез,”—дип үтенгән...

Азат күрше хатында фотоаппаратын һәм төшергән җиде кассетасын, аннары ике калын альбомда эскизларын калдырган булып чыкты.

—Монда сәнгать әйберләреннән башка нәрсә юк—бер дә шикләнмәгез,—дигән Азат.—Ләкин шулай да аларны башка һичкемгә бирмәгез, хәтта сораучы булса да—әйтмәгез. Ярыймы?

—Борчылмагыз, күрше,—дигән Екатерина Васильевна.—Алла боерса, иртәгә үк үзегез кереп кире алып чыгарсыз әле... Шулай да... Илдар дигән кешене мин ничек табармын соң?

—Ул үзе табар,—дигән Азат.

Екатерина Васильевна сүзне күңеллерәк якка борырга тырышып:

—Көчегегез бик матур... Яхшы токымнанмы әллә?—дип сораган.

—Анысын белмим... Акыллы токымнан,—дип кенә җавап биргән Азат, елмая төшеп.

Инде чыгып барышлый, ишек янына җиткәч, Азат, үзалдына

әйткәндәй, бик арыган тавыш белән:

—Ул гаепле түгел... Аны мәҗбүр иткәннәр,—дип куйган.

Монысын Екатерина Васильевна аңламаган.

Иртәгесен Азат квартирының ишеге артында көчекнең өзгәләнеп шыншуын ишеткәч, күршеләр ишекне шакып караганнар. Ни гаҗәп, ишек ачык булып чыккан, димәк, Азат аны бикләп маташуны кирәксенмәгән.

Ул диванында утырган килеш йокыга талган...

Екатерина Васильевна моннан соң булган хәлләр, врач чакыру, милиция килүе, төрле кәгазьләр тутырып, үлем фактын рәсмиләштерүләре һәм башка дөньяви мәшәкатьләр турында да тәфсилләп сөйләде.

Ә жирләвен кичә генә жирләгәннәр икән. Башта кайсыдыр авылга алып китеп күмү турында сөйләнсәләр дә, соңыннан, махсус рөхсәт белән, шәһәрнең иске зиратында иң әчкәрегә бер почмакта урын тапканнар. Монысы артыннан, имештер, Азатның таныш хатыны бик каты йөргән. Ә алар Азат Сәйдәшев белән горзагска гариза да биреп куйган булганнар икән...

Мин ишегалдына чыктым.

Дөнья иркен, ләкин шушы күз камаштыргыч якты дөньяда минем өчен Азат Сәйдәшев юк иде хәзер. Бу дөньяда аңа урын табылмады. Бу дөньядан ул бер генә хыялын да тормышка ашыра алмыйча китте.

Ишегалдына инде җан керә башлаган, комлык тирәсендә берничә сабый мәш килә. Баягы уенчык машина тагы бер тәгәрмәчен югалтса да, "выжж-выжж" итеп, ком ташуында. Ала көчек тә "үз ишләре" арасында сыеныр жир тапкан, ләкин ишек ачылгач та минем тарафка күтәрелеп карады.

—Музгарка! Музгарка, кил монда!—дип дәштем мин.

Һәм ялгышмадым. Маэмай, колакларын шомрайтты да, томырылып яныма килеп житте. Мин аны күтәреп алдым.

Музгарканы Азат Сәйдәшев җәсәде үзенә мәңгелек түшәк тапкан Яшел Үзән зиратына да күтәреп алып кердем. Мин кырыйларына кәс тезгән яңа кабер янында басып торганда Музгаркамның тыны да чыкмады, әйтерсең лә ул да бу мизгелнең мөһимлеген аңлый иде.

Кабер өстенә замани символ—йолдызлы ай беркетелгән тимер пирамида утыртылып, аңа өч венок сөяп куелган: берсе—автобаза администрациясе, профсоюз һәм хезмәт коллективы исеменнән, икенчесе—Азатның күршеләреннән, ә өченчесенең кара тасмасына кыска гына итеп "Кадерле кешемә" дип язылган иде.

* * *

Азатның кинәт вафат булуы бөтен тормыш тәртибемне, яшәү фәлсәфәмне, тоткан мәсләгемне какшатты—гомумән, мине тәмам үзгәртте сыман. Ә бит мин үземне инде калыплашкан, "буыннары каткан" бер шәхес дип саный идем...

Шулай да егылмыйча калдым, чөнки миңа, чынлыкта Сәйдәшевнең берданбер варисы буларак, байтак эш башкарырга кирәк иде: шул көнне үк мәрмәр вагыннан катырып ясалган ташка, аннары кабер тирәсен әйләндереп алу өчен юан чылбыр белән дүрт тимер баганага заказ бирдем. Алар бер айдан әзер булырга тиеш иде. Һәйкәлташ куярга рөхсәт алу, аны илтеп урнаштыру кебек эшләрдә мин автобаза администрациясенә, беренче нәүбәттә Азат сөйләве буенча жылы тәэсир калдырган кадрлар бүлеге мөдиренә исәп тоттым һәм шушы атнада ук кабат Яшел Үзәннән әйләнеп кайтырга дип планлаштырып куйдым.

Азатның яңа кассеталарын да эшкәртергә бирдем. Исәбем аның фоторәсемнәреннән берничә альбом төзү иде, чөнки әүвәлгеләреннән

күренгәнчә, туган илен сагынып кайткан сәнгатькяр Азат Сәйдәшевнен күзе табигатебездә без инде күрми башлаган гүзәллекләрне дә тотып алган иде.

Музгаркага олы бүлмәмдә бер почмак әзерләп, аны тәрбияләргә керештем, билгеле бер вакытларда тышка алып чыгып, йомышларын шунда үтәргә өйрәтә башладым. Монын өчен белгечләр, эт асраучылар белән киңәшергә, төрле белешмәләр актарырга да туры килде. Минем тәрбиям башлыча хуплауга һәм бүләкләүгә—асылда йомшаклыкка нигезләнгән булганга, эшем әкрен барды, ләкин мин барыбер Музгаркага, ул ничек кенә ялгышмасын, жәза бирү ысулын кулланмадым, кул яга, тавыш күтәрә алмадым.

Менә шушындый көндәлек бурычлар һәм мәжбүри мәшәкатьләр мине авыр уйлардан йолып калдылар шикелле.

Икенче кичне мин Азат калдырган эскиз дәфтәрен һәм аерым битләр салынган папканы алып актара башладым. Папка эченнән Азатнын Сәнгать академиясен унышлы тәмамлавын раслаган диплом һәм сигезгә бөкләнгән бер игъланнамә килеп чыкты. Каләри хәл анлаганымча, немец телендәге бу игълан Азат Сәйдәшев—Отто Клейн дигән рәссамнын персональ күргәзмәсе турында һәм датасы да бик күптән түгел—анын моннан ике ел ярымнар элек кенә булганлыгын хәбәр итә иде.

Әйе, Азатнын мина сөйләп бетермәгән, ләкин сөйләячәк нәрсәләре әле байтак калгандыр, күрәсен.

Менә Азатнын ватмандагы акварельләре һәм карандаш-каләм белән төшергән рәсемнәре, эскизлары. (Кәгазьне дә, буяуларны да ул ФРГ дан ук алып кайткан дип уйлыйм.)

Калай түбәле озын бүрәнә йорт. Мин анарда Атна авылында без торган өйне таныдым. Азат ишек төбендәге баскычларны да хәтерли, ничә басмалы икәнен дә онытмаган икән. (Бу баскычлар астында без откан шәмәйләребезне саклый идек. Бер көнне безнен баскыч асты бушап калса, икенче көнне Азатлар шәмәйгә тәмам ярлылана торганнар иде.)

Икенче рәсемдә кулларына кәшәкә тоткан баш-алты малай сурәтләнгән. Аларнын берсе миндер, мөгаен. Менә бусы, чандыррагы... Ә бу түгәрәк чырайлысы кем икән? Банк мөдире малае Руфка ич! Хәзер прокуратурада эшли бугай. Рәсемдә Азат юк.

Менә ике бәләкәй малай житәкләшеп тора. Айдар белән Робертны күргәч, йөрәгем сыза башлады.

Идел аркылы салынган тимер челтәрле күпер—кайчандыр моннан өч бала—Сәйдәшевләр поезд белән үткән. Күперне Азат тау башыннан төшергән...

Менә Васильево шәһәрчегенен хәзерге вокзалы. Монда бүген кин ябалдашлы тупыллар да, чуман-чуман карга оялары да юк инде... Егерменче гасыр башында такталан укмаштырган ямьшек вокзал урынына егерменче гасыр ахырына хас шундый ук шыксыз пыяла-бетон.

Рәсемнәр арасында игътибарымны авыл юлында туктаган цистерналы машина жәлеп итте. Шундый ачык, якты, жылы һәм күнелле төсләр. Сөт ташучы машина. Шоферы ун як ишеген ачып, үзенен танышынамы, әллә хәзер генә төшкән пассажирынамы елмаеп кул изи, саубуллаша... Шундый мөлаем чырайлы, миһырбанлы шофер... "Их, Азат,—дидем мин, рәсемне күрүгә,—адәми шайтаннар нәселеннән булган теге шоферюганы шушындый матур итеп сурәтләгәнсен. Явызлыкнын аргы ягына чыккан бәндәдән чын яхшылыклы кеше ясагансын..." Хәер, болар бит синен хыялларын...

Без барыбыз да менә шушындый "социалистик реалистлар"быз инде, чөнки аллавыч табигать безгә кичәге чынбарлыкны аллы-гөлле итеп күрсәтә торган күзлек кидерә. Кичәге көн матуррак әлбәттә, чөнки без яшьрәк булганбыз, чибәр булганбыз һәм офыкларыбыз очсыз-кырыйсыз сыман тоелган.

Мүкләк сыер янында басып торган бу малай Атнадагы Фәриттер инде. Менә аның ачык, көләч йөзе кемне дә ышандыра. Аның елмаюы алдамый.

Папкадагы иң соңгы биттә мин йөгрек каләм төшергән хатын-кыз сурәтен күрдем. Юк, Азат аның йөзен ачмаган, матур иякле ак овал гына калдырган. Кем ул? Түбәндәрәк—озын толымнарын алга ташлаган кыз бала сурәте... Бусы кемгә ишарә? Әлбәттә, Ганжәгә—Азатның тәүге мәхәббәтенә.

Азатның калын блокнотын мин профессор фон-Клейн дәфтәренең дәвамы сыман кабул иттем, чөнки монда Азат та үзенә ошаган яки үзен сискәндергән хикмәтле сүзләрне язып барган... Шушында ук кайбер көндәлек вакыйгаларны да теркәгән, үзенең уй-фикерләрен кәгазьгә ышанып тапшырган. Аның блокноты Ишембаевлар кулына кермәве ничек әйбәт.

“Унтугызынчы гасыр ахырында Тютчев: «Мөмкин түгел Россияне аңлау гакыл белән, Гомум аршын белән үлчәү мөмкин түгел,»—дип күкрәк суга. “Мондый илгә ышанырга ярыймы соң, Тютчев? Ана таянырга ярыймы?”—диясе килә бу искиткеч нәфис шагыйрьгә. Ә бүгенге совоклардан: “Мондый илең белән мактанып буламы соң, бичаралар?”—дип сорыйсы килә. Хәер, мин сезнең авыздан: "Туган илдән туйган ил яхшы" дигән яман сүзне дә ишеттем... Александр Пушкин: “Мина рәхәт булган жирдә—минем Ватаным” дип әйткән, имеш. Олуг шагыйрьнең олуг хатасы бу! Мин моны Пушкинның беркайчан да(!) туган иле чикләрен атлап чыкмаган булуы белән генә аңлатам.

Егерменче гасыр башында Андрей Белый да:

Юк бул күздән,
Югал, и Россия,
Россиям минем!—

дип юкка гына әйтмәгәндер, гамьсез Россияне аңлый алмый гажиз булганга әйткәндер.”

“СССР—нәкъ театр сәхнәсе шикелле, монда чынбарлык хыялый күренешләр белән буталып беткән, большевистик сценарий буенча уза торган мәжбүри тамашада уены-чыны бергә: монда икейөзлелек эчкерсез иман белән, чеп-чи ялган чын тугрылык белән кара катыш, монда уенчык хәнжәр дә йөрәкне яралый...“

“Безнең галимнәребезгә гап-гади укымышлылык житми.”

“Хезмәт кешене барлыкка китергән дә, аннары анардан янә хайван ясаган...”

Яки: “Кешене хезмәт тудырган һәм калган эшне аракыга тапшырган.”

(Азат Сәйдәшев бередә профессор Клейн белән бәхәскә керә иде шикелле.)

“Бәдән ачлыгы бер нәрсә, ә менә фикер ачлыгы... Анысы СССРда беркайчан да өзелеп тормаган, цензура тамыр жәя барган саен, елдан-ел көчәйгән генә. Нәтижәдә чынлап та яңа тип кеше—“совет кешесе”—партия карарларын “Ура!” кычкырып бердәм хуплый торган һәм үзенең наданлыгыннан, хәбәрдарсызлыгыннан, зәгыйфьлегеннән, ихтыярсызлыгыннан хурланып, үз-үзенә ачу итеп аракы чөмерүче, тозлап-борычлап сүгенүдән һәм хатынын табалаудан тәм табучы ике йөзле, ике стандартлы мескенчәк бәндәләр (Homo sovjeticus яки, теленә шайтан төкергән бер эстрада жырчысы әйтмешли, “совоклар”) барлыкка килгән. Һәм бу чир тиз генә үтмәс шикелле. Моның өчен өч-дүрт буынның дөнья кичүе кирәк.”

“Совок”ны коммунистлар “тискәре селекция” ярдәмендә барлыкка китергәннәр. Кайчандыр селекционерлар көтүдә кып-кыска, аеры аяклы сарык бәрәннәре тугач, шуларны кушылдыру юлы белән, тәбәнәк кенә

киртәне дә сикереп үтә алмый, ягъни кача алмый торган яна токым сарык чыгарганнар. Совок—менә шундый ангыра сарык инде. Бичара мутант!"

"Радиотапшыруларны томалау—китапларны утка ягуга тин. Моны беренчеләрдән булып Һитлер эшләгән. Аннары, сугыштан сон, "Америка авазы", "Азатлык" һ.б. көнбатыш радиостанцияләренен "авызын томалау" эшенә сталинчылар алына. Ә китапны утка ягу фикере безнен эрага кадәр 213 нче елда ук борынгы Кытай императоры Цинь Ши-хуандинын киңәшчесе Ли Сы дигән кешенен башына килгән, имеш. Ул бу идеясен үзе үк тормышка ашырган һәм бер очтан фикри дошманнарын терелэй жиргә күмәргә боерган... СССР да күпме китап юк ителгәнен исәпләп чыгарып буламы икән?"

"Тереза-ана, Альберт Швейцер, академик Сахаров, Сергей Ковалев кебек изге кешеләр—абсолют вөждан ияләре дә яши дөньяда. Аз алар, бармак белән генә санарлык, әмма бөтен жир планетасын әкияти филләр дә, кит балыгы да, үгез дә түгел, шушы чандыр Сахаровлар үз жилкәләрендә күтәреп торалар. Калган бәндәләр—әзергә бәзерләр генә. Алай гына да түгел, алар Сахаровларны таптап китәргә дә күп сорамыйлар, аннары, рухи һәм матди бөлгенлеккә төшкәч, әле кичә генә үзләре көлгән, мәсхәрә иткән, рәнжеткән кешеләргә табына башлыйлар. Бу табынуга да ышанмыйм мин, чөнки кешене аллалаштыру һәрвакыт фажига белән тәмамлана."

"Үзеннән көлә белмәгән халык хөр халык түгел."

"Җинаять кодексында үлем җәзасы каралган икән, димәк, үтерергә ярый."

"Тукай бүләгенә тәкъдим ителгән бу көяз бәндәнен шигыреннән илһам исе түгел, тир исе килә. Шигырьләре тимер-бетоннан катырган... Ул бит Тукай бүләгенен дәрәжәсен төшерәчәк! "Шигырьне алай язмыйлар,—үпкәләмә, Думави!" дигән булыр иде ана Габдулла Тукай."

(Азатны мин Тукай клубындагы "Әдәби ел йомгаклары" жыелышына алып баргач, ул президиумда утырган бер чиновник шагыйрьнен тәнәфес вакытында арткы бүлмәдә нәкъ театраль Ленин позасына басып, бер кулын кесәсенә тыгып торганын күргән. "Тройка"дан, сакалы белән кепкасы гына житми... Аннары броневигы... Шуннан сон Азат киләчәктә барыбер лауреат булачак бу шагыйрьнен ижат жимешләрен караштырып чыккан иде.)

Жан Кокто: "Шагыйрьнен тормышы вафатыннан сон башлана."

"Гажәп, "халыкчанлык, халыкчанлык" дип авыз суы корыталар. Чынлыкта исә әдәбиятка кара халыкчанлык түгел (анысы артыгы белән житкән), бәлки аристократизм житми. Бу юнәлеш Фатих Әмирханда булган, Гаяз Исхакыйда да булган, Дәрдмәндтә булган. Аристократизмнын соңгы чаткыларын без яшь Шәриф Камалда, хәтта яшь Ибраһимовта күрәбез. Ул беркадәр Әмирхан Еникида дәвам итә кебек..."

"Картаймыш көнендә кешенен сәнгатьчә фикерләве йомшый, зәгыйфьләнә. Лев Толстой гомере кичендә: "Әдәби әйберне булдыра алмыйм, уенчык белән уйный алмаган шикелле,"—дигән. Шундый ук фикерне Чарльз Дарвинда да очратабыз. Ә бит фикер гигантлары!"

"Сүзлек актарып утырам. Чыпчык, чәүкә, күгәрчен, карлыгач, карга, кәккүк, керәшә, сыерчык, акчарлак, карчыга, лачын, сандугач, челән, чомга, чумгалак, чүрәкәй, каз, үрдәк, тавык, чәберчек, чукыр, чуллык, козгын, шонкар, ябалак, саескан, тукран, аккош, каракош...—болар барысы да гадәти кош исемнәре. Аларда "ч" һәм "к" авазлары артык еш очрый сыман тоелды мина. Беләсе иде, тел тарихчылары бу хакта ни уйлый икән? Бу атамаларда "очу" сүзенен "ч" авазы эләгеп калмадымы икән? Ә "к" авазында?"

(Боларны Нурихан Фәттахка әйтәсе булыр, үзенен йөгәнсез хыял тулпарын чыбыркылап, чыгарсын бер-бер нәтижә,"—дип уйлап куйдым. Гомумән, татарда да Велемир Хлебников кебек сүзне һәм авазларны хисаби

яктан үлчи ала торган хыялый бер даһи туса иде! Ә бәлки без шундый хыялый даһиебызны күрми калганбыздыр? Сигизмунд Кржижаеновскийны хәзер кем белә? Ә бит чын әдәбиятчылар аны "прозеванный гений" диләр. Азат Сәйдәшевләр—әнә шундый генийлар токымыннандыр дим мин.)

Реаль социализм казыган бихисап исемсез каберләрдәге сөякләр социалистик реализмның бишек җырына каршы: "Долой!"—дип пышылдыйлар. Ишетмисезмени?"

А.И.Герцен: "...һәм социализм үзенең барлык фазаларында хәдтин ашып, адәм көлкесе булганчы тәрәккый итәчәк тә, шул чагында азсанлы баһадирлар янә: "Долой!"—дип сөрән салачаклар."

М.А.Бакунин: "Кичәге көрәшчеләр, хакимиятне үз кулларына алгач, максудларын түгел, уртак эшләрен дә түгел, бәлки үзләренең төшемле урыннарын саклый башлаячаклар."

Н.П.Огарев: "Җәмгыятькә карата шәхеснең тоткан урынын билгеләүгә без нинди юл белән ирешербез соң? Ә монардан башка безгә алга бару бик кыен булачак, монардан башка безнең буталып калып, хөррият дигән нәрсәне җуеп, шәхесне җәмгыятьтә, коллективта (моны социализм дип атасак та була) харап итүебез һәм уенчык парламентларга, сайлау хокукларына төренгән әлеге дә баягы золымга кире кайтып, янадан кадими тәртипләрне кабатлый башлавыбыз мөмкин."

"Социализм таңында ук фикер ияләре кисәткән нәрсәләр СССРда бөтен тулылыгы белән тормышка ашкан. Мин шәһәр китапханәсендә Герценның 30 томлыгыннан ("Әсәрләренең тулы җыелмасы"!) күпме эзләсәм дә, әлеге сүзләрен таба алмадым, чөнки аларны кыскартып басканнар."

"Завод-фабрика хуҗаларын һәм эре җирбиләүчеләрне экспроприацияләгәч, аннары гади халыкны, крәстиәнне, мәчет-чиркәүләрне, музейларны талаганнан соң, совет системасы табигатьне талау һәм агулау хисабына, ягъни киләчәк буыннар өлешенә кереп яшәгән булып чыкты."

"Сталин алты-җиде тапкыр сөргеннән качкан һәм һәр юлы сәфәре ифрат уңышлы чыккан. Бу качышлы уенны патша охранкасы үзе оештырган дигән фикер дә бар, дөрес, моны расларлык документлар табылмаган. Иосиф Җугашвили үзенә әзме-күпме кагылышы булган барлык материалларны архив-музейлардан чүпләтеп, ахырда юк иткән, эзен яшергән, диләр. Германиядән Франциягә товар ташыганда мин машинама өлкән яшьтәге бер туристны утырткан идем. Ул Россиядән киткән беренче эмиграция вәкиле булып чыкты. Сөйләшә торгач, яна танышым Сталинның "психологик портреты"на нисбәтән үз версиясен тәкъдим итте. Тайга аша бер ялгызын үтү мөмкин түгел. Димәк, революционер "Кобо" бер үзе генә качмаган, берәр кулдаш ияртеп кача торган булган. Аның юлдашы ревоюционер булган булса, бу хакта бер-бер истәлек калыр иде, хәлбуки истәлекләр юк. Димәк, ул үзенә ярдәмчеләрне шундагы криминаль мохиттән, уголовниклар арасыннан эзләгән. Билгеле булганча, тайга аша үткәндә ачтан үлмәс өчен, тәҗрибәле бандит үзе белән "тере консерва", яки, үзләре әйткәнчә, "бозау" ияртә торган булган. Ул беркатлы, наданрак һәм күндәм кешене эзләгән, төрле хәйләләр белән аны котыртып, бергәләп качарга күндергән... Хәстәрләгән ризыклары беткәч, ул үзенең юлдашын үтергән... Без бүген Иосиф Сталинның коточкыч кешелексез-леген, аяусызлыгын, кансызлыгын беләбез. Әлеге танышым фикеренчә, Сталин соңгы кешелек сыйфатларын менә шушы вакытларда ук җуйган булырга тиеш. Чөнки адәм итеннән авыз итүче инде беркайчан да кеше була алмый... Соңыннан, күп еллар үтеп генсек булып алгач, исерек вакытында ул моны хатыны Аллилуевага ычкындырган булырга мөмкин. Аллилуеваның үз-үзен үтерүендә төп сәбәп, бәлкем, шушы булгандыр, диде танышым. Ә бәлки ире соңгы шаһитны үз кулы белән юк иткәндер...

Әлбәттә, болар коры фараз гына, ләкин психологик яктан ул күп нәрсәне аңлатып бирә."

"Большевик житәкчеләргә дә фиргаүннәр чире йоккан—Кызыл мәйданны Мисыр пирамидалары янындагы кебек мәетләр шәһәренә әйләндереп бетергәннәр. 7 ноябрь көнне хәрби парад алдыннан маршал Леонид Брежнев мавзолей трибунасыннан нотык тотты. Көн салкынча, жил иде. Шул кыска гына нотыкны да ана берничә кәгазь битенә эре хәрефләр белән басып биргәннәр, күрәсен. Икенче битне ачкан чагында генсекнын бармагын ялап төкрекләп алуын күрдем дә ихтыярсыздан көлеп жибәрдем. Аннары үз-үземнән оялдым."

"Бөтен ил күләмендә политинформация сабаклары бирелә торган бердәм "политкөн", бөтен ил табынына килька белән хек куела торган бердәм "балык көне»—үсеп житкән социализм казанышлары микәнни? Ә социализмнын аръягында халыкны нинди көн көтә?"

"Иртән электричка белән Казанга килеп төшкән чагымда Сәйдәш маршы аһәннәре астында "Татарстан" поезды Мәскәүдән кайтты. Аннан төшүче пассажирларнын һәркайсында дүртәр-бишәр сумка, бәләкәй арба. "Авоська" дип атала торган ятьмәләрендә алтынсары әфлисуннар, куертылган сөт банкалары, колбаса... Сәфәрчеләрне каршы алырга тагы да күбрәк халык килгән. Мәхшәр... Мәскәүдә бу поездларны "казылык поездлары" дип атыйлар икән, чөнки ярлы провинция көне-төне азык-төлекне башкаладан ташырга мәжбүр. Кыскасы, Мәскәү коточкыч спрутка әйләнгән дә, бөтен илнен желеген суырып ята, күрәсен."

"Мәшһүр стеналар: Олы Кытай стенасы, Берлин стенасы, Туры стена (Айдагы тау)."

"Өлкә комитеты секретаре үзенен бер чыгышында республикабызда кимчелекле балалар күп туа, алар өчен махсус интернатлар төзеп өлгерә алмыйбыз, дигән."

"Мин үземнен Илһам Шакировны ни өчен яратканымны анлап та, анлатып та бетерә алмамдыр. Анын сүзләре һәм фигыльләре Рудольф Нуриевныкы кебек береаз сагайта да, ләкин шушы бер жырчынын самими нечкәлеге хакына татар эстрадасынын барча кимчелекләрен гафу итәсен. Илһам белән Рудольф күктән ингән илаһи аһәннәрне һәм канатлы хәрәкәтләрне, үзләреннән гүзәллек өстәп, тәнре хозурына кире кайтаралар сыман..."

(Блокнотындагы язмага караганда, сонгы көннәрдә Азат Достоевскийнын "Идиот"ын, аннары Хаузернын "Карангыдан килгән Гаспар" дигән китабын укыган. Икесе дә авыр китаплар. Һәлакәтле китаплар... Аларны бер очтан уку—хәерлегә түгел. Чөнки, икесе дә тәжрибәсез сабыйлыктан аяусыз чынбарлыкка кайтып төшкән, юк, кайта алмаган бәхетсез шәхесләр турында. Кыскасы, Азат үзенен күнел төпкелендә нинди көрәш барганлыгын яхшы анлаган, мина сиздермәскә тырышкан гына. Ә мин бит сизә идем, аны ярты сүзеннән анлый идем. Фажига әкрен-әкрен генә өлгерә килгән икән...)

"Ураза бәйрәме көнне Казанга ук барып гает намазы укып кайтучы бер карт белән таныштым. Анын тормыш философиясе галәттән тыш тыныч: "Үлем дә хәят кебек бер нигъмәт итеп яратылган",—диде ул".

П.Буль («Квай елгасы аша күпер»): "Әгәр дә кешене вакытында чын эшкә жикмәсән, ул пыскып янып әрәм була."

Самуэль Джонсон: "Адәмнәрнен барча өметләре юкка гына... Китапханә безне шуна ышандыра."

"Торгынлык. Жил дә исми. Рәсәй үлем исереклеге белән йоклый. "Мерзость запустения", усал Салтыков-Щедрин әйтмешли. Бу торгынлык идарә итүче фирканен ялгышларыннан гына килеп чыгамы икән? Сәбәп совет халкынын, беренче нәүбәттә рус милләтенен картаюында түгелме? Андый теорияләр дә бар. Әгәр, чыннан да, сәбәпнен табигате нигездә биологик тамырлы булса, Ватаныбызнын перспективасы юк. Ә янарыш тыныч юл белән килми."

"Мин бу дөньяга кирәк түгел. Универсум миннән башка да яши ала."

(Мин боларны Азатның үз сүзләре дип кабул иттем.

—Юк, синсез галәмнең бер почмагы китек, Азат!—дип кычкырам мин бүген.

Әйе, Азат барыбер кирәк бу дөньяга. Азат безнең хәтеребездә яшәгендә шайтани шәхесләр хакимият башына менә алмаслар, бәлки. Сез безне пакълисез, шәһит китүчеләр. Алла безне сезнең кебекләр аркасында гына ярлыкаса ярлыкар!)

Дәфтәренең соңгы битләреннән берсенә Азат: "Без әүвәлге тормышыбызда Илдар белән игезәк балалар булмаган идек микән?"—дип тә язып куйган.

"Игезәкләр дә бер-берсеннән аерылуны бик авыр кичерәләр, имеш. Сабый чакларында ук аерылып һичбер элемтәсез төрле гаиләләрдә тәрбияләнгән игезәкләр арасында аңлаешсыз психофизиологик бәйләныш гомер буена саклана, алар бер үк вакытларда, бер үк авырулар белән авырыйлар, охшаш профессия сайлыйлар, бер үк вакытта өйләнәләр, хәтта еш кына сайлаган җефетләренең исемнәре дә бер булып чыга икән. Кыскасы, алар Сиам игезәкләре кебек бер-берсенә бәйләнгән булалар.

Галәмнәр белән бергә адәмнәр дә бер-берсеннән ераклашамы? Шулай да булсын, ди, доктор Клейн. Ләкин игезәкләр бу канунга буйсынмый. Игезәкләрне ерак аралар да, ерак дәверләр дә аера алмый. Игезәкләр бер-берсеннән киселмиләр."

Блокнотны актарган чагымда мин Ишембаевлар Азатны юкка гына күзәтмәгән, дип тә уйладым. Демократиядән авыз иткән кешенең реаль социализм шартларына күнегә һәм җайлаша алуына алар ышанмаганнар һәм беркайчан да ышанмаячаклар. Асылда алар хөр фикерле бер генә кешегә дә ышанмыйлар. Алар—Сталин шәкертләре. Алар—Иблис куштаннары. Дәүләт дигән ирексезләү коралы алар өчен иң югары хакыйкать һәм шул ук дәүләт дигән нәрсә аларга савым сыер булып хезмәт итә. Дәүләт аппараты булмаганда, алар чарасызлар, ягъни бернигә сәләтсез бичаралар.

Их, Азат, Азатым... Балачак дустым, сәйдәшем... Нинди авыр йөк, моң һәм сагыш йөкләп киттең син миңа, Азат Сәйдәшев. Бу йөкне ничек күтәрим дә кайда илтеп бушатыйм күңелемне? Мине аңлар игезәкләрем кайда?

* * *

Автобазаның кадрлар бүлеге мөдире Бикбау ага, чыннан да, әйбәт кеше булып чыкты. Артык сораулар яудырып маташмады, һәм без бик тиз уртак тел таптык. Азат Сәйдәшев каберенә чардуган һәм таш кую турында монда да уйлашканнар. Бу эшне бухгалтер ярдәмчесе булып эшләүче Галия ханымга тапшырганнар, чөнки Галия ханым де-юре булмаса да, де-факто һәм, һич югында биредәгеләр өчен, Азатның җефете булып исәпләнә икән. Бикбау аганың тел төбеннән аңлашылганча, администрация Азатның квартирасын Галия ханымга алып бирү турында да эш йөртә башлаган. Дөрес, бу хакта Галия ханым үзе белми дә булыр.

Бикбау ага мине бухгалтер ханым белән таныштырырга дип урыныннан кузгалса да, мин аны туктаттым:

—Хәзергә кирәкми...—дидем, чөнки, турысын әйткәндә, мона мин, гомумән, әзер түгел идем. Мин Азат Сәйдәшевны башка беркем белән дә бүлешә алмый идем...

Бикбау ага миңа бик игътибар белән карап куйды да:

—Ихтыярыгыз...—диде.—Алайса болай итик. Бер айдан сез туры миңа шылтыратыгыз, сез әйткән вакытка һәм тиешле урынга йөк машинасы җибәрербез, бөтенесен бер көн эчендә хәл итәрбез... Үзегезнең координатларыгызны калдырсагыз да әйбәт булыр, каршы түгелсездер бит?

Мин каршы түгел идем. Телефонны да бирдем.

Автобаза идарәсеннән чыккач, ишегалдындагы "Мактау тактасы"на игътибар иттем. Аннан кемнендер беренче рәттәге фоторәсемен куптарып алганнар да урыны хәзергә бушап калган иде. "Акуловныкыдыр,"—дип уйладым мин битараф кына.

Капка төбендә жимерек автобус та күренмәде. Ихтимал, аны кабат ремонтлый торганнардыр.

Азатның каберен зират кылырга кердем. Анда яңа чәчәкләр күргәч, үземне ниндидер каршылыклы, көнчел һәм бик үк гадел булмаган хисләр биләп алды.

Азат ышанып тапшырган кассеталарны эшкәртеп, негативларын алуга, аннары үземнең хан заманасыннан калган фотозурайткычым ярдәмендә Азатның игътибарын жәлеп иткән һәр кадрны күздән үткәреп, язмалары буенча фотосурәт алынган урынны һәм көнне билгеләүгә атнадан артык вакытым китте. Мин бу эшне бик жентекләп башкардым, чөнки фоторәсемнәр миндә туган кайбер сорауларга жавап та бирделәр. Азат Раифа тыюлыгындагы ярымтайгада, Идел һәм Зөя буйларында, Ослан тавында булган, хәтта Кама тамагына да барып чыккан иде. Һәркайда ул табигатьнең гүзәл бер почмагын, нәфислеген тапкан, шундагы кыргыйрак аланны, онытылган чишмәне, сөрелгән басу уртасында калган ялгыз наратны чын сәнгатькяр генә белгән алымнар кулланып сурәтләүгә ирешкән... Мина шунысы мәгълүм булды: иң гүзәл кадрларны Азат бөтенләй икенче, галиерәк фотоаппарат белән һәм төсле итеп түгел, бәлки аклы-каралы тасмага төшергән иде. Димәк, еш кына өстәмә бизәкләр һәм төс фотосәнгатькә комачау итә... Сәнгать чук-чачакларга мохтаж түгел. Сәнгать "әйе" һәм "юк"ны гына белә, катлы-катлы фикри гыйммраннар ана килешми.

Азат жанлы табигатьне төшерү белән мавыкмаган. Шулай да күзенә чалынган пошый һәм тиеннәр игътибардан читтә калмаганнар, ә бер рәсемендә агач төбендә саескан каурыйлары тузгып ята иде. Ишеткәнем бар: картаймыш көнендә әжәле житкәч, саескан агач ботагына менеп кунаклый, ә ачкүзле кардәшләре аның егылып төшкәнен шул тирәдә түземсезләнеп көтеп утыралар икән... Хәер, кем белә, бәлки каннибализм аларда үзенә бер төрле ритуалдыр, йолалыр?

Аклы-каралы рәсемнәрнең соңгы икесендә су уртасында утырган почык пирамида—Казанны яулап алучылар истәлегенә корылган һәйкәл һәм тау башында көнбатыш авыннан ычкынырга омтылган мәхбүс Жәлил фигурасы... Аерым-аерым килеш уртакулдан узмаган иҗат жимешләре, ә менә икесе янәшә килгәндә бу сурәтләр татар кешесен ыңгырашырга мәжбүр итә.

Мин фотолар арасында Галия ханым рәсеме дә очрар дип көткәнмен икән. Юк, Азат аны фотога төшермәгән. Мин, ничектер, бу ханымны күз алдыма китерергә тырышып карадым, ләкин күңел көзгем буш иде.

Өйдә Сәйдәшевләр сәгате суккан саен сискәнеп китә идем, тора-бара әллә күнектем, әллә үз-үземне жиңеп, сәгать тавышында тормышчан аһәннәр дә таба алдыммы—ул сукканда күңелемә жылы хатирәләр ташкын булып иңә, өмет уята, жилкендерә башлады...

Минем Азат рәсемнәреннән фотоальбом төзеп утыруларымда бер-бер мәгънә бар идеме соң? Бу эшнең кирәге чыгармы? Файдасы? Мин үземә мондый сорау биреп маташмадым. Күңел төбемдә мин ниндидер бер могжизага ышана идем. Ничә еллар үткәч Азатны табып кабат югалтканнан соң, мин, әзрәк хорафатка да бирелеп, үземнең күргән төшләремә дә игътибар итә башладым бугай.

Башта ук уйлаганыбызча, бер айдан Азат каберенә таш куйдык. Автобазага аеруча күңелем булды: транспорт белән дә, кешеләр белән дә тәэмин итте.

Һәйкәлне урнаштырып, инде жил-яңгырдан төсләре киткән венокларын әйбәтләп сөяп куйгач, ярдәм итешүчеләргә рәхмәт белдереп, өлкәнрәгенә акча суздым. Ул:

—Без, абый кеше, акча өчен дип килмәдек-килүен...—дисә дә, хәердән булганга күрә, бишлекләрдән баш тартмады.

Мин егетләргә тагын рәхмәтләр яудырып, рәхмәтемне автобаза администрациясенә дә тапшыруларын үтендем.

Инде зират капкасы янында саубуллашкан вакытта егетләрдән берсе:

—Сез Сәйдәшевнең кеме буласыз, туганым?—дип кызыксынды.

Мин:

—Азат Сәйдәшев—минем балачактагы күршем, классташым һәм дустым!—дип тотырып җавап бирдем.

—Алайса, сезнең үзегезгә рәхмәт! Мин, бирган булса, Сәйдәшевка дигән яңа автобусны йөртәчәкмен, Яшел Үзәнгә юлыгыз төшсә—рәхим итегез!

—Рәхмәт!—дидем мин бу игелекле җанга.—Рәхмәт... Кем белә, бәлки утырырга да туры килер... Һәрхәлдә мин бу зиратка килеп йөриячәкмен.

—Изге кеше иде, мәрхүм,—диде өлкәннәре, уйчанланып.—Утны-суны кичкән һәм кешелеген саклап калган дип сөйлиләр. Шуңа дуслары да онытмый торгандыр...

Азатның хезмәттәшләре кафега сугылырга кыстап караганнар иде, мин, гафу үтенеп, баш тарттым. Минем Азат Сәйдәшев белән икәү генә ялгыз каласым килә иде.

* * *

Өч ел узды.

Табигать кушканча, өч елга олыгайдым, әмма хәзер мин үземне элеккедән сәламәтрәк хис итәм сыман. Чөнки мин бүген Азат өчен дә, бу дөньяда Сәйдәшевләрнең вәкиле буларак та яшәргә тиеш идем.

Ашыкмыйча гына, Сәйдәшев турындагы истәлекләремне тәртипкә китереп, кәгазьгә төшергәли башладым. Каләмем килеп төртелгән чакларда мин, иелеп, аяк астында уралып йөргән Музгарканы сыйпап алам да, маэмайның тугрылыклы күзләренә карап:

—Ничава, бәләкәч...—дим.—Без җиңәлмәгән дошман тумаган!

Ул минем белән килешә.

Атна урта мәктәбе укытучысы Маликов белән хат алышабыз, күрешеп тә сөйләшәбез. Мин аңа Атна авылына нисбәтле кайбер фактларны табыштым һәм тора-бара авылның тарихы, аның аеруча эз калдырган кешеләре белән тәмам кызыксынып киттем. Ике тапкыр Атнада булып, кешеләре белән очрашып, балачактан калган тәэсирләремне яңарткач, шуңа ышандым: бу авыл мине үгисетми, "улым" дип әйтеп, кочагына алырга әзер... Шул рәвешле, мәрхүм Азат миңа нигеземне, туфрагымны табарга булышты.

Тарих белән шөгыльләнә башлагач, мин университет обсерваториясенә каршы почмакта урнашкан "Букинист" кибетенә ешрак сугылгалый торган булдым. Анда мине күптән беләләр, ишектән керүемә үк ачык чырай белән каршы алалар иде. Кибет бинасы бик иске, кысан, тәбәнәк, яртылаш җиргә сеңгән, хәтта уртасына тимер багана куярга мәҗбүр булганнар. Аның каравы биредә, башка кибетләр белән чагыштырганда, демократия күбрәк, "блат" азрак (барын-бар инде!). Кайчагында чын мәгънәсендәге уникаль басмаларны шушында очратасың һәм чиратсыз аласың.

Ялгышмасам, НЭП елларында бу тирәдә ниндидер бер яһүд карты "харчәүнә" кебегрәк нәрсә тоткан. Такташлар аны "Теремок" дип атап йөрткәннәр, еш кына шунда тамак ялгап чыкканнар, өстәвенә яһүд эшмәкәре татар сәнгатькярләрен, кесәләрендә җил уйнаган чакта, кәтәчәккә ашаткан да бугай. Йорт номерлары туры килмәсә дә (берсе—так, берсе—җөп), мин нигәдер "Теремок" шушы бәләкәй кибет урынында булгандыр дип күз алдыма китерә идем. Менә бүген дә "Букинист" кибетенә килеп кергәч, үземнән яшьрәк Такташ очрар сыман тоелды. Әкәмәт, мин аңа кем дип эндәшергә тиеш булыр идем? Һади дип кенәме? Юк, телем бармас иде. Такташ үзе дә, тишек ботинкасына карап: "Син, брамат, аптырама. Фәкыйрьлек сәнгать әһелен түшәмгә төкереп ятмаска өйрәтә, һич югында гөнаһлы җир улларына якынайта. Гомер-бакыйга шулай булган һәм шулай

була бирсен. Ярлылык—сәнгатьнен анасы, ә атасын шайтан да белми...,"— дияр иде.

Букинистлар белән сөйләшенеп, татар тарихына караган искерәк китапларны минем өчен калдырып торырга дигән килешүебез бар иде. Нәкъ шушы елны кибетчеләргә халыктан гарәпчә язулы һәм дини китапларны да комиссиягә алырга рөхсәт иттеләр. Итүен иттеләр, әмма бик тиз тыйдылар да. Чөнки андый китап белән кызыксынучылар һич тә көтмәгәндә артык күп булып чыкты. Халык чын дөреслеккә, иманга сусаган, тынчу һәм әхлаксыз торгынлыктан туйган иде... Ләкин, кем әйтмешли, чүлмәктән бер ирекка чыккан гыйфритне кире куып кертеп кара ди син! Букинист Валентина Андреевна, төрле сылтаулар табып, татарча иске китапларны да өстәле астында тотып тора һәм квитанция тутырганда аларны "Төрле китаплар" дигән гомуми юлга, "уптым илаһи" гына кертә торган иде.

Китап кабул итә торган почмак сату залыннан шкаф белән генә аерылганга, андагы сөйләшүләр аермачык ишетелеп тора.

Шкафның пыяла ишеген ачканчы ук, утызынчы елларда Мәскәүдә нәшер ителгән "Әдәби энциклопедия"нең баштагы өч томына күзем төште. Китап сөючеләргә хас дулкынлануым юкка гына булмаган икән. Бу томнар кайчандыр Такташ сатып алган китаплар булып чыкты. Икенче томының титул битендә өске сул як почмакка латин хәрефләре белән кыеклап "Такташ" дип язылган, ә көрән төстәге форзацында инде гарәп хуруфатында Такташның икенче хатыны Гөлчәһрә ханымның, шулай ук кызыл кара белән, хисләнеп язган язуы бар иде. Анысы утыз икенче елның 19 нчы гыйнварына карый. Гөлчәһрә ханым, зәңгәр күзле Һадиының вафатына бер ел тулгач, улы Аванны тезенә утыртып язган татлы да, сагышлы да сүзләр... Бу мизгелдә Такташның беренче хатыны Хәмзина Гөлчәһрә һәм Такташ үлеп яраткан уллары Рафаэль кайда иделәр микән? Пырдымсыз Хәмзина Һадины никадәр рәнжеткәнен аңлаган идеме икән әле? Һади, ике Гөлчәһрә, ике угыл... Бер төенгә төйнәлгән биш язмыш... Бу төен мәңгелек, аны Такташның үлеме дә чишә алмаган.

Энциклопедия томнарының кибет киштәсенә ничек кабат килеп эләгүе турында сөйләп тормамдыр, ләкин Валентина Андреевнадан сорашып, мин бу мәсьәләне ачыкладым, әлбәттә.

Күп уйлап тормастан, аксыл металлдан сырлап эшләнгән борынгы, матур касса аппараты янына акча түләргә киләдем. Куанычым йөземә чыккандыр, күрәсен, яшь кенә кассирша:

—Әйбәт китапка юлыктыгыз, ахры,—дип елмайды.

—Әйе, бик һәйбәт китаплар таптым...—дидем һәм ирексездән авыр сулап куйдым.

Шул чагында китап кабул итү бүлмәсеннән спортчы кыяфәтендәге берәү чыкты. Әле генә Валентина Андреевна белән шыпыртын, юмакайланып сөйләшкән кеше. Мин хисләремне яшерә белмим, күзкарашым аны өтеп алды булса кирәк, ул авызын ачып япты да, бер мизгелдә мәгърүр төсен җуйды.

Ишембаев иде ул.

Димәк, Пәрвез җепләре монда да килеп җиткән.

Ишембай китаплар актарып маташмады, бәладән башаяк дип ахры, кисәк кенә кул сәгатенә карап алган булды да, пыяла ишеккә борылды.

Букинист ханым белән аның ни йомыш йомышлап йөрүе турында сүз куертмаска, төпченмәскә булдым. Шайтан белсен, бәлки, чыннан да китапка гашыйктыр, библиофилдыр? Мәхәббәт бирәүне дә аямый бит. "Шикләнәсен икән—төпченмә",—дигән ди пәйгамбәр.

Мина, танышлык буенча, тагын бер кыйммәтле китап—татарның иң асыл заты Шиһабетдин Мәрҗанинен туына йөз ел тулу уңае белән 1915 елда Казанда басылган хатирәләр мәҗмүгасе калдырылган иде. Монысы өчен мин аеруча сөенде, хәтта Ишембаевның алтын тешен күргәч купкан ачуларым таралып китте.

Шулай итеп, мин бүген Такташның үзе белән, аннары Мәрҗани

хәзрәтләре белән очраштым дияргә була. Бер-берсенә капма-каршы кебек булсалар да, калебләре затлы һәм саф матдәдән яратылганга, мин аларны күнелемдә дошманлаштырырга тырышмыйм.

Өйгә кайтышлый, трамвайга утырып, Ирек мәйданыннан үттем. Миннән арттагы утыргычта ике татар хатыны, әйләнә-тирә дөньянын колагы бар икәнен онытып, быдыр-быдыр сөйләшеп бардылар. Башка чарам булмагач, аларга ияреп, чирек сәгать эчендә бөтен шәһәрне айкап чыктым. ул вакытта бик дефицит исәпләнгән келәм һәм хрусталь бәяләрен белдем, аннары импортный кара ванна турында гәп куерттык. Фәләннәр тагы яна фатирга күчкәннәр, ә фәләннәрнең улы наркоман икән... Теге "Победа" кинотеатрына каршы яшелчә кибетенен директрисасы асылынып үлгән икән. Өендә стенасына унар кат ковер элгән булган, ышансан—ышан, ышанмасан—юк. Фәләнгә операция ясаганнар, унышсыз чыккан, өмет юк дигәннәр...

Колагыма таныш сыман фамилия чалынгач, күчеп утыру уеннан кире кайттым. Байчурин... Әйе, Сәйдәшевләрне Сталин җәһәннәменә озатышкан бәндәнен фамилиясе сагайтты мине. Байчурин дигән бераү, картаймыш көнендә карчыгын өеннән куып чыгарып, Ирек мәйданы тирәсендәге "сталинка" йортында ике бүлмәле фатирында ялгыз гына калган. Алланын фәрманы кыска—төнлә паралич сугып, ун көнләп урын өстендә берүзе яткан бу, күршеләре дә абайламаган... Персональный пенсиясен китергәч кенә шау-шу кубарып, ишеген ватып керсәләр, жан тәслим кылган була инде бичара. "Бичарасын бичара, ләкин карчыгына утыз жиденче елны үз кулы белән унтугыз кешене атып үтерүе турында ычкындырган булган, низаглары да шуннан чыккан, имеш...,"—дип сөйләде әлеге хатыннарнын берсе, аеруча хәбәрдары.

Өйдә мине, гадәттәгечә, биниһая куанган Музгарка каршылады. Көн эссе булганга, бер камыр стакан морожный алган идем. Үзем өчен түгел, чөнки мин ангинадан интегәм. Имештер, Искәндәр Зөлкарнәин уйлап тапкан бу ризыкны Музгарка ашыкмыйча, ләззәтен сузып кына, телен салкын куырып алганга ял итә-итә, ялап бетерде. Акылы бар, артыгын сорамый ул. Биргәненә канәгать.

Яна китапларымны актарып, ялгыш бөкләнеп калган битләрен тырнак белән ышкып тигезләп чыккач һәм китапларны сөеп-сыйпап туйгач, аларны киштәгә дәрәҗәле урынга, үз ишләре янына куйдым.

"Густав Беккер" моңлы тавышы белән өчне сукканда телефон шылтырады. Музгаркам да, аларга кушылып, мине ашыктыргандай, түземсез өн биреп куйды.

Бүгенге көн тагын бер сюрприз әзерләгән икән.

Мина Яшел Үзәннән Бикбау ага шылтыратты.

Башта жайлап кына исәнләште, хәл-әхвәлләрне сорашты, иҗат унышларым турында белешергә дә онытмады. Әдәби журналда "Күрешү" дигән хикәямне укыган икән, аны да телгә ялды. Аннары гына:

—Минем бит сезгә бер үтенечем бар, Илдар Хәлилович,—диде.— Шәхси үтенеч... Хәер, шәхси генә дә түгел, күмәк үтенечебез...

—Тынлыйм, Мирсәет ага.

—Хәтерлисез микән, Сәйдәшев вафат булгач, анын... жәмәгате Галия ханым турында сүз булган иде.

—Әйе.

—Бүгенгесе көндә Галия ханымнын ике яшь ярымлык кызы бар. Искиткеч матур, чая бала... Галия бер ел чамасы аны карап өендә утырды. Хәзер кызы бакчага йөри, әнисе байтактын эшкә чыкты инде... Тынлыйсызмы?

—Тынлыйм. Бик игътибар белән тынлыйм...

—Бала тирә-юнь белән кызыксына башлаган, инде хәреф танып маташа... Галия ханым кызын әтисе Азат Сәйдәшевнен зиратына алып баргалый икән. Алар анда ике букет чәчәк куеп кайталар.

—Әйе, ул чәчәкләрне күрәм мин...

Тамагым карлыкканга, сүздән туктап тордым. Ниһаять:

—Баланың исеме Ганжә түгелме?—дип сорый алдым.

—Ганжә? Юк, Ганжә түгел. Чәчкә.

—Чәчкә? Әлбәттә, Чәчкә! Ганжә бөресе, ачылып, Чәчкә була... Мин сезне тыңлыйм, Мирсәет ага, бүлдергәнем өчен гафу итегез, зинһар.

—Озын сүзнең кыскасы, мәсьәлә шунда: Чәчкә, әтием кем иде, туганнары һәм дуслары кайда, дип сораша башлаган... Хәзерге бакча балалары бик тиз өлгерәләр бит... Галия ханым, аптырагач, Казанда әтиеннең бик якын дусты яши дип әйтеп ташлаган, ә бала моны күңел төбенә салып куйган. Аңлыйсызмы?

Кадрлар бүлеге мөдире, минем ни әйткәнемне көтеп тормыйча, сүзен дәвам итте:

—Безнең бухгалтерия хатыннары бу хакта олы бер "киңәшмә" оештырганнар. Ышанасызмы, берсе мондый хыялый тәкъдим керткән: "Әйдәгез, берәр оста артист белән сөйләшик тә, ул Азат Сәйдәшевнең дусты ролен менә дигән итеп башкарыр,—дигән.—Киләчәктә барысы да ачылыр, әлбәттә, ләкин ул вакытка бала үсә төшә, аңласа да фаҗига булмас",—дип, фикерен дәлилләп маташкан...

—Юк!—дидем мин кинәт.—Юк, ничек инде мин үз ролемне ниндидер Кыш бабайга ышанып тапшырыйм? Шаяртып әйтүем түгел. Азат Сәйдәшевнең дусты берәү генә. Сез бит моны бик яхшы беләсез, Мирсәет ага.

—Беләм. Шуңа шылтыратам да.

Калганнары турында без тиз килештек. Ул Галия ханым белән сөйләшә дә, алар минем "визит" көне турында уйлашалар. Бикбау ага менә алдагы якшәмбене билгеләргә киңәш итте. Бу көнне без аның белән икәүләп Чәчкә Сәйдәшеваны күрергә барачакбыз. Аннары инде, ни язган булса—шул.

Һәрхәлдә "Густав Беккер"га да, Азатның блокнотына, эскизларына һәм фоторәсемнәренә дә табигый варис, чын хуҗа үсә дип куандым мин. Кем белә, бәлки Чәчкә әтисе эзеннән барып, миңа билгесез булып калган нәрсәләрне дә эзләп табар әле...

Мин генә түгел, ни тыйнак Музгарка да, үзенә яңа дуслар буласын сизгәндәй, дөнья бетереп чабып йөрде.

Әлбәттә, монда бернинди мистика юк—Музгарка минем күңелемдәгенене сизә ул.

НӘНИЛӘРГӘ БАГЫШЛАНГАН ИҖАТ

Балалар язучысы, шагыйрә Мәрзия Фәйзуллина—Мәрзия Низам кызы Фәйзуллина (Тәрҗеманова) 1930 елның 11 июнендә Арча районының Шушмабаш авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлагач, Казанга килә, төрле оешмаларда эшли. Илленче елларда яза башлап, 1955 елда мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен «Салават күпере» исемле беренче китабы басылып чыга. 1956 елдан башлап ул балалар бакчасында тәрбияче-педагог булып эшли, нәниләр дөньясына тагы да якыная; нәтиҗәдә алар өчен «Чәчәкләр сәгате», «Ике көрәк», «Зур дулкыннар» һ. б. китаплары дөнья күрә. 1958-1964 елларда шагыйрә читтән торып Мәскәүдә М. Горький исемендәге Әдәбият институтында укып, аны тәмамлый. СССР Язучылар берлегенә кабул ителә (1965). Бу елларда аның «Детгиз», «Малыш» кебек нәшриятларда, русчага тәрҗемә ителеп, «Цветочные часы», «Стихи», «Пропала кошка» исемне китаплары басылды һәм алар турында язучы С. Баруздин, тәнкыйтьче В. Дементьевларның «Наш современник», «Октябрь» журналларында мәкаләләре дә дөнья күрде, РСФСР Язучыларының икенче съездында А. Бартоның балалар әдәбияты турында докладында да иҗатына матур бәя бирелде...

Хәзер М. Фәйзуллина—егермегә якын китап, көндәлек матбугатта күренә килгән кызыклы публицистик мәкаләләр, чыгышлар авторы, озак еллар әлеге балалар бакчасында эшләп, нәниләрнең якын дустына әйләнгән шагыйрә. Зур юбилее белән котлап, укучыларыбызга бу санда М. Фәйзуллина иҗатыннан кайбер үрнәкләр тәкъдим итәбез.

Мәрзия Фәйзуллина

Кыш бабай

Җилкәсенә капчык асып,
Кыш бабай килеп керде,
Төрле кызык сүзләр әйтеп,
Бүләк өләшеп йөрде.

Аннан Кыш бабай тыпырдап
Бик шәп бии башлады.

Биемәскә, аягында
Безнең апа башмагы!

Суган тураганда

Ашка салырга суганның
Сайлап алдым олысын.
Әрчи башлагач еладым,
Килмәсә дә елыйсым.

Күзгә керә әчесе,
Ничек кенә әрчисе!

Әрчүен әрчедем инде,
Эшнең бетте зурысы,
Пычак белән вак-вак итеп
Калды аны турыйсы.

Ашка суган турыйм мин,
Көлә-көлә елыйм мин!

Каюлы читек

Әти алган бүләк итеп
Миңа каюлы читек.
Сабан туйда күрсәтермен
Тыпырдап биеп китеп.

Бу читекне һәрбер кеше
Күреп исе китәчәк.
Балтырлары—яшел болын,
Бизәкләре—күк чәчәк.

Һәр адым атлаган саен,
Шыгыр-шыгыр итә ул.
Тик кузгатып кына җибәр,
Үзе биеп китә ул.

Чебиләр

Тышта бик җылы булса да,
Тун кигәннәр чебиләр.
Яңа гына тусалар да,
Йөгерешеп йөриләр.

Эремчек, тары ярмасы,
Суалчан яраталар.

Суалчан дип ботинкамның
Бауларыннан тарталар.

Көш-көш дигәч, китсәләр дә,
Тагын килеп тарталар.
Тарта-тарта ботинкамның
Бауларын чуалталар.

Күл буенда

Суны көзге итеп карый
Яр буенда таллыклар.
Бер-бер артлы сикреп чыга
Су өстенә балыклар.

Алар: сез күлгә чумсагыз,
Безгә һава—күл, диләр,
Алтын кояш нурларында
Коенырга телиләр.

МИЛЛИ СӘЯСӘТ ҺӘМ МИЛЛИ МАТБУГАТ

ТАТАРСТАННЫҢ ДӘҮЛӘТ СУВЕРЕНИТЕТЫ ТУРЫНДА ДЕКЛАРАЦИЯ КАБУЛ ИТЕЛҮНЕҢ 10 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП

РОССИЯНЕҢ, аның составындагы милли республикаларының, аз санлы милләтләрнең һәм халыкларның тарихи үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында фикер йөрткәндә милли сәясәт проблемасын һич төчитләтеп үтеп булмый. Бу аңлашыла да, чөнки Россия кебек күп милләтле дәүләтнең үз территориясендә яшәүче һәр халыкны саклап калуны һәм үстерүне күздә тоткан милли сәясәте булуы зарур.

Милли сәясәт төшенчәсе асылда бик күп принципларны эченә ала. Шуларның иң мөһиме—башка кешеләрнең һәм милләтләрнең мәнфәгатьләренә зыян китермәгән хәлдә, аерым шәхеснең дә, тулаем конкрет этносның да милли ихтыяҗларын үз вакытында һәм мөмкин кадәр тулырак канәгатьләндерү.

Патша самодержавиесе һәм совет дәүләте рус булмаган халыклар өчен мондый шартларны тудырмады гына түгел, киресенчә, аларның милли үзаңын томалап килү өчен нык тырышты. Казанны яулап алганнан соң үз дәүләтчелеген югалткан, әмма аны кире кайтару, яңадан торгызу өчен күп тапкыр баш күтәргән татарларга карата Россия аеруча шикләнеп карады һәм кырыслык күрсәтте. Шуңа күрә дә патша самодержавиесе эзлекле рәвештә татарларның мәнфәгатен кысу сәясәте үткәреп килде, көчләп чукындыру юлы белән ассимиляцияләүгә ирешергә омтылды, мөселманнарга Россиянең югары һәм профессиональ уку йортларында укуны тыйды, мәктәпләрне һәм мәгърифәт учреждениеләрен тоту өчен акча бирмәде. Кыскасы, татар халкының икътисадый һәм мәдәни үсешен тоткарлау өчен күп тырышлык куйды. Шуны гына әйтү дә җитә: татар һәм рус халыкларының алдынгы карашлы вәкилләре татар телендә вакытлы матбугат булдыру өчен 100 ел буе көрәш алып бардылар.

Чит ил тарихчылары билгеләп үткәнчә, Европада патша самодержавиесе үз территориясендә яшәүче халыкларны ассимиляцияләүгә омтылучы бердәнбер дәүләт була. «Бу сәясәт Казан татарларына карата чагыштырмача уңышлы кулланыла...» (Беннигсен А. Россия мөселманнары. Панорама-Форум, 1995, № 3).

Ассимиляцияләү алымнарыннан тыш патша самодержавиесе милли яшәешне басып тору һәм оныттыру өчен башка төрле алымнар да

кулланды. Халыкның тарихи үткәнен оныттыру, башка төрки халыклар белән аралашуын чикләү юнәлешендә аеруча нык эш алып барылды.

Бу исә, үз чиратында, татарларның аңында кимсетелгәнлек, үзләрен икенче сортлы милләт итеп тою хисе тудыра, аларга кол психологиясен сеңдерә килде.

Бөек Октябрь революциясеннән соңгы ун елда хәл бераз үзгәрә. Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелгәч, республика хөкүмәте мәгариф, сәламәтлек саклау һ. б. мәсьәләләрне Мәскәүдән бәйсез, мөстәкыйль рәвештә хәл итә башлагач, милли мәгариф, культура-агарту учреждениеләре челтәре киң җәелеп китә. Сәяси һәм административ аралашуда татар теленең роле күтәрелү, милли кадрлар тәрбияләүне даими игътибар үзәгендә тоту милләтнең, аның икътисадының һәм мәдәниятының үсешенә зур йогынты ясый.

Әмма егерменче еллар уртасында бу процесс туктатыла. Совет хөкүмәтенең империячел сәясәте революциягә кадәрге чордагы ысуллар белән алып барыла башлый. Биредә татарларны аеру, бүлгәләү ысулы бик оста кулланыла. Бер ярым миллионга якын татар Башкортстанга кертелә, байтагы Ульяновск, Куйбышев, Горький өлкәләренә, башка төбәкләргә бүленә. Нәтиҗәдә татарларның дүрттән өч өлеше Татарстаннан читтә булып чыга. Кыска гына вакыт эчендә ике тапкыр алфавит алмаштыру да милли аң үсешенә зур зыян сала.

Территория ягыннан чикләү халыкны милли тарихыннан аеру белән бергә алып барыла. Тарихчы Д. Исхаков фикеренчә, 1940 елдан башлап соңгы вакытка кадәр «Татар галимнәренә Алтын Урда темасы буенча эшләү тыела иде», «Совет чорында СССРда татар ханлыклары тарихы бөтенләй өйрәнелмәде». (Исхаков Д. Татар ханлыкларының этносоциаль структурасы мәсьәләсенә карата (XV-XVI гасыр урталарында Казан һәм Касим ханлыклары мисалында). Панорама-Форум. 1995, № 3). Утызынчы еллардан, бигрәк тә Бөек Ватан сугышыннан соң ассимиляция процессы аеруча көчәйде. Татарстан һәм Башкортстан шәһәрләрендәге татар мәктәпләре ябылды, өлеге республикалардан читтә чыгып килгән һәм сугыш вакытында ябылып торган татар газеталары яңадан торгызылмады. Милли автономияләрдә чыккан балалар газеталары һәм журналлары Бөтенсоюз каталогына кертелмәде. Болар барысы да милләтнең дәрәҗәсен төшерүгә китерде. Татар теленең, мәдәниятының, милли үзенчәлекләрнең бөтенләй югалу куркынычы туды.

Сиксәненче елларның икенче яртысында башланып киткән демократик үзгәртеп корулар иҗтимагый аңның уянуына, инде сүнеп бара торган милли хисләрнең яңадан кабынып китүенә уңай йогынты ясады.

Казандагы һәм төбәкләрдәге Татар иҗтимагый үзәкләре (ТИҮ) һәм алар нәшер иткән газеталар бу нисбәттән туплаучы һәм юнәлеш бирүче көч булдылар. Самара татар иҗтимагый үзәгенең «Бердәмлек» һәм Ульяновск үзәгенең «Өмет» газеталары Россиядә һәм татарлар күпләп яши торган Үзбәкстан, Казакъстан кебек БДБ илләрендә татар телендәге массакүләм мәгълүмат чаралары системасын яңадан торгызу процессын башлап җибәрделәр. Хәбәрдарлык шартларында матбугатның әһәмияте һәм йогынтысы нык артты. Шуңа күрә татар иҗтимагый үзәкләре һәркайда үз газеталарын булдырырга омтылдылар. Бүген аларның саны Россия төбәкләрендә генә дә егермедән артып китә.

Бу елларда республика матбугаты шулай ук җитди үзгәрешләр кичерде. Бу барыннан да элек шуның белән аңлатыла: журналистлар элек тыелган темаларны калку итеп күтәрү мөмкинлеге алдылар. Биредә шунысы аеруча мөһим: матбугат битләрендә милли үзаң тәрбияләүнең, тарихи хәтерне яңартуның үтемле алымнары киң кулланыла башлады.

Милләт язмышы, аның теленең, мәдәниятының халәте белән кызыксынуга игътибарның артуы республиканың дәүләт статусын күтәрүгә юнәлтелгән гамәлләр эшләүгә этәрүче көч булды. Үз милләтенең үзенчәлекләрен хөрмәт иткән, үзенең башкалар белән тигез хокуклы булырга таләбенең гаделлеген аңлаган халык кына үзенең югалткан дәүләтчелеген яңадан

торгызу кебек гаять катлаулы мәсьәләне хәл итүдә республика җитәкчелегенең, милли хәрәкәт лидерларының ныклы таянычы була ала. Шуңа күрә дә матбугат дәүләтчелекне торгызу өчен көрәшне нәкъ менә милли рух тәрбияләүдән, милли үзаңны күтәрүдән башлады да.

Элек коммунистик идеология биләп торган һәм илдә демократик үзгәртеп корулар башлангач хасыйл булган бушлык озакка бармады, татар телендә чыга торган матбугатта ул урынны тиз арада милли яңарыш идеясе биләп алды.

Вакытлы матбугат бу теманы яктыртуны берничә юнәлештә алып барды. Шуларның беренчесе—милли рухны уяту һәм көчәйтү темасы иде. Халыкка чын тарихны күрсәтүне күздә тоткан материаллар бастырып, газета-журналлар үз алларына ике максат куйдылар: беренчедән, үзләренең укучыларын элек тыелган фактлар белән таныштыру; икенчедән, халыкны милләтнең килеп чыгышы турында бер идея тирәсенә туплау иде. Элек исемнәре тыелган күренекле шәхесләр турындагы, борынгыдан килгән йолаларыбызны, гореф-гадәтләребезне саклап калу һәм үстерүгә кагылышлы язмалар да шул максатларны күздә тотты. Икенче зур юнәлешне татар теленә, аның статусын үзгәртүгә, аны дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрүгә, мәдәниятыбызны үстерү проблемаларына караган материаллар тәшкил итә. Татар телендә чыга торган газета-журналларның барысы да бу темаларны яктырту буенча максатчан эш алып бардылар. Газеталар көн кадагына суга торган, оператив жанрлар белән эш итсәләр, журналлар саллы, дәлилле, анализлы язмалар бастырдылар. Тулаем алганда исә матбугатның бу эше татар халкының милли үзаңы уянуга, мөстәкыйльлек өчен яңа күтәрелешенә китерде.

Массакүләм мәгълүмат чараларының «дүртенче хакимият» сыйфатындагы роле нәкъ менә шул чорда, Декларациянең эчтәлеге хакында, республикабызның сәяси һәм икътисадый мөстәкыйльлек дәрәҗәсе турында, «Татарстан Россия составында каламы, әллә аннан чыгамы?» дигән бәхәсләрнең кызган чагында аеруча ачык чагылды. Инде игълан ителгән суверенитетны республикада яшәүче бөтен халыкның тавыш бирүе белән раслау өчен референдумга әзерлек вакытында Россиянең массакүләм мәгълүмат чаралары Татарстанны «Россия Федерациясе составыннан чыгарга» омтылуда, «сепаратизмда» гаепли башладылар. Эш Россия Федерациясенең Конституцион судына кадәр барып җитте. «Тыңлаусыз», «баш бирмәс Татарстанга» каршы Россиянең барлык матбугат чаралары ябырылды. Аларның республикада бара торган вакыйгаларны берьяклы гына «яктыртуы» республикада милләтара низаг кабызып җибәрүе бик тә мөмкин иде.

Менә шул чагында ныклы, принципиаль позициядә торган демократик матбугат республикада тотрыклылыкны саклап калу буенча гаять зур эш башкарды. «Ватаным Татарстан», «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан яшьләре», «Шәһри Казан» газеталары, «Казан утлары», «Идел», «Мирас», «Сөембикә» журналлары, рус телендә нәшер ителә торган «Республика Татарстан», «Молодежь Татарстана» газеталары Татарстан Республикасы Югары Советы сәясәтен, республика алдында торган бурычларны халыкка аңлату буенча актив эш алып бардылар. Республика җитәкчеләренең, халык депутатларының чыгышларында, журналистлар язмаларында республикада һәм аның тирәсендә бара торган вакыйгаларга объектив бәя бирелде. Вакыты-вакыты белән матбугат бу болгавыр чорда юнәлеш бирүче бердәнбер чыганак булды.

Әлбәттә, иҗат интеллегенциясе, милләт язмышына, республикабызның киләчәгенә битараф булмаган зыялылар, тарихчылар, төрле тармакларда эшләүче галимнәр дә бу иҗтимагый-сәяси күтәрелештән читтә кала алмадылар, матбугат чаралары аша җәмгыятьтә бара торган вакыйгаларга үз мөнәсәбәтләрен белдерделәр. И. Р. Таһиров, Р. К. Вәлиев, Б. Ф. Солтанбеков, А. Л. Литвин, Р. С. Хәкимов һәм башка галимнәр Татарстанның үткәне, киләчәге, аның дәүләтчелеге турында үз фикерләрен уртаклаштылар, Татарстанның мөстәкыйльлегенә теш-тырнаклары белән каршы булган сәясәтчеләрнең һәм галимнәрнең «дәлилләре» нигезсез булуын фаш иттеләр.

Җәмгыятьтә бара торган процессларны мөмкин кадәр тулы итеп яктыртырга омтылыш газеталарның үзләренең дә эчтәлеген, материалларны бирү формаларын тамырдан үзгәртте.

Матбугат алдында торган гаять житди һәм катлаулы бурычлар, әлбәттә, газета-журналларның структурасына да йогынты ясамый калмады. Аларның саны артты, оештыручыларның һәм матбугатны матди яктан тәэмин итүчеләрнең составы үзгәрде, хосусый һәм оппозициядәге газеталар барлыкка килде. 1989-1994 елларда газета битләре Татарстанның киләчәге, аның дәүләтчелеген торгызу турында киеренке, кайчак хәтта кискен көрәш мәйданына әверелде.

Массакүләм мәгълүмат чаралары, аерым алганда газеталар, Татарстанның дәүләтчелеге темасын тикшерүдә, Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларациянең мәгънәсен, Татарстанның яңа Конституциясенең эчтәлеген халыкка аңлатуда максатчан эш алып бардылар, республиканың киләчәге турында үзара һәм үзәк матбугат чаралары белән бәхәсләштеләр. Менә болар барысы да газеталарның колачын киңәйтте, тулаем журналистиканың үзен яңа баскычка күтәрде, журналистларның иҗат мөмкинлекләрен арттырды. Журналистлар җәмгыятьтә бара торган вакыйгаларга карата гына түгел, хакимият структураларына, республика җитәкчеләренә карата да үз фикерләрен ачык итеп белдерү мөмкинлеге алдылар. Бу аңлашыла да, чөнки Татарстанның дәүләтчелекне яңадан торгызу темасын калку итеп күтәрү, бу хакта авыз тутырып сүз әйтү мөмкинлеге аларга соңгы ун елда гына насыйп булды бит.

Дөрес, Совет хакимиятенең беренче елларында матбугатта татарларның дәүләти мөстәкыйльлеге хакында кызу бәхәсләр булып ала. Әмма Совет хакимияте ныгып, Сталин диктатурасы урнашкач, бу бәхәсләр тына.

Илленче-алтмышынчы елларда, Хрущев «җепшекләре» чорында һәм соңрак алтмышынчы-җитмешенче елларда да Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы тарихына караган китаплар, күпсанлы язмалар басылып чыга. Әмма аларда сүз, нигездә, Октябрь революциясе «татар халкына биргән ирекләр һәм мөмкинлекләр» турында, Советлар илендә барлык милләтләр, шул исәптән татар халкының «әдәбияты, мәдәнияте, мәгарифе үсеше өчен тудырылган шартлар» турында бара.

Тагын шунысы да бар. Бу чорда чыккан китапларның һәм газета-журнал мәкаләләренең байтагы чит илләрдә әлеге тема буенча эшләүче авторларны тәнкыйтьләү рухы белән сугарылган иде. Моның сәбәбе шунда: нәкъ шул чорда чит илләрдә татарларның дәүләтчелегенә кагылышлы хезмәтләр аеруча күпләп чыга. Г.Исхакый, Т. Дәүләтшин, А. Акыш, Б. Мусабаев кебек авторлар белән бергә, немец профессоры Г. Менде, Америка профессоры Р.Пайпс, инглиз тарихчылары, В. Монтей, А. Беннигсен, Ш. Келькеже һәм башка бик күпләр Татарстан тарихына, Идел буе республикаларының дәүләтчелегенә, аларда милли мәсьәләләрнең хәл ителешенә кагылышлы китаплар, монографияләр, мәкаләләр бастырып чыгаралар. Партия күрсәтмәсе буенча аларны «фаш итәргә», «халыкка чын хакыйкатьне аңлатырга» кирәк була.

Туксанынчы елларның икенче яртысында газета-журналларда дәүләтчелекне торгызу өчен барган көрәш процессын анализлаган күләмле язмалар, ул киеренке көннәрдә кабул ителгән документларны анализлаган материаллар күпләп басыла башлады. Журналист Р. Юнысовның «Идел» журналында (1997 ел, № 1-12; 1998 ел, № 1-8) басылып чыккан «Татарстанда референдум» дигән язмаларында ул киеренке көннәрдә Татарстан һәм Россия матбугат чараларының эше күрсәтелгән, авторның Россия белән Татарстан арасында төзелгән килешүләргә мөнәсәбәте белдерелгән.

Соңгы елларда Татарстанның дәүләтчелеге тарихына караган газета-журнал мәкаләләре генә түгел, китаплар да чыга башлады. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе, академик И. Р. Таһировның «Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век)», академик Б.Л. Железновның «Правовой статус Республики Татарстан» дигән китаплары, Р. С. Хәкимовның «Белая книга Татарстана. Путь к суверенитету.

1990-1995» дигән рәсми документлар җыентыгы, Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Вәкаләтле Вәкиллеге тарафыннан Мәскәүдәге «ИНСАН» нәшриятында чыгарылган «Суверенный Татарстан» дигән китап һәм башкалар әнә шундыйлардан.

Академик И. Р. Таһиров бу юнәлештә иң актив эшләүче галимнәрнең берсеседер, мөгаен. Ул үзенең соңгы хезмәтләрендә татар халкының мөстәкыйльлеккә, бәйсезлеккә лаек булуын дәлилли, моңа ирешүнең юлларын эзли, ачыклый, тәкъдим итә. Галим буларак, ул тарихи күзлектән чыгып эш итә, чорына күрә зур үсеш алган дәүләтчелеге булган һәм аннан беркайчан да баш тартмаган татар халкының тарихи традицияләрен барлый, бәйсезлек өчен көрәш баскычларын ачыклый.

«Панорама-форум»ның «Мониторинг законодательства Республики Татарстан» дип аталган санына аерым тукталып үтәсе килә. Хокук мәсьәләләрен өйрәнү буенча республикада Д. Войхман, С. Князькин, А. Курдюков һәм башкалар Татарстанның дәүләтчелегенә кагылышлы проблемаларны төрле аспектларда карыйлар. Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк, әлеге хезмәтләр журналистларның практик эшчәнлеге өчен дә бик мөһим, чөнки Татарстанның дәүләт статусы, аның Россиядә генә түгел, БДБ илләре, ерак чит илләр берлегендә тоткан урыны турындагы проблемалар матбугат битләрендә, теле-радиотапшыруларда әледән-әле кузгатыла, алар тирәсендә әле һаман да кызу бәхәсләр бара бит.

Хәзер аерым авторларның һәм коллективларның Россия белән Шартнамә мөнәсәбәтләре урнаштыру процессын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре дә бар инде. Бу яктан караганда академик Э. Р. Таһировның «Татарстан: национальные и государственные интересы» дигән хезмәте игътибарга лаек. Автор анда, әлеге процессны анализлап, аның тарихи чыганакларын һәм хәзерге халәтенең ихтимал булган нәтиҗәләрен күзаллый, Россия белән Татарстан арасындагы Шартнамәнең киләчәген фаразлый.

Тагын шунысын да әйтеп китү бик мөһим: Татарстанның дәүләтчелегенә кагылышлы китапларда, газета-журналларда басылган мәкаләләрдә Татарстанның мөстәкыйльлеге, суверенитеты һич тә татарлар өчен генә түгел, ул бөтен Татарстан өчен, анда яшәүче барлык халыклар өчен кирәк дигән фикер кызыл җеп булып сузыла.

Быел без унынчы тапкыр Республика көнен билгеләп үтәбез. Сиксәненче еллар азагында—туксанынчы еллар башында Россиядә җәелеп киткән демократик үзгәртеп корулар зур икътисадый кыенлыклар, сәяси каршылыклар белән бара. Бу процесс турында төрле фикерләр әйтелә. Әмма бер нәрсәне һич инкарь итеп булмый: илдә демократик үзгәртеп корулар безгә сүз иреге, матбугат иреге бирде, уй-фикерләребезне ачыктан-ачык әйтү, ниһаять, гасырлар буе яшерелеп тотылган чын тарихыбызны өйрәнү мөмкинлеге тудырды. Соңгы елларда Татарстанның дәүләтчелеге хакында авыз тутырып сөйли, яза алабыз, матбугат, радио-телевидение аша республикабызның киләчәге турында иркенләп фикер алышабыз икән—боларга шушы үзгәртеп корулар нәтиҗәсендә ирешелде бит.

Телебезне, динебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калу, моннан биш гасыр элек югалткан дәүләтчелегебезне торгызу өчен тарих безгә уникаль мөмкинлек бирде. Аннан нәтиҗәле файдаланмасак, тарих үзе дә, киләчәк буыннар да безне гафу итмәс. Хәзерге буын дәүләт җитәкчеләренең, җәмәгать эшлеклеләренең, сәясәтчеләрнең, галимнәрнең һәм, әлбәттә инде, массакүләм мәгълүмат чараларының төп бурычы дәүләтчелегебезне торгызу буенча яуланылган казанышларны саклап калу һәм ныгытудан, аларны тагын да үстерүдән гыйбарәт.

Габделхак ШӘМСЕТДИНОВ

Дин һәм тормыш

Мирза
Мәхмүтов

КОРЪӘН СҮЗЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

Коръәннең тәрҗемәләре хакында

Без урысча чыккан Коръәннең кайсы тәрҗемәләреннән файдаланабыз? 80 еллар азагында Корьәнгә ихтыяҗ тугач ук, халык урысча И. Ю. Крачковскийның тәрҗемәсеннән файдалана башлады. Аның тәрҗемәсе фәнни максат белән башкарылган, автор тарафыннан тәмамланмаган, алай да дингә игътибар артып киткәч, бигрәк тә соңгы ун ел эчендә, бик күп санда тарала.

И. Крачковскийның тәрҗемәсе юлга-юл «подстрочная форма» дип санала. Аны хәтта хәрефкә-хәреф тәрҗемә дип тә атарга мөмкиндер (отличается «нарочитым буквализмом»—В. Д. Ушаков). Тәрҗемә аңлашылмауга, ялгышка, мәгънәнең югалуына, хәтта текстның «караңгылыгына» китерә, диләр. Шуңа күрә И. Крачковский тәрҗемәсен укыганда, кеше күп кенә аятьләрнең мәгънәсен аңламый, ярымйорты гына аңлашылган текст аркасында Корьән изге китап, дини истәлек булып хәтердә калмый.

Мәгънәви тәрҗемәләрнең бер үрнәге итеп галимнәр Валерия Порохова нөсхәсен күрсәтәләр. Бу автор Корьәннең эчтәлеген урыс телендә халыкка җиткерүчеләрнең иң зурысы булды. Монда ирекле тәрҗемә ысулы белән шигырь формасында бирелгән аятьләр җиңел укыла, ләкин аларның бер ишесе мәгънәсенә бер дә туры килми, «Алла кәлимәсе» урыны-урыны белән бозыла. Мәсәлән, В. Д. Ушаков күрсәткән хаталарның бер-икесе турында гына әйтик. Порохова тәрҗемәсендә Муса пәйгамбәр «хайваннар өчен агач башларыннан җим кагып төшерә» (20:112). Гомумән, галимнәр В. Пороханы урыс теле стилистикасына да зыян китергән, дип тә язалар, рецензиясез, фәнни редакциясез чыккан, дип тә әйтәләр. Гарәп галимнәре дә борчылып сөйлиләр, «Корьәнне шигырь иткән», диләр.

Тәрҗемәченең максаты укучыларга Коръәннең тулы мәгънәсен җиткерү, аны аңлаешлы итү, әлбәттә. Ләкин В. Порохова тәрҗемәнең тышкы ягына гына түгел, аның эчке әдәби-нәфислегенә җитәрлек игътибар итмәгән. Мәсәлән, Корьәндә булган антропоморфизмнар (кешегә хас сыйфатларны хайваннарга, әйберләргә күчерү) төшеп калган, «Хода йөзе», «Ходa кулы» шикелле тәрҗемә ителми торган сүз тезмәләре бирелмәгән, бу тәрҗемәнең образлылыгы киметелгән, ди профессор В. Д. Ушаков.

Корьәннең төрле телләргә тәрҗемәсе бар, дип әйтелде инде. Инглиз теленә, мәсәлән, гарәп теленнән күп тәрҗемәләр арасында Әхмәдия мәзһәбе тарафдары Маулана Мөхәммәд Али тарафыннан 1917 елны тәрҗемә ителгән. Китап Англиядә бастырыла һәм Гарби (Көнбатыш) илләрендә киң тарала. Шуннан соң аның инглиз телендә генә дә 15 ләп басмасы чыга. Бу тәрҗемәнең төп аермасы—киң фәнни шәрехләүгә, тарихи аңлатмаларга бай булуында. 1997 елны бу Китап инглизчәдән урысчага доктор А. Салецкий тарафыннан тәрҗемә ителеп, АКШта басылып чыга.

Ахыры. Башы 5 санда.

Урысчага соңгы тәрҗемә

Белгеч буларак, доктор Ушаков өр-яңа тәрҗемәләр арасында дагстанлы профессор Мөхәммәт-Нури Османов китабына югары бәя бирә. Ләкин бу хезмәттә дә кимчелекләр барлыгын әйтә. Мәсәлән, аңлатмалар күбрәк тәфсирләргә, мөселман факиһлары *(дин белгечләре)*, галим-голямәләре *(ислам белгечләре)* күрсәткән фактларга, дөньяви хәлләргә таянып эшләнгән, И. Ю. Крачковскийның комментарийларыннан артыгы белән алынган, диелә.

Шулай да М. Османов күп кенә фактлар, терминнар, төшенчәләргә аңлатмалар бирмәгән, дип яза В. Д. Ушаков. Мәсәлән, икенче сүрәнен 255 аятендә: «аның тәхете җир һәм күкләрне ала» дигәнне «җир һәм күкләр аңа буйсына» дип ялгыш тәрҗемә ителгәне күрсәтелә. Дөньяви төшенчәләр Коръән телендә «изгелек», илаһият төсмерләре ала. Мәсәлән, «тәхет» сүзе Коръәндә бөтен дөньяны үз эченә ала һәм изгелек (эзотерик) функциясен үти торган төшенчә безнең аңыбызда бирәр патшаның утыра торган урындыгы булып күзаллана. Шуңа күрә аны мәгънәгә зыян китермичә генә тәрҗемә итеп тә булмый шикелле.

Изге китапларның **эзотерик** *(иррациональ)* ягын читтә калдырырга ярамый, чөнки аларда яшерен, ягъни гайрегыйльми *(бүгенге фәнгә мәгълүм булмаган)* мәгълүматның булуы бар. Бусы да Коръән тәрҗемәләренең бер үзенчәлеге.

Коръәннең татарчага тәрҗемәсе

Коръәнне бер үк телгә ничә тапкыр күчереп була? Изге китапны тәрҗемә итү тарихы—үзе генә дә бу Китапның тирән эчтәлегенә, аның мәгънәви рухына, әдәби нечкәлекләренә үтеп керү тарихы ул. Һәр тәрҗемә камил тәрҗемәгә ирешү максатының бер баскычы диләр, ләкин тулы, мөкәммәл тәрҗемәнең булуы шикле, чөнки һәр тәрҗемәнен үз кимчелекләре бар. Шуңа күрә тәрҗемәченең бурычы 100 процентка үтәлергә мөмкин дә түгел шикелле... Тәрҗемә Коръәннең серләренә төшенү, стилистик, әдәби-нәфислегенең үзенчәлекләрен күрсәтү юлының берсе булып кына кала.

Коръәннең татарча беренче тексты XX гасыр башында басылып чыккан санала. Фән күзлегеннән караганда, Ногмани тәрҗемәсе, ул Коръән-тәфсир тәрҗемәсе, ягъни аңлатмалы тәрҗемә. Тәфсирдә, аңлатмада һәрвакыт авторның субъектив карашы тәкъдим ителә. Коръән-тәфсир укучының үзенә фикер йөртергә урын калдырмый торган—дини аңлатма. Шуңа күрә галимнәр Коръәннең төгәл тәрҗемәсе кирәклеген исбатлыйлар. Яңа, чын мәгънәсендә тәрҗемә танылган татар язучысы Рабит Батулла тарафыннан башкарылган. Шул сәбәпле аның теле дә хәзерге, халыкның мәгълүм, татар әдәби теле. Тулаем алганда, Батулла Коръән тәрҗемәсен, кыенлыкларны җиңеп, уңышлы башкарып чыккан.

Язучы аны асылда төрекчәдән алып эшләде, әмма Ногмани варианты да исәпкә алынмады түгел, алынды. Аннары Коръәннең төрле телләрдә тәрҗемәләре булуы да ярдәм итте. Урыс телендәге текстларга да игътибар булмады түгел, булды. Аннары редактор Коръәннең татарчага тәрҗемәсен гарәпчәсе белән чагыштырып, тикшереп, тиешле җирләрдә төзәтеп чыкты.

Коръәнне татарчага тәрҗемә итү телебезгә йогынты ясамый булмас, аның дини генә түгел, фәлсәфи, сәяси, иҗтимагый терминнары да активлашачак, артачак һәм татар теленең элекке үз (урыс теленнән азат) стиленә кайту юлларына тәэсир итми калмас, дип уйлыйм. Коръәннең элек-электән үк телебезгә, фикер йөртү рәвешебезгә йогынтысы зур булган, әлбәттә. Мисал өчен генә әйтик, татарныкы икәненә шик тудырмаган «Күңел күзе белән күрмәсәң, маңгай күзе—ботак тишеге» дигән мәкаль

бар, ул Коръән теленнән кереп калган икән (22:46).

Телебездә бик күп гарәп алынмалары бар. Коръән текстын ана телендә укыгач, аларның мәгънә төсмерләре ачыкланачак, әлбәттә. Шулар арасында **иман, хөррият, хак, хакыйкать, харам, хәләл, инсаният, канун, вөҗдан, фикер, зыялы, дөнья, рух, рухият, намус** шикелле абстракт төшенчәләр фикер йөртүдә кешенең гомумиләштерү мөмкинлеген киңәйтәләр. Мондый сүзләрнең күбесе күптән татарлашып беткән, читтән кергәнлеге хәтта сизелми дә, ләкин сөйләм телебездә аларның күбесе актив кулланыла, дип әйтеп булмый.

Тәрҗемәнең кыенлыклары

Соңгы дистә ел эчендә татар телендә шактый күп илаһият әдәбияты мәйданга чыкты дигән идем. Алар арасында Коръәннең аерым сүрәләр, аятьләр, хәдисләр, догалары тәрҗемә ителгән. Бу мәкаләдә дүрт китаптан мисаллар алынды: Ногмани хәзрәтнең тәфсир тәрҗемәсе *(Казан, 1996)*, Җәлил хәзрәт вәгазьләре *(Казан, Мәдәни җомга, 1998)*, Батулла *(Казан, 2000)* һәм Фәрит Сәлманның *(Казан, 2000)* Коръән тәрҗемәләре. Шуннан алган кайбер мисалларны тел белеме җәһәтеннән карап, чагыштырып күрсәтмәкчебез, чөнки тәрҗемәченең юлында берничә киртә күренә. Беренчедән, **күп мәгънәле сүзләр;** икенчедән, гарәп теленнән татар теленә кергән **алынма сүзләр**; өченчедән, **Коръән теле, сөйләм теле** буларак, татар әдәби теленә адекват күчерелмәү әнә шундыйлардан.

Коръән кебек бөтендөнья мәдәниятенең хәзинәсен теләсә кем «ирекле рәвештә» тәрҗемә итәм, дип, мәгънәләрен бозып күрсәтү телебезгә дә, фикер йөртүебезгә дә, һичшиксез, зыян китерә. Шуңа күрә дин әһелләре генә түгел, фән әһелләре дә моңа игътибар итми калмас, дип ышанам.

Буяумы, мәсләкме, чукындырумы?

Алдарак икенче сүрәнең 138 аятен Батулла һәм Сәлман икесе ике төрле тәрҗемә иткәнен күрсәткән идек. Бу мисал бик гыйбрәтле, чөнки Коръәндә күп мәгънәле сүз, кагыйдә буларак, бер генә мәгънәсендә кулланыла. Әйтик, «сыйбгат» сүзенең берничә мәгънәсе бар. Тәрҗемәчеләрнең бер ишесе аны төрлечә аңлап, төрлечә тәрҗемә итәләр.

Мәсәлән, урыс теленә ничек күчерелгән? XX гасыр башында Г. С. Саблуков: «*Мы* по крещению Божию; и кто лучше того, кто по крещению от Бога? И ему мы поклоняемся» *(Г. С. Саблуков. Коран, перевод с арабского, третье издание, Казан, 1907)*. Нигә Саблуков мөселманнарның Изге Китабының сүзләрен болай тәрҗемә иткән? Чөнки ул, православие миссионеры, гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә христиан *(мәсихләр)* дини терминнар кулланган һәм башкача аны бирә дә алмаган! «Без» сүзенә юкка гына басым ясамаган, ягъни без христианнар «кто по крещению от Бога, тому и поклоняемся».

Димәк, «сыйбгат» сүзенең мәгънәсе—«чукындыру» («крещение»). В. Порохова да шул ук юлдан барган: «Вот таково крещение Господне, а может кто-нибудь помимо Бога—лучше окрестить? И лишь ему мы предаемся!» *(Коран. Перевод Пороховой.— Дамаск, 1998)*.

«Сыйбгат» сүзен еш кына «буяу» («краска») мәгънәсендә язалар. Америкада басылып чыккан «Священный Коран» китабында болай диелгән: «*(Мы берем)* цвет Аллаһа, и кто лучше Аллаха в расцвечивании, и мы Ему поклоняющиеся[1]»).

Шул ук «сыйбгат» сүзе төрек теленә ничек тәрҗемә ителгән? «Син Аллаһның буявына бак! *(Вафтиз де не ки!)* Кем Аллаһыдан да матуррак буяу буйый белер? Иште

[1]Тәрҗемәче А. Садецкий комментариенда «сыйбг» сүзендә «буяудан» башка «суга төшерү» мәгънәсе дә бар дигән. Шуннан мөселман булмаган кайбер тәрҗемәчеләр «сыйб» сүзеннән «чукындыру» мәгънәсен чыгаралар, чөнки чукындыру суга төшереп башкарыла. Ләкин шул ук автор «сыйбгат» сүзенен «дин» мәгънәсе дә бар ди, дин кешенең рухи дөньясына яңа төс кертә, аның мәсләген үзгәртә.

биз она ибадет еденлериз!» *(Куръәни-Кәрим... Истанбул, 1994).* Икенче берәү шул ук телгә болай тәрҗемә иткән: «Сез Аллаһның биргән төсен алыгыз. «Без аңа гына табынабыз, диегез». *(Куръән-Хаким. Истанбул. 1998).* Димәк, төрек теленә «сыйбгат» сүзе күбесенчә «буяу» дип алынган.

Ләкин «сыйбгат»—күп мәгънәле сүз. Гарәпчә-урысча сүзлектә аның мондый мәгънәләре күрсәтелгән: «Сыйбгат»—1) краска; 2) цвет, окраска; оттенок; 3) характер; (напр., характер доклада и. т. п.); 4) мнение; направление; исповедание». *(Х.К. Баранов «Арабско-русский словарь».—М., 1957, с. 539.)*

Нигә урыс яки төрек тәрҗемәчеләре «сыйбгат» сүзенең беренче мәгънәсен генә алганнар? Мәгълүм түгел. Дөрес, бу сүзнең күп мәгънәлелеген истә тотып тәрҗемә иткән авторлар да бар. Мәсәлән, гасыр башында татар теленә Ногмани тарафыннан болай тәрҗемә ителгән: «Коръән хөкемнәре Аллаһ динедер, шул дингә керегез! Аллаһ диненнән күркәмрәк дин булырмы? Шулай булгач, Аллаһ динен кабул итегез һәм Аллаһка гына гыйбадәт кылабыз һәм аңа гына итагать итәбез, диегез!» Озынрак сүзле булса да, Ногмани хәзрәт бу аятьнең мәгънәсен дөрес биргән.

Монда «сыйбгат» сүзе «дин» мәгънәсендә алынган, андый мәгънә дөрестән дә бар. Моны зур галим И. Ю. Крачковский да күргән, ул «По религии Аллаха! А кто лучше Аллаха религией? И мы ему поклоняемся!» дип тәрҗемә иткән.

Әлеге аятьнең урыс, төрек, татар теленә күчерелгән вариантларын күрдек. Инглиз теленә тәрҗемә итүчеләр бу аятьне ничек аңлыйлар икән? Менә бер вариант: «Such is GODs system, and whose system is better than GODs? Him alone we worship». *(QURAN. The final Testament (Рашад Халифа тәрҗемәсе, март, 1992, США).* (Татарчасы: «Шундый ул Ходайның «системасы», Кемнең системасы Ходайныкыннан яхшырак? Аның үзенә генә без табынабыз!». «Дин», «мәсләк» сүзен монда «система» сүзе белән биргәннәр. Һәм дөрес тә: «сыйбгат» төшенчәсе Аллаһның мәсләге, дине, тәгълимат системасы булмый нәрсә булсын?

Кыска аңлатмалы гарәп теле сүзлеге «Әл-Мөнҗәд» бу сүз турында нәрсә ди? Монда да «суга төшерү» мәгънәсе бар, ләкин төп мәгънәсе «дин» дигән *(Әл-Мунҗад. Бәйрут, 1956).*

Гарәп дөньясында иң абруйлы Коръән-тәфсирләрдән «Җәләләйн»(«ике Җәлил») дип аталган тәфсир бар *(Коръән-тәфсир. Бәйрут, 1992).* Анда 138 аятьне ничек аңлатканнар? «Сыйбгат» сүзе төрле мәгънәдә булса да, Коръәндә ул «дин», «мәсләк» мәгънәсендә алынган, диелә.

Димәк, «сыйбгата Аллаһы» төшенчәсе «Аллаһның төсе», «Аллаһның буявы», «чукындыру»лар түгел, әлбәттә, «Аллаһның дине», «Аллаһның мәсләге» (ислам диненә алып бара торган юлы), Аның фикере, принцибы, карашы дисәк, дөрес булыр. «Бәкара» сүрәсенең 138 аяте болай тәрҗемә ителергә тиеш: «Аллаһ дине, Аллаһ мәсләгеннән яхшырак *(дөресрәк)* мәсләк кемдә бар. Без Аңа табынабыз!»

Бер генә мисал белән булса да Коръән теленнән тәрҗемә итүнең кыенлыгы күрсәтелде шикелле. Теге яки бу аятьнең мәгънәсен төрлечә аңлап, төрлечә тәрҗемә итүләр Коръән тәрҗемәләрендә аз түгел. Ләкин күбесенчә мәгънәви, компенсация ысулы белән тәрҗемә ителгән нөсхәләр дә очрый. Тәрҗемәләр ирекле дә була, дидек. Ләкин һәр ирекле тәрҗемәнең чиге була, барыбер төп нөсхәнең мәгънәләрен бозарга ярамый. Төп нөсхәдәге мәгънә ана телебездә дә шул мәгънәдә аңлатылырга тиеш. Бу фикерне түбәндәге мисаллар белән дәлилләп була.

Җәлил хәзрәт тәрҗемәсе һәм Ногмани нөсхәсе турында

Җәлил хәзрәт китабыннан берничә мисал китерик. Монда без өч мәсьәләгә игътибар итәр идек: 1)тәрҗемә үзенчәлекләре; 2)фонетик язылыш үзенчәлекләре; әлиф-ләм язылышы; 3) синтаксик үзенчәлекләр.

Җәлил хәзрәт вәгазь сөйли һәм үзенең сүзләренә дәлил итеп Коръәннән аерым аятьләр китерә. Сүрә эченнән «йолкып» алынган аятьләрнең мәгънәләре алдарак килгәннәрдән өзелеп, бозылалар. Гарәп теле синтаксисы татар һәм урыс телләре синтаксисларыннан логикасы белән аерылып тора. Мәсәлән, ирекле тәрҗемәләрнең

41 сүрәдән алынган 33 аятьнен бер үрнәге. Гарәпчә: «Вә мән ахсән каүлән-мим-мән дагаа иләә Аллаһы вә гамилә салихан-вә калә «иннәни мин-эль муслимиина». Татарча: «Аллаһы янына өндәгән, игелек кылган һәм «мин мөселман» дип әйтүчедән яхшырак кеше бармы?»

Җәлил хәзрәт тәрҗемәсендә ул болай бирелә. «Минем сүзләремне адәм балаларына житкерүчедән дә сөйкемлерәк кеше юк» (20б.).

Ләкин аятьнен мәгънәсе башка, анда яхшы кеше булунын өч шарты күрсәтелгән: Аллаһы янына чакыручы, өндәүче, игелек кылучы, үзен мөселман дип танытучы. Җәлил тәржемәсендә боларнын берсе дә юк; аятьтә булмаган мәгънә—«Минем сүзләремне...»—күрсәтелгән.

Җәлил хәзрәтнең икенче китабынын 52 битендә шул ук аять кабатлана: «Аллаһы Тәгаләнең сүзен кешеләргә житкерүче кешедән дә күркәмрәк кешеләр булмас» дип тәржемә ителгән. Җөмләнен гомуми мәгънәсе ялгыш түгел түгелен, ләкин шулай ук тәржемә адекват түгел: Аллаһ сүзен кешеләргә житкерүче сүзләре дә, андый мәгънә дә бу аятьтә юк. Гарәпчә «яхшырак» (кеше турында) сүзен бер урында «сөйкемлерәк», икенче урында «күркәмрәк» сүзләре белән тәрҗемә итүнең зыяны юк, киресенчә, ул текстны матурлый гына. Минемчә, дөресрәк варианты болай булырга тиеш: «Аллага иман китергән, игелекләр кылган һәм «мин чынлап та мөэминнәрдән» дип әйткән кешедән дә яхшырак кем бар?».

«Вә мин шарри гасикын иза вакаба» (113:3). «—(Айны) каплаган карангылык яманлыгыннан Аллаһка сыенам») дигән аятьне Җәлил хәзрәт болай биргән: «наданлыктан, карангылыктан, үз-үзенә ясаган золымнардан, Аллаһым, Үзен сакла, Сина гына сыенамын». Бу аять Батуллада ничек әйтелгән?: «Дөм каранггы төннәрдәге мәкердән... Аллаһка сыенам». Редакциясе башкарак булгач, аятьнен мәгънәсе дә азмы-күпме үзгәргәне күренеп тора.

Тагын бер җөмләне алып карыйк. Җәлил язмасында бер үк аять ике төрле тәржемә ителгән. Мәсәлән, «Мөлек» («Падишалык»—67:18): «Ва ләкад кәззәбә-әлләзина мин каблиһим фа кәйфә кәәнә нәкир»— «Аллаһ Раббыбыз: үзен танымаган бер генә кавемне дә жир йөзендә калдырмабыз», ди *(Җәлил хәзрәт китабы, 122 бит)*. Димәк, Алланы танымаган халыкны Ул юк итә. Ләкин «Жир йөзендә калдырмабыз» сүзләре гарәпчә аятьтә юк һәм андый мәгънә дә юк. Монда: «Элегрәк булганнар танымаганнар *(ягъни динне кире какканнар—М. М.)*, танымаганнарга ачуым көчле булды», диелгән. Урысча: «И несомненно, отвергли бывшие прежде них, так же как *(ужасно)* было неудовольствие мое». Порохова: «Отвергли веру многие из них *(раньше)*, И вот тогда-как страшен был мой гнев!» «Жир йөзендә калдырмабыз» дигән фикер монда да юк!

Икенче жирдә, 150 биттә, шул ук аять икенче төрле тәржемә ителгән: «Муафыйк булмасагыз, дөньяда динен ташлаган бер генә кавемне дә, бер генә милләтне дә Мин яшәтмәдем»—дигән иде Аллаһы Тәгалә»,—ди Җәлил хәзрәт. Әгәр бусы да «ирекле» тәржемәгә керә икән, Коръәнне теләсә кем тәржемә итә ала дигән сүз! Ә бит элек, әйткәнебезчә, Коръәнне башка телләргә тәржемә итү тикмәгә генә тыелмаган.

Тагын бер мисал. «Әт-тахиййәту ли-ллахи ва-с-салавату ва-т-тайбату». Бу сүзләрнең мәгънәсе болайрак: «Сәламнәр Аллага һәм догалар, һәм яхшылыклар Аллага *(булсын)*». Җәлил хәзрәт моны ничек тәржемә иткән? «Тел һәм тән гыйбадәтләребез барысы да фәкать Синен өчен генә» *(85 б.)*. Ләкин «тел», «тән» сүзләре аятьтә юк.

Коръән сүрәсендәге (45:13): «Ва сәххәра ләком ма фи-с-самавати ва ма фи-ль-арды җәмиган минһу иннә фи заликә-ль-айяти ликавми йәтәфәккәруна» дигән мәгънә Җәлил хәзрәт тәржемәсендә мондый рәвеш алган: «Мин бөтенесен кеше өчен яраттым, Мин бөтенесен кешегә хезмәт итәр өчен яраттым» (62 б.). Күренә ки, гарәпчә җөмләдә булган бик әһәмиятле «күк» һәм «жир» төшенчәләре төшеп калган. Димәк, аятьнен мәгънәсе бозылган. Бу хәл Р. Батулла тәржемәсеннән дә күренә: «Күкләрдә һәм Жирдә ни булса, шуларнын барысын да Ул үз катыннан иңдереп, сезнен карамакка бирде. Әлбәттә, бу турыда уйлап караган кешеләр өчен гыйбрәтләр бар». Бу тәржемә гарәпчәсенә тәнгәл килә, «гыйбрәт» сүзе генә урынсыз кебек, чөнки «аять» сүзе «могжиза» дигән сүз.

Моны раслау өчен гарәпчәдән бер вариант китерик: «Жирдә дә, күктә дә булганнарны, *(аннан булган бар нәрсәне кебек)*, барысын да Ул сезгә буйсындырган. Чынлап та, бу фикер йөртүче кешеләр *(кабилә)* өчен *(аятьләр)* могжизалар». Коръәндә «аять» сүзе, әлбәттә, «могжиза» («чудо», «знамения») мәгънәсендә кулланылган, дип уйлыйм. Урысча нөсхәләрдә дә шулай. «И подчинил Он вам все, что есть на небесах и все, что есть на земле,—все, что от Него. Воистину, есть в этом знамения для людей

размышляющих» *(«СК», 977 б.)*. Валерия Порохова нөсхәсендә шулай:

И Он вам подчинил все то,
Что суше на земле и в небе,—
Как все, что от Него исходит.
В этом, поистине, знамения для тех,
Кто размышляет (535 б.).

Ләкин гарәп грамматикасына игътибар итмәүчеләр бер үк аятьне мәгънә ягыннан дөресрәк тәрҗемә итсәләр дә ул төрле авторда төрлечәрәк килеп чыга. Мәсәлән, шул үк аятьне Ногмани китабыннан карыйбыз: «... Ислам динен кабул итәргә кешеләрне чакыручы мөселманның сүзеннән дә күркәмрәк, файдалырак сүз булырмы һәм ул һәркайда әйтелер: мин мөселман, бу эшләрне эшләргә мин бурычлымын, дип...» (41:33). Болай киң иттереп күчерү, минемчә, тәрҗемәгә түгел, аңлатма, тәфсирләргә хас. Дөресрәк тәрҗемә ителгән вариантны без Р. Батулла нөсхәсендә күрәбез: «Аллаһка юнәлергә өндәгән һәм дә үзе дә игелекле гамәлләр кылган вә: «Мин мөселман!»—дигән кешенен сөйләшүеннән дә тәмле сүзле башка берәү бармы икән?». «... Тәмле сүзле башка берәү» юк шул, чөнки Коръәндә юк.

Бер үк аятьне төрле редакциядә, башкарак мәгънәдә бирүләр еш очрый. Мәсәлән, Ногмани нөсхәсендә: «... Аллаһы нигъмәтләгән пәйгамбәрләр, турылык белән алга чыкканситдыйклар, Аллаһы юлында сугышып шәһит булган мөэминнәр... Шушы дүрт төрле затларга юлдаш булу—ни күркәм, ни хуш юлдашлыклар» (4:69). Шул үк аятьне Р. Батулла болай тәрҗемә иткән: «Кем Аллаһка вә Рәсүлгә итәгать итсә, менә шулар Аллаһ тарафыннан хуп күрелгән пәйгамбәрләр, гадел вә тугры булган ситдыйклар, шәһидләр вә игелекле адәмнәр белән бергә булачаклар. Алар гаҗәеп аркадашлар».

Янә берничә мисал. Ногмани: «Тәхкыйк бу кәферләрдән элгәре кәферләр пәйгамбәрне ялганга тоттылар, аларга минем мәкерем газаб белән тотмагаклыгым ничек булды?» (6:18). Р. Батулла аны болай язган: «Хактыр ки, алардан элек яшәгәннәр дә моны, Коръәнне ялганга чыгарды. Ләкин минем аларга китергән җәзам нинди дәһшәтле булды». Бусы оригинал текстка якынрак. Әмма барыбер бер үк аятьне икесе ике төрле тәрҗемә итә. Бишенче сүрәдәге сигезенче аятьне Ногмани болай тәрҗемә итә: «Әйе Аллаһ хөкем итүчеләрнең гадел хөкем итүчеләреге түгелме? Барча кешене гаделлек белән хөкем итмәсме?» Батулла: «Аллаһ ин гадел хөкемдарларның ин гаделе түгелме?» Урысча: «Разве Аллах не лучший из судей?» *(Священный Коран)*. Димәк, Ногмани тәрҗемәсендә татар теле аксый, Батулла русчасы-адекват тәрҗемә, «судья»ны «правитель» сүзе белән дөрес алмаштырган.

Фәрит Сәлман тәрҗемәсе турында

Тәрҗемәчеләр күп көч куйсалар да, аларның хезмәтләре кимчелекләрдән хали түгел, дигән идек. Әйтик, Фәрит Сәлман хәзрәтнең тәрҗемәсендә урыны-урыны белән татар теле логикасы аксый шикелле. Коръән кебек фәлсәфи, гаять катлаулы китапны тәрҗемә итәр өчен гарәп телен һәм ислам фарыз-гадәтләрен, дога-намазларын яхшы белү генә аз . Үз телеңне яхшы белү дә төп шарт булып тора.

Ф. Сәлман нөсхәсеннән берничә мисал алып карыйк. «Аерылдырылган хатыннар үзләре белән өч күрем сагалап торырлар...» (2: 228). Татар телендә «аерылган» хатыннар була, «аерылдырылганнар» очрамый кебек. Шул үк аятьтә: «...Аллаһ карыннарында яратып булдырганны аларга яшерергә рөхсәт ителмәс...» (2:228). Бу җөмләне башка тәрҗемәләр аша гына аңлатып булыр дип уйлыйм. В.Порохова: «... И им запрещено сокрыть, что богом создано в их чреве...» Крачковский да: «... Что сотворил Аллах в их утробах...»—ди. Димәк, Аллаһ карыннарында бала яралган түгел, дип аңларга кирәк. Моны Батулла әфәнде бик ачык татарча әйтеп бирә: «...Аерылган хатыннар, әгәр алар Аллага ышансалар, Ахирәт көненә инансалар, үз карыннарындагы *(беренче иреннән балага узганлыгын)* яралгысын яшерсә, хәләл булмас...».

Ялгыш тәрҗемәләр Сәлман хәзрәт нөсхәсендә еш кына очрый шул. Икенче сүрәнең 286 аятеннән бишесен генә күрсәтик. «Тудыручы аналар балаларын ике ел

имезәләр... Баласы туучы хәленнән килгәнчә аларны яхшылык белән тукландырырга һәм киендерергә тиешледер...» (2:233). «Сездән бәрәрегез жан биреп үзеннән соң хатыннарын калдырса, алар үзләре дүрт ай һәм унны көтеп торсыннар...» (2:234). «Диндә ирексезләү юктыр. Тугрылык та ялгышудан аерылды инде... (2:256). «Әгәр бәрәү тарлыкта булса, хәле яхшырганчыга кадәр мөмкинлек булсын...» (2:280). «Аллаһка кире кайтып китәчәк көннән куркыгыз! Соңрак ул һәр жанга аның кәсеп кылганына карата бирер һәм алар рәнжетелмәс тә!» (2:281).

Шул ук аятьне, мәсәлән, Батулла ничек тәржемә иткән? «Ан булыгыз! Аллаһ хозурына барачак көн турында уйлап, куркып яшәгез. *(Ул көнне)* һәркемгә үзе кылганнар өчен түләү итеп, гаделлек илә таман өлеш *(жәннәт яки жәһәннәм)* бирелер» (2:281). Бу, шиксез, кыскача аңлатмалар белән аңга сеңдереп, чын татар телендә әйтелгән фикерләр.

Сәлман хәзрәт тәржемәсендә икенче сүрәдә генә түгел, башкаларында да татарча аңлаешсыз жөмләләр бар. «Ләкин үзләренең Раббыларыннан курыккан өчен—астында елгалар агып торган түрләр һәм алардан югары төзелгән түрләр Аллаһтан вәгъдә буларак!..» (39:20). Нинди «түрләрдән югары түрләр» турында сүз бара соң? Бу аятьнең мәгънәсен муллалар үзләре дә аңлар микән? Шул ук сүрәдәге 21 һәм 22 аятьләрнең дә мәгънәләре шулай ук «серле йомгак» кебекләр. Шуның шикелле жөмләләрне ничек аңларга кирәк?

Тагын бер аятьне чагыштырып карыйк. Ф. Сәлман тәржемәсе: «Үз йөзен Аллаһка тапшырып, яхшылык кылучы булып, Хәниф булучы Ибраһим милләте юнәлешендә булучыдан да кем дин ягыннан яхшырак икән?...» (4:125). Нәрсә ул «Хәниф булучы Ибраһим милләте... булучыдан»? Бу жөмләне кайсы татар аңлар икән? Күбесе аңлар-аңламас игътибар итмичә узып китәр, дип уйлыйм. Шул ук аятьне Р. Батулла нөсхәсеннән укыйбыз: «Гадел эшләр кылып, үзен Аллаһка багышлап, Ибраһим хәнифнең Аллаһны бер дип таныган диненә табынган кешедән дә мәһабәт дини кеше булырмы икән?.» (4:125). Күренә ки, аңлаешлы татарча жөмләләр гарәпчәдән дөрес тәржемә итү нәтижәсе генә түгел, алар Коръәннең тирән мәгънәләрен һәр кешенең аңына житкерүче корал да.

Аңлаешсыз сүзләр, кытыршы жөмләләр бер-ике жирдә генә очраса әле бер хәл. Коръән сүзләрен ялгыш тәржемә итеп, ул китапларның Китабын кызганмасагыз, ичмасам, татар телен кызганыгыз, диясе килә.

Хәзер **тәржемә** мәсьәләсенә аерым тукталып карыйк. Беренчедән, Сәлман хәзрәт нөсхәсендә тәржемә ителмәгән гарәп сүзләре артык күп шикелле.. Мәсәлән, (2:47) «... Мин үзегезне галәмнәр өстендә фазыйләтләндердем». Бу ни дигән сүз? Моның мәгънәсен имамнар да сүзлексез генә аңлый алыр микән? «Фазыйләт» дигән гарәп сүзе татар телендә «өстенлек» мәгънәсендә иске язмаларда очраштыргалый. Ләкин татар фигыле рәвешендә булмагандыр, әлбәттә. Аннары «әл-галәмин» сүзе монда «галәмнәр» (дөньялар) мәгънәсендә түгел, «халыклар», «кабиләләр», «кешеләр» мәгънәсендә кулланылган, чөнки галәмнәр өстеннән Аллаһы Тәгалә үзе генә була ала. Әлеге аятьнең гарәпчәсе: «фаддалтуком галә әл-галәмин...», татарча «...мин сезне *(башка)* халыклардан өстен иттем», яки башка «халыкларга карата өстенлек бирдем» дөресрәк булыр иде.

«Татарлашып» беткән гарәп сүзләре безнең телебездә шактый, әлбәттә, ләкин алар татарның үз сүзләрен кысрыклап чыгарырга тиеш түгел. Бүгенге татар халкы хәзерге татар әдәби телендә сөйләшә һәм укый, шул телдә фәнни фикер йөртә белә, шул телдә генә башка халыклардан кергән фикерләрнең асылына төшенә.

Тәржемә дөрес, матур булса, гарәп телендә булган фикерләр, аятьләрнең мәгънәләре ана телендә дөрес чагылыш тапса, Коръәнне татарчага кайсы телдән тәржемә итсәң дә ярый, әлбәттә. Ләкин гарәпчә текст белән «турыламыйча» ярамый. Әмма Сәлман хәзрәт нөсхәсендә татар теле стилистикасы һәм лексикасында күбрәк урыс һәм башкорт телләреннән тәржемә иткәнлек сизелә. Мәсәлән, «Йосыф» сүрәсенең

49 аятен Сәлман хәзрәт болай биргән: «Шуның артыннан бер ел килер. Ул елны кешеләргә яңгыр җибәрелер һәм алар чыгарлар». Кемнәр «чыгарлар»? Каян чыгарлар?

Ул башкорт телендә чыккан Коръәннән «...ул йылды кешеләргә ямғыр ебәрелер һәм улар *(емеш)* хығырдар» җөмләсеннән «хығырдар» сүзен «чыгарлар» дип ялгыш тәрҗемә итә һәм Коръән аятенең мәгънәсен югалта. Юкса, Коръәндә «чыгару» түгел, җимеш сутын сыгу турында сөйләнә.

Югарыда күп мәгънәле сүзләрне тәрҗемә итүдә аеруча читенлек бар, диелгән иде. Аларны Коръәннең беренче битеннән үк, «Фатиха» сүрәсеннән бик ачык күреп була. Беренче аять: (1:1) «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим»—«мәрхәмәтле һәм рәхимле Аллаһның исеме белән *(башлыйм)*». Ф. Сәлман: «Дөньяда һәркемгә шәфкатьле, ахирәттә иман әһелләренә генә рәхимле Аллаһ исеме белән»—дип, гарәпчә текстта булмаган *(Ногманиның тәфсиренә ияреп)*, үзеннән өстәмә мәгънә чыгарып язган.

Икенче аятьтә «Галәмнәрнең тәрбия кылучы раббысы Аллаһка мактау», дигән һәм сноскада «галәмнәр» ике дөнья мәгънәсен бирә, җир, күк кенә түгел, космосны да эченә ала, дип аңлаткан. Бусы, минемчә, артык «ирекле тәрҗемә»: алай аңлаткан галәмнәрнең ничек «тәрбия кылу»ы мөмкин икән? Асылда Коръәндә «Әлхәмдүлилләһи раббиль-галәмин»—«халыкларны тәрбия кылучы Аллаһка дан *(булсын)*» диелгән *(Ногмани нөсхәсен кара)*.

Дүртенче аять (1:4) «Малик йауми-д-дин»—«кыямәт көненнән падишаһына» дип тәрҗемә ителгән. «Малик» сүзенең ике төрле мәгънәсе бар: 1) хуҗа, ия, бар итүче; 2) патша. Минемчә, бу җөмләдә «малик» сүзе «падишаһ» түгел, чөнки Аллаһ берәр дәүләтнең патшасы гына түгел—кыямәт көне иясе, хуҗасы, бар итүчесе мәгънәсендә йөри *(Кара: «Священный Коран, с. 5, пункт 7)*.

«Фатиха» сүрәсенең 7 аяте болай күчерелгән: «үзен ирештергәннәрнең юлыннан, ачуга тарыган һәм тайпылып адашканнарныкыннан түгел!». Бу аятьтә ике мәгънәле сүзләр икәү. «Ирештерү»: 1) бәхеткә ирештерү; 2) үчекләү, үртәү. «Ачу» сүзе дә ике мәгънәле: 1) күңел ачу, капка ачу; 2) нәфрәт, ачу килү. Аятьтә Аллаһның ачулануы, аның нәфрәте турында сөйләнә. Бу очракта бәлки «ачуына тарыганнар» яки «синең нәфрәтеңне казанганнар» кебегрәк аңлату кирәк булгандыр. Юкса, Коръәнне беренче аятеннән үк аңлау бик кыен.

Күпмәгънәле сүзләрнең иң дөрес ишесен сайлап алу табигый рәвештә дә кыен. Сүзнең мәгънәләре арасыннан нәкъ шушы җөмләне тәрҗемә итәргә кирәклесен сайлап алуга күп төрле фактлар, шул арада бер дә көтелмәгәне комачаулый. Мәсәлән, Л. Н. Толстойның «Война и мир» романы татарчага «Сугыш һәм тынычлык» дип тәрҗемә ителгән. Дөресме? Юк, ялгыш тәрҗемә. Ник алай? Урыслар үзләре шулай язалар. Ә чынлыкта исә, монда омонимия һәм омография хикмәтләре бар, берүк әйтелешле «мир» сүзе «халык» һәм «тынычлык» мәгънәсендә кулланылган. «Мир» сүзе элек «ъ»—«ять» хәрефе белән язылып, «халык» мәгънәсен аңлаткан. «Мировой судья»—«Народный судья», «На миру и смерть красна» («Ил белән үлем дә җинел»), «Пустить по миру» («Халыктан хәер сораштыру»). Димәк, бу роман «Сугыш һәм халык» итеп тәрҗемә ителергә тиеш, чөнки роман сугышта халыкның катнашуы турында бәян итә. Әмма «мир» сүзеннән «ять» төшеп калгач, «тынычлык» мәгънәсе генә кулланыла башлый. XX гасырның урталарында җәмәгатьчелек аң-телендә сүз шулай үзгәргән икән, шулай булгач 14 гасыр элек кулланылган Коръәндәге сүзнең мәгънәсе үзгәрүе дә ихтимал.

Ләкин тәрҗемәче «уяу» булсын иде. «Дин», «мәсләк» сүзен «буяу», «халык» сүзен «галәм» яки «тынычлык» сүзе белән бутамасын, алмаштырмасын иде. Интуиция түгел, төгәл белемгә таянып тәрҗемә итү мәгъкул.

Текст бөтен нечкәлекләре, мәгънә төсмерләре, синонимнарның да мәгънәви аермасы белән бирелмәсә, Коръән шикелле борынгы китапның эчтәлегенә төшенү читен шул. Мона Ф. Сәлман нөсхәсеннән янә бер мисал китерик: «... Сез үлекләр идегез, үзегезне терелтте. Янә үзегезне үлекләндерәчәк...» (2:28). «Үлек» сүзе ике мәгънәле: мәет һәм эрен, ярага җыелган шакшы үлек. Гарәпчә «йумитуком»—«сезне үтерәчәк» дигән сүз. Коръән сүзенең мәгънәсе белепме-белмичәме бозылган. Моның ише хаталар аятьләрнең мәгънәсен караңгылый, дип уйлыйм. Батулла «йумитуком» сүзен «җаныгызны алачак», дип мәгънә ягыннан дөрес тәрҗемә иткән.

Янә бер мисал. (2:36)—«Шайтан исә аларны икесен дә үзенә котыртып абындырды, һәм алар булган төштән үзләрен чыгарды». Моны ничек аңларга кирәк?

Шайтан аларны үзенең гәүдәсенә абындырттымы, әллә котыртып абындырды, ягъни туры юлдан яздырдымы? Шайтан аларны нинди «төштән» чыгарды? Төш—орлыкмы ул, әллә йокыдагы төшме ул, әллә яшәү урынымы? Менә шундый икеле-микеле җөмләләр укучыны аптырашта калдырачак, әлбәттә. Бу аятьнең мәгънәсен башка тәрҗемәчеләр ничек биргән? Атаклы төрек дин галиме Хәмди Языр бу җөмләне бик дөрес һәм җинел аңлаешлы итеп болай тәрҗемә иткән: «Шул сәбәпле шайтан аларны... икесен дә муллык эчендә яши торган урыннарыннан чыгарды». Ягъни *җәннәттән* чыгарды. Шул ук фикерне Порохова да бирә: «Но Сатана увлек их в грех и вывел из блаженства, в котором находились они там».

Гарәп сүзләренең Коръәндәге мәгънәләренә тиешле игътибар итмичә тәрҗемә ителгән аятьләр очрый, дигән идем. Кызганычка каршы, бу Коръәннең галәти сүзләренә генә түгел, аның төп терминнарына (төшенчәләренә) дә кагыла. Һәр тәгълиматның төп фикерләре мәгълүм төшенчәләр—терминнар белән бәян ителә, аңлатыла. Исламның төп төшенчәләре—«иман», «дин», «тәүхид» (Алланың берлеге), «коръән», «сәлам», «салят» (намаз) шикелле терминнар арасында «фуркан» термины-төшенчәсе дә бар.

Тәүхид—биш фарызның беренчесе, Исламның терәге: «Лә иләһе иллә Аллаһы, Мөхәммәдү расүлү-Аллаһы» («Алладан башка Хода юк, һәм Мөхәммәд аның илчеседер»).

«Фуркан» сүзе Коръәндә нинди мәгънәдә кулланылган һәм тәрҗемәчеләр аны ничек аңлыйлар һәм укучыга төшендерәләр? «Бәкара» сүрәсенең икенче аятендә болай диелгән: «Ва из атайна Муса әл-китаба ва-әл-фуркана ләгалләкүм тәхтәдуна» (2:53). Бу аятьтә тәрҗемәчеләр «фуркан» сүзенә сөртенәләр.

Мәсәлән, Ф. Сәлман хәзрәт тәрҗемәсе: «Тугры юлга күнәрсез дип Мусага *китап белән аергыч* тапшырганны исегезгә төшерсәгез иде» *(кыек хәрефләр минеке—М. М.)*. Монда ике ялгышлык бар. Беренчесе, «фуркан» сүзе аңлашылмый: бу ни дигән сүз? Моңа урысча текстларда ялгыш тәрҗемәләр булуы да комачаулый. Мәсәлән, И. Крачковский белән В. Порохова «фуркан» сүзен «различение» дип алганнар. Аларга иярептер, башка тәрҗемәчеләр дә «фуркан» сүзенә абыналар. Күрсәтелгән аятьтә генә түгел, Ф. Сәлман нөсхәсенең башка аятьләрендә дә (мәсәлән, «Гыймран» сүрәсенең 4 аятендә) «фуркан» төшенчәсе аңлаешсыз «аергыч» сүзе белән тәрҗемә ителгән (3:4). Бу аятьнең тәрҗемәсендә тагын бер кимчелек бар—«исегезгә төшерсәгез иде» гыйбарәсе гарәпчәдә юк, каян килде ул татарчасында?

Шул ук аятьне Р. Батулла ничек тәрҗемә иткән? «Тугры юлны табарсыз, дип Мусага *(хакыйкатьтән яманны аера торган хөкемнәрне)* Фурканны *(Коръәнне)* бирдек». Монда «фуркан»ның төп мәгънәсе дөрес күрсәтелгән, ләкин без ике төгәлсезлек күрәбез. Беренчедән, гарәпчә «табарсыз» димәгән, чөнки туры юл Китапта күрсәтелгән инде; «тәхтәдуна» сүзен «туры юлга басарсыз» дип тәрҗемә итү дөресрәк булыр иде. Икенчедән, аятьтә Коръән Мусага бирелгән, дип әйтелмәгән, чынлыкта исә, Коръән Мөхәммәд пәйгамбәргә иңдерелгән. Мусага «аль-китаба ва-ль-фуркана» бирелгән. Әл-китаб—ул Тәүрат (Тора).

Бу аятьне дөрес тәрҗемә итүчеләр дә юк түгел. Мәсәлән, 1909 елны басылып чыккан Коръән-Тәфсирдә Ногмани хәзрәт тәрҗемәсендә болай диелгән: «...Мусага китап бирдек. Ул китап хак белән батыл арасын аеручы иде». «Различение» генә түгел шул, **хак** белән **батыл** *(ялган белән хакыйкать)* арасын күрсәтүче. Бик үк төгәл булмаса да төп мәгънә чагылдырылган. «Ул китап»—Тәүрат, а менә «фуркан» чыннан да хәләл белән харамны аеручы. Башка телләргә «фуркан» сүзен ничек тәрҗемә иткәннәр? Төрекләр вариантын без Батуллада күрдек инде. «Хак иле батылы аеран хукумлери вердик», диелгән Караман тәрҗемәсендә *(Kuran-I kerim ve turkce aciklamali meali, Medine, 1997)*. Димәк, «фуркан»—күрсәтмәләр, төп кагыйдәләр.

Рашад Халифә инглизчә тәрҗемәдә болай дигән: «Recall that we gave Moses scripture and the statute book, that you may be guided» *(Quran. The final Testament. USA, 1992)*. «Statute book»—свод законов, ягъни «кануннар мәҗмугасы». Менә сиңа «аергыч»! Менә сиңа «различение». Әгәр Х. К. Барановның гарәп теле белгечләренә бик мәгълүм «Арабско-русский словарь» китабын ачып караган булсак, анда «фуркан»ның мәгънәсен күргән булыр идек: «фуркан—различение (добра от зла). Аль-Фуркан—священное писание; Библия; Коран».

Димәк, «фуркан»—җиденче күктә сакланган һәм шуннан Мусага Тәүрат белән бирелюлы иңдерелгән төп Коръәннән күрсәтмәләр («аеран хукумлери») ул. Аллаһ барлык диннәр өчен дә бер булгач, «тәүхид»нең төп мәгънәсе, аның Сүзе дә бер булырга тиеш

түгелме соң? Ләкин изге китаплар күп төрле ич! Аллаһ Сүзенең берлегең ничек аңлатырга? Китапларның эчтәлек ягыннан берлеген «фуркан» тәэмин итә. Төрле вакытта бер үк чишмәдән алынган су кебек, Коръәннең үзендә әйтелгәнчә, барлык Изге китаплар—Тәүрат (Мусага), Зәбур (Даудка), Инҗил (Гайсәгә), Коръән (Мөхәммәдкә) бер үк «чишмә»—бер үк нөсхәдән, «фуркан»нан алып, күчерелеп төзәтелгән, яңартылган төстә пәйгамбәрләргә иңдерелгән диелә. Күктәге Коръән турында Ф. С. Пушкин да язып калган: «С небесной книги список дан Тебе, пророк, не для строптивых; Спокойно возвещай Коран, Не понуждая нечестивых!» «Фуркан»—яхшыны яманнан аера торган гомуми дин кануннары. Аятьнең дөрес тәрҗемәсе болай булыр иде: «Бәлки сез туры юлга басарсыз дип, Мусага Китап һәм кануннар бирдек».

Димәк, «тәүхид» төшенчәсе белән «фуркан» төшенчәсе ислам теориясенең (догматикасының) логик бәйләнешен тәэмин итәләр. Фуркан сүзен дөрес тәрҗемә итү—ислам тәгълиматын аңлату өчен бик мөһим шарт.

Мәгълүм ки, хатадан берәү дә саклана алмый, бигрәк тә тәрҗемә текстларда. Урысча Коръән укып, йөз чөеруче татарлар күп. Инде татар телендә дә без аларга ярым-йорты фикерләр, ялгыш сүзләр, ватык җөмләләр тәкъдим итә башласак, Коръәнгә сокланып карый башлаган татарлар да бу китаптан бизә башламас микән?

Тәрҗемә теориясендә әйтелгәнчә, без оригинал текстның сүзләрен генә түгел, аларның мәгънәсен, хәтта мәгънә төсмерен дә дөрес, матур һәм җиңел аңлаешлы ана теленә тәрҗемә итәргә тиешбез. Фәрит хәзрәт Сәлман да, Рабит әфәнде Батулла да эшне шулай итеп башкарырга тырышканнар, әлбәттә. Барыбер тәрҗемәләр бер-берсеннән аерылып торалар; нөсхәләр күпме булса, аларны камилләштерү юллары да бардыр. Атаклы татар язучысы Р. Батулла каләменнән төшкән нөсхә тәрҗемәнең дөреслеге белән генә түгел, татар теленең матурлыгы белән дә сокландыра.

Алынма сүзләрнең тәрҗемәсе турында

Алынмалар. Татар телендә искергән һәм гамәлдән чыккан яки чыга язган сүзләр бик күп; әйтик, сонра, лязем, гафил, гафләт, тәхкыйр, тәсдыйк, вә, илә шикелле таныш кебек булсалар да мәгънәләре бик үк ачык булмаган сүзләр әнә шундыйлардан. Алар текстны җиңел аңлауга комачаулыйлар. Теләсә кайсы телдән тәрҗемә иткәндә тәрҗемәченең «ялган дуслары» килеп чыга. Ул «дусларның» бер төре—тәрҗемә ителәчәк телдән кергән алынма сүзләр, ике телдә дә кулланыла торган бер үк лексика. Татар телен бай дибез, аның байлыгы терминнар хисабына да арта. Татар теле терминологиясе төрле чорларда төрлечә үсә. Мәсәлән, техника, механика, физика, химиядән терминнар күбесенчә совет заманасында гына урыс теленнән кергәннәр. Гарәп теленнән татар теленә 10 меңнән артык сүз һәм гыйбарәләр алынган[1].

Элек мәдрәсәләрдә укып чыккан татар яшьләре дини терминнарны яхшы белгәннәр. 70 елга сузылган совет дәһрилек дәверендә ул терминнарның күпчелеге телдән төшеп калып юк булганнар. Бүген рухият һәм руханият әдәбиятын укыгандамы, урысчадан тәрҗемә иткәндәме кешеләрнең күбесе эквивалент сүз таба алмыйча аптырыйлар һәм ислам турында сөйләгәндә дә урысча терминнардан файдаланалар.

Татар теленә кергән гарәп алынмаларының бер ишесе актив кулланышта йөри (китап, мәктәп, мәчет, вөҗдан, газап һ. б. ш.); бер ишесе төшеп калган (тәхкыйк, гатыф, имла һ. б.). Актив кулланылышта булганнарының да бер өлешенең мәгънәләре еш кына тарайган яки үзгәргән була. Шуңа күрә Коръәнне тәрҗемә иткәндә бу сәбәптән дә төрле кыенлыклар килеп чыга. Мисал итеп «нигъмәт» сүзен алыйк. Сүзлектә «нигъмәт»—*книж.* пища, еда, кушанье, снедь, яства. «Нигъмәтле»—*уст.* имеющий пищу *(припасы) (Татарско-русский словарь. М. 1966, 398 б.).* Димәк, нигъмәт—китап сүзе, нигъмәтле, гомумән, искергән инде. Гарәп телендә исә бүген дә «нигъмәт»нең беренче мәгънәсе—**бәхет**, үзенең Раббысына вә аның нигъмәтләренә көфрән нигъмәт кылучылар, ягъни иман китермичә, ислам динен кабул итмичә, үзен-үзе һәлак итүчедер. Монда «нигъмәт» сүзенең мәгънәсе «ризык»ка бер дә якын түгел шул.

Татар телендәге «нигъмәт»нең мәгънәсе бик тар, аны «ризыкка» гына кайтарып калдыралар. Менә «Фатиха» сүрәсенең 7 аятендә болай диелгән: «Сыйрат әлләзина

[1]К. З. Хәмзин, М. И. Мәхмүтов, Г. Ш. Сайфуллин. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. Казан, 1965.

әнгамтә галәйхим». Җәлил хәзрәт тәрҗемәсендә: «Йа, Раббым, безне Үзеңнен кин ризыклы, мул ризыклы юлларга күндер» *(Җ., 69 бит).* Ләкин «әнгамтә» сүзендә ризык кына түгел, монда «бәхет», «рәхмәт», «шәфкать», «мәрхәмәт» мәгънәләре күбрәк шул. Бу аятьне, мәсәлән, «Священный Коран» китабында: *Веди нас по* «...стезе тех, кому ты даровал милость» дип тәрҗемә иткәннәр. В. Порохова тәрҗемәсендә дә «Милостью Твоею одарен...» диелгән. Димәк, урыс тәрҗемәчеләре «нигъмәт» сүзен дөрес аңлаганнар: монда сүз «ашамлык», «ризык» турында гына түгел, бәлки киңрәк мәгънәдә, «рәхмәтенне бирдең» мәгънәсендәдер.

Мәсәлән, Батулла: *«(Зинһар)* юлдан язганнар вә нәфрәтенә дучар булганнар юлына төшермә» ди. Монда да «ризык» мәгънәсе юк.

Димәк, «рәхмәтеңне биргәннәрне юлыннан алып бар, җитәклә». «Ризык» сүзе белән тәрҗемә итү, гомумән, ирекле тәрҗемә өчен дә «бик ирекле». Ник «рәхмәтеңне» сүзе дөресрәк соң? Чөнки «кемнәргә ул рәхмәтен биргән һәм кемнәр туры юлдан барган?» соравына җавап 4 сүрәнең («Ниса») 69 аятендә күрсәтелгән: пәйгамбәрләргә, изгеләр, мәрхәмәтле кешеләргә, һәр мөселман аларны үзенә үрнәк итеп алырлык кешеләр алар, чөнки киләсе аятьтә алар болай билгеләп үтелә: «гайрель-мәхдуб галәйхим ва лә-д-далин». Моны Җәлил хәзрәт «...берүк безне начар, бозык кешеләр белән тоташтыра күрмә»—дип тәрҗемә иткән. Ләкин Коръәндә «начар, бозык» кешеләр турында сүз дә юк ич! Анда «алар, кемнәргә синең ачуың чыкмады *(ачуланмадың)* һәм адашып йөрмәгән» кешеләр... Кемнәр соң алар? Алар шул ук изгеләр, пәйгамбәрләр, чөнки алар гына адашмыйча йөргән *(СК, Комментарий, с., 7 п. 9).* «Сезне туры юлдан җитәкләүче юлдашыгыз Мөхәммәд галәйһи-с-сәлам туры юлдан һич адашмады, һәм бозылмады, азмады» (53 сүрә, 2 аять; бу «Фатиха» сүрәсенең җиденче аятенә җавап, башкача аның тулы мәгънәсе аңлашылмый да).

Татар теленә кереп тә, мәгънәви тотрыклылыкларын югалткан сүзләр тәрҗемәченең «ялган дуслары» булып йөри, дигән идек. Мәсәлән, «хаким» һәм «хәким» сүзләрен алыйк. Беренчесенең мәгънәсе—«хөкем итүче», икенчесенеке—«акыл иясе». Коръәндәге (95 сүрә, 8 аять) «Әләйсә Аллаһы би-ахкәми-ль-хакиминә»? («ахкәм»—иң зур акыл иясе, хәким; «хакиминә»—хөкем итүчеләр) Җәлил хәзрәт китабында болай тәрҗемә ителгән: «Хөкемнәрнең хөкемдары—Аллаһы Тәгалә. Ул хөкем итәчәк безне...» «Хөкемдар»—«правитель», ягъни аятьтәге ике төрле сүз икесе дә бер үк «хаким» мәгънәсендә бирелгән. Бу аять урысча ничек тәрҗемә кылынган соң? «Разве Аллах не лучший из судей?» *(«СК», с. 1218).* Порохова: «Ужель Аллах не самый мудрый судия?» Монда тәрҗемәче бик зур осталык белән «хаким» («хөкем итүче») сүзе белән «хәким» («акыл иясе») сүзен икесен дә дөрес кулланган. Татарча «Аллаһ иң акыллы *(зирәк)* хакимнәрдән түгелмени?» дип әйтү аятькә якынрак варианты булыр иде шикелле.

Тәфсилләбрәк әйткәндә, алынма сүзләрнең «ялган дуслыгы» шуннан гыйбарәттер—гарәп сүзенең мәгънәсе татар телендә үзгәрү ихтималы бар. Шуны исәпкә алып, кайбер сүзләрнең этимологиясенә игътибар итү зарури. Мәсәлән, гарәпчә «хикма» («мудрость») дигән күп мәгънәле һәм гаять әһәмиятле сүз татар телендә кулланыламы?

«Хикмәт» сүзен гарәпләр «хикма», «хакәмә»—«тезген» сүзеннән чыгаралар. Димәк, «хикмәт» («мудрость») кешене яман галәт-холыктан саклый. Сүзнең мәгънәсе эш-гамәлгә бәйләнгән. «Дөрес гамәл тудырган һәр дөрес сүз—«хикмәт» ул», ди атаклы дин галиме Абу Җәгъфәр. Ләкин «хикмәт»нең функциясе киңрәк: ул гамәлгә генә түгел, хакыйкатькә дә бәйләнгән. Икенче бер дин белгече әл-Җәрҗәни фикеренчә: «Хакыйкатькә туры һәрбер сүз—«хикмәт» ул *(«мудрость»).* «Ул хикмәтне теләсә кемгә бирә, хикмәткә лаеклы кеше бәхет, игелек бүләген алган» *(була)* диелә Коръәннең «Бәкара» сүрәсенең 269 аятендә. Димәк, «хикмәт» камил белемгә ия булу һәм шул белемгә таянып гамәл кылу ул. Шулай, Коръәндә «хикмәт» сүзенең мәгънәсе киң; ул пәйгамбәрлек, гаделлек, белем, дөньяны тирән аңлау, акыл белән эш итү һ. б. аңлата.

Без «хикмәт»не («мудрость»ны) «зирәк» сүзе белән бирәбез, «хикмәт» сүзе татарча—«зирәклек» дип аңлатыла. «Мудрый»ны да—«акыллы», «зирәк» һәм өченче мәгънәсендә генә «хикмәтле» дип тәрҗемә итәләр *(Русча-татарча сүзлек, М., 1984, 277 б.).* Сүзлекләрдә әле бер хәл, әмма язу, бигрәк тә сөйләм телендә андый сүзләрнең мәгънәләрен гел урысчадан китереп чыгару—бу инде чикләнгәнлек, әйтерсең лә татарда «мудрый» төшенчәсе элек-электән бөтенләй дә булмаган...

Искерәк сүзлекләрдә—«хакимият»—«власть» сүзе книжный дип күрсәтелгән. Бүгенге көндә ул сүз активлашты шикелле: «Хаким»—1) повелитель, властелин, правитель; 2) *книж.* судья; бу мәгънәдә бездә кулланылмый. «Хәким»—*уст. книж.* 1) ученый, мыслитель, мудрец, философ *(Татарча-русча сүзлек. М., 1966, 620 б.)* Димәк,

сүзлек аны да иске сүзләр арасына керткән, татар лексикасыннан чыгарып ташланган. Шул рәвешле, алфавитларны бер генә йөз ел дәвамында да өч-дүрт мәртәбә алмаштыра башласак, алга таба да ана телебездәге күп сүзләрдән колак кагачакбыз әле.

Тәрҗемәченең «ялган дуслары» татар телендә әлегә аз түгел шул. Мәсәлән, **«хәер»** сүзе сүзлекләрдә дөрес бирелсә дә, татарның аңында һәм язу-сөйләм телендә ул «хәерче» төшенчәсе белән бәйле мәгънәдә формалашкан. Берәүне ачулансак, «хәерсез!» дип орышабыз ләбаса. «Хәер» сүзе бездә хәерчегә бирелә торган нәрсә итеп, «милостыня» мәгънәсендә генә кулланыла. Ләкин «хәер» сүзенең бездә төшеп калган төп мәгънәсе «игелек», «мал-дәүләт», «яхшылык» дигәнне аңлата.

Шундый ук сүзләр рәтендә гарәпчә «хулкъ» сүзеннән татар теленә кергән **«холык»** сүзе дә тора. Гарәп телендә аның мәгънәсе—«гадәт», («нрав»), без «холык»ны рәсми телдә урысчадан кергән «характер» сүзе белән аңлатабыз, «нрав» икәнлеге фәкать «холыксыз» сүзендә генә чагылыш таба. Сүзлектә дә «характер» сүзе «характер», «холык», «табигать» дип бирелә. «Нрав» сүзе татарчага «холык», «табигать», «гадәләр», «гореф-гадәтләр» дип тәрҗемә ителә..

«Мөбарәк» сүзе Коръәндә «благословенный» мәгънәсендә йөри (ягъни «фатиха алган», олы кешенең рөхсәтен, ризалыгын алган). Без ул сүзне «тәбрик итәм», «котлы булсын» кебек мәгънәсендә генә кулланабыз. Татарча сүзлектә—«бәхетле», «имин». Урысчадан тәрҗемә иткәндә ул сүз «благословенный» түгел, «счастливый», «благополучный» булып кала түгелме соң? Тәрҗемәчеләр тиешле сүз (урысныкына эквивалент сүз) таба алмагач, төрлечә боргалап карыйлар.

Гарәп сүзләренең татар телендә мәгънәләре бөтенләй яки өлешчә туры килмәгән андый алынма сүзләр байтак: садака, хаким, хәким, җәза, золым, бәрәкәт, җәннәт, нәфис, мәртәбә, хак, мазлум, залим, нигъмәт, кәлимәт һ. б. әнә шундый сүзләр. Гарәпчәдән татарчага күчергәндә алар тәрҗемәчегә «аяк чалалар», татарда урнашкан мәгънәләре тәрҗемәгә механик рәвештә кереп китә (моны фәндә «телләр интерференциясе» дип атыйлар).[1]

«Нәфес» сүзен татар теленнән урысчага тәрҗемә иткәндә мондый мәгънәләре күрсәтелә: 1) страсть, желание, вожделение, похоть; 2) *уст. книж.* душа; нәфсе ямән—ненасытный, жадный; нәфесле кеше—алчный *(Татарча-русча сүзлек, 406 б.).* Гарәп телендә бу күп мәгънәле сүз—1) 1. Җан; 2. Кан; 3. Кеше; 4. Грам. зат; 5. Ният, теләк; аппетит; 6. Тырышлык, дәрт; 7. Горурлык; 8. Асыл, нигез. 2) 1. Үзе; 2. Шул ук. *(Кара: Х.К. Баранов. Арабско-русский словарь., М., 1957).* Коръәндә бу сүз нинди мәгънәдә күбрәк очрый һәм без аны, үз телебездә эквивалентлы булмагач, ничек дип тәрҗемә итәргә тиешбез? Билгеле, сүз сөрешенә карап.

«Мәсләк» сүзе гарәп телендә «доктрина», «принцип», «убеждение» не аңлата. Шуннан чыгып, татар телендә «мәсләкле»—убежденный, идейный булырга тиеш шикелле. Ләкин ашык-пошык язган тәрҗемәчеләр кул астыннан нинди генә сүзләр чыкмый? «Мәсләкле» түгел, «идеяле», «принциплы» дип язалар, гәрчә татарча сүзлекләрдә «мәсләк»—1) убеждение, мировоззрение; 2) *перен.* принцип, идея, цель.

Инде тагын **«бәрәкәт»** сүзен алып карыйк. Татарча-русча сүзлектә (1966) мәгънәсе болай бирелгән: 1) изобилие, достаток; 2) *рел.* небесный дар. Татар телендә бу сүздән ясалган сүзләр дә бар: бәрәкәтле—экономный; бәрәкәтлелек—экономность; бәрәкәтсез—неэкономный. Гарәп телендә «бәрәкәт» сүзенең мәгънәсе—«благословенный», «небесный дар» дигәнгә туры килә. Татар телендә киң кулланыла торган «тәбрик», «мөбарәк» сүзләренең этимологиясе «экономный» мәгънәсеннән ерак торалар («мубарәк»—«благополучный», «счастливый»). Димәк, «бәрәкәт» ике телдә ике төрле мәгънәдә кулланыла торган сүз. Мәсәлән, Коръәндә 16 сүрәнең 18 аятендә ул «благословенный», «счастливый» мәгънәсендә кулланылган да.

«Җәннәт» сүзенең гарәпчә беренче мәгънәсе—«бакча». Икенчесе—кешенең теге дөньяга күчкәч рәхәт хәлдә яшәү урыны. Чиксез, кызган таба шикелле ифрат эссе ком сәхрәсе, бөртек үлән үсми торган ташлы-комлы сусыз чүлләрдә яшәгән бәдәви (күчмә

---

[1]Психологиядән мәгълүм булганча, кеше өчен конкрет фикерләү ансатрак (күреп, ишетеп, сизеп алган баш, кул, кеше, агач, су, юл, йорт, икмәк, шикелле сүзләр (объектлар) тиз аңлашыла. Әмма күренми, ишетелми торган әйберләрне таныш булмаган сүз аркылы аңлау читенрәк). Абстракт төшенчәләрне үзләштерү кыен, гарәптән күбрәк җан, намус, җәннәт, дин, фикер һ. б. ш. абстракт сүзләр керә һәм алар фикерләү дәрәҗәсен күтәрә, мәдәниятнын күрсәткече булып тора.

кабиләләр) гарәпләр өчен иң зур бәхет— агачлары күп бакчаларга керү. Чагыштырып карасаң, безнең—татарларның табигатьнен яшел кочагыннан—«җәннәттән» чыкканыбыз да юк. Шулай булгач, без татарларга ниндирәк җәннәт кирәк икән?

Коръән текстыннан без «җәннәтнең» бер түгел, күп икәнлеген аңлыйбыз. Татарча «җәннәт» сүзе бер генә мәгънәле—«оҗмах» «рай». Бәлки аны болай аңлау православие һәм урыс теле тәэсиредер, аларда да «рай» бер генә була. Ана теленә тәрҗемә ителгән «күп җәннәтле динне» татар дөрес аңлармы икән?

Гарәпчә «садака» *(каты «с» белән)*—«дуслык», «сыйдкъ» сүзеннән килә—«дөресен сөйләргә», «ихлас булырга» дигәнне аңлата. Татарча «садака» (сүзлектә ул сүз «сәдака» дип язылa) дип әйтелгән сүзнең мәгънәсен белмәгән кеше юк—ул хәер, хәтта хәер- садака дип тә әйтәләр (милостыня, подаяние мәгънәсендә) гарәпчә ике төрле язылa—«даль» хәрефеннән соң озын «а» сузыгы булса, «садака»—мәгънәсе «дуслык»; кыска сузыклы булса— «хәер». Коръәндә «садака» сүзе күбесенчә «дуслык», «тугрылык», «дөреслек» мәгънәсендә кулланылган. Бусы тәрҗемәченең «ялган дусты» түгелме соң?

«Залим» сүзе татар телендә «тиран» мәгънәсендә генә кулланыла. Ләкин Коръәндә, мәсәлән, мондый җөмлә дә очрый: «...Аллаһ сугыштан баш тарткан залимнәрне белә» (2:246). «Залим» кем ул? Сугышка барырга теләмәүче, хәзергечә әйткәндә—«дезертир».

Хәзерге татар телендә бөтенләй кулланылмаган **«тәхкыйк»** сүзе Ногмани тәрҗемәсендә бик еш очрый. Ул бер нәрсәнең дөреслеген тикшерү, «хакыйкатьне эзләү», «шиксез» мәгънәсендә дә йөри.

Ногмани 100 сүрәнең 7 аятен болай тәрҗемә иткән: «Тәхкыйк имансыз кеше үзенең имансызлыгына Аллаһуга каршы кылган эшләре белән гуаһдыр». Монда «тәхкыйк» сүзенең урынын табып булмады, «гуаһ» (танык, шаһит) исә хәзерге телдә бөтенләй юк. Бу аятьне Батулла ансат кына тәрҗемә итә: «Хактыр ки, ул яман кылмышлары белән алар көферлекләренә үзләре шаһит».

Аңлашылуы читен булган җөмләләр Ногмани тәрҗемәсендә ешрак очрый шул. Мәсәлән, ул 89 сүрәнең 2 аятен болай тәрҗемә иткән: «Вә ун төн белән ант итәм, ул ун төннән морад зөлхиҗҗә аеның әввәлгесе ун көннәредер, яки Рамадан аеның ахыры ун төннәредер». Р. Батулла шул ук аятьне болай бирә: «Ун кичәнең *(Зөлхиҗҗә аеның)* исеме изге булсын...». Тәрҗемәче монда «ант итәм» сүзеннән киткән һәм аятьнең мәгънәсен бик матур биргән..

«Чыктым аркылы күпер»

Тәрҗемәнең тагын бер кыенлыгы: гарәп һәм татар синтаксисларының аермасында, дип инде әйтелгән иде. *(Кара: «Нәху кирәкме соң?»)* Әйтик , Габдулла Тукай урыс теле синтаксисына ияреп татарча язуны усал итеп тәнкыйтьләгән. Ни өчен дисәгез, татар теленең логикасын бозган өчен. Гарәп телендә логик предикат, урысча «перешел через мост» кебек, субъекттан алда бара. Без моны Коръәннән беренче сүрәсе «Фатиха»дан ук күрәбез. «Әл-хәмду лилләәһи раббиль-галәмин ар-рахмәнир-рахим». Туры тәрҗемә: «Дан *(булсын)* Аллаһуга халыклар тәрбиячесе, мәрхәмәтле, рәхимле»,—дип татар теле грамматикасын ватып-сындырып тәрҗемә иткән аятьләрне аңларга тырышабыз. Әгәр «Мәрхәмәтле, рәхимле халыклар тәрбиячесе Аллаһка дан *(булсын)*» дисәк, бу аятьләр үзеннән-үзе дә аңлашыла.

Тагын бер мисал алыйк. Коръәндә: «1) Куль әгузу би-рабби-ль фәләкъ. 2) мин шарри ма халәка. 3) ва мин шарри гасикыйн изә вакаба.» Урысчага тәрҗемәсе: «1) Скажи «Ищу я убежища у Господа зари». 3) От зла того, что сотворил Он. 3) И от зла тьмы кромешной, когда она приходит».

Формаль логика нигезендә бу өч аятьнең структурасы болай үзгәрергә тиеш: 2-3-1, ягъни: «2) От зла того, что сотворил Он, 3) И от зла тьмы кромешной 1) скажи «Ищу я убежища у Господа зари».

Урыс телендә «туры тәрҗемә» инверсиягә саналу ихтимал. Ләкин татар теленә бу бер дә килешми, чөнки татар теле грамматикасында логик предикат (хәбәр) ахырда куела («күпер аркылы чыктым»). Шуна күрә өченче аятьне үзен генә бирү ялгыш тәрҗемәгә китерә...

1) Таң Хуҗасына сыенам (Куль әгузу би-раббиль-фәләкъ); 2) Ул яралткан усаллыкның (мин шарримa халака); 3) Дөм караңгылык усаллыгыннан, әгәр килә күрсә.

Бу—Җәлил хәзрәт тәрҗемәсе *(икенче бүлек, 192 бит,—тәрҗемәнең өченче*

варианты). Ничек дөрес булыр иде? Татар синтаксисы буенча, бәлки, киресенчәрәк язарга кирәктер: «2) Ул яралткан усаллыктан, 3) әгәр килә күрсә, дөм караңгы усаллыгыннан, 1) Таң Хуҗасына сыенам».

Синтаксиска карата тагын бер мисал (92:20): «Мәгәр сәваб вә нигъмәтләр бирелер, ахирәт өчен кыла торган гамәлләрен фәкать Аллаһ ризалыгы өчен генә һәм Аллаһ кушканча гына кылган тәкъва кешегә». Бирелдә дә логик предикатны татар җөмләсенең азагына күчерү дөресрәк булыр иде, ягъни... «тәкъва кешегә... сәваб вә нигъмәтләр бирелер» дип әйтү дөрес булыр иде...

Фонетика. Һәрбер телдә чит телдән кергән сүзләрнең кыен, читен әйтелешенә үзенә күрә бер фонетик чикләнүләр куела. Мәсәлән, татар теленә урысчадан «председатель», «кровать», «больница» һәм башка шундый татар фонетикасы өчен авыр әйтелешле сүзләр керүен кергән, ләкин тел аларны кабул итмәгән, шуңа татарлар «персидәтел», «карават», «булнис» дип сөйлиләр. Урыс теленә күчерелгән гарәп текстларында да андый хәл булгалый. Мәсәлән, урысларда «җ» авазы булмагач, ул «дж» хәрефләре белән бирелә. Османов «хажж» сүзендәге ишле «җ» не аңлатыр өчен «хадждж итеп биргән. Мондый язуны урыс та, татар да әйтә алмый, әлбәттә.

Гарәп теле фонетикасы урыслар өчен генә түгел, татарлар өчен дә авыр; чөнки гарәпләрдә «гайн», «гәйн», «хәмзә», «ха», «хә» кебек махсус авазлар күп, өчтәрле «с», «х», «з» хәрефләре бар. Аларның бер ишесе татарча Коръән текстында дөрес бирелмиләр. Мәсәлән, Җәлилдә «саллаллаһу галәйһиссәлләм» дип тоташ язылган җөмләне аерып бирергә кирәк, чөнки анда ике түгел, бишләп аерым сүз бар: «Салла Аллаһу галәйһи ва сәлләм» («Аллаһ аңа дога кылды һәм сәләмләде»).

Фонетик тәрҗемәләр әлиф-лямнең (артикльнең)(«әл-китаб», «әс-сәлам» кебек) язылышында да дөрес булырга тиеш. Мәсәлән, «ва йукыймуна ас-салават» урынына «йукиимууна-ссаалаәтә» дип яза Җәлил хәзрәт. Шулай ук еш кулланыла торган «бисмиллә» сүзе дә «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» дип язылса, «ләһир» һәм «рахмәнир» дигән аерым сүзләр бар шикелле тоела. Дөресе болай булырга тиеш: «бисмилләһир-рахим» (яки татар сөйләм телендә әйтелгәнчә, «бисмилләһир-рахмәниррахим» формасында тоташ бирелсә дә зыян булмас (төрекләр, мәсәлән, шулай язалар да). Вак-төяк ялгышлар да очрый: мәсәлән, татарның үзендә еш кулланыла торган «газап» сүзе Җәлил текстында нигәдер гел «гәзәб» дип язылa.

Йомгак сүз. Тәрҗемә вариантлар да, ялгышлар да булуы ихтимал, чөнки Коръән тирән эчтәлекле генә түгел, безнең өчен серле дә Китап. Кайбер авторлар Коръәнне мәгънә ягыннан өч өлешкә бүләләр: беренчесе—**әхлакый тәгълимат**; икенчесе—**дини мәсләк**; өченчесе—**риваятьләр, чагыштырма мәгълүмат**. Безне өчесе дә кызыксындыра, әлбәттә, ләкин беренчесе, тәрбияви җәһәттән, бигрәк тә әһәмиятле дип уйлыйм. Коръәнне ике генә өлешкә бүлүчеләр дә бар. Беренче өлеше—без аңлый алмаган әйберләр (илаһилык, фәрештәләр, изге китаплар, кыямәт көне һ. б. ш.). Коръән аларга ышанырга өнди. Икенче өлеше—безнең аң-белемебезгә «сыя» торган әйберләр. Бу турыда «Гыймран» сүрәсенең 7 аятендә ачык әйтелгән: «Ул Китапта ачык мәгънәле аятьләр белән бергә серләре яшерен мәгънәләре әле ачыласы аятьләр дә күп; аларны Аллаһы белә; гыйлемле кешеләр «без Изге Китапка ышанабыз, чөнки Хаким аны үзе безгә индергән» диләр».

А. С. Пушкинның «...Да притечем и мы ко свету, И да падет с очей туман» дигән сүзләре нәкъ менә шул турыда да инде. Күзебезне ачып карасак, Коръәндә борынгыларның тормыш тәҗрибәсен, фикер йөртү логикасын, идеологиясен һәм чын хакыйкать өчен көрәш барлыгын күрербез. Коръән Сүзенең эчтәлекле мәгънәсе кешеләргә озак һәм акрын ачыла. Беренче карашка Изге язу тарихтан читтә яши сыман, ул вакыт категориясе белән чикләнмәгән, шуңа күрә дә кешелек дөньясына һәр дәвердә аның яңа тарафлары, яклары күренә, аңлашыла башлый. Шул рәвешле кешеләрнең аңына, мәсләгенә диннең йогынтысы бетми, вакыт-вакыт яңара да. Шуңа күрә Изге китапларның яңадан-яңа тәрҗемәсенә халыкларның ихтыяҗы артканнан-арта барачак.

...Хәзерге вакытта «мусульманский экстремизм», «исламский фундаментализм» шикелле сүзләр белән мөселманнарны хур итәргә тырышалар. Бу тәнкыйтьнең нигезе юк, чөнки сәясәтчеләр, беренчедән, сәясәтне дин белән бутыйлар (бандитларны мөэминнәрдән аера белмиләр); икенчедән, христианнар, православие дине вәкилләре мөселманнарга каршы тору традицияләрен йомшак сүз белән булса да дәвам иттерәләр; өченчедән, исламга тискәре караш наданлыктан килә: россияннар Коръәнне түгел, аның мәгънәви эчтәлеге турында Пушкинны да укымыйлар! Кызганыч ки!

Мансур Хәсәновка 70 яшь

ОЛЫ ГАЛИМ, КҮРЕНЕКЛЕ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

Олыгая барган саен үткәнгә, бигрәк тә яшьлек чорына ешрак әйләнеп карыйсың. Кемнәр бар иде... Ничек яшәдек тә ничек «яшьнәдек»... Кемнәр шул еллар чоңгылында югалып калды... Кордашлардан кемнәр бүген яшьлектәге хыял-омтылышларныаклады...

Безнең яшьлекнең иң матур чоры университет, фәнни китапханә залларында китап «кимерү», Лобачевский бакчасында, университеттан Кремльгә сузылган урам буйлап «һава сулап» йөргәндә булган сөйләшү-фикер алышулар, кызлар күзләү, һәртөрле кичәләрдә күңел ачу... белән бәйле. Әй, ул вакытлар! Яшь ассистент та, аспирант та, яшь язучы да, студент та, нәшрият хезмәткәре дә тиң һәм тигез заманалар! Ул вакытта

безнең дус һәм бердәм даирә киләчәктә академиклар, танылган язучылар, профессорлар булачак кешеләрдән тора дип кем башына китергән?! Безне берләштергән рух—ул белемгә омтылу, коммунист-лар вәгъдә иткән матур киләчәккә ышану, шунда ук татарның киләчәге өчен кайгыру, милли мәнфәгатьләрнең юллары торган саен киселә-ябыла баруы өчен пошыну иде. Ә бит туган якларыбыз бик тә төрле, чыгышларыбыз да, характерларыбыз да төрле... Киң эрудицияле, шагыйрь йөрәкле, кайнар холыклы Рәфыйк Нәфыйгов... Тимер логикалы, аек практик акыллы, һәрчак тыныч-сабыр Мирфатыйх Зәкиев... Үз эченә бикләнгәнрәк холыклы, шаян-тапкыр сүзгә рәхәтләнә белә торган Нурихан Фәттах... Тиз мавыгучан, кайвакыт артык самими Хәлиф Курбатов... Кызыксынучан, куләгәдәрәк торырга яраткан, бераз гына хәйләкәррәк Нил Юзиев... һәрвакыт милли рухы бөркеп торган, туры холыклы Фәрит Хатыйпов... Бүгенге милли интеллигенциянең асыл затлары! Алар арасында аз сүзле, бигрәк тә сәяси мәсьәләләрдә бик хәбәрдар, нык хәтерле булуы белән Мансур Хәсәнов аерылып тора. Бүгенге 70 яшьлек аксакал, академик, Татарстан Фәннәр академиясенең Президенты, танылган галим, оста җитәкче...

Оештыруга сәләт, һәртөрле, бигрәк тә рәсми кәгазьләр язуга осталык, купьяклы белемгә омтылу Мансур Хәсән улын студент елларында ук яшьтәшләре арасында аерып куйды. Студентлар арасында инде тормыш тәҗрибәсенә ия булуы (авылда китапханәче булып эшләп килгән), партия әгъзасы (ә факультетта андыйлар бик аз) булуы белән дә бер башка югары тора. Ул бездән (бүгенге күренекле язучылар Әхсән Баянов, Хәниф Хәйруллин, Мәдәният министры урынбасары булып эшләгән Юныс Әминов, профессор Марсель Бакиров, фәннәр кандидаты Римма Галиева һ. б. биргән студентлар группасыннан) бер ел алда укыды. Бүгенге профессорлар Гомәр Саттаров, Рифат Сверигиннар белән бер группада. Иң дәрәҗәле, Сталин исемендәге стипендия алып укыды. Менәрләгән студент арасыннан бердәнбер вәкил буларак университет тормышы белән реаль идарә итүче партком әгъзасы иде. Күз буяу өчен генә, әйдә, студентлардан да бер вәкил булсын инде, дип кертелгән әгъза түгел, ә профессорлар, доцентлар белән тиң әгъза. Җиң сызганып партком эшендә катнашучы. Мин аның партком секретаре

өчен чыгышлар хәзерләгәнен тәгаен беләм. Матур, язгы көн, ә ул парткомда,— комачауламасыннар өчен өстеннән бикләнеп алынган бүлмәдә,—доклад язып утыра. Димәк, бу студент инде профессор эшләсе эшне эшли, тегенәр тик әзер текст белән танышып, җыелыш-мазарда укып чыгасы гына кала...

Яшьлек дустыбыз—яшьтән үк сәяси мәсьәләләр белән кызыксынучан кеше булды. Дөньядагы, илдәге политик тормышта барган үзгәрешләрнең эчке сәбәпләрен барыбызга караганда да тирәнрәк анлый, матбугатта язылганнарның юл араларыннан өстәмә мәгълүмат ала белә. Хәтереме!.. Ул шул вакытларда сәяси тормышта мәгълүм бер роль уйнаган житәкчеләрнең генә түгел, КПССның һәрбер Өлкә Комитеты беренче секретарьларының исем- фамилияләрен белә һәм хәтерли. Аларны никадәр белүемне сынап, мина «имтихан» оештыра. Бервакыт, 1957 елда мин Тоболдан җәйге ялга кайткач булган очрашуларның берсендә мин дә аның хәтерен сынап карадым: партиянең Төмән Өлкә Комитеты беренче секретаренең фамилиясен әйтүен сорадым. Нык ышанам инде: белмәс! Төмән ул вакытта бик тә уртакул бер өлкә (әле нефть һәм газ табылмаган, эзләнүләр генә бара), андый секретарьләр ил күләмендә йөзләрчә. Шаклар каттым: белде бит... Әле бүген дә ул үзе партия Өлкә Комитетында, аннары Татарстан Министрлар Советында эшләгәндә аралашкан кешеләрнең, күрше республикалардагы, өлкәләрдәге, Мәскәү һәм Ленинградтагы житәкчеләрнең исемен-әтисенең исемен хәтерли, алар белән бәйле дистәләрчә истәлекләрне хәтерендә тота. Шул вакытларда илдә барган сәяси тормышның без—гади укучылар—белмәгән, белә дә алмаган әллә нинди четерекле вакыйгаларыннан хәбәрдар, югары эшелондагыларның бер-берсенә шәхси мөнәсәбәтеннән дә дистәләрчә мәгълүмат бирә ала. Һәм аларны бүген тарихи мажаралы хикәят тынлаган кебек тынлыйсын.

Студент елларында без аның белән бер ишек алдында яшәдек. Ишегалды нинди диген? Университетның китапханә, анатомия театры, обсерватория урнашкан—ягъни эчке ягы. Мин анда университет ректораты астындагы бүлмәләрнең берсендә маржа тутәйләрдә 5 ел яшәп укыдым. Күршедә генә бүгенге профессор, әдәбият галиме Рифат Сверигин яши. Бераз арырак, университетның техник хезмәткәрләре Зәкәрия абый белән Зәйнәп апаларда, шулай ук подвалда Мансур Хәсәнов фатир алып торды. Ул чакларда аның белән аралашулар бик үк еш булды дип әйтә алмыйм. Чөнки аның буш вакыты юк иде диярлек: факультет, аннары университет күләмендәге һәртөрле җәмәгать эшләре аның вакытын бик ала. Ул елларда студент тормышы кайнап тора: һәртөрле җыелышлар, масса күләм чаралар, дивар газеталары чыгарулар, фәнни түгәрәкләрдә актив эшләү, шәһәрдәге мәдәни кичәләргә йөрү, язучылар, композиторлар белән очрашулар—без аларда катнашуны үз бурычыбыз итеп саный идек. Ә бит Мансур—гади студент кына да түгел, татар бүлегенең, алай гына да түгел, тарих-филология факультетының һәм универси-тетның горурлыгы, сүзе укытучыларга да, деканатка да, партия оешмаларына да житә торган шәхес, житди шәхес. Имтиханнарын да ул гадигадәтенчә генә бирми, сессиягә кадәр үк күбесен тапшырып бетерә, (барысын да бишкә!) каникулларга алданрак чыга, киләсе уку елына мая туплау өчен төрле эшләрдә эшли... Ә менә ул аспирантурада укыганда аралашулар ешрак булды, ул минем якын киңәшчеләремнән берсе иде.



Яшь галимнәр—Нил Юзиев, Мансур Хәсәнов һәм Азат Әхмәдуллин. 1956 ел.

Мансур Хәсән улы гомере буе житди кеше булды. Укуда һәм хезмәттә генә түгел, шәхес буларак та житди, хәтта, мин әйтер идем, кырыс ул. Бу аның олы житәкче

урыннарда эшләгәндә барлыкка килгән хасияте түгел, яшьтән үк аның характеры шундый булды. Кичәге иптәш һәм дус итеп нииндидер үтенеч белән килсәң дә ул бик үк ачылып китми. Ләкин белеп торасың, ул синең үтенечеңне аяк астына салмаячак, кулыннан килгәнчә ярдәм итәчәк. Мин үзем аңар кичәге дуслыктан файдаланып мөрәҗәгать итүдән сакланырга тырышам, дистанция саклыйм. Зур, һәрчак эштәге житәкчене артык борчыйсым килми. Ә инде аңардан алган ярдәмне онытмыйм, күңелемнән рәхмәт укыйм. (Еш кына рәхмәтемне әйтеп тә бетермимдер, чөнки беләм, ул артык кәнфитләнүне яратмый.) Бер генә мисал. Аспирантура тәмамлагач партия Өлкә Комитеты мине Татарстан дәүләт радиокомитетына художестволы тапшырулар буенча баш редактор итеп эшкә жибәрде. Бу җаваплы һәм авыр хезмәттә ел ярым эшләгәч минем сәламәтлегем тәмам какшады. Шул арада миңа Тел, әдәбият һәм тарих институтына эшкә кайтырга тәкъдим булды. Моның өчен югары оешмаларның рөхсәте кирәк иде. Һәм мин ул вакыттагы Өлкә Комитетының мәдәният бүлеге мөдире булып эшләүче Мансур Хәсәновка киңәш һәм ярдәм сорап мөрәҗәгать иттем. Һәм аның ярдәме белән генә радиодан китә алдым...

Кирәк урында, кирәк вакытта Мансурның күңел сизгерлеген раслый торган мисал-дәлилләр миндә җитәрлек. Мәсәлән, архивымда аның мин Тобол педагогия институтында эшләгәндә язган хатлары саклана. Җылы, дустанә, кайгыртучан хатлар. Чит-ят җирдә эшләп яткан дустының хәлен, Казанны сагынуын аңлап-белеп язган хатлар... Берсе аерата истәлекле. Ул анда үзенең яңа гына өйләнгәч булган кәеф-хәлен, кәләше Разиянең күркәм гадәтләрен, хис-тойгыларын бәян итә. Чын шигъри поэма! Шул хатында тасвирлаган хисләренә ул гомере буе тугры калды, сабыр, иплe-итагатьле Разия ханым белән бәхетле гаилә төзеп, ике тәүфикълы малайлы булдылар, дүрт онык үстерешәләр...

Мансур Хәсән улының университеттан һәм аспирантурадан соңгы хезмәт юлы текә булды, үсеше тиз булды. Кыска-кыска араларда татар әдәбияты кафедрасында ассистент, тарих-филология факультетында декан урынбасары, «Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире булып эшләде. Бүген кайберәүләр ул еллардагы партия номенклатурасындагы кадрларны гел дә бетереп ташлау ягында торалар. Юк шул. Бик сирәк очраклардан кала партия органнары үзләренә кадрларны сайлап ала һәм үстерә белә иде. Бу очракта да шулай. Тырыш, перспективалы егетне партиянең Өлкә Комитетына лектор итеп алалар. Озак та үтми мәдәният бүлеге мөдире итеп билгелиләр. Пропаганда, фән, мәгариф, мәдәният эшләрен алып бару өчен зур, берләштерелгән бүлек оештырылгач, М. Хәсәнов бүлек мөдире урынбасары булып эшли, аннары фән һәм уку йортлары буенча мөстәкыйль бүлекне җитәкли.

Директив органнарда эшләп зур тәҗрибә туплаган, инде шул арада докторлык диссертациясен дә яклап өлгергән профессор М. Х. Хәсәновны 1971 елда ТАССР Министрлар Советының рәисе урынбасары итеп билгелиләр. Ә 1984 елдан 1992 елга кадәр инде ул—рәиснең беренче урынбасары. Беренче урынбасар җитәкләгән өлкәләрдәге (Мәгариф, Мәдәният, Сәламәтлек саклау министрлыклары, иҗтимагый тәэминат, радио һәм телевидение, физкультура-спорт, даруханәләр, дини эшләр, архив һ. б. дистәләрчә комитетлар, идарәләр һәм бүлекләр, иҗат оешмалары) эш—тавык чүпләп бетермәслек. Кыскасы, республиканың рухи-мәдәни тормышы һәм сәламәтлек торышы тулысынча аның карамагында. Мансур Хәсән улына кадәр ул вазифаларны башкарган Рәйсә Юныс кызы Ярмөхәммәтованың (хатыным Фираяның бертуган апасы) әйтүенә караганда республиканың барлык бюджетының 80 %—нәкъ менә шушы җитәкче карамагында. Яңа уку йортлары ачу, музейлар булдыру, һәйкәлләр торгызу, больницалар, спорт-комплекслар, уку биналары кордыру һ. б. кебек дистәләрчә мәшәкатьләр, тарихта калырлык җаваплы һәм күңелле мәшәкатьләр белән көн саен, айлар һәм еллар саен шөгыльләнү өчен көч-җегәр генә түгел, акыл һәм компетентлык та кирәк. Әйтик, әнә Казанда Мулланур Вахитовка һәйкәл кую мәсьәләсен хәл итү өчен Мәскәү юлы ничә мәртәбәләр тапталган, иң югары оешмаларның карарын чыгарту өчен күпме көч, осталык һәм белем сарыф ителгән! Ә инде урыннар сайланып төзү эшләре башлангач, бүген әйтергә дә көлке саналырлык «киртә» килеп чыга: шәһәрдәге һәйкәлләр В. И. Ленинның Азатлык мәйданындагы сыныннан да биек булырга тиеш түгел икән! Ә болай барса, Мулланур Вахитов һәйкәле биегрәк булырга тора?! «Хәсәнов ни караган?!!» Моңысын уңай хәл итү өчен дә күпме дипломатик осталык һәм нервылар кирәк...

Мансур Хәсән улы республика җитәкчелегенең бер җаваплы әгъзасы булып торган 31 ел дәвамында эшләнгән мондый эшләрнең кайберләрен генә атап китик: Тукай-Кырлай авылында Г. Тукайның мемориаль комплексын төзү, Казанда шагыйрьгә

музей ачу, Казан мәдәният институты (бүгенге мәдәният һәм сәнгать академиясе), Чаллыда педагогия институты, Казанда Волгоград физкультура һәм спорт институтының филиалы (бүген ул Чаллыда мөстәкыйль институт буларак яшәп килә) ачу һ. б. һ. б. Бу елларда партия Өлкә Комитетында да, Министрлар Советында да милли мәсьәләләр буенча төп белгеч, милли кадрларны иң яхшы белүче—ул Мансур Хәсәнов булгандыр, шәт. Шуңа күрә дә мондый эшләрдә төп авырлык һәм җаваплылык аның өстенә төшә.

Республикадагы рухи тормыш өчен җаваплы кешеләрнең берсе буларак бүгенге юбиляр мәгариф, мәдәният һәм сәламәтлек өлкәләренең материаль-техник базасын ныгытуны үз эшчәнлегендә төп юнәлешләрнең берсе итеп карый. Мәсәлән, 20 ел эчендә республикада 500.000 укучыга исәпләнгән 1000 нән артык мәктәп төзелә. Ә ул вакытта республикада гомум урта белем мәктәпләрендә барлыгы 500 мең укучы булуын исәпкә алсак, мәктәпләрнең укыту-материаль базасы өр-яңадан эшләнгән дип әйтә алабыз. Ә күпме профессиональ-техник училищелар (ПТУ) ачыла! Кыскасы, бу вакыт эчендә һәр район ПТУ лы (ә кайберләүләре икешәр училищелы) була. Мәгариф учаклары өчен спортзалы булган, укыту-техника җиһазлары белән тәэмин ителгән заманча яңа биналар төзү буенча 70-90 елларда Татарстан Бөтенсоюз һәм Россия күләмендәге ярышларда гел дә I яки II урыннарны алып килгән, Күчмә Кызыл Байракны үз кулында тоткан икән инде, монда М. Хәсәновның да өлеше зур иде. Сәламәтлек саклау (больницалар, амбулаторияләр, аптекалар), мәдәният (клублар, китапханәләр, мәдәният сарайлары), мәктәпкәчә яшьтәге балалар (бакчалар, ясләләр) учреждениеләре белән дә шул ук хәл. Бүген совет чорындагы һәммә нәрсәне, йомшак кына әйткәндә, исәпкә-санга сукмау модада. Ә бит югарыда саналганнар—партия һәм совет органнарының алдан күреп, план нигезендә алып барган, Ф. Табеев, Г. Усманов, М. Хәсәнов кебек җитәкчеләрнең, урыннардагы җаваплы кешеләрнең дә уңай эшләре нәтиҗәсе. Аларга тиешенчә бәя бирә белергә, мондый уңай хезмәтләре өчен бүген зур итеп рәхмәт әйтә белергә дә кирәк.

Шул ук вакытта бүгенге академикны без галим, аерым алганда әдәбият белеме

Мансур Хәсәнов Фәннәр Академиясенең еллык йомгак җыелышын алып бара. Президиумда уңнан сулга: академиклар К. Ә. Вәлиев, К. М. Салихов, И. Х. Фәхретдинов, Ф. Х. Хәмидуллин, халык депутаты Р. И. Вәлиев, Дәүләт Советы рәисе Ф. Х. Мөхәммәтшин һәм академик Л. П. Зарипова.

буенча иң абруйлы, иң зур белгечләрнең берсе дип таныйбыз. Киң масштаблы оештыру һәм җаваплы җитәкчелек эшен җитди фәнни тикшеренүләр белән бергә кушып алып бару үзе генә дә аны хөрмәтләргә җитә.

Мәгълүм ки, татар әдәбият белемен үстерүне дәвам иттерүдә төп учаклардан берсе—Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы. Аның шәкерте буларак Мансур Хәсәнов биредәге иң алдынгы традицияләрне тирән үзләштергән. Ул—

олы галимнәр Хатип Госман һәм Якуб Агишевлар шәкерте. Аның беренче җитди гыйльми хезмәте булган—Галимҗан Ибраһимовның беренче чор иҗаты турындагы кандидатлык диссертациясе (ул аны 1961 елда яклаган иде) Фәнни һәм әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын шунда ук җәлеп итте. Чөнки олы язучының мирасы укучыга яна гына кайтарылган вакыт. Безнең буын укучылары аны ишетеп кенә белә: халык дошманы! Һәм без шуңа чын күңелдән ышанабыз. Әле шул стереотип фикер хакимлек иткән чорда диссертация авторы Г. Ибраһимовның әсәрләрен һәм хезмәтләрен анализлап аларның татар әдәбияты тарихындагы лаеклы урынын дөрес билгеләде. Моның өчен XX гасыр татар матбугатын һәм әдәбиятын, бигрәк тә 1917 елга кадәрге өлешен җентекләп өйрәнде. Ә бит ул хәзинә берничә дистә журналлар, йөзләрчә газеталар һәм китаплардан тора. Аларны укып-өйрәнеп чыгу өчен генә дә аспирантка көне-төне баш күтәрми китапханәләрдә һәм архивларда утыру кирәк булды. Әгәр дә 80-90 елларда әдәби һәм мәдәни мирасыбызны халыкка җиткерү процессында бу өлкәләрнең күренекле вәкилләре Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Шиһабетдин Мәрҗани, Фатих Кәрими, Гаяз Исхакый, Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан һ. б. турында, аларның иҗтимагый фикергә, әдәбиятка, мәдәниятка алып килгән яңалыгы, әдәбият-мәдәният тарихындагы урыны турында гомумиләштерелгән саллы фикерләр әйткән һәм әйтә килә икән, монда Мансур Хәсәновның шул елларда ук язма һәм басма рухи мирасыбызны тирән өйрәнгән булуы җирлек булып тора.

Бүгенге татар әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть галимгә бигрәк тә түбәндәге хезмәтләре өчен бурычлы. Аларны берничә тармакка аерып карарга мөмкин.

Илдә үзгәртеп корулар башлангач, әдәбиятны да тоталитар система кануннары басымыннан коткару бурычы иң мөһиме булып алга килеп басты. Икенче сүзләр белән әйткәндә, матур әдәбиятны (һәм сәнгатьне дә) өйрәнүнең методологик һәм методик принципларын ачыкларга һәм яңартырга кирәк булды. Мәгълүм инде, совет чорында әдәбият белеме һәм тәнкыйть әсәрләрне сыйнфый күзлектән торып бәяләүне алга куеп эш йөртте. Чөнки кешелек җәмгыятенең үсешен бары тик сыйныфлар көрәше генә барлыкка китерә дип раслана иде. Һәр әсәрдә, шул җөмләдән хәтта әллә кайчан, Урта гасырларда ук иҗат ителгәннәрендә дә сыйнфый-иҗтимагый конфликт эзләү кагыйдәгә әверелгән иде. Бусы бердән. Икенчедән, күмәкчелек (коллективчылык) шәхесне күмеп китте, ягъни кеше, иң беренче, башкалар өчен яши, җәмгыять интересларын гына кайгыртырга тиеш, дигән советчыл аксиома шәхес мәнфәгатьләрен артка чигерде. Нәтиҗәдә әдәбият иҗтимагый вазыйфаларында гына түгел, сәнгатьчә камиллеккә ирешүдә дә кимчелекләр кичерде. Чөнки шәхси мәнфәгатьләрне икенче сортлы нәрсә итеп карау матур әдәбиятны үзенең иң көчле коралларыннан берсе булган психологизмга тиешле бәя биреп җиткерә алмауга китерде.

Бүгенге әдәбият гыйлеме һәм әдәби тәнкыйть боларны дөрес аңлый, кичәге хаталарны ачып салырга, аларны кабатламаска тырыша. Бу яктан Мансур Хәсәнов хәзерге теоретикларның алгы сафларында бара. Без моны галимнең татар әдәбияты тарихына караган хезмәтләрендә, аерым алганда югарыда әйтелгән Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Г. Исхакый, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, шулай ук Г. Камал, К. Тинчурин һ. б. бөек язучыларга багышланган мәкаләләрендә һәм чыгышларында күрәбез. Ул бигрәк тә милли әдәбиятыбыз тарихында күренекле роль уйнаган әдип һәм җәмәгать эшлеклесе, галим һәм публицист Галимҗан Ибраһимов иҗатын тирән өйрәнде, аерым иҗади шәхеснең мирасын фәнни тикшеренүләрнең үрнәге булырлык хезмәтләр бирде. Мина аның докторлык диссертациясен яклавында (1971 ел) булырга туры килде. Мәскәүдәге СССР Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтында. Галимҗан Ибраһимов иҗатының Октябрь революциясеннән соңгы чорлагы эволюциясенә багышланган хезмәт Махсус Совет әгъзалары тарафыннан бик тә уңай бәяләнде, яклау бик югары кимәлдә узды. Аерым алганда, оппонентларның берсе—Көнчыгыш әдәбиятлары белгече, күренекле галим И. С. Брагинский диссертациянең татар әдәбият белеме өчен генә түгел, башка төрки халыклар гуманитар фәннәре өчен дә әһәмиятле булуын билгеләп узды. Соңрак танылган әдәбият галиме, СССР Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы Г. И. Ломидзенын да М. Хәсәнов хезмәтләрен югары бәяләвен беләм. Г. Ибраһимов турындагы кандидатлык һәм докторлык диссертацияләренә таянып галим зур күләмле монография язды, аны Мәскәүнең «Наука» нәшриятында бастырды. Ул Казанда да берничә басмада дөнья күрде.

Вакытында Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясен әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендәге хезмәтләргә дә бирәләр иде. Нил Юзиевкә бу бүләк шул вакытта

бирелде. Шулай, бу премияләргә кандидатуралар тикшергәндә, академик М. Зәкиевнең «бүген бу премиягә иң лаеклы хезмәт ул, әлбәттә, Г. Ибраһимов турындагы монография» дигәнен хәтерлим. Ләкин, нишлисең, шул эшнең башында утырган кеше үзен алга куя алмый иде шул инде!

Классик әдип турында тирән, тулы, комплекслы хезмәт буларак бу китаплар менә ничә еллар инде югары уку йортларында милли әдәбиятларны һәм иҗтимагый фикер тарихын өйрәнүче студентлар өчен уку әсбабы, татар әдәбиятын язганда терәк төсендә хезмәт итәләр. Урта мәктәпләр өчен татар әдәбиятыннан дәреслекләргә М. Хәсәнов язган Г. Ибраһимов турындагы бүлек тә гаять уңышлы булып чыкты. Бу дәреслекләр инде егермеләп мәртәбә басылды. Аларның фәнни редакторы буларак миңа һәр басмага тиешле өстәмәләр, үзгәрешләр кертергә туры килә. Ә менә Г. Ибраһимов турындагы бүлекләргә редактор төзәтмәләре бик үк кертелми, чөнки алар бүген язылгандай, методик-педагогик таләпләргә дә, чор таләпләренә дә җавап бирә.

Галимнең бу олы әдип һәм күренекле шәхесне тирәнтен өйрәнүе аның 8 томлык сайланма әсәрләрен әзерләп бастыруда да күренде. Татар әдәбияты тарихында мондый күләмдәге күптомлыкның чыкканы юк иде әле. Басманың инициаторы да, редколлегия җитәкчесе дә, томнарга кереш сүзне язучы да Мансур Хәсәнов булды. Монда тагын Фатих Әмирханның 4 томлы җыентыгы да аның җитәкчелегендә әзерләнеп басылып чыгуын да искә алырга кирәк. Аның җитәкчелегендә Гаяз Исхакыйның 15 томлыгы басыла башлады. Аның ике томы чыкты да. Бу зур хезмәтне әдипнең иҗат мирасын төрле яклап анализлаган һәм яктырткан «Татар ренессансының бөек каһарманы» исемле әтрафлы һәм җитди кереш мәкалә ачып җибәрде, авторы—Мансур Хәсәнов.

Бүгенге юбиляр әдәбият тарихын өйрәнүне татар иҗтимагый һәм фәлсәфә фикерен өйрәнү белән бергә бәйләп алып бара. Ә бит әдәбиятыбыз белеменә нәкъ менә шул җитми. Аның фәнни эзләнүләренең үзәгендә милләтнең яңадан тууы (Янарыш) проблемалары ята. Монда аның татар ренессансының нигез ташларын салган, XIX гасырның икенче яртысында һәм XX йөз башларында иҗат иткән Ш. Мәрҗани, Г.Исхакый, С. Максуди, Р. Фәхретдинов, М. Бигиев һ. б. кебек шәхесләргә багышланган методологик характердагы, төрле гыйльми җыентыкларда, журнал һәм газеталарда басылган фәнни мәкаләләрен, конференцияләрдә укылган доклад-чыгышларын аерып күрсәтергә кирәк. Хәзерге вакытта академик бу темага зур монография өстендә эшли, дөресрәге, аны тәмамлап килә, ел ахырына кадәр бастырып чыгарырга ниятли. Мансур Хәсәнов каләме астыннан чыккан йөзләрчә мәкалә, дәреслекләр, 5 монография янына тагын бер җитди монографик хезмәт өстәләчәк. Ә ул хезмәтләр арасында татарча һәм русча гына түгел, инглиз, төрек һ. б. телләрдә басылып чыкканнары да бар.

Татарның янарыш темасын өйрәнүне галим әдәбият, фәлсәфә, иҗтимагый фикер өлкәләрендәге алда әйтелгән тикшеренүләре белән генә түгел, милли сәнгатьнең башка тармаклары, аларның тарихы, культурология мәсьәләләре белән бәйләп, ягъни киң мәгънәсендә комплекслы алып бара. Аның Салих Сәйдәшев, Баки Урманче, Нәҗип Җиһанов, Рөстәм Яхин, Хәлил Әбҗәлилов һ. б. турындагы мәкаләләре һәм чыгышлары шуны раслый. Шулай ук аның милли азатлык хәрәкәтенең күренекле эшлеклеләре Мулланур Вахитов, Мирсәет Солтангалиев турындагы хезмәтләре дә шул теманың бер өлеше булып тора. Милли кыйммәтләребезне, гомуми милләтебезне саклап калу гына түгел, ә торгызу, алга үстерү юлында мондый хезмәтләр, әлбәттә инде, зур роль уйный.

Әйе, зур җитәкчеләрнең берсе буларак Мансур Хәсәнов Татарстанның сәяси-иҗтимагый тормышында да, мәдәнияте, сәнгате һәм әдәбияты барышында да күренекле роль уйнады һәм уйный. Мәгариф, югары һәм махсус урта белем учаклары буенча мисалларны алда китердек. Әдәбият һәм сәнгать буенча аның 21 ел буена (1971-1992) Г.Тукай исемендәге дәүләт премияләрен бирү комитетын җитәкләвен дә өстик. Ә 1993 елдан алып ул—Татарстан Президенты янындагы фән һәм техника буенча дәүләт премияләре бирү комиссиясенең рәисе.

Мәгълүм булганча, Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итүгә хәзерлек башланды. Бу датаны Россия Президенты В. В. Путин «бөтендөнья тарихы өчен дә мөһим», дип әйтте. Дистәләрчә елларга сузылган әлеге бәхәсле мәсьәләне тәмамән хәл кылуда Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты һәм Казан дәүләт университеты галимнәре күп көч куйды. Эшнең иң кызган һәм җаваплы чорында Казан галимнәренә, шәһәр хакимиятенә халыкара фәнни җыелыш-киңәшмәләр уздырып абруйлы белгечләрнең фикерен ишетергә, фәтвасын алырга кирәк булды. Чыннан да, Мәскәүдән, С. Петербургтан, 20 ләп чит илләрдән галимнәр катнашында өч шундый конференция эшләде. Аларның карарлары Татарстан Фәннәр академиясе Президиумында, Россия

Фәннәр академиясенең Тарих бүлемендә яклау тапты. Һәм шулар нәтиҗәсендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Президентлары 2005 елда Казанның барлыкка килүенә 1000 ел тулуны киң билгеләп үтү турында указлар кабул иттеләр. Бу эшләрнең актив катнашучысы, оештыручысы күп вакытта ТФА Президенты М. Х. Хәсәнов булды. Һәртөрле документлар аның кулы аркылы үтте, соңгы кат редакцияләнде, кире каккысыз уңай формулировкалар төсен алды. Ул—бу бәйрәмне хәзерләү һәм уздыру буенча Россия Президенты җитәкчелегендә оешкан комиссиянең әгъзасы буларак эш алып бара.

Әйе, 1991 елда Татарстан Фәннәр академиясе төзелеп, аның Президенты итеп сайлангач (1992 елның феврале) академик Хәсәновның фәнни-оештыру эшчәнлеге яңа бер баскычка басты. Төрле өлкәләрдәге, бөтендөньяда танылган фәнни мәктәпләргә ия булган Татарстан җөмһүрияте һәм Казанның галимнәрен бер түбә астына җыйнаудан башлады эшне Президент. Гаять зур фәнни потенциалны Татарстан файдасына да, Россия киңлегендәге гыйльми мөмкинлекләрне үстерү юнәлешендә дә, Бөтендөнья күләмендәге казанышларга ярашырлык төстә дә кулланып тәрәккый иттерүнең төп, приоритетлы юллары билгеләнде. Кыска гына вакыт эчендә безнең Академиябез үзенең төп бурычын— фәнни эшләрне координацияләү, фәнни тикшеренүләрнең нәтиҗәләрен практик тормышка ашыру, республиканың җитештерү көчләренә актив һәм нәтиҗәле төстә булышу бурычын үтәү югарылыгына күтәрелде. Бүген Академия фәнни потенциалны республиканың төп җитештерүче көчләреннән берсенә әйләндерде. Җәмәгатьчелек күптән хыялланган капиталь хезмәтнең—Татар энциклопедик сүзлегенең басылып чыгуы бөтен фәннәрне бер түбә астына җыйнап эш итүнең матур бер мисалы булды. Бу эш белән турыдан-туры шөгыльләнүче Энциклопедия институтының да академик М. Хәсәнов директорлыгында яшәвен әйтергә кирәк. Хәзер Татар энциклопедиясенең күптомлы басмасын хәзерләү эше дә бик актив һәм нәтиҗәле бара. Боларның барысын да М. Х. Хәсәнов җитәкли. Шуның өстенә бит әле аның «Фәнни Татарстан» журналының оештыручысы һәм баш редакторы булуын да искә алырга кирәк.

Ничек өлгерә диген?! Югарыда сөйләнгән барлык эшләре өстенә бүгенге юбиляр— татар әдәбиятчыларының якын киңәшчесе һәм булышчысы да. Аның бу җәһәттәге хезмәтен күрсәтү өчен бер-ике сан китерү дә җитәр кебек: академик җитәкчелегендә дистәдән артык докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре якланган; ул 12 докторлык һәм күп кенә кандидатлык диссертацияләре якланганда рәсми оппонент булган. Казан дәүләт университеты һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты каршындагы докторлык һәм кандидатлык диссертацияләрен яклау буенча махсус советларның әгъзасы төсендә дә ул фәнни кадрлар хәзерләүгә үз көчен кертә. Күп кенә фәнни конференцияләрдә катнашырга да вакыт таба. Шул җөмләдән—чит илләрдәге фәнни форумнарда да. Ул Румыния, Венгрия, Австрия, Шри-Ланка, Польша, Франция, Төркия, Швейцария, АКШ, Канада, Куба, Германия h. б. кебек илләргә барган фәнни, хөкүмәт яки парламент делегацияләрен җитәкләде яки әгъзасы булды.

Татарстан Фәннәр академиясен оештырган һәм аның академигы итеп сайланган М. Х. Хәсәнов шулай ук Халыкара информатизация академиясе, Россия гуманитар академиясе, Россия технология академиясе, Чувашстан милли академиясенең хакыйкый әгъзасы, Төрек гуманитар фәннәр җәмгыяте һәм Американың Мериленд университеты каршындагы «Көнбатыш—Көнчыгыш» фәнни советы әгъзасы h. б. Дәүләт күләмендәге, фәнни һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен ул ике мәртәбә Хезмәт Кызыл Байрагы (1966, 1986), «Халыклар Дуслыгы» (1980), «Почет Билгесе» (1971) орденнары, «Бөек Ватан сугышы (1941-45) елларындагы данлы хезмәт өчен» h. б. медальләр белән бүләкләнде. Шулай ук ике мәртәбә (1980, 1990) ТАССР Югары советы Президиумы, Әзербәйҗан ССР Югары советы (1972) Мактау грамоталары белән бүләкләнде, «СССР Мәгарифе отличнигы» (1981), «РСФСР Халык мәгарифе отличнигы» (1978) билгеләрен дә йөртә. Ә 1994 елны Кол Гали исемендәге халыкара премия, 1995 елда Татарстанның атказанган фән эшлеклесе исеме бирелде.

Хөкүмәт, төрле җәмәгать оешмалары тарафыннан бирелгән күпсанлы бүләкләр һәм исемнәр өстенә халык мондый шәхесләрне үзенчә итеп «егет кеше» дип атый. Мансур Хәсән улы Хәсәнов—бу үтемле сүзгә тулысынча лаеклы кеше. Юбилей котлы булсын, ныклы сәламәтлек, яңадан-яңа иҗат уңышлары Сезгә, данлы академигыбыз!

Азат ӘХМӘДУЛЛИН,

Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы.

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Рецензияләр конкурсы

ШАГЫЙРӘНЕҢ ХЫЯЛЫНДА ЙӨРТКӘН КИТАБЫ

Бу китапны кулга алган саен күз алдыма килә дә баса Сажидә, килә дә баса: нәни генә куллары белән күкрәгенә җыентыгын кыскан, зәңгәр күзләре монсу гына елмая кебек... Китапның затлы дерматин белән төрелгән конгырт тышлыгына, алтынсу бизәкләр эченә «Тормыш, исәнме» дип куелган. Әмма миңа бу сүзләрне дә, чиядәй мөлдерәмә иреннәрен сабыр кыймылдатып, автор үзе пышылдый шикелле тоела:

... Гомер озын, дисәм, рас булырмы,
Сиздерми дә узды, дисәмме?
Күп тә түгел, гомер, аз да түгел,
Бер икәнсең,—тормыш, исәнме!

Мөхтәрәм укучым аңлагандыр инде—мин Сажидә Сөләймманованың 1998 елда «Рухият» нәшрияты тарафыннан чыгарылган шигырьләр җыентыгы турында сүз алып барам. Мөхәррире—Әдип Маликов, төзүчеләре—Асия белән Әнвәр Маликовлар, җаваплы мөхәррире—Илсөяр Хәйруллина.

Китап Әдип Маликовның «Табулар һәм югалтулар» исемле кыска гына кереш сүзе белән ачыла. Бу кереш, зур булмаса да, шагыйрәнең тормыш юлын, ифрат нечкә хисләргә төреп, тулысынча тасвирлап бирә. Без мондый җыентыкларны кулга алгач, озын-озын кереш-аңлатмалар укып интегә торган идек. Укымый китсәң, яхшы түгел кебек, ә инде төшенергә теләп, җентекләп өйрәнә башласаң, һич очына чыгып булмый. Анда авторның бөтен иҗатын, кечкенә генә әсәрләрен дә кертеп, анализ ясала торган иде. Әдип Маликов исә Сажидәнең шигырьләрен укучының үз хөкеменә тапшырып бик дөрес эшләгән. Алдан кемдер «чәйнәп» бетергәч, аларны укып торасы да калмый лабаса. Аның каравы монда шагыйрәнең кеп-кечкенә чагыннан башлап вафатына кадәр күргән-белгәннәре, кичерешләре, тырышып-тырышып яшәве, әти-әнисе, гаиләсе турында тулы мәгълүмат бирелә.

Гадәттә, әдәбият галимнәреннән яздыртыла торган кереш сүзләрнең очына чыга алмый интеккән укучы әлеге керешкә күз салса, аннан аерылып китәргә теләмәячәк. Чөнки мондагы һәр сүз, телгә алынган һәр вакыйга авторның үз күзе белән күреп, йөрәгә аша үткәрелгән хәлләрне генә, ягъни бары тик хакыйкатьне генә сурәтли. Әдип Маликовның бу мәкаләсе һичнинди шапырынуларга да, купшылыкларга да кызыкмыйча, ихлас күңелдән язылган булуы әдипләрнең тормышы турында язарга алынган тәнкыйтьчеләргә үрнәк итеп тоттырырлык. Югыйсә, Сажидә Сөләймановань Әдип абыйдан да яхшырак белүче юк, ул—аның ире дә, иҗат сердәше дә. Укучыны шаккатырам, дисә, әллә ниләр уйлап чыгарган булыр иде. Бәхеткә, Әдип абый ул мавыктыргыч, әмма хәтәр юлдан китмичә бик дөрес эшләгән. Күрәсең, кулына алганчы ук, уйдырманың юлы кыска, дигән хакыйкатьне таянычы итеп сайлап куйган. Һәм һич ялгышмаган ул: гади генә сурәтләнгән шушы кыска гына мәкалә Сажидәбезнең бөтен мәгърурлыгын төп-төгәл иттереп сурәтли дә бирә. Тик киләчәктә шагыйрәнең иҗатын һәм тормыш юлын тәфсилләп өйрәнергә алынучылар шуны белеп торсын иде: Әдип

Маликов тарафыннан язылган «Табулар, югалтулар» мәкаләсендәге һәр җөмләне әллә ничә табаклы гыйльми хезмәт итеп шәрехләргә мөмкин. Мисалга бер генә җөмлә китерәм.

Мәкаләдә: «...1976—1980 елларда каты авыру хәлендә яшәде»,—диелә. Бу елларның һәр көнен, шагыйрәнең бөек иҗаты белән бәйләп караганда, Адәм баласының, бигрәк тә татар хатынының нинди могҗизави батырлыкка ия икәнлеген раслауда файдаланырга мөмкин. Шул үлем белән бәхәсләшә-бәхәсләшә Сәҗидә әллә ничә китап чыгарды, җырлар язды, «Азат хатын» журналының эшендә катнашты, университетта укучы улын, Язучылар берлегендә җитәкче булган ирен тәрбияләде, бакчасында гөлләр үстерде, дусларына шатлык өләште, явызларга каршы көрәште... Болар да—гомуми сүзләр генә, аларның да һәммәсе тирәннән өйрәнү, мисаллар сорый. Шагыйрәнең сагышлы тормыш юлына, татлы иҗат җимешләренә тәфсилле бәя бирә башласаң, үзенә бер китап кирәгер иде.

Төзүчеләр әлеге кыен хәлдән чыгуның тагын бер юлын тапканнар: китапның йомгаклау өлешендә шагыйрә иҗаты турында аның каләмдәшләренең фикерләре дә китерелә. Алары да төрле елларда төрле газит-журналларда чыккан зур-зур мәкаләләрдән алынган кыска-кыска җөмләләрдән генә гыйбарәт. Шулары да бик җиткән, бик таман. Алар, бер яктан, шагыйрә аралашкан әдипләр даирәсен ачыклауда бер этәргеч ролен үтәсә, икенче яктан, бу иҗат байлыгының кыйммәтен билгеләүдә өстәмә таяныч була ала.

Сәҗидә иҗаты турында кыска-кыска фикер әйтүчеләр арасында төрле җөмһүриятләрнең олпат шагыйрьләре дә, олуг галимнәр дә, хәтта шагыйрәнең шигырьләрен укып шигърияткә аяк баскан шәкертләр дә бар. Тик, әйткәнемчә, китапка кертелгән сүз-уйланулар бик җыйнак, аларның җәмгысы 15 бит кенә урын алган. Кереш сүзнең дә шул чама икәнлеген искә төшерсәк, 500 дән артык битле китапның калган һәр сәхифәсе—шагыйрәнеке. Укучы игътибарына Сәҗидә Сөләйманованың шигъри дәрьясы тәкъдим ителә. Ал кулына, укы, уйлан: кем ул Сәҗидә Сөләйманова, аныниләр шатландырган, ул нинди борчуларда янган? Шигырьләр барлык сорауларыңа да җавап бирер.

Шагыйрәнең әсәрләре китапта аерым алты бүлеккә тасланып, һәр бап саен Сәҗидәнең олыгая бару рәвешендә сайланган фото-сурәтләре куелган булса да, шигырьләр хронологик тәртипкә генә карап тезелмәгән. Бүлекләр күбрәк билгеле бер фикер нигезенә җыелган, минемчә. Кайбер шигырьләрнең кайсы елда язылуын куеп та тормаганнар. Бу хәл дә, әле вафатына ун еллап калганда язылган шигырьләрнең иң соңгы бапка кертелүе дә минем фаразымны раслыйдыр, мөгаен. Төзүчеләр, күрәсең, хронологиядән дә бигрәк, шагыйрәнең уй-фикер эзлеклелеген алгарак чыгарганнардыр. Һәм, әлбәттә, дөрес эшләгәннәр, чөнки иң мөһиме—авторның омтылышларын, укучысына ни әйтергә теләвен ачыклау лабаса!

> ...Бу дөньяда уен түгел ярты гасыр яшәүләре.
> Ярсып-ярсып бер сөйләсәң, телең тешләп, дәшмәүләре...
>
> *(«Ш. Бикчуринга»).*

Сәҗидә шигырьләрендә—безнең язмышыбыз. «Безнең» дию ем тулаем халкыбыз кичергәннәрне күздә тотса да, бу очракта мин күбрәк татар кызлары турында уйланам. Ихтыярсыздан. Менә Сәҗидә шигырьләре этәрә.

> ...Маңгайга язганын сөртеп,
> Тир белән суга салам.
> Язмышны үзем язам мин,
> Бәхетне үзем табам.
>
> *(«Бәхет»)*

Дөрестән дә, безнең чынбарлыкта кызларыбыз шул хәлгә калдырылган ки, аларга сугыш тартып алган ата-баба кайгыртучанлыгы да, абыйлар терәге дә, хәтта ирләр ышыгы да калдырылмаган. Үзе тир түкмәсә, чәче белән җир себермәсә, ничек яшәр иде кыз бала?

Ятимлекләр, матди җитенкерәмәүләр, канунсыз тормыш хакыйкате, диннән-телдән яздырылулар алдында Кеше булып калу өчен татар кызына шигъри җан ничек ингән? Бу—үзе бер могҗиза бит!

...Ярага—тоз, арага ут сала дошманнар,
Корыч булсам да, бер эрер идем,
—Мин—кеше!

—дип, Сажидә Сөләйманова «Кеше» шигырендә безнең гомум халәтебезне тасвирлый.

Кешегә хас иң мөкатдәс сыйфатларга тугрылык саклап калу жанга рәхәтлек бирә. Бик яман күренешләр арасыннан яктылык күреп алу, явызлардан арынып, үзенә теләктәшләр табу кешенең өметен арттыра, яшәргә куәт өсти. Гомер дигәнең дә кайгы белән шатлыкның, яктылык белән караңгылыкның чиратлашып баруыннан гыйбарәт түгелмени?! Илле яше тулар-тулмас әҗәл белән ачык яланда көч алыша башлаган шагыйрә якты дөньядагы һәр мизгелнең кадерен тоя. Моны аңлый белмәгәннәргә тизрәк төшендерергә дә тырыша кебек. Китаптагы һәр шигырь шуны дәлилли.

...Өзелмәсен, тукталмасын вакыт—
гашыйклыгым шул ук, җырым шаһит—
янам-көям, җирне-күкне багып,
шуннан артык юк та инде бәхет.

(«Мин—Зөһрәсе җырның»).

Сажидә шигырьләрендә—безнең җаннар сулкылдавы. Аның һәр шигырь юлы, күргәнегезчә, корычтай нык мантыйк белән өрфиядәй нечкә хисләрнең сихри бәйләнешеннән үрелгән. Хисләр, хисләр, хисләр! Туган җиргә, ата-анага кайнар мәхәббәтме ул, сөю-сөелү хикмәтләреме, яки, киресенчә, тыннарны кысылдырырлык нәфрәтме—барысы да шагыйрә каләменнән энҗе бөртекләредәй сафлык-нәфислек белән шигырь юлларына ифрат иңле тезелеп бара. Гашыйклык галәмәтләре турында күпме гасырлар буенча, нинди генә осталар җырламаган?! Инде бу хакта авыз ачып әйтергә җөрьәт итүе дә мөмкин булмастыр шикелле. Сажидә шигъриятендә исә шул бөек хис өр-яңача ачыла. Кызыксынучылар китаптагы «Сөюмени», «Хатлар язам», «Күзләреңдә», «Тәңкә карлар» кебек дистәләгән шигырьләргә мөрәҗәгать итсен иде. Укып карасалар күрерләр: Сажидә шигырьләрендә сурәтләнгән сөю хисләре: «Мин сине яратам!»—дип, ерактан кычкырып тормый, аларны аңлый-тоя белү сорала. Нәфрәти хисләр исә, киресенчә, шәрәләндеребрәк бирелә. Әйтик, һәркемнең иң явыз дошманы булган үлем күләгәсе турында шагыйрә болай яза:

...Үлем—көндәш,
җан һәм кан дошманы!
Сизсәң аның синнән узасын,—
телгә алмыйсың,
сүз катмыйсың ана,
эчтән янып, яшерен сызасың.

(«Кайчагында кеше»).

Сажидә шигырьләрендә—Адәм баласының Җирдә яшәү мәгънәсе. Шагыйрә озын булмаган гомерендә дә, ифрат бай иҗат хәзинәсендә дә ваклыклардан—өстен, мәгънәсез бәхәсләрдән читтә, тормышның мең дә бер мәшәкатьләреннән күпкә югары булып кала алды. Шигъри нәфислекне талымлап торырга теләмәгән, ахмак такмакларны тизрәк отып алырга ашыккан беркатлы укучы зәвыгына иярмәде ул. Киресенчә, Сажидә үз иҗатына әдәби сүзнең кыйммәтен тоярга тырышкан сабыр, эзләнүчән укучыны тартырга теләде. Шагыйрә исә үзе дә шигырьдән-шигырьгә яшәү мәгънәсенә тирәннәнрәк төшенә бара кебек иде.

...Җыр иштеп килдем бу дөньяга.
Соңгы юлга җыенып көтәләр
сабыр гына ни көтәләр, дисәм,
миннән җавап җыры көтәләр.

(«Җыр иштеп»).

Гомернең соңгы дәверендә, шигъри осталыгы тәмам чарланып җиткәндә иҗат ителгән шигырь-поэмаларын автор аеруча шул юнәлешкә, Кешенең бу фани дөньяда яшәү нәтиҗәсен аңлауга һәм аңлатуга таба бора кебек. Бу җәһәттән мисалга Сажидәнең

дистәләгән шигырьләрен сузып-сузып язып куярга мөмкин булыр иде. Китапны кулына алганнар аларны үзләре дә тиз табар. Әмма берсеннән берничә юлны тәгаенләп күрсәтми уза алмыйм. Менә ул:

...Ни белән үлчәнә үткән гомер?
Калган эзләр белән,
кеше күңеленә орлык итеп
салган сүзләр белән.
Һәм өметләр белән!
—Йә табылган,
Йә тапталып калган...
Гомерен алда—
Үлчәүләргә сыймас хыялларың барда.

(*«Ни белән үлчәнә»*).

Күргәнебезчә, гомергә бәя биргәндә, Сажидә үз күңеленә иң газиз булган зурлыкларга таяна, аларның да иң кадерлесе иттереп кеше күңелендә йөргән хыял зурлыгын телгә ала. Хәйләкәр, һай, хәйләкәр бу урында шагыйрә: мең-миллионлаган укучыны гомернең алда да барлыгына ышандыру өчен үзендәге бетмәс-төкәнмәс байлыкны—хыялны төп терәк иттереп куя. Хәер, ул башкача булдыра да алмас иде. Иҗаты белән генә түгел, шәхсән үзе белән дә якыннан аралашып яшәгәнлектән мин яхшы беләм: Сажидә Сөләйманова бинихая ихлас җанлы иде. Шигырьләре нинди булса, үзе дә нәкъ шундый булырга тырышып яшәде. Югыйсә, сер түгел, әдәби әсәрләрдә һәр автор изгелек, гаделлек, матурлык төшенчәләрен әләм итеп ала, шул сыйфатларны хуплый, шул хистойгыларга ия булган образлар иҗат итә һәм укучыны да изгелеккә өнди. Әмма кайбер авторлар өчен бу өндәмәләр шул кәгазьдә генә кала, ул үзе дә үзе язганнарга ышанмый, үзе тәкъдим иткән яхшылыкларга омтылып та карамый. Тукай әйтмешли, язганы «шагыйрәнә ялган» булып кала. Сажидә Сөләйманованың исә кылган гамәлләре дә, тормыш итү алымы да, үз-үзен тотышы да язганнарына, шигырьләрендәге идеалына, тәңгәллеккә ирешер дәрәҗәдә, якын иде. Шуңа күрә мин аның әлеге шигырендәге: «Гомерен алда—үлчәүләргә сыймас хыялларың барда»,—дигән юлларын турыдан-туры аның үз тормышындагы, кешене мәңге яшәтерлек, якты хыялларына бәйлим.

Дан-шөһрәт артыннан чабу кебек ямьсез гамәлләрдән ерак торган, матди байлык тупларга омтылуның ни икәнен дә белергә теләмәгән шагыйрәбезнең иң матур хыяллары шигърияткә бәйле иде. Язарга, язарга, язарга, аннары матбугатта чыгарырга, аннары китаплар бастырырга!.. Үзе язган бер генә юлны да укучыга ишеттермичә калдырырга теләми иде ул. Күп язды һәм шактый әсәрләренең, әллә ни соңармыйча, дөньяга чыгуына да ирешә килде ул. Әмма, кызганыч ки, Сажидә исән чакта матбугат битләренә әләгүе дә, китап чыгаруы да бинихая авыр булды. Редакциясе, нәшрияты кабул итеп алса да, махсус тикшерүчеләр кабат тоткарларга мөмкин иделәр. Алар автор белән бәхәсләшеп тә тормый, инде басылып ята торган әсәрне, умырып, алып кына ата. Шигырьләренең бер генә юлы төшерелеп калдырылса да, бик рәнҗи иде Сажидә.

Берсендә мин аңа бу юллардагы тырышлыкларын мактарга тотындым: «Әй көчле дә син, Сажидә, язган һәр әсәрең «ялт» итеп килә дә чыга, килә дә чыга!»- дидем.

—Чыгуын чыга да, әле барыбер минем шигырьләр барлык укучыларга барып ирешми шикелле. Шул кадәр ишеттерәсем килә—һәммәсе каршына басып үзем сөйләп бирер идем!..—ди.

Сөйләвен дә сөйли иде ул. Үзенең илле яшьлегенә багышланган бер кичәдә, Язучылар берлегенең Тукай исемендәге клубында Сажидә ике сәгать буе үз шигырьләрен укыды. Укып та күрсәтте, яттан да сөйләде, ә тамашачылар хәйран калып тыңлады да тыңлады. Күпләре аның бик җитди чиргә юлыкканлыгын белә иде бит инде. Шагыйрә исә, шул авыру зәхмәтенә үч иткәндәй, сәхнә түрендә кала бирде, берсеннән-берсе үтемлерәк шигырьләрен тезде дә тезде. Чәче башы, йөзе-бите дә бизәлгән, яңа гына тектерелгән, ак чәшке тиресеннән уелган тар гына якалы күе зәңгәр күлмәге дә, ялтыравыклы башмаклары да бик килешле иде. Соңыннан, халык таралып, без аны тәбрикләргә сәхнә артындагы кечкенә бүлмәгә җыелгач, шигъриятебезнең ул вакыттагы әйдәүчесе Сибгат ага Хәким дә соклануын яшермәде:

—Мин сине бу кадәр үк оста сөйлисеңдер дип уйламаган идем!—дип, гадәтенчә, сабыр гына мактап куйды.

Шагыйрә үзе дә бу кичәдән бик канәгать иде. Чөнки ул шигырьләренең кешеләрне битараф калдырмавын йөрәге белән тойды, хуплауларны үз күзләре белән күрде. Бу кичә—аның хыял байлыгының тормышка ашкан бер мизгеле иде. Бер мизгеле генә, хыял дәрьясының бер тамчысы гына. Аның әллә нинди ашкынулы хыялларын чамалап мин кайвакыт:

—Ярар инде, ни барына канәгать бул, артыгына нәфесләнмә!—ди торган идем.

Беләм: «нәфес» зур сүз, безнең халыкка нәфесле булырга ярамый, бу тыела. Сажидәнең андый гадәте дә юк. Әмма шулай урынсызга кисәтүемнең дә сәбәбе бар—Сажидә Тукай исемендәге бүләк алырга бик тели иде. Мин исә, Казандагы төрле комитетлардагы хәлләрне, Әлмәттә яшәүче Сажидәгә караганда, күбрәк беләм. Шуна да авыру шагыйрәне кирәкмәгән ымсынулардан, сәламәтлеккә зыян китерә торган кичерешләрдән сакларга тырышам. «Нигә кирәк ул сиңа? Юкка өметләнмә, соңыннан нәүмизләнеп калулары кыен булачак. Кандидатураңны да куйдырттырма!»—дип кисәтә килдем.

—Беләсенме,—диде Сажидә,—Ул бүләкне алган шагыйрьләрнең сайланма әсәрләрен чыгаралар бит. «Шигырь китапханәсе» сериясеннән. Әй, шәп тә китаплар чыгаралар! Тышы да каты, ике катлы тыш белән. Бизәлеше дә бик матур, затлы...

Алай санап-санап күрсәтмәсә дә, мин шагыйрәнең үз әсәрләрен күп итеп, матур иттереп бастырып чыгарырга хыялланып яшәвен белә идем инде. Кремль янындагы онкология шифаханәсендә, әҗәл белән тартышып, дәваланганда да гел әдәбиятка, татар укучысына әйтеп калдырырдай сүзләре өчен борчылып ятты ул. Шатландырырга тырышып мин ана «Гөлбадран» повестының «Казан утлары»нда басылган нөсхәләрен китердем.

—Китап булып чыксын иде ул!—диде. Сажидә әле һаман хыяллана иде.—Шигырьләремнең русчасы һаман чыкмый, безнең халыкның күпмесе татарча белми хәзер. Һәр язганны русча да чыгара барсаң икән ул!..

1970 елны Пермьдәге китап нәшрияты—ни гаҗәп!—башкорт, коми-пермяк, татар һәм удмурд шагыйрьләренең русчага тәрҗемә ителгән гомуми бер җыентыгын чыгарды. «Четыре ветра» исемле шул китапка үзенең шигырьләре дә кертелгәнлекне белгәч Сажидәнең шатланганына чик-чама булмады. Ашыгып-ашыгып бу китапны безгә дә бүләк итте. Анда аның өч кенә шигыре кергән иде. Китапның шул битләрен ачты да укып та күрсәтте.

—Кем тәрҗемә иткән моны?—дип, каш җыерып, төпченергә тотындым мин.—Шуңа шатланган буласың—шигыреңне такмакка әйләндереп калдырган бит, урыс такмагына... Янгырашын гына түгел, хәтта сүзләреңнең кыйммәтен дә, төп фикереңне дә җилгә очырган бит бу!—дим.—Аннары сүзләремне раслау өчен дигәндәй, тәрҗемәне кычкырып кабат укып күрсәтәм:

... Чем измеряется жизнь?
Утратами непомерными.
Друзьями, что в горе первыми
На помощь к тебе пришли.
Еще—надеждою светлой,
Мечтаю твоей заветной.
С нею—не сгинешь в пути,
С нею—вся жизнь впереди.

Тагын сораулар тезәм: кайда монда синең шигырьдәге «калган эзләр», «кеше күңеленә орлык итеп салган сүзләр» кайда, кайда «өметләр», «үлчәүләргә сыймас хыяллар» кайда??? Кем соң ул синең шигыреңне әрәм иткән А. Домнин дигән кеше? Мин андый шагыйрьне ишеткәнем дә юк...—дим.

Дуладым, кыздым. Кулына урыс китабын тотып сөенгән Сажидәкәй-күбәләкне тәмам аптыраштa калдырдым. Ул исә бу мин әйткәннәрне күптән кичергән икән инде, сабыр гына аңлатып бирде:

—Мин генә түгел, барлык шагыйрьләр дә шул хәлдә бит, тик барыбыз да ризалашабыз, шигырьнең шәүләсен генә булса да, укучыга, татарча белмәүче укучыларга ирештерәсе килә. Шәп шагыйрьләр тәрҗемә белән шөгыльләнми. Мин үзем дә бу рәвешле русчага әйләндерер идем дә, Домнин кебекләргә гонорар түләр өчен, моңа юл куймыйлар. Татарча белмәгән килеш кәсеп итәләр...

Менә шулай. Күңел түрендә әллә нинди ризасызлыклар тоеп яшәсә дә,

язганнарын укучысына ирештерү өчен, төрле килешүләргә дә бара белә иде ул. Шигырьләре хакына, шигырьләренә бәйле хыяллары хакына... Аның хыялларын башка һәр кешедән тирәннәнрәк Әдип абый белеп яши. Белә дә һәм Сажидәбезнең барлык хыялларын тормышка ашыру өчен көчен дә, вакытын да кызганмый тырыша.

Ни кызганыч, Ходай Тәгалә һәр язучыга да Әдип абый Маликов кебек кайгыртучан яр бирмәгән. Кайбер әдипләребез гомер буе ялгыз яшиләр. Андыйлар үзләренчә, шаярткан булып: «Ялгызлыкның үз рәхәте бар аның»,—диләр. Шулае да шулайдыр, тик гомер дигәненнең күзгә күренмәгән, икенче өлешен дә истән чыгарып булмый. Житмәсә, жирдә яшәгәндә, кешенең, бигрәк тә татарның кадерен белү—юк дәрәҗәсендә. Без бу кадерсезлекне тәмам канунилаштырып та бетердек бугай инде. Бер-беребезнең кадерен белик, дигән сүзләр киресенчә әйләнә, яманлыклар арта гына бара шикелле. Олуг иленнең иң зур житәкчеләре дә, бөтен дөнья алдында ялган сөйләүдән, кеше жанын кыюдан тартынмыйлар икән, гаделсез сугышларда сөлектәй егетләрнең гомере өзелә икән, күпме булачак галимнәр, талант ияләре кырыла икән,—каләм очы белән көн кичергәннәр арасында гына рәхим-шәфкатьне кем күрсәтсен?

Дөрес, безнең зурлап, сайлап куйган үз житәкчеләребез, Идарәбез, Аксакалларыбыз бар. Исән чакларында ижатларына юл таба алмыйча, бөтен хыялларыфәләннәре белән Мәңгелеккә күчкән әдәбият әһелләренең мирасын үз вакытында пөхтәләп, барлап кую—әнә шул сайланган затларыбыз бурычы. Хәер, мин моның белән әллә ни яңалык ачмыйм. Моннан егерме еллар элек бу эш нәкъ шулай итеп алып барыла да иде. Берәрсенең җеназасын чыгуга Идарә, үзенең чираттан тыш утырышында Мирас комиссиясе төзи, ана мәрхүмнең иң якын затларын туплый, булышырга иң намуслы, эшчән, булдыклы әдипләр дә өстәлә иде. Мин, мәсәлән—Сажидә Сөләйманова мирас комиссиясе әгъзасы. Дөрес, әллә ни майтара алмадым, берничә кичәдә чыгыш ясап, бер-ике мәкалә язуым белән чикләнергә туры килде. Эшнең зурын комиссия рәисе итеп сайланган Әдип абый Маликов башкара килә. Аңа рәхмәт яусын! Тик, әлеге дә баягы, һәр язучыга мондый кайгыртучан гомер юлдашы тими. Күпләребезнең балалары татарча сөйләшә дә белми.

Чынбарлык исә безнең бу хәлләр белән санашып торырга теләми, иң талантлы язучыларны чүпли бирә. Соңгы ике корылтаебыз арасында гына да егермедән артык каләмдәшебез «китеп» барган иде. Әле алай гынамы соң—әле корылтай тын алырга тукталган арада да икәве бу хәвефле дөнья белән мәңгелеккә саубуллашты. Мәрхүмнәр арасында, мин белгәннәреннән генә дә, ифрат мул архивлы, хатлар язышуга һәвәс, язган «четерекле» әсәрләрен бастырырга кулай вакыт көтеп интеккән әдипләр бар. Вакытында рәхим-шәфкать күрсәтә алмавыбызга рәнжемәсеннәр өчен, тәүбә әйтә-әйтә, шундыйларның мирасын берәмтекләү—бүгенге идарәчеләрнең иң беренче вазыйфасы түгелмени соң? Ять-яшьли китеп, песи теле чаклы гына китаплар калдырган шагыйрьләребезнең кульязмалары кулында, фотолары, хатлары, көндәлекләре кайда? Туган көннәре түгәрәк санга килеп терәлгәч кенә берәр мәкалә чыгаралар да—вәссәлам. Кайберәүләренә анысы да тими. Барлык рәнжетелгәннәрнең һәм онытылганнарның исемнәрен дә, бастыра алмый калган язмаларын да бередә санап чыгу мөмкин түгел, шулай да кайберләре үзләре әйтеп тора шикелле. Мәсәлән, Газиз Кашапов. Ул Хәсән Туфан эзләреннән урап йөреп, өйрәнеп, трилогия язып ята иде... Нәби абый Дәүли, гомеремнең иң авыр дәвере, әсирлектән котылып кайткач, туган илдә күргәннәрем хакында язам, тик әлегә бастыра алмыйм, вакыты житмәде әле, житмәде, ди торган иде... Фәннур Сафин, Фаил Шәфигуллин, Рәшит Гәрәй, Калыйр Сибгатуллин кебек талантлы шагыйрьләрнең соңгы елларында ижат иткән әсәрләрен кайчан укырбыз, кайда чәчелеп яталар икән алар?

Шәриф Хөсәенов—язучыларыбызның берсенә дә охшамаган, аеруча кин карашлы, күп белүчән, сәнгатьнең күп төрләрен өйрәнгән һәм әллә ниләр белән шөгыльләнүче эрудит шәхес иде. Ул әллә кемнәр белән хатлар алыша, опера, балет дөньясын, андагы атаклы шәхесләрне яхшы белә, китаплар, рәсемнәр жыя, фотога төшерә иде. Гаиләсе юк. Нәселендә кульязмалар белән шөгыльләнердәй кеше юк. Аның хәзинәсендәге һичниндн акчага да сатып алып булмый торган байлыклар шулай әрәмшәрәм булып бетәр микәнни?

Бу сорауларга теләсә кем җавап бирә алмый. Мондый үзе изге, үзе ифрат катлаулы, үзе шактый чыгымнар да таләп итә торган эшне бары тик кулында власть булган житәкчеләр генә күтәрә ала. Андый мөмкинлеге булган затларыбыз, язучылар

башына басып, бары тик үзләренә генә яңадан-яңа шөһрәтләр яулап йөрүдән беразга туктап торып, әдәбиятыбызга, халкыбызга тарихына бик кирәкле булган әлеге гамәлне юлга салсыннар иде. Шуңа ияреп аларның үзләренә дә шөһрәт килер.

Һич югында, күрше-дусларыбыз, башкортлардан үрнәк алырга яки алардан калышмаска тырышырга кирәк. Нажар абый Нәжминең әле «кырыгы»н да үткәреп өлгермәгәннәр иде—миңа истәлекләр язуымны сорап хат килеп төште. Баксаң, шундый ук үтенеч Татарстан язучыларының дистәләбенә килгән икән. Хәтта авыру хәлдә яткан Әмирхан ага Еникидән дә истәлек алып калдылар. Бу—бигрәк гыйбрәтле хәл бит. Әмирхан абыебыз үзебезнең дистәләр белән саналган мәрхүмнәребез турында да фикерләр әйтеп калдыра алган булыр иде. Кем сораган да, кем кайгырткан! Безнекеләр шул күбрәк үз мәнфәгатьләре артыннан чабалар. Кызганыч, һай, кызганыч! Үтәр еллар, кайгыртучылар да табылыр, бәлки, форсат ычкынган булыр...

Мин 1959 елны Габделҗаббар Кандалый иҗаты турында диплом якладым. Эзләнүләр вакытында шагыйрьнең беркайда да басылмаган әсәрләре дә табылды. Диплом яклангач, үзара сөйләшеп утырганда, сүз иярә сүз китеп кенә, җитәкчем Хатыйп ага Госманга әйтеп куйган идем:

—Хатыйп ага, минем бер хәлгә исем китте: и-и бу татар шагыйрьләренең язмышы!—дим.—Карагыз инде—Габделҗаббар Кандалыйның вафатына 1960 елда Йөз (!) ел тула. Шигырьләре әдәбиятка өр-яңа агым алып килгән, куктәге шигъриятебезне җиргә төшергән. Шуның да кулга тотарлык бер китабы юк. Ил буенча сибелгән шигырьләр. Әле дәреслеккә, әле календарь битенә эләккән берле-икеле әсәрләр... Кая карый бу әдәбият институтында утыручы галимнәребез?..

—Карале!—дип, Хатыйп ага минем сүзне үргә алды.—Ул галимнәрне көтеп торганчы, әллә үзебез алыныйкмы? Ярдәм итәрсеңме?

Мин диплом җитәкчемә үз кулымдагы бөртекләп җыелган шигырьләрне тапшырдым. Ел да үтмәде, шагыйрьнең вафатына 100 ел тулу вакытына Кандалыйның Беренче (!) китабы басылып чыкты. Күрәсең, татар әдипләренең язмышы шундый, аларга диган китаплар, алар әсәрләренең төп бәяләмәсе әнә шулай гасырлар аша көттереп килә. Тик бүгенге тәрәккыят чорында бу төр эшләрне гасырларга ук сузмаска иде! Теләсәк, башкарып чыга алмаслык түгел бит. Сажидә Сөләйманова иҗатының бүген «гөрләп чәчәк атуы», Әдип абый Маликов тырышлыкларының шундый мул нәтиҗәләргә китерүе—менә иң көчле дәлил. Шагыйрәнең вафатына егерме еллап вакыт узды. Шигырь сөючеләр исә моны сизми дә торганнардыр әле. Чөнки шагыйрәнең китаплары еш басыла, аның иҗатына багышланган кичәләр дә, сирәгрәк булса да, оештырыла килә. Хөрмәтле Әдип абый Маликов әдибәнең һәр язганын барлап куйды да, эзлекле рәвештә, Сажидә хыялында бөреләнеп калган һәр эшне тормышка ашыра бара. «Гөлбадран» да һәйбәт китап булып дөнья күрде, «Шигырь китапханәсе» сериясендә дә Сажидә шигырьләре чыкты, «Бер сәяхәт тарихы» да, «Фал китабы»ның урысчага тәрҗемәсе дә... Үзләре исән чакта күптомлыклар чыгара-чыгара арып беткән, әллә нинди бүләк ияләре булган олпат ир-егет әдипләребез дә, вафатларына ел тулмас борын онытылып торганда (Кайда ул Афзал Шамов китаплары? Мирсәй Әмир, Ибрай Гази, Хәсән Туфан, Нури Арсланов, Салих Баттал әсәрләренең яңа басмалары кайда??? Юк бит, юк!), Сажидә Сөләйманованың берсеннән-берсе затлырак, калынрак, катырак вә ялтыравыклырак тышлы китаплары чыга да тора, килә дә чыга.

Менә тагын шундый басмаларның берсе—«Тормыш, исәнме!» китабы Сажидәбезне ип-исән килеш өйләребезгә китереп кертте. Укы, рәхәтлән, кадерле замандашым! Сажидә Сөләйманова дигән шагыйрәнең һәр әсәре, һәр юлы һәр сүзе җаныңа шифа бирсен! Укыган саен шигырьләрнең авторы кичергән фидакарьлек турында да уйлан, бу гыйбрәтле әсәрләр белән танышып торырга мөмкинлек бирүне мәрхәмәтле затларны да онытма. Шулай тирәнгәрәк китеп уйланулар тормыш кадерен белергә, яшәү мәгънәсенә төшенергә ярдәм итәр, гомер агышына изге шагыйрәбез Сажидә Сөләйманова кебек үк шөкерана кылып карарга өйрәнерсең.

...Бу язда да тагын, бу язда да
Шомырт чәчәкләре иснәдем.
Чәчәк алып килгән бу кем?—дисәм,
Син икәнсең, тормыш, исәнме!

Кояш ТИМБИКОВА

Сәнгать

ШАГЫЙРЬ АРТИСТ

Йөрәгеңне җуя күрмә,
Әллә кая куя күрмә.
Сыйдырсын ул туган илне,
Җырлап йөр син «Әллүки»не,
Онытсаң да, энем, мине,
Онытма син Туган Илне!

Рәшит Әхмәтҗан. *(«Энем Илдуска»)*

Шигърият һәм сәхнә. Шагыйрь һәм артист. Бу төшенчәләр бер-берсе белән янәшә торсалар да, һәрбер артист нәфис сүз остасы була алмаган кебек, һәрбер нәфис сүз остасы да артист була алмый. Шушы ике биеклеккә чын сәнгати дәрәҗәдә бердәй ирешә алучы зур талант ияләре—элгәррәклэрдән Хәким ага Сәлимҗанов, Габдулла ага Шамуковлар булса, бүгенгеләрдән, мөгаен, Илдус Әхмәтҗановтыр...

Артист, сәхнәдә уйнау дәверендә йөзләгән рольләр башкарса да, галәттә, халык күңелендә бер-ике роле белән кала. Әйтик, Шәүкәт Биктимеров—Әлмәндәр карт, Ринат Таҗетдинов—Мәхдүм, Равил Шәрәфиев исә Әҗәл булaрактыр... Ш.Хөсәеновның «Әни килде» әсәрендәге Ана образы безгә Галимә Ибраһимова уйнавы белән кадерле. Исламия Мәхмүтова И. Юзеевның «Кыр казлары артыннан» спектаклендәге Ясминә булып...

Юк, бу аларның башка рольләрне начар уйнап, монысын гына яхшы уйнадылар, дип әйтү түгел, хикмәт—күңелгә якын булган, күздән яшь китерерлек, аның уй-кичерешләрен үзеңнеке итеп кабул итеп, син әйтәсе килгән сүзләрне аның аша ишетеп, мәңге истә калырлык образ тудыра алуларындадыр. Илдус Әхмәтҗанов, дисәк, безнең күз алдына ин беренче Тукай образы килә.

Тарихи шәхесләрне уйнау—күп артистларның хыялы. Әмма теләк бер нәрсә, мөмкинлек—икенче. Йөз-кыяфәтнең дә азмы-күпме охшаган булуы, образны тулырак гәүдәләндерү өчен әчке доньяның да, күңеленнең дә әлеге зат белән күпмедер дәрәҗәдә тәңгәл килүе кирәк.

Тукай ролен ул беренче тапкыр 1976 елда режиссер Әхтәм Зарипов куелышындагы «Яз сулышы» исемле телевизион спектакльдә башкара. Күренекле режиссер Ә. Зарипов Илдус Әхмәтҗановны, талантлы артист булуы белән бергә, кеше буларак та югары бәһали.

«Илдус тудырган образларның характерлары, холкы бар. Ул образны ачуда персонажның үзенчәлеген табудан, холык-фигылен ачыклаудан башлый. Бу—бары тик чын профессиональ артистларга гына хас сыйфат. Ин күркәм сыйфатларының тагын берсе—аның тумыштан интеллигент булуыдыр. Чын зыялы, затлы кеше ул! Эш белән онытылып киткән чакларда да ул үз дәрәҗәсен һәм үз урынын онытмый. Һәркемгә шәхес итеп карый. Аңа вельможа да, бомж да—кеше. Хаксызга рәнҗетсәләр—авыр кичерә, озак терелә. Вәгъдәле, иманлы кеше».

Икенче тапкыр ул Тукай булып 1986 елда Туфан Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» спектаклендә уйный. Тукаебыз аның башкаруында горур, мәһабәт, әчке җегәре ташып торган зыялы зат булып гәүдәләнә. Бу спектакльдән соң хәтта аның үзенә дә Тукай дип эндәшә башлаучылар була. Ходай Тәгалә, әйтерсең лә, Тукайны иртә алганына үкенеп, аның урынына, аның эшен, фикерләрен халыкка җиткерергә

Илдус Әхмәтжановны җибәргән. Тукайның 100 еллык бәйрәменә килгән Мостай Кәрим спектакльне карагач: «Тукай ролен башкаручы Илдус Әхмәтжанов яхшы уйный. Тукай—тормышчан, ышандыра. Артист шагыйрь образын әдәпле итеп, югары культура күрсәтеп башкарды. Мин тере Тукайны күрдем»,—ди.

Татар әдәбиятында, сәнгатендә бер нәселдән чыккан аталы-уллы, яки абыйлы-энеле талантлы шәхесләр бик күп. Бертуган Садри һәм Әхмәтһади Максудилар, Галимҗан Нигъмәти, Нәкый Исәнбәт, Фатих Әмирханнар нәселе, Нил һәм Илдар Юзеевлар, Гали һәм Яхъя Халитлар, Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннар, Хөснул һәм Аллаһияр Вәлиуллиннар, Рәшит һәм Илдус Әхмәтҗановлар...

Үзе турында артык ачылып сөйләргә яратмый артист. «Сон мин бит болай да бөтенләем белән сезнен каршыда, сәхнәдә бөтен җаным белән ачылам бит инде»,—дип әйтүеме, зыялы кешеләргә хас булган тыйнаклыкмы, үзем өчен серле булган бу шәхес турында тагын да күбрәк беләсе килү мине, берничә ел бергә эшләгән олуг шагыйрь Рәшит Әхмәтҗановның хатыны—заманында Илдус Әхмәтҗановның укытучысы булган Луиза ханымга илтте.

Илдус Әхмәтҗанов «Яз сулышы» телевизион спектаклендә Тукай ролендә.

—Ул нәселгә хас ин төп сыйфат нинди?—дип соравыма Луиза ханым:

—Горурлык!—дип җавап бирде.

—Һәм барысы да гаҗәеп сабыр, сүзгә осталар. Аларның фикерле итеп сөйли белүләренә шакката идем. Рәшит, әтисенә охшап уенчак, җор күнелле булса, Илдус киресенчә, әнисенә охшап сабыр, басынкы. Анын кечкенәдән үк үз эчке доньясы бар иде. Кемнәрдер өчен, бәлки, ул сәер, үз эченә бикләнгән малай булып күренә торган булгандыр. Искиткеч кешелекле, ярдәмчелләр алар.

... Хатирәләр, хатирәләр... Бергә эшләгән елларда профкомга кәгазьләр тутырырга туры килгәндә: «Ничә яшьтән эшли башладың, Рәшит абый?»,—дип сорагач, «Биш яшьтән, багырьләрем, мина тормыш нужасын биш яшьтән тарта башларга туры килде»,—дигәч, без аны, уенчак күнелле кеше буларак, шаяртадыр дип уйлый идек, ләкин, әтиләре иртә үлү сәбәпле, ишле бала белән тол калган авыру әниләренә балалар үзләре ярдәм итмичә, кем итсен соң?!

... И ул үсмер чакның татлы йокылары! Сәҗидә апа, акрын гына басып, нарасый Илдусны котүгә уятырга дип янына килә... Илдус әнисе эндәшкәнче үк инде вакыт җиткәнен тоеп ята, тиз-тиз генә капкалап ала да, чандыр иненә чыбыркысын салып, авыл башына юнәлә. Һәр җәй саен шулай, һәр көн саен шулай... Берничә елдан соң, башкалабызнын ин зур театрларынын берсендә—Галиәсгар Камал театры сәхнәсендә М. Фәйзинен «Ак калфак» спектаклендә көтүче Бакый ролен уйныйсы егеттән тормыш үзе шулай репетиция ясаттыргандыр, мөгаен.

Юк, ул малкайларны, ачы итеп сүгенеп, чыбыркылап кумый, инде йокы да ачылган, җәйге көн үзенекен итә—тәннәр дә язылган, аларны үз көйләренә җибәрә дә хыял дингезләренә чума, күнелдә кичә яза башлаган шигыренен дәвамы туа башлый. «Әллә шагыйрь булырга инде?»,—дип сөйләнә ул үзалдына. Әнә бит, Рәшит абыйсын ничек яраталар, ул кайткач анын белән очрашулар оештыралар, кызлар анын шигырьләрен яттан сөйли, күбесе ана гашыйк та... Тик Рәшит абыйсы ошатырмы? Килешерме анын белән ярышу? Туганнары арада ин сабыр, тагын да кешелеклерәк булган энекәшләрен авылда калдыру ягында, Рәшит абыйсы исә аны сәнгать доньясына тарта, театр училищесына укырга керергә өнди. Нечкә күнелле шагыйрь абыйсы сизә: анын урыны—сәхнәдә.

1968 елны ул Казанга театр училищесына укырга килә. Татар әдәбиятыннан

язылган иншасын укыганнан сон, комиссия členнары Хэй Вахит, Рэшидэ Жиһаншиналар сокланып: «Язучы булырга тиешле бала бит бу, эллэ университетнын татар теле һэм эдэбияты бүлегенэ жибэрикме икэн?»—дип тэ уйлап куялар, тик этюдларны да оста башкара, тиз элэктереп ала, сүзне тоя белэ,—артистка кирэк ин топ сыйфатлар—төз гэүдэ, ачык, матур тавышлы бу егетне университетка жибэреп «эрэм» дэ итэселэре килми. Әлеге курс студентлары Ленинград театр, музыка һэм кинематография институтына укырга жибэрелэ. Илдус Әхмэтжановнын табигатьтэн, тумыштан килгэн талантына Ленинград-Петербург кебек борынгы, зыялы шэһэр, анын тарихи шэхеслэре белэн аралашу, мэһабэт театр залларында үзенне шэхес итеп тоеп, башны горур тотып йөрүлэр дэ тээсир итмэгэндер дип кем эйтэ ала? Әле авылдан чыгып, ерак болын басуыннан, авыл клубыннан башка жир күрмэгэн малай-егеткэ чагыштырып карап гыйбрэт алыр, акыл туплар өчен бу зур мэктэп түгелмени? Ятим балага олы сэнгать доньясына чыгарга мэрхэмэтле язмыш үзе юл ачып торгандыр, күрэсен...

Биш елдан драма һэм кино артисты дипломы алып кайтканнан сон, 1973 елдан Г. Камал театрында эшли башлый Илдус. Төрле дэрэжэдэге рольлэрне уйный ул. Беренче зур роле—Р. Батулланын «Өчэү юлга чыктык» спектаклендэ Мирзахан. Илдус Әхмэтжановнын характерына капма-каршы роль. Лэкин анын яшенэ, бүгенге халэтенэ туры килэ. Ул да бит, Мирзахан кебек, институт тэмамлап яна гына эшкэ кайтты. Димэк, анын уй-кичерешлэре, хыяллары синеке дэ... Тик ул «тискэре» герой. Әдэбиятта «унай һэм тискэре» геройлар, «социалистик реализм» методы чэчэк аткан чорлар. Тамашачы гадэттэ «унай» герой яклы. Һэм менэ шул «тискэре» образ аша тамашачы мэхэббэтен, анын ышанычын яулыйсы бар. Спектакль тэмамланып, зал алкышларга күмелгэч, үзенэ эйтелгэн котлау сүзлэрен ишеткэч кенэ жинел сулап куя яшь артист.

Икенче роль—Г. Боровикнын «Канлы күлэгэлэр»ендэ Педро роле. Бу рольне уңышлы башкарганы өчен ана республика ижат яшьлэре конкурсынын лауреаты исеме бирелэ.

Театр тормышына чын-чынлап кереп, инде ныклап уйный башлыйм дигэндэ, генэ ир-атлар үзарга тиешле тагын бер мэктэп—армия хезмэте аны да читлэтеп үтми.



Илдус Әхмэтжанов Ч. Айтматовнын «Ахырзаман» спектаклендэ Бастонролендэ. Ирназар ролендэ—Шамил Бариев. 1987 ел

Бу рольне ана ерак «Герман илләре»ндә «уйнарга» туры килә.

Илдус Әхмәтжанов 27 еллык иҗат дәверендә кырыклап роль башкарган. Берберсен кабатламый торган, купчелеге капма-каршы булган, артисттан зур осталык таләп итә торган рольләр.

Рус классикларыннан М. Горькийның «Һаваларда йолдыз»ында Алексей Пешков, А. Н. Островскийның «Җимерелгән бәхет»ендә Дерюгин, В. Распутинның «Авылдашлар, акча кирәк» пьесасында ревизор, Чыңгыз Айтматовның «Ахырзаман»ында Бастон (1989 елда бу роль өчен Илдус Әхмәтҗановка Муса Җәлил премиясе бирелә), татар драматургларыннан М. Фәйзинен «Асылъяр»ында Искәндәр, «Галиябану»да Бәдри, Г. Исхакыйның «Алдым-бирдем»ендә Әхмәди, Ю. Сафиуллинның «Идегәй»ендә Субра карт, Т. Миннуллинның «Гөргөри кияүләре»ндә Гөргөри, З. Хәкимнең «Су төбендә сөйгәнем» спектаклендә Галелша... Кызык бит: бөек Тукай һәм исерек Галелша...

«Гөргөри кияүләре»ндә исә Илдус Әхмәтҗанов бөтенләй башка яктан, көлкеле образлар тудыра алучы артист буларак ачыла.

Гөргөри исемле керәшен карты, ата-бабалардан калган гореф-гадәтләрнең югала баруына нык борчылуын белдереп, кечкенә кызын керәшен йолалары буенча кияүгә бирергә тели. Яшь гаиләләрнең таркалуын да нәкъ менә шушы йолаларның сакланмавыннан күрә ул.

Драматик рольләрдә уйнап күнегелгән артистның комедия жанрында да югары биеклектә кала алуын күреп сөенәсең, аның талантына сокланасың. Төп герой Гөргөри тудырган шушы рух спектакльнең башыннан-ахырына кадәр сәхнәне бербөтен итеп тота ала.

Әйе, капма-каршы персонажлар... Чын профессиональ артистның көче дә, сәләте дә нәкъ менә шунда—кирәк чакта, ролен зуррак булса—зурая, кечерәк булса, кечерәя белүдә икән.

—Бүгенге драматургия, театр тормышына килсәк, ул үз сүзен әйтте, үзен күрсәтте инде. Кайчандыр дәүләтчелеге булган, олуг тарихы булган халык өчен театр сәнгате белән генә чикләнеп калу бик аз. Безгә чын-чынлап кино сәнгате, татар киносы турында уйлый башларга вакыт җитте. Читтән артистлар чакырып китереп түгел! Үзебезнекеләрне дә күрә белергә генә кирәк. Бу уйлар 1997 елда Мисырда «Исә болгар җилләре» фильмын төшергәндә дә һич башымнан чыкмады,—ди Илдус Әхмәтҗанов чын мәгънәсендә борчылып.

Бер кешедәге шуның кадәр көчкә-җегәргә, хәтергә, итагатьлелеккә, зыялылыкка, әле тәрҗемә эше белән шөгыльләнүен дә искә алсак, белемгә хәйран каласың! Лопе де Веганың «Мәхәббәт мажаралары»н ул шигырь белән тәрҗемә иткән. А. Н. Островскийның «Капкан саен калҗа булмый», «В. Шекспирның «Король Лир», «Антоний һәм Клеопатра», «Ромео һәм Джульетта» әсәрләре аның тәрҗемәсе аша татарча яңгыраш алган. Һәм күңелендә йөргән шигъри сурәтләүләре, шигырь белән әйтәсе килгән фикерләре шушы тәрҗемәләрдә чагылыш тапкан. Әйе, Шекспирны тәрҗемә итү өчен, аны сәхнәдә татарча яңгырата алыр өчен зур шагыйрь талантына ия булу да кирәк шул!

Илдус Әхмәтҗанов, драма артисты буларак, Тукай образын уйнап танылу алса, нәфис сүз остасы буларак та, Тукай аның иҗат мирасының төп өлешен тәшкил итә. Быел Тукай премиясенең ана бирелүе дә аның Тукайлыгының рәсми төстә танылуы булып тора. Әлеге премия ана Тукай шигырьләреннән төзелгән «Сөй гомерне, сөй халыкны» дигән театральләштерелгән программасы (1992-96 еллар) һәм «Өзелгән өмет» (1997-2000) циклы өчен бирелде.

—Барыбыз да китап укырга яратканлыктан, өйдә китап күп иде. Инде 10-11 яшьләремдә Тукайның дүрттомлыгын укып чыккан идем. Кайсы бите нинди шигырь, нинди аңлатмалар белән бирелгән, аларны яттан белү—инде ул вакытта ук минем яшәү рәвешемә әйләнгән иде,—ди Илдус. Сүз дә юк, ике өлкәдә дә—драмада да, нәфис сүздә дә Тукайны иҗат итү зур белем, әйтер идем, тарихи белем, осталык, саклык таләп итә. Ялгыш кына да үзеннән «мишәр сөйләменне» әйтеп җибәрергә ярамый, бүгенге чордан булган сүзләр дә кирәргә тиеш түгел. Гомумән, Тукай шигырьләре, татар шигърияте иҗатымның ахырына кадәр минем төп иҗат эшчәнлегем булып калыр, ахры,—ди артист.

Әйе, Илдус Әхмәтҗанов шигырьне сөйләп кенә чыкмый, хис һәм фикер

берлегән бергә кушып, йөрәк һәм акыл аша уздырып аннан образ тудыра. Тукай шигырьләрен, С. Хәкимнен «Кырыгынчы булмә», Р. Фәйзуллиннын «Сәйдәш» поэмасын һәм башка татар шагыйрьләренен шигырьләрен тетрәнеп, бермәлгә тын да алмыйча, онытылып тынлыйсын. Хәзерге доньяннан китеп, шагыйрь тудырган, бу очракта артист тудырган доньяда яшәп аласын.

Тукай премиясенен кырык елдан артык тарихы бар. Моннан утыз бер ел элек бу премия нәфис сүз сәнгатендә бердәнбер Айрат Арслановка бирелгән.—Нәфис сүз остасы дигән исем—халык артисты дигән исем белән бер дәрәҗәдә булырга тиеш. Һәм Илдус Әхмәтҗанов менә егерме җиде еллап шушы өлкәдә эйдәп баручы артист. Анын кебек чын мәгънәсендәге Нәфис сүз Остасы булу өчен Туган телне бөтен нечкәлекләре белән тоярга, халкыннын үткәненә һәм киләчәгенә хөрмәт белән карый белүче миллэтпәрвәр булырга кирәк»,—ди Айрат Арсланов.

Миллэтпәрвәрлек... 1991 елнын май ае. Республикабызнын язмышы хәл ителгән көннәр. Шәһәр уртасындагы мәйданда тугел, су буендагы таллар күләгәсендә дә эсселеккә чыдап булмый. Бер төркем язучылар, сәясәтчеләр игълан иткән ачлыкта Илдус Әхмәтҗанов та бар. Сәясәт уенынын ахыры ни белән бетәсен, нинди юнәлеш аласын кайвакыт анын башында торучы дәүләт сәясәтчеләре үзләре дә белеп бетермиләр. Ул-бу була калса, бер нәселдән ике корбан буласы... Әнә абыйсынын мәйданны ярып шигырь укуы ишетелә:

Яшәргә! Яшәргә! Азатлык алмыйча
Кузгалып китү юк быелгы җәемнән.

Ике туган монда да янәшә. Һәм сонгы минутларында да...

1995 ел. 5 январь. «Архивны Илдуска бирерсен»,—ди Рәшит абый Луиза ханымга, шул арада шаян сүзләр дә әйткәләп куя, ни уйларга да белмәссен... Яна ел вакыты бит, чыршы бәйрәмендә көне буе аю булып «уйнап» йөреп арыган булса да, иртәгә үзе дә авырулар кабул итәсе табибә җингәсен ял иттерәсе килеп, абыйсы янында үзе генә утырып кала. Сәгать төнге ике. Тыныч кына яткан абыйсы кулларын алга сузып, талпынып ала һәм шул минутта ике туганнын күзләре очраша. «Утны сүндер!»- ди абыйсы кинәт кенә. Ут ничек тиз сүнсә, шулай ук тиз генә кабына да. Абыйсы мәнгелек йокыга талган... Нинди генә югары дәрәҗәләргә ирешсәк тә, туганнар өчен барыбер «абый-апа», «энe-сенел» булып калабыз шул. Мөгаен, Рәшит абыйсы да шигъри күнелле энесен куркытасы килмәгәндер, бәлки...

Табигать бушлыкны яратмый. Бүгенге буынга Тукайлар рухын Илдус Әхмәтҗанов кебек талантлы улларыбыз житкерсэ, киләчәккә бәлки «Каргышлы балачак» телефильмында инде Тукайнын Уральскийга китүгә хәтле чорын сурәтләп күрсәткән улы Рөстәм илтер? Һәрхәлдә, мона жирлек бар. Тукай белән янәшә күмелгән шагыйрь Рәшит абыйсы да, Татарстаннын халык артисты, Муса Жәлил һәм Тукай премияләре лауреаты—этисе Илдус Әхмәтҗанов та, Тукай үзе дә, талантлы уллар тудыра белүче татар халкы да мона шат булыр иде. Иншалла, шулай булсын! Буыннар чылбыры өзелмәсен иде!

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА

*

Нәби Дәулинең туууына 90 ел

КАЙТМЫЙ ЕЛЛАР, КАЙТАЛАР ҖЫРЛАР...

Татар халкы талантларга бай. Шул исәптән әдипләргә дә, шөкер, кытлык юк. Әмма күңелләрдә якты йолдыз булып калганнары, еллар узса да арабызда юклыгына һаман ышанып булмый торган шәхесләр алай ук күп түгелдер. Әнә шундый якты шәхесләрнең берсе—шагыйрь, прозаик, драматург һәм публицист Нәби Дәүли. Аның фашистлар әсирлегеннән качып-котылып кайтканнан соң язылган «Яшәү белән үлем арасында» повесте һәм «Җимерелгән бастион» романы әдәбиятыбызда чын-чынлап зур вакыйга булды, язучыга гомумтанылу шөһрәтен алып килде. Каһәрләнгән сугышның әлегәчә без белмәгән якларын ачып бирүләре, фантастикага якын кискен вакыйгаларга бай булулары белән әлеге әсәрләр укучыларның кызыксынуын бик тиз яулап алды. Әлеге әсәрләрне матбугатта басылып чыккан алтмышынчы елларда без—университет студентлары кулдан-кулга йөртеп укый идек. Йөрәк каны белән, әсирлек ачысын кабат-кабат күңеленнән кичереп язылган сәхифәләр тәэсиреннән башыма шундый уй килә иде: Муса Җәлил, Нәби Дәүли кебек нык ихтыярлы, чыдам, фидакарь әдипләрне тоткын хәленә куеп, язмыш, мөгаен, фашизмның чын йөзен, фашизм тәмугының бөтен дәһшәтен дөньяга фаш итәргә теләгәндер. Һәм язмыш ялгышмаган...

Ошбу мәкаләмне язарга утырыр алдыннан мин Нәби абыйның үземдә булган китапларын кулыма алып, кабат укып чыктым. Әсирлек ачысы белән язылган әлеге ике әсәрне ул миңа култамгасын салып бүләк иткән иде. *«Маннафка, якташыма, каләмдәшемә истәлек итеп һәм киләчәктә зур уңышлар теләп, Н. Дәүли. 12 март, 1975».*—Бу китапның язылуына кырык елга якын вакыт узып киткән икән. Шушы

Беренче рәттә (уңнан сулга): Нәби Дәүли, Мөхәммәт Садри, Сибгат Хәким, арттагы рәттә Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Габдрахман Минский һәм Фатих Хөсни. «Социалистик Татарстан» редакциясенең М. Җәлил музеенда.

вакыт эчендә дөньяда һәм илдә бихисап үзгәрешләр булды. Элек язылган күпләгән әсәрләр үз төсләрен җуеп, мәгънәләрен югалтып, онытылуга дучар ителделәр. Хәтта Бөек Ватан сугышына карата да карашлар төрледән хәзер. Әмма «яшәү белән үлем арасында»гы Яхшылык белән Явызлыкның, Хакыйкать белән Ялганның, Яктылык белән Караңгылыкның, Гаделлек белән Гаделсезлекнең... аяусыз көрәше калды, ул төрле шәкелләргә кереп дәвам итә. Ул көрәш еш кына канкойгыч сугышларга әверелеп, әле Кореяда, әле Вьетнамда, әле Әфганстанда, әле Кавказның бөркетләр оялаган биек тауларында калкып чыга...

Нәби Дәүли, фашизм белән йөзгә-йөз очрашып, аның бөтен мәкерен үз җанында кичергән солдат, үз әсәренең азагында яшь кешегә мөрәҗәгать итеп, болай ди: «Ә явызлык ул—фашизм... Бәлки ул дошманның исеме киләчәктә башкача аталыр. Бәлки ул башка киемгә төренеп йөрер, ләкин аның явыз җисеме үзгәрмәс. Ул һаман фашист, һаман үтерүче булып калыр... Син үз йөрәгеңнең сафлыгын сакла. Мин синең күзләреңә иң якты өметләр белән карыйм, яшь кеше!..»

Нәби Дәүлигә гомумтанылу шөһрәтен «Үлем белән яшәү арасында» повесте алып килсә дә, аның шагыйрь буларак таланты утызынчы елларда ук бөреләнгән иде инде. Ә чын-чынлап зур әдәбият мәйданына ул тормышның кырыс сынаулары аша килә. Бик яшьли ятим булып калу, балалар колониясендә тәрбияләнү, шунда эшче яшьләр мәктәбендә уку, аннары бәхет эзләп, Донбасс якларына сәфәр чыгу, Донецк шәһәрендәге металл эшкәртү заводында тимерчелек эшенә өйрәнү, металл кою...

Шул елларда Нәбиулла Донбасста чыга торган «Пролетар» гәзитенә беренче шигырьләрен яза, очерк, мәкаләләрен җибәреп тора. Сәләтен күреп алган егетне тиздән әлеге гәзит редакциясенә әдәби хезмәткәр итеп чакырып алалар. Шунда ул армия хезмәтенә алынганчы эшли.

Ерак Көнчыгыштагы чик буе гаскәрләрендә хезмәт итеп кайтканнан соң, булачак язучы 1935 елда шагыйрьләр мәркәзе—Казанга кайта һәм Ватан сугышы башланганчыга кадәр яшьләр гәзите—«Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») редакциясендә әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли. Бу инде Нәби Дәүлинең шагыйрь буларак формалашу, укучылар күзенә чалыну еллары. Әйе, республикабыз яшьләр гәзите, күпләгән әдипләр өчен, шул исәптән, Нәби Дәүли өчен дә өйрәнү, әдәбият күгенә күтәрелү өчен канат ныгыту мәктәбе булды. Шуна микән, яшьлек рухы, романтик күтәренкелек, оптимизм Нәби Дәүлинең гомер буена аерылмас юлдашлары булып калдылар. Ул үз иҗатында һаман яналыкка, яшьләрчә осталык үрләренә омтылды. Әсәрләренең эчтәлеге, шәкли-формасы ягыннан да яшьләр шикелле һаман эзләнеп яшәде. Шуның өчен дә булса кирәк, аны яшьләр үз тиңнәре кебек яраттылар.

Иҗаты канатлы, үзе яшьләрчә романтик булса да, ул Җирдән аерылмады. Күрәсең, яшьтән үк ятимлек ачысын күрү, тимер кыйнаучы эшчеләр арасында кайнап яшәү, аннары фашизм әсирлегендәге кимсетелүләр, аннан кайтканнан соң үз илендәге «ышанычсызлар» исемлегендә торып, үзендәге шушы кара тапны бетерү өчен үҗәтләнеп иҗат итүләр аңа бар дөньясын онытып, романтик зәңгәрлектә генә очарга комачаулагандыр. Аның «Беренче адымнар» дигән шигыре җанында кайнаган уй-хисләрен ачып бирә шикелле:

... Танып алдым шунда мин Кояшны,
Белмәсәм дә әле исемен.
Киттем йөреп тәүге адым белән,
Хуш инде, хуш, минем бишегем!

Хуш инде, хуш, минем аккаеным,
Тәрәзәмне озак сакладын.
Гафу ит син, әгәр күрешмәсәк,
Минем хәзер шундый чакларым.

—Сезнең белән очам, очам,—диеп,
Торналарга әйттем сүземне.
Йөгердем мин, кинәт егылдым да,
Кеше итеп белдем үземне.

Ә торналар очты, карап калдым,
Ак җилкәннәр йөзеп үткәнен.
Мин беренче кабат белеп алдым
Минем юллар Җирдә икәнен...

Әйе, язмыш шагыйрьгә җәяүләп тә, түшенә ятып та җирдән бик күп араларны узарга, утлар-сулар кичәргә тәгаенләп куйган икән шул. Ул сугыш башында ук чолганышта калып, дошман кулына эләгә, Бухенвальд лагерында үлем белән янәшә тереклек итә, шунда антифашистик азатлык көрәшендә катнаша, әсирләрнең алда булачак восстаниесе өчен кораллар әзерләшә. Ниһаять, Кызыл Армия Германия

жирләренә килеп кергән бер мәлдә, көрәштәшләре белән әсирлектән качып, үзебезнекеләргә килеп кушыла, фашистларга каршы сугышуын дәвам итеп, илгә жиңүчеләр сафында кайта. Кайта дигәч тә, жиңел генә кайта алмый әле ул. Аны башта элеккеге әсирләр белән бергә сыер вагоннарына төяп, автоматлы конвой озатуында фильтрация лагерына жибәрәләр. Юлда янә ачлык-ялангачлык жәфаларын кичерү, кимсетелүләргә дучар булу... Инде аннан акланып кайтканнан соң да, әледән-әле дәүләт иминлек органнарына чакырып, сорау алу, туктаусыз тикшереп торулар...

Миңа бу зур әдипнең якташы буларак та, (ул Әлки районының Мәүләшә дигән кечкенә генә бер авылында туган), соңрак каләмдәше буларак та аның белән әледән-әле очрашкалап тору, сөйләшеп утыру, республикабызда уздырылган Әдәбият-сәнгать көннәрендә бергә катнашу насыйп булды. Шундый вакытларда ул сирәк-мирәк үз башыннан кичкән, ләкин китапларына кертелмәгән хәл-әхвәлләрне дә сөйләштергәли иде:

—«Черек күл»гә бер чакырылуым вакытында яшь кенә капитан сорау алды,— ди Нәби абый. Күренеп тора, фронтта дары исен иснәмәгән бу, киемнәре дә энә-жептән яңа чыккан, ялт итеп тора. Өсталендә гипстан ясап куелган, тешләрен ыржайткан юлбарыс сыны. Теге капитан үзе миннән сораштыра, үзе шул юлбарысның авызына ап-ак бармакларын тыгып-тыгып ала. Сөйләгәннәремә ышанмавы бәбәгенә чыккан, төрле провокацион сораулар бирә, яный, куркыта. Мин әйттем шунда: «Син мине куркытма, энем, дидем, мин фашистлар тоткынлыгында тере юлбарыслар авызыннан чәйнәлеп чыккан солдат. Инде килеп, синең гипстан ясалган бу чучелоңнан да шүрли торган киемнәремне фильтрация лагерына илткәндә бер кисәк ипигә алыштырдым мин. Аны да конвой кулымнан тартып алып, этләренә ташлады. Инде хәзер миндә курку хисенең духы да калмады»,—дидем... Шуннан соң егетем минем белән адәмчә сүләшә башлады...

Нәби ага юктан да кызык табып, авызындагы барлык тимер тешләрен ялтыратып хахылдап көләргә ярата иде. Мондый вакытларда аның йөзен чуарлаган тирән җыерчыклар краяшлы жил кагылган күл өстен хәтерләтә иде.

Якташ абый нинди генә шартларда да көләч йөзле, мишәрләргә хас артык туры сүзле, дуамал, ләкин эчкерсез, ихлас күңелле кеше буларак күз алдымда тора. Аның белән сөйләшкәндә ничектер үзеннең шәхси кайгы-хәсрәтләрең кичерәеп кала, онытыла, рухың яктырып китә, тормышның кадере арта, кешеләргә ышанычың ныгый сыман иде. Әдәби очрашуларда чыгыш ясаганда ул тыңлаучыларга да шундыйрак тәэсир итә иде шикелле. Үзенең күпне күргән аз гына карлыгулы-томат тавышы белән бәхет турындагы, икмәк, жир турындагы, шул хикмәтле ризыкны ижат итүче, адәм баласына яшәү көче бирүче жир кешеләре турындагы шигырьләрен аеруча бер рухлану белән укый иде ул:

Гади сорау: нәрсә соң ул икмәк?
Кирәк, дуслар уйлап карарга.
Ләкин әле икмәк ашау гына
Ярдәм итмәс жавап табарга.

Икмәк нәрсә?
Озын тургай жыры,
Кышкы буран, көзге жил дә ул.
Кайгы да ул, ләкин шатлык та ул,
Бәхет тә ул, изге сүз дә ул.

Дүрт яшеннән ятим калып, үз ризыгын үзе табарга өйрәнгән, фашизм концлагерьларында ачлыкны күргән кеше өчен икмәкнең кадере никадәр олы булуы табигыйдер.

Нәби абый сөйли:

—Лагерьда немец конвоирлары кайвакыт без—әсирләрнең ачка интегүләреннән үзләренә кызык ясыйлар иде. Жиргә бер буханка ипи ташлыйлар һәм кайбер әсирләрнең талаша-талаша шул икмәкне бер-берсеннән йолыккалавын авызларын ерып карап торалар. Үзара сөйләшәләр. Мин инде алман телен аз-маз аңлый идем. «Менә бит, нинди алар совет кешеләре! Бер кисәк ипи өчен бер-берсенең бугазын чәйнәргә әзер торалар. Ә үз илләрендә «Кеше кешегә туган, дус», дип лыгырдаган

булалар...» Әйе, урыс әйтмешли, ачлык ул туган апан түтел шул. Ләкин без нинди генә хәтәр шартларда да чын Кешелек сыйфатларыбызны җуймадык...

Без күреп тордык: элекке әсир-мәхбүсләрнең күбесе үткәннәре турында ачылып сөйләшергә шикләнәләр, җәмгыятьтәге тискәре күренешләргә ризасызлыкларын да кычкырып әйтергә куркалар, дәшми калуны кулай күрәләр иде. Нәби Дәүли исә андыйлардан булмады. Ул язучылар белән очрашуга килгәләгән партиянең Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Табеев белән дә теге яки бу мәсьәләдә бәхәскә кереп киткәли иде. Җыелыш вакытларында залдан чәнечкеле репликалар угы җибәреп утыручыларның да иң активы ул иде. Күрәсең, Ватан алдында үзенең йөзе ак булуга, әсирлектәге Муса Җәлил һәм аның индәшләре шикелле дошманга каршы яшерен көрәшкәнлеге турындагы фактларның кайчан да булса Илгә кайтып ирешәчәгенә ышанып яшәгәндер. Шулар хакында ул үзенең үлемсез әсәрләрендә язса да, үзе исән вакытта Нәби абыйның әсирлектәге батырлыгын дәлилләүче рәсми документлар табылмый торды. Андый документ язучының тууына 80 ел тулу көннәрендә генә Казанга кайтып иреште. Казанның Актерлар йортында үткәрелгән тантаналы кичәдә хәрби комиссариат вәкиле юбилярның хатыны Нажия апага Нәби Дәүлинең сонарып килгән медален тапшырды. Ул укыган документның эчтәлеген тәрҗемә итеп, тулысынча китерәм:

«Үлем лагере Бухенвальдта әсирләрнең яшерен оешмасында булганы, шул оешма өчен кораллар табышканы һәм соңыннан лагерьдагыларның үз-үзләрен азат итүләренә китергән кораллы восстаниедә катнашканы өчен, Советларның сугыш ветераннары комитеты Дәүләтшин Нәбиулла Хәсән улын «Антифашистик азатлык көрәшендә катнашучыга» медале белән бүләкли.

Бухенвальд-Дора группасы секретаре—Н. Дегтярев.»

Ялган, яла, гайбәт эше Иблис гамәлләре бик житез булса да, Хакыйкать барыбер бер көн килеп, өстен чыга, ләкин соңлабрак килеп житә шул ул көн...

Бөек Жиңүнең 30 еллыгына багышлап, «Татарстан яшьләре» газете редакциясендә уздырылган «Түгәрәк өстәл» янындагы сөйләшүдән соң, истәлек өчен төшерелгән фоторәсем бу. Уңнан-сулга: Шамил Маннапов, Нәби Дәүли, Госман Бакир, Мөхәммәт Садри, Сәмигулла Хәйретдинов, Роза Рәхмәтуллина, Габдулла Шәрәфи, Рина Зарипова һәм Рәфикъ Юнысов.

Гомеренең азагына таба Нәби ага үзенең ятимлектә узган балачагы, үсмер еллары турында автобиографик роман язды. Аның «Язмышка юл» һәм «Кояшка таба» дигән ике кисәге укучыларга ирешеп калды. Шәхес культы елларында хаксызга кыерсытылучыларга багышланган «Сталинга хат» повестен тәмамларга өлгерде Нәби

ага. Әле ул үзенең «балачак бишеге»—Әлки якларына тагын бер кайтып, истәлекләрен янартырга, бик яшьли якты дөнья белән хушлашкан әти-әнисе каберләренә чал башын иярга, каты телле, әмма йомшак күңелле якташлары белән очрашып сөйләшергә хыяллана иде.

Күрешүләребезнең берсендә аның йөзе гадәттә булмаганча моңсу иде.

—Беләсеңме, Маннаф, (ул миңа шулай дәшәргә ярата иде), мин туган ягыбызга багышлап җыр яздым бит әле. «Әлкием, әллием-бәллием». Музыкасын Зиннур Гыйбадуллин язды. Әйбәт килеп чыкты. Аны якташ җырчыбыз Мирсәет Сөнгатуллин җырлаячак.

—Бик шәп булган, Нәби абый. Юкса, бик күп районнарның үз җыры бар, безнең Әлки алардан кимме әллә? Моңа шатланырга кирәк, ә сез бүген нишләптер моңсу күренәсез.

Нәби абый авыр сулап, көрсенеп куйды:

—Мына ул җырны якташларыма алып кайтып, тыңлатасы иде дә бит, кәеф юграк. Безнең районга кайтып килүнең Сират күперен кичүгә тиң икәнен үзең дә беләсең. Машина белән килеп алсалар, кайтыр идем кайтуын...

—Ярар, Нәби абый, Язучылар союзының матур әдәбиятны пропагандалау бюросындагы иптәшләр белән бу турыда киңәшермен,—дидем мин. Сүземдә тордым. Тиздән Татарстан Язучылар берлегенең ул вакыттагы идарә рәисе Туфан Миңнуллин исеменә КПССның Әлки район комитеты секретаре Нәҗип Баһманович Бакиров имзасы белән рәсми хат килеп төште. Нәби Дәүли белән мине туган районыбызга очрашуга чакырганнар иде. Без инде бу чарага әзерләнә дә башлаган идек. Әмма берничә көннән очрашуларның әлегә кичектерелеп торуы турында әйтеп, райкомнан Язучылар берлегенә кабат хәбәр иткәннәр. Соңыннан белдек: анда башка эшкә күчүе сәбәпле, райкомның беренче секретаре алышынган икән...

Шуннан озак та узмастан, Нәби ага каты авырып, хастаханәгә керде. Ә тагын ярты елдан, 1989 елның маенда Нәби Дәүлинең йөрәге тибүдән туктау турындагы кайгылы хәбәрне ишеттек. Инде ул үзен «таң белән уятып, дөньяга озаткан» туган ягыбызга җыр булып кына кайта ала иде:

...Китсәм дә мин тагын каядыр,
Әлкине сагынып уйлармын.
Гафу ит, туган як, улыңны,
—Яңадан кайтмаса юлларым.

Әлкием, әллием-бәллием,
Син минем балачак бишегем.
Күңелдә—мәңгелек исле гөлем,
Йөрәктә яши лә исемең...

Шагыйрьнең туган төбәгенә карата җылы уллык яратуын да, газиз җирен даимән сагынып яшәвен дә, тиздән барысы белән дә мәңгелеккә аерыласын сиземләп сагышлануын да тоям мин бу җырда.

Шулай да, үлем белән яшәү арасында калган чакларында да Әҗәлне җинә алган, «атказанган» яисә «лауреат» шикелле купшы исемнәр алып «бозылмаган», төшенкелек явызга бирешмәүчән Нәби ага Дәүли «каядыр китсә дә» үз иҗатының халык күңелендә каласына тирәннән ышана, шуңардан яшәү көче, җан тынычлыгы таба, очрашуларның дәвамлы булачагына өмет итә иде. Инде аның бу өметле уйлары-хыяллары җан җылысын саклаучы әсәрләрендә, радио аша әледән-әле яңгырап торган моңлы-аһәңле җырларында гына калды...

Ә йөрәктән чыккан ихлас җырларга күперсез елгалар да, асфальт түшәлмәгән кыен юллар да киртә була алмый. Чөнки алар җир кешеләренә багышланганнар. Нәби Дәүли бу турыда кат-кат искәртә. Хәтта ул үзенең Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән соңгы шигъри мәҗмугасын да «Мин Җирдә калам» дип исемләгән. Шулай аталган шигырендә ул: «Әгәр миңа Айга очарга ракетага утыр, дисәләр, Ай кешесе булып яшәргә мең ел итеп гомер бирсәләр, нишләр идем икән?»—дигән сорау куя да, болай дип җавабын да бирә:

Юк, мин очмыйм, мин Җирдә калам.
Җирдә минем йөргән сукмагым.

Бер минут та мин яши алмам,
Күрми торсам сезне, дусларым,
Йөрәгемне яну алганда,
Эчми торсам Идел суларын.

....

Йөрәгемдә каным суынып,
Жир жылысын әгәр сизмәсәм.
Сөйгән кешем минем кем булыр,
Яннарымда сине күрмәсәм?
Икмәгемне куеп табынга,
Синең белән бергә булмасәм?

«Бер көн артык миңа мең елдан, Айда түгел, туган илемдә!»—дип нәтижә ясый шагыйрь. Аның «Жирдә калу» дигән образлы фикеренә үз иҗаты, үз жырлары белән туган халкы күңелендә калу турындагы уйлары салынганлыгы да аңлашылса кирәк. Шөкер, Нәби ага Дәүлинең уй-хыяллары безнең көннәрдә тормышка юл яра, аның иҗаты, аның жырлары үз гомерен дә озайтып, яшь буын күңеленә күчә, жир кешеләре белән киләчәккә бара.

Нәби Дәүли иҗаты күп тармаклы, зур иҗат. Аны бер мәкаләдә генә колачлау һич мөмкин түгел. Ул шагыйрь һәм прозаик булудан тыш, бик шәп публицист, тәнкыйтьче һәм драматург та бит әле. Аның балалар өчен язган пьесалары әле бүген дә Казан курчак театры сәхнәсеннән төшкәне юк. Әйе, ул балаларның яраткан язучысы да. Ә бу зур иҗат әле тиешенчә өйрәнелмәгән. Каләмдәшләреннән Гали Халит, Зәки Нури, соңрак вакытларда Салих Маннапов, Марсель Галиевнең очеркларыннан һәм кайбер китапларына карата рецензияләрдән кала, Нәби Дәүли иҗаты турында этрафлы хезмәтләр юк та бугай. Нәби абый исән вакытта моңа үзе дә борчыла торган иде. Кыскасы, милләтебезнең талантлы улы, һәрьяклап кызыклы шәхесе калдырган рухи хәзинә җентекле өйрәнүчесен һәм халкыбызга җиткерүчесен көтә.

Шамил МАННАПОВ

Киләсе санда укыгыз

«...Саимәнең күңел күпере аша беренче мәртәбә Гүзәлне имезгәндә тойган бәхетле минутлары йөгереп үтте. Хәтта бала имезгән вакыттагыча имчәкләре чеметкәләгәндәй булды. Әйтерсең лә, күкрәкләренә шаулап сөт төшә. Ул үзе дә сизмәстән күкрәкләрен капшап алды. Тик кисәк кенә шул чиксез бәхетле минутларын өч ел буе чит кеше баласы белән уртаклашуын, ә үз йөрәк җимешен бүген имеп яткан малай урынында күз алдына китереп, бөтен тәне куырылып куйды...»

Әлеге өзек «Тулгак» исемле яңа повестьтан алынды. Аның авторы Гөлчәчәк Галиева—мондый күләмле әсәр белән «Казан утлары»нда беренче мәртәбә катнаша. «Тулгак»—сугыштан соңгы авыл, район тормышын яктырткан, кешеләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтен, авыл кешесенең психологиясен тирәннән ачып бирә алган мавыктыргыч вакыйгаларга бай, җанлы тел белән язылган әсәр. Аны сез журналыбызның җиденче санында укый аласыз.

Безнең календарь

Гомәр Галинең тууына 100 ел

Егерменче-утызынчы елларда күренекле әдип, тәнкыйтьче, әдәбият галиме, җәмәгать эшлеклесе саналган, татар совет язучыларының, һич бәхәссез, абруйлы лидерларыннан берсе булган атаклы Гомәр Гали исеме бүгенге укучыларыбызга, яшь буынга таныш микән? Әйе, «ни сөйли» ул бүген—гасыр азагында һәм инде яңасына күчкәндә? Безнең замандашлар, ягъни илле-алтмыш яшьлекләр, татар совет әдәбиятын өйрәнгәндә, табигый, аның исеменә еш юлыкты. 1958 елда басылган калын сайланмасын да, аңа яшьтән үк уңган-өлгер әдәбиятчы-тәнкыйтьче дә булган Гариф Ахунибыз язган кереш мәкаләне дә кызыксынып укыдык без. Әйе, бу әдип тә, илленче еллар азагында арабызга иҗатлары белән кайткан Г. Ибраһимов, К. Тинчурин, Г. Нигъмәти, Х. Туфаннар кебек үк, халыкның күңел күгендә кабат балкыган йолдызыбыз дип ышандык. Хәсән ага Туфанның: «Г. Ибраһимов—әдәбиятыбызның мәгънәви президенты, рухи җитәкчесе булса, Г. Гали—әдәбиятыбызның баш министры иде» дип әйткәне дә хәтердә. Хәсән ага, гомумән, бу олуг яшьтәше—колоритлы шәхес турында дулкынланмыйча сөйли алмый иде: аңлавыбызча, ул—аның (һәм «бунтарь» Такташның да!) иҗади, эзләнүле шигырь яшьлегенең, хәтта йөрәгенең «комиссары, Фурмановы» булган икән (соңгы егерме елында бу миссияне аксакал өчен Мостай Кәрим үтәвен дә беләбез).

Әйе, тирән белемле, киң эрудицияле, шигырьне бик яраткан Г. Гали дусларына файдалы күп кинәшләр бирүче, алар өчен борчылып, янып яшәүче эчкерсез дус булган. Такташ һәм Туфаннарның шигырь ярышлары, чәчәнлек-импровизация белән «әйтеш»ләренең дә шаһиты булган ул, язып барып, «бу—тарихка калырга тиеш» дип, җыеп та куйган... Әмма, кызганыч ки, алар сакланмаган. Бу турыда Хәсән ага 1966 елның көзендә без, бер төркем әдипләр, пароход белән Әстерханга—әдәбият атналыгына барганда, кайта-кайта сөйләгән иде... Соңыннан да аның иске Матбугат йортыбызның бүлмәләрен: «менә бу Гомәр Гали утырган кабинет...» дип, горурланып күрсәтеп йөргәне хәтердә.

Шунсы да кызыклы: Х. Туфанның беренче китабын да, үзе Урта Азия республикалары буйлап сәяхәттә йөргәндә, нәкъ менә дусты Г. Гали (Галимҗан Нигъмәти белән бергәләп!) җыеп, төзеп, 1929 елда «Яңалиф» нәшриятында дөньяга чыгара (мондый хәл утыз биш елдан соң да бер кабатланды: Рәшит Әхмәтҗан солдат хезмәтендә чакта, 1965 елда, аның беренче китабын—«Хыялларым үзем белән» мәҗмугасын шулай өлкәнрәк каләмдәшләре әзерләп, бастырып чыгарган иде!). Хәсән ага бу хәлдән бихәбәр булып, Ташкентта, китапханәдә үз китабы белән очраклы рәвештә «күрешеп», бик гаҗәпләнә. Мондый кайгыртучанлык Фатих Кәримгә, соңрак Сибгат Хәким кебек яшьләргә карата да була. Фатих Кәрим дә Г. Галине бик нык хөрмәт итә, 1937 елда Г. Гали кулга алынгач, «ул гаепсез иде, дип, аның өчен—елап тост күтәрә»—соңыннан үзенә карата кузгатылган гаепләү кәгазендә дә шулай язылган була... Сибгат ага да бу әдип турында тирән хөрмәт белән, гел сокланулы сүзләр әйтә иде. Бигрәк тә Г. Галинең зур шигърият өчен, талантлы шагыйрьләр өчен янып, кайгыртып яшәве кадерле иде аңа. «Беренче срогын тутырып кайткач, миннән ун еллык «Совет әдәбияты»н алып торып укыды. Китергәндә бик күңелсезләнгән иде. «Сибгат, поэзия бик начарайган—төшкән бит... Бу ни хәл?!» дип борчылып сөйләгәне күз алдында тора», диде Сибгат ага.

Башка өлкәннәребездән дә күп яхшы сүзләр ишеттек. Әнә шулай күзаллана иде безнең буында Гомәр Гали—нәкъ менә аның тынгысыз рухын онытмаган, зур милли ялкынын дәвам иткән шагыйрьләр, исән замандашлары аша... Һәм бу легенда-кыйсса безгә дә кадерле иде! Хәзер биографиясен, иҗат юлын да хәтердә яңартып узыйк.

Гомәр Билал улы Галиев 1900 елның 16 июнендә хәзерге Буа районының Иске Тинчәле авылында туа. Крестьян гаиләсендә. Мәктәп-мәдрәсәдә белем ала. Бик яшьтән, «бәхет эзләп», читкә чыгып китә, Донбасс шахталарында эшли. Гражданнар сугышында катнаша. 1919-1920 елларда Сембердә чыгучы татарча газеталарда язышка башлый. 1921 елда исә яшь әдип Казанга килә, ТКУга—Татар коммунистлар университетының әдәбият бүлегенә укырга керә. Шул чорда көндәлек матбугатта хикәя-очерклары басыла. 1925 елда исә ТКУ тәмамлаган яшь Г. Галине, сәнгать белгече П. М. Дульский белән бергә, Парижга—сәнгать күргәзмәсенә җибәрәләр (булган бит заманнар!). Күпме тәэсирләр! Ул чорда чит илгә чыга алу бәхете эләккән беренче татар әдибе була ул; кайткач, газета-журналларда кызыклы сәяхәтнамәсен бастыра, соңрак «Гажур» нәшрияты аны «Чит илләрдә» исемле аерым китап итеп чыгара (1926). Үзем ул Парижларны житмешенче елларда гына күргәнгә, бу юлъязмаларны сокланып, көнләшеп укыганым истә—студент чак бит!

1925—1927 елларда Г. Гали—«Безнең юл» журналы (соңыннан «Атака», «Яңалиф», «Совет әдәбияты» исемнәрендә чыкты, шул ук үзебезнең—«Казан утлары»! Чыннан да «Безнең юл»ның—безнең журналның беренче редакторларыбыздан берсе булган әдип белән ничек горурланмаска?!) баш мөхәррире. Ә 1927 елдан, ун ел дәвамында, Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият секторы мөдире булып эшли. Менә кайда бирелә аңа әдәбият көчләрен, талантларын туплар өчен иркен мәйдан! Әле бит ул төрле уку йортларында, институтларда татар әдәбияты да укыта (медицина институтында кафедра мөдире дә була!). Монда да күпме укучылар тәрбияли бу тынгысыз шәхес.

Ул—шулай ук, «татар пролетар язучылары», аннан Татарстан язучылары берлеген оештыручылардан—башта комитет, аннары—идарә әгъзасы. 1934 елдан—СССР Язучылар союзында тора. 1937 елда хаксызга репрессияләнә. 1947 елда төрмә срогын тутырып кайтса да, 1949 елда яңадан кулга алына, Себергә сөргенгә озатыла—1954 елда ул шунда, фаҗигале рәвештә, вафат була.

Китапларын да искә төшерик: «Бәхет» (1924), «Кубан буйларында» (1927), «Нәфисә җиңги» (1928) кебек хикәя, очерк җыентыклары... К. Нәҗми һәм Г. Нигъмәтиләр белән берлектә чыгарган «Ун ел эчендә татар матур әдәбияты» китабы (1930)... Моңа өстәп, мәктәпләр өчен дәреслек-хрестоматияләр бастыруын да әйтергә кирәктер. Ә тәнкыйтьче буларак, мирасында Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, М. Фәйзи, К. Тинчурин, К. Нәҗми, Х. Туфан кебек зур язучыларның әдәби портретлары, күп мәкаләләр бар. Большевистик рух, вульгар социологизм шаукымы да сизеләдер—бүгенге күзлектән караганда. Хәер, әдип—үз чоры, катлаулы заман баласы булганны да онытмыйк. Г. Ахуновның да аңа багышланган мәкаләсе «Нигез ташларын салганда» дип атала бит. Шулай, нигезләрне алмаштырып, үзгәртеп яңаны салу—үзе үк хәтәр эш. Чынлыклар, мәгънәви мирас ташлары буталып, убылып торганда, нәкъ шул ташлар шактый күп олуг затларыбызның үз башларына да җитмәдемени?

Халкыбызның нинди шартларда да талантын раслап, рухи мәдәният көчен, акыл-фәһемен саклап, бүген дә әле иҗтиһат, эрудиция, уңганлык, булганлык үрнәге булып саналырга хаклы Гомәр Гали кебек асыл затларыбызны онытмыйча, кабат-кабат исемнәрен яд итәргә тиешбездер. Чөнки һәммәбез дә әнә шундый зур шәхесләргә бурычлы!

Рәдиф ГАТАШ

Әнәс Кариның тууына 80 ел

Шагыйрь Әнәс Кари (Әнәс Кари улы Кариев) 1920 елда Татарстанның Азнакай районы Уразай авылында крестьян гаиләсендә туа. 1937 елда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1939 елда Үзбәкстандагы Үргәнеч институтын тәмамлый һәм шунда ук ике ел укытучы булып эшли. Аннары Туган якларына кайтып 1942 елга кадәр урта мәктәптә укыта. Шул елның көзендә ул фронтка китә, каты яраланып армия хезмәтеннән азат ителә. Сугыштан кайткач та укытучылык һөнәрен ташламый, берникадәр вакыт Үргәнеч укытучылар институтында, Арча педагогия училищесында һәм Питрәч районының Янсуар урта мәктәбендә укытучы булып эшли, шул ук вакытта иҗат эше белән дә шөгыльләнә.

Ул нигездә балалар өчен иҗат итә. Аның «Балаларга бүләк»—1947, «Гөлбакча»— 1948, «Күңелле ел»—1951, «Сыналган мәхәббәт»—1956 һ. б. китаплары укучылар тарафыннан яратып кабул ителә.

Ул 1954 елның 4 апрелендә вафат булды.

Шамил Шаһгалинең тууына 80 ел

Драматург Шамил Шаһгали (Шамил Шаһгали улы Миңлегалиев) тумышы белән Башкортстанның Чакмагыш районы Калмабаш авылыннан. Яшьләй ятим калып, балалар йортында тәрбияләнә. Чиләбе өлкәсендәге Аргаяш урта мәктәбен һәм Эстәрлетамак шәһәрендә бер еллык радистлар курсын тәмамлый.

1941 елны Свердловск хәрби училищесына укырга керә. 1942 елдан ул—хәрәкәттәге армиядә. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз, Икенче һәм Өченче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр белән бүләкләнә.

Ватан сугышыннан кайткач, Ш. Шаһгали Уфада Башкортстан халык иҗаты йорты директоры булып эшли. Соңрак ул К. А. Тимирязев исемендәге Башкорт дәүләт педагогия институтының тел һәм әдәбият бүлегендә укый. Озак еллар Башкортстанда һәм Татарстанның Чирмешән район үзәге урта мәктәбендә тел һәм әдәбият фәннәре укыта. Алтмышынчы елларда ул Мәскәүдә Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларны һәм Мосфильм киностудиясе каршындагы режиссерлык курсларын тәмамлый.

1955 елны Ш. Шаһгали үзенең «Бала бәхете—ана бәхете» исемле беренче пьесасын яза. 1956 елны авыл тормышын сурәтләгән «Таң атканда» пьесасы дөнья күрә. Бу пьеса белән ул Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсенә аяк баса. 1962 елны нефтьчеләр тормышына багышланган «Без аерылышмабыз» драмасы да шул ук театр сәхнәсендә куела. Драматургның «Яшьлек мәхәббәте», «Дуслык һәм мәхәббәт», «Тайга йолдызы», «Курай моңы» исемле пьесалары алтмышынчы—житмешенче елларда Татарстан һәм Башкортстанның профессиональ һәм халык театрлары репертуарына кертелә. «Тайга йолдызы», «Курай моңы», «Буран» драмалары рус теленә тәрҗемә ителеп, күп кенә театр сәхнәләрендә уйнала.

1955—1983 еллар арасында драматург өч дистәгә якын сәхнә әсәре иҗат итә. Шуларның унтугызы татар, башкорт, рус, чуваш театрлары тарафыннан сәхнәгә куела.

Шамил Шаһгали 1987 елны вафат булды. Ул 1962 елдан Язучылар берлеге әгъзасы иде.

Uquçı süze

. . .

Jurnalnıņ 2000 nçe yıldagı berençe sanın uqıgaç, küņelgə rəxətlek inde. Yazuçılar tügərək østəl artında tınıç, matur əngəmə oyıştırgannar: birelep, yotılıp uqıp çıqtım. Ləkin əle bik tıyılıp, üz-üzləren tıyıp qına søyləşkənnər kebek sizdem. F. Minnullin kebek ədəbi tənqitçelər yuq şul xəzer. Şulay da, əlege yazmalarnı uqıgaç, kiləçəktə ədəbi tənqit bulaçagına ışandım.

Min, məsələn, üzem «Qazan utları» jurnalın qulıma alu beləm ük axırın uqıy başlıym. Başqa uquçılar da minem kebekter dip beləm. Beləsezme ni øçen şulay başlıym: mine, uqıtuçı bularaq ta həm çın tatar xatın-qızı bularaq ta, tatar artistlarınıņ, səngət əhellərenen, yazuçılarnıņ, galimnərnen həm, gomumən, kürenekle şəxeslərebeznen nindi eşlər başqaruları qızıqsındıra. Qazanıbızda da, məgrifət uçagı bularaq, nindi eşlər bargan, millətkə faydalı nərsələr eşlənelə, şularnı beləse kilə, çønki uquçılarıma yanalıqlarnı citkerəsem bar, uqıtuçılar belən təmləp-təmləp bəxəsləşəse bar, ul yanalıqlarnı awıl xalqına, əti-ənilərgə citkerəse bar; üzemneņ belememne arttırası, fikerne çarlıysı, telemne kamilləşterəse, søyləmemne maturlıysı, ütkenlise bar h. b. Menə «Qazan utları», cəməgət, bezne nərsələrgə øyrətə, şuņa kürə utlar yap-yaqtı yanıp bezgə dəres yulnı kürsətergə tieş.

Miņa bu məqələmne yazarga etərgeç birgən Tufan agaga zur rəxmətemne citkersəgez ide. Anıņ: «Uqıtuçılarga məcbüri yazdırırga kirək jurnalnı... Kommunistlar çorında şulay ide bit...» digən süzləre mine uylandırdı. Tufan aga bu fikerne, møgayın, bəxəs quzgaltır øçen genə əytkənder, məcbürilekne yarata torgan yazuçı tügelder ul. Tufan aga, zinhar øçen məcbürilekne kertə kürməgez, məcbüri eşləngən eş təmle bulmıy, qəderle bulmıy, yazılsaņ da uqıysı kilmi anı, kemneder açulanasıņ gına, tagın şul uq citəkçelərgə genə eləgə. İņ yaxşısı jurnal, yugarıda əytkənemçə, şəp çıgarga tieş, uquçı atlıgıp torsın, anıņ øçen. Min üzemneņ təqdimnərne əyttem inde. Məcbüri eşlətü aşıysı kilməgən əyberne, koçləp aşatu kebek ul. Tufan aganıņ min üzem bøten yazmaların uqıp barırga tırışam, anıņ yazmaları basılıp çıqqan gazetalarnı ezləp tabıp uqıym. Bøten xalıq yarata anıņ yazmaların, rəxmət aņa, şulay dəwam itərgə xoday sawlıq-səlamətlek birsen. Xalıq arasında xəzer, Tufan əytkən bit, Tufan şulay dip yazgan bit dip küp søylilər. Bu bit Tufannı yaratu digən süz. Tufannı yaratabız, ixlastan yaratabız, Arçadan deputat itep saylanuı belən çın küņeldən gorurlanam, awıl xalqı da şulaydır dip beləm. Üzebeznen Kama Tamagı rayonınnan kandidat itep kürsətelsə də, ul ütəçək ide, monı min ışanıp əytə alam. Bezneņ rayon xalqına küp eşləde ul, bez monı beləbez. Rəxmət aņa!

Tuqta, beraz çitkə kitelde, axrı. Ləkin yazılırga, əytelergə tieşle fikerlər alar. Hiç xilaflıq yuq monda.

Xørmətle «Qazan utları» xezmətkərlərə, jurnalnı yaxşırtu həm uquçı küp alsın øçen, berniçə təqdim yazıym əle.

1. Ə. Borhanovnıqı şikelle ütken, fənni publisistik yazmalar kirək.

2. Ayırım yazuçılar icatına həm şəxesenə qarata yazmalar bulsın ide. Məsələn, M. Yunısov, W. Yunıs, Z. Xəkim h. b. bik küplər turında. Nik urısnıņ Puşkinınıņ pra-pra-pra babaları, tugannarı, onıqları, əllə kemnəren ezləp tabıp dəresleklərgə kertələr, uquçılarga øyrətələr. Ul Yeseninnı tagın! Ə bezneņ Tuqaylarnıņ, Taqtaşlarnıņ, X. Tufannarnıņ h. b. bik küplərneņ nəsel-nəsəplərə yuqmı əllə?

S. Rəmievlərneņ həm F. Əmirxannarnıņ nəsel ceplərə turında yotılıp

uqıdıq bit. Mondıy yazmalar bezgə uqıtuçılarğa hawa kebek kirək, şəxeslər ürnəgendə uquçılarnı, yəş buınnı tərbiələrgə kirək.

3. Tel həm ədəbiat ğalimnərenen nərsə, nindi tema estendə eşləwlære həm şulay uq, ğemumən, şəxes bularaq niçek yəşəwlære, millətkə niçek xezmət itülære turında yazmalar bulsın ide. Xəzer beznen kandidatlarıbız, doktorlarıbız bik küp bit. Ə bez, uqıtuçılar, beznen belən bergə awıl xalqı alar turında bernərsə belmibez. Nindi açış yasağannar, nindi yanalıq kertkənnər, nindi tema estendə eşlilər, xalıqqa, millətkə, telebezgə, ədəbiatıbızğa ul açışlarnın faydası barmı, yuqmı? Bolar barısı da beznen eçen qızıqlı bit.

4. Millətebez eçen can atıp eşləp yerüçe səyəsətçelərebez turında beləsebez kilə.

5. Telebez turında yazmalar bulsın ide. Çenki telebez bik çuarlana. Bügen bu məs'ələdə tatar tele uqıtuçıları aptıraşta. Məsələn, "sıynıf" ta dibez, "klass" ta dibez, "yanvar'" da dibez, "ğinwar" da dibez. Küp andıylarğa misallar.

Qısqası, «Tizrək qaytıym əle, «Qazan utları» kilgən ide, şunı uqıysı bar", dip aşığıp qaytırlıq bulsın. Təmle aş aşıysı bar kebek qızıqtırıp torırlıq bulsın ide.

Yarıy, xuşıgız! İsən-saw eşləgez! İcadi unışlar telim Sezgə!

Mədinə KƏRİMULLİNA.
Kama Tamağı rayonı.

* * *

Ğarif Axunov əsərlərenen kübese berençe mərtəbə "Qazan utları" jurnalında dənya kürə. Anın əsərlərendə surətləngən waqiğalarnın baytağı bez ğemer itkən çorğa turı kilə. Şunadırmı, Ğ. Axunov icatı künelemə bik yaqın. Bez bit anın belən yəştəşlər, ber zaman keşelære. Tormış dəreslegen osta itep kürsətə belgəngə canğa yaqındır inde ul əsərlər. Menə "Küz nurım" digən yazmasın da (Q.U. №2, 2000) yaratıp uqıp çıqtım. Şunısı qızıq, ədipne dəwalağan tabibə Rezidə Ğaliullina minem küzləremə də operatsiə yasağan ide. Qulı cinel buldı anın. Küzlərem xəzer də bik əybət kürə. Tabibənen awırularğa cılı mənəsəbəten, olı künellelegen yazuçı bik osta, matur surətləgən diəsem kilə.

Tağın şunısı da bar: xalıqqa tanılğan, əsərləren xalıq yaratıp uqığan yazuçılar üzlərenen tormış, icat yulları turında üzlære isən çaqta yazıp çığarğa tieşlər dip uylıym min. Andıy əsərlərne uquçılarnın yaratıp uquları eçen genə tügel, yazuçı yəşəp icat itkən çornın ədəbi moxitı, ictimağı tormışı belən, şul çaqtağı waqiğalar həm alarğa qarata yazuçının mənəsəbəten anlaw eçen, avtornın tormışınnan ğibrət, anın şəxesen ürnək itep alu eçen. Yazuçının barlıq əsərləren uqıp barsaq ta, avtornın üze turında kübebez bernərsə də belmi bit. Ber genə misal. Barlas Kamalov belən ğemer buyı tanış-beleş bulıp yəşəsəm də, anın tormışındağı qayber bik ğibrətle nərsələrne "Qazan utları"nın 1 sanındağı "Ütkənnərgə borılıp qarasam" digən yazmasınnan uqıp qına beldem.

Yazarğa unaysız bulsa da, tağın ber nərsəne əytmiçə qala almıym. Qayber avtobiografik yazmalarda yazuçı, bilgele ber tanılğan şəxes belən yəmsez mənəsəbətləren kürsətep, opponentın "taptap-tipkələp" kitə. Ğədəttə ul mərxüm keşe bula. Mondıy urınnarnı uqığanda təmle rızıq aşağanda awızğa çeben kerep kitkən kebek bula. Tormış bit inde ul: kem kem belən açulanışmağan da, kem kem belən bəreleşməgən?! Dənyanıqı—dənyalıqta! Ülgənnərdən üç alu kileşmi.

Nurulla BİKMULLİN.
Vasilyevo bistəse.

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Казанда традицион шигырь бәйрәме булып узды. Быел ул Җинүнең 55 еллыгына багышланды. Митингны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин ачып җибәрде. Аннан соң сүз Тукай премиясенең быелгы лауреатларына бирелде. Алар—шагыйрь **Зөлфәт**, артист **Илдус Әхмәтҗанов**, рәссам **Шамил Шәйдуллин**. Яна лауреатлар хезмәтләрен югары бәяләгән өчен халыкка, республика җитәкчеләренә рәхмәтләрен белдерделәр.

Шигырь бәйрәмендә шагыйрьләр Г.Рәхим, К. Латыйп, А. Хәлим, М. Әгъләм, Р.Гаташ, Х. Әюп, Р. Мингалим, Ә. Рәшит, Л.Шагыйрьҗан, С. Гәрәева, Г. Морат, И.Гыйлаҗев, Н. Хисамов, Р. Газизов, Р. Рахман һ. б. чыгыш ясадылар. Бәйрәмдә шулай ук күренекле артистлар—А. Арсланов, М. Галиев, А. Вәлиев, И. Биктаһировлар катнашты. Шигъри митингны шагыйрь З. Мансуров алып барды.

Бәйрәмдә Татарстан Премьер-министры урынбасары И. Хәйруллин, ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары Р. Миннуллин, ТР мәдәният министры И. Тарханов катнашты.

Яна лауреат шагыйрь Зөлфәтне якташлары—Мөслим районы хакимияте башлыгы Р. Шәрипов һәм Мөслим «Якташлар» җәмгыяте вәкилләре котлады.

Тукайның тууына 114 ел тулуга багышланган әдәби очрашулар Кырлайда һәм республиканың бүтән район-шәһәрләрендә дә үткәрелде.

СЫНЛЫ СӘНГАТЕБЕЗ—МӘСКӘҮДӘ

Мәскәүдә рәссамнарның Үзәк йортында Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музее һәм Татарстан Рәссамнар берлеге коллекциясеннән рәсем сәнгате һәм гамәли сәнгать күргәзмәсе ачылды. Күргәзмәгә Татарстан сынлы сәнгатенең 100дән артык классик һәм хәзерге заман әсәрләре куелган. Анда сынлы сәнгатебезнең бер гасырлык үсеш чоры чагыла.

Күргәзмәне ачуда Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, Русия Федерациясе министры Р. Абдулатыйпов, Татарстан вице-премьеры И. Хәйруллин, мәдәният министры И. Тарханов, матбугат, телерадиотапшырулар эшләре һәм масса-күләм коммуникация чаралары министры З. Вәлиева катнашты.

ТАТАРДА ДӘҮЛӘТЧЕЛЕК ФИКЕРЕ

25 апрель көнне Фәннәр академиясенең кече залында «Татар халкының дәүләтчелек тарихы» дип исемләнгән конференция үткәрелде.

Академия һәм университет галимнәренең чыгышлары «Борынгы чорда һәм урта гасырларда төрки-татар дәүләтчелегенең мөһим мәсьәләләре», «XYI гасырның икенче яртысында—XX гасырда татар дәүләтчелек фикере һәм аны тормышка ашыру юллары» кебек темаларга багышланды.

БЕЗНЕКЕЛӘР ИЛ ГИЗӘ

Апрель башында Пермь өлкәсендә Татар әдәбияты көннәре уздырылды. Ул Пермь өлкәсе белән Татарстан арасындагы мәдәни хезмәттәшлек килешүе нигезендә оештырылды.

Әдәбият көннәрендә Татар ПЕН үзәге президенты язучы Туфан Миннуллин, Язучылар берлеге рәисе урынбасары Галимҗан Гыйльманов, Әхсән Баян, Батулла, Лалә Гыймадиева, Фәйрүзә Мөслимова, Мәсгут Имашев, Илсөяр Иксанова, Рәшит Ягъфәров катнашты. Татар зыялылары өлкәнең Барда, Орда, Уинск, Күнгер, Октябрь, Суксун, Березовка, Лысьва районнарының татар авылларында бик күп чаралар уздырдылар.

* * *

Татарстан мәдәният министры урынбасары З. Нигъмәтуллина җитәкчелегендәге делегация (аның составында Татарстан Мәдәният министрлыгының төп белгече Э. Камалова, Татарстан яшүсмерләр китапханәсе хезмәткәрләре, язучылар М. Хәбибуллин, Ж. Дәрзаман, К. Миңлебаев, баянчы Х. Нигъмәтҗанов, Татарстанның халык артисты К. Хәйретдинова, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле биючеләре Ләйсән һәм Айрат Хәмитовлар бар иде) 20-22 апрельдә Оренбургта Татар әдәбияты көннәрендә катнашты.

* * *

Төркиянең Спарта һәм Анкара шәһәрләрендә төрки дөнья мәдәнияте һәм сәнгате симпозиумы тәмамланды.

Анда Татарстан рәссамнары һәм сәнгать белгечләре дә катнашты. Алар—Рөстәм Шәмсүтов, Бакый Урманче исемендәге премия лауреатлары Наилә Кумысникова

(күн мозаикасы) һәм Фәридә Хасьянова (графика), шулай ук танылган сәнгать белгече Гүзәл Сөләйманова-Вәлиева.

«ДӘДӘ КОРКЫТ» КИТАБЫ ЮБИЛЕЕ

Төрки халыкларның әдәбияты бик бай, аларның тарихы да шактый борынгы. 1983 елда татар әдәбиятының күренекле ядкаре «Кыйссаи Йосыф» әсәренең иҗат ителүенә 750 ел тулу олы вакыйга итеп билгеләп үтелгән иде. Моннан берничә ел элек кыргыз халкының бөек эпосы «Манас»ка мең ел тулуны шулай ук зурлап бәйрәм иттеләр.

Ниһаять, әзербәйҗан халкының һәм барлык төрки дөньяның бөек эпосларыннан берсе «Дәдә Коркыт» китабы әсәренә 1300 ел тулды. Әзербәйҗан башкаласына дөньяның барлык төрки илләреннән дәүләт эшлеклеләре, галимнәр, язучылар тантанага җыелды.

Әлеге тантаналарда Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, филология фәннәре докторы Фоат Галимуллин катнашты.

ЖУРНАЛИСТЛАР СӘҮДӘГӘР ЙОРТЫНА КҮЧӘЧӘК

Казан мэры К. Исхаков Журналистлар йорты урнашачак бинада—Тельман урамындагы 24 нче йортта киңәшмә үткәрде.

XX гасыр модерн стилендәге бу матур йорт кайчандыр сәүдәгәр Перельштейннныкы булган.

Журналистлар йортын дәүләт кабул итүе 1 июньгә билгеләнгән. Киләсе ике-өч атнада ул барлык кирәкле җиһазлар белән дә тәэмин ителәчәк. 20 июнь тирәсендә, Сабан туена монда беренче кунаклар көтелә—Казанда «Бөтенрусия—2000» дигән матбугат фестивале узачак.

ЯҢА КҮРГӘЗМӘ

Күренекле әдип, XX гасыр башында татар мәдәниятенә өлкәсендә актив хезмәт иткән җәмәгать эшлеклесе Фатыйх Кәриминең (Мөхәммәтфатыйх Гыйльман улы) тууына (1870-1937) апрель аенда 130 ел тулды. Шушы уңайдан Татарстан Милли китапханәсендә аның тәрҗемәи хәленә һәм иҗатына багышланган «Милләт хадиме» исемендә күргәзмә ачылды.

Анда әдипнең «Мохтәсаре тарихе гомуми», «Мохтәсаре җәгърафия», һ. б. китаплары, күпсанлы тәрҗемә әсәрләре, ул оештырып, бастырып чыгарган мәҗмугалар, басмалар урын алган. Күргәзмәгә аның чордашлары, фикердәшләре, күренекле әдипләр Р. Фәхретдин, С. Рәмиев, С. Максуди h. б. китаплары, аларның Ф. Кәрими хакындагы фикерләре дә бай эчтәлек бирә.

КАБАРДА-БАЛКАР РЕСПУБЛИКАСЫ ТАТАРЛАРЫ БЕРЛӘШТЕ

Нальчик Кабарда-Балкар Республикасы татарларының оештыру конференциясе узды. Анда «Туган тел» исемендәге татар мәдәният үзәге төзелде.

Кабарда-Балкарда өч меңнән артык татар яши. Татар мәдәни үзәген төзүгә моннан ике ел элек ике республика җитәкчеләре кул куйган килешү нигезендә ирешелде. Конференция кысаларында «Идегәй» эпосын балкар телендә тәкъдирләү булды.

АМЕРИКАДА ТАНЫЛГАН ТАТАР КЫЗЫ

Казанда «Европа-Азия—2000» дип аталган музыка фестивале булып үтте.

15 илдән җыелган музыкантлар арасында ерак Америкадагы Коннектикут шәһәреннән «Lumina» квартеты да бар. Аның җитәкчесе—татар кызы Асия Мортазина—70 нче елларда Одесса консерваториясен тәмамлагач, чит илгә киткән була.

ТАТАР ГАЛИМЕ ТУРЫНДА

Төркиянең Анкара шәһәрендә Ататөрек мәдәният, тел вә тарих җәмгыяте, Ататөрек мәдәният мәркәзе тарафыннан өч айга бер мәртәбә «Билге» (Bilge) исемле гыйльми журнал чыгып килә. Бу халыкара басма битләрендә тарих, әдәбият, сәнгать, тел һәм, гомумән, рухи эшчәнлекнең төрле тармакларына багышланган материаллар басыла, төрки һәм чит ил галимнәре чыгыш ясый. 1999 елда бу дәрәҗәле журналның халыкара редколлегия әгъзасы итеп Татарстаннан филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университетының кафедра мөдире профессор Хатыйп Миңнегулов сайланды.

ИСКӘ АЛУ

Мәдәният һәм сәнгать академиясе профессоры Рәхилә Мифтаховага март аенда 60 яшь тулган булыр иде.

Танылган җырчының якты хатирәсенә багышлап Зур концерт залында искә алу кичәсе үтте. Концерт белән тәмамланган бу искә алуда Айдар Фәйзрахманов, Венера Ганиева, Римма Ибраһимова, Люция Хәсәнова, Юрий Борисенко чыгышлары тыңланды.

Тышлыктагы сурәтләр

Тышлыкның беренче битендә: «Сабантуй»—Абрек Абзгильдин картинасыннан фоторепродукция.

Тышлыкның дүртенче битендә: язучы Мәрзия Фәйзуллина

ЯҢА КИТАПЛАР

ЗӨЛФӘТ. **«Йөрәгемне былбыл чакты».**
Казан: «Рухият» нәшрияты.—1999.—416 бит.
Тиражы—3000 данә.

Бу китап быел Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Әлеге томлык—шагыйрьнең моңа кадәр чыккан китаплары арасында иң күләмлесе, шигъри потенциаль ягыннан иң көчлесе. Кереш аннотациядә мондый сүзләр бар: «Зөлфәтнең бу шигырьләре шигърият канаты кагылган һәр буын кешесенә атап язылган. Ихластан әйтелгән мәхәббәт сүзләре, югалтулардан әрнегән зарлы хисләре, тормыш тәҗрибәсе һәм акыл туплаган, олыгайган кешегә хас уйланулар бу китапта.» «Ходай сулышы», «Гомерлек ырымнарым», «Гөлләр күрсен сине төшендә», «Гаҗәепләр» дигән дүрт бүлектән торган җыентыкка кереш сүзне Башкортстанның халык шагыйре Нәҗар Нәҗми язган. Басманың мөхәррире—Галимҗан Гыйльманов. Төзүчесе—Фирая Маликова. Бизәлеш рәссамы—Шамил Насыйров.

Татарское народное творчество: В 14 томах.—Том I. *Сказки: сказки о животных и волшебные сказки.* Төзүчесе һәм кереш сүз авторы—Л. Җамалетдинов.—Казан: «Раннур» нәшрияты, 1999.—352 бит. Тиражы—50000 данә.

Татар фольклористикасы тарихында беренче тапкыр «Татар халык иҗаты» фәнни җыелмасы 14 томлык булып рус телендә басыла башлады. Бу басма Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнгән. Ул—халык әкиятләренә багышланган өч китапның беренчесе. Китапта 75 текст урын алган. Том төзүченең «Татарские народные сказки» дип исемләнгән кереш мәкаләсе белән башлана. Анда шулай ук күләмле генә искәрмәләр, әкият сюжетларының типологик анализы һәм тәрҗемә ителмәгән сүзләргә аңлатмалар да урнаштырылган. Фәнни мөхәррире А. Садыйкова. Басманың җитәкчесе Ф. Урманчеев.

Индекс 73210

Мәрзия Фәйзуллина

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)